ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

2.2006





# “КАЗАН УТЛАРЫ” ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕНӘ

*Кадерле дуслар!*

*Озак еллар дәвамында милләтебезгә ышанычлы юлдаш булган “Казан утлары”ның 1000 нче саны чыгу – барыбыз өчен дә истәлекле вакыйга. Шул уңайдан мөхтәрәм журналыбызның өлкән һәм яшь авторларын, редакция хезмәткәрләрен, тугрылыклы укучыларын— әдәбият сөючеләрне чын күңелдән котлыйм.*

*“Без – мәдәниятле, китаплы-әдәбиятлы халык!” дип һәрчак горурланып әйтә киләбез һәм моңа хакыбыз да бар. Инде моннан йөз еллар элек үк безнең әдәби журналларыбыз чыга башлаган. “Казан утлары”—XX гасыр башында нәшер ителгән “Әлгасрел-җәдид”, “Шура”, “Аң” журналларының дәвамчысы ул. Иҗади шәҗәрәсен 1922 елда дөнья күргән “Безнең юл”дан исәпләсәк тә, аның сиксән елдан артык тарихы бар. Шунысы үзенчәлекле: Бөек Ватан сугышы чорында күп басмалар ябылган, ә бу журнал өзлексез чыгып килгән. Димәк, халыкка корал һәм икмәк кебек үк кирәк булган ул.*

*Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал буларак, “Казан утлары”ның халыкка хезмәте гаять зур һәм гаять әһәмиятле. Ул күпләгән каләм осталарының шигырь һәм поэмалары, хикәя һәм романнары белән таныштырудан тыш, тормышның төрле өлкәләрен колачлап, театр, музыка, рәсем сәнгате, скульптура, архитектура, гомумән, мәдәниятебезнең киң офыгын чагылдыра, милли иҗат традицияләрен саклый.*

*“Казан утлары” халкыбызның иҗтимагый-сәяси фикерен үстерү, аның гыйбрәтле тарихын фәнни дәлилләр белән шәрехләү, дөньяның төрле төбәкләренә сибелеп яшәүче татарны рухи яктан берләштерү вазыйфасын башкарып килә. Ул чын мәгънәсендә бөтен халык журналына әверелде. “Казан утлары”ның яктысы Җир шары буйлап тарала. Сөекле Казаныбызның мең еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә без моңа тагын бер кат инандык.*

*Хөрмәтле милләттәшләр!*

*“Казан утлары”—иҗтимагый-әдәби журналларыбыз арасында үз укучыларына 1000 тапкыр барып ирешкән беренче басма. Бу, һичшиксез – олы казаныш һәм аның мәгънәсе бик тирән дип саныйм. 1000 сан— халкыбыз турында мең китап, рухи хәзинәбезнең мең томы дигән сүз. Әлбәттә, мең сан чыгарган олпат, зыялы журналның милләт алдында җаваплылыгы да мең кат арта. “Казан утлары”, киләчәктә дә, бөек Тукаебыз әйткәнчә, “халык күңеленең һич кугәрмәс вә тутыкмас көзгесе” булып калыр дип ышанам. Редакция хезмәткәрләренә, каләм осталарына, журналның меңнәрчә укучыларына саулык-сәламәтлек, иҗат сөенечләре, бетмәс-төкәнмәс илһам теләп калам.*

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Минтимер ШӘЙМИЕВ**

*Февраль, 2006 ел.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2006

# 2

**(1000)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Әхмәт Рәшит, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(8432) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Зөлфәт

## ЯШӘР БЕЗНЕҢ ЖУРНАЛЫБЫЗ!

*"Казан утлары"ның меңенче саны чыгу уңаеннан*

*Ил язмышын, тел язмышын*
*Калмый бары көйләп-сөйләп —*
*Шул язмышның булды үзе*
*Безнең газиз әдәбият!*


*Үткәннәрдән киләчәккә*
*Җиңел түгел юлларыбыз...*
*Шул юлларда кәрван башы*
*Һаман — Олуг Журналыбыз!*

*Булды һәрчак әдәби сүз*
*Халкыбызның таянычы.*
*Ул — аның наз каләме дә...*
*Һәм ялт иткән шам кылычы!*

*Гасырлардан гасырларга*
*Исән-имин күчәр өчен,*
*Заманнарның давылларын,*
*Упкыннарын кичәр өчен*

*Безнең барлык ышанычны,*
*Өметләрне бара төяп*
*Халкыбызның җан аклыгы*
*Һәм ныклыгы — әдәбият.*

*Нинди генә булсалар да*
*Киләчәккә юлларыбыз,*
*Исән безнең кәрван башы, —*
*Яшәр газиз журналыбыз!*



Равил
Фәйзуллин

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире,
Татарстанның халык шагыйре

# МЕҢ САН — МИЛЛИОН УЙ

Игътибар иткәнсездер, хөрмәтле укучыларыбыз, журналыбызның кулыгызда торткан бу саны элгәрге чыкканнардан аерылып тора. Аерылыр да шул: мененче санның нәкъ үзе бит инде ул! Түгәрәк даталар нисбәтендә төрле юбилейларга шаһит булынса да, матбугатыбыз тарихында мондый, 1000 кебек зур санга бәйләнешлесен күргән, үткәргән юк иде әле. Чыннан да, юбилеймы бу? Истәлекле датамы? Бәйрәм—тантана өчен бер җай-форсатмы? Төгәл җавапка, бәлки, артык ихтыяҗ да юктыр, әмма шунысы тәгаен: татар матбугатының, татар рухының зурлыгын күрсәтүче зур биеклек билгесе бу.

Шуңа күрә дә, мәгънәви эчтәлеге белән дә, материалларның бизәү-урнаштырылу ягыннан да үзгә бу сан. Ният—гасыр буе диярлек чыгып тупланган мең саннан, ретроперспектив күрсәтелештә, вакыт елъязмасын, аның рухын гадел чагылдырырга тырышып, аерым үрнәкләр биру, әдәби эстафетаны бүгенге буыннарга тоташтырып карарга тырышу иде. Беренче тәҗрибә буларак, безнең тупланмабыз, ихтимал, камил үк тә түгелдер. Чөнки җыелып килгән мирасның күләме бик зур: мең сан эчендә—дистә меңләгән әдәби әсәрләр—роман-повестьлар, хикәяләр, поэма-шигырьләр, пьесалар, мәкаләләр, гыйльми язмалар, сәяси документлар... Шулай да, бу санга кергән шушы кайбер материаллар аша да, игътибарлы укучы күп дистә елларга сузылган иҗтимагый-әдәби елъязманың үзәк "төеннәре"н күрә алыр, үткән әдәби-мәдәни тормышыбызның төп сәхифәләрен күз алдына китерер дип ышанабыз.

Кайчак күңелгә шундый самими уй килә: безнең журнал (утыз елдан артык "Совет әдәбияты", соңгы кырык елда "Казан утлары" исеме белән чыга) турында тәфсилләп сөйләп торуның хаҗәте дә юк, аны бөтен татар дөньясы белә! Әйе, бу—дөрескә якын хакыйкать. Чыннан да, үзен зыялы, мәгърифәтле дип санаган, милли җанлы һәр татар гаиләсенә барып ирешә торган басмага әверелгән иде ул.

Йөзәр мен тираж белән чыккан чаклары булды, дөньяның татарлар яши торган бөтен кыйтга-төбәкләрендә алдырдылар аны, укучылары да миллионлап исәпләнде. Әмма бу күрсәткечләр, ни кызганыч, инде үткән гасырга карый. Объектив дип әйтерлек житди сәбәпләр дә житәрлек. Күреп торабыз: соңгы дистә еллар эчендә Кешелек дөньясы искитмәле үзгәрешләр кичерде. Фән һәм әхлак өлкәсендә бу үзгәрешләр бигрәк тә нык сизелә. Аларның унае да, тискәресе дә һәммәбезгә—тулы бер халыкка да, аерым индивидиумга да кагылмый калмады, билгеле. Компьютер заманы китапны, басма сүзне кысрыклый башлады, ижтимагый тормышта әдәби сүз көченә ихтыяж кими төште... Бүген "Безнең журналны бөтентатар дөньясы белә!" дип лаф ору беркатлылык булыр иде. Шуна күрә, безнең басманы электән белгәннәрнең хәтерен янартып, яна буыннарга сабак-гыйбрәт булсын дип, журналыбыз тарихы турында берничә сүз әйтеп китик. 1000 нче сан чыгу мона унай форсат бирә.

Иң әүвәл шуны искәртеп узыйк: милли матбугат кайчан барлыкка килгән булса, ижтимагый-әдәби басмалар да шул елларда ук чыга башлый. Кагыйдә буларак, һәр басма тирәсенә әдипләр, журналистлар тупланучан. Халык арасында танылуга йөз тоткан һәр басма оста каләм ияләренә, сүз тылсымчыларына мохтаж. XX йөз башындагы милли матбугатыбызны Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, С. Рәмиев һ. б. исемнәреннән тыш күз алдына китерү кыен. Үткән ел татар җәмәгатьчелеге көндәлек милли матбугатның 100 еллыгын билгеләп үтте. Татар әдәби журналларының чыга башлавына да йөз елга якын. Мин моны "Әлгасрел-жәдит", "Шура", "Аң" кебек басмаларны күз алдында тотып әйтүем.

"Казан утлары"ның башлангычын совет чорыннан—1922 елда чыккан "Безнең юл" журналыннан исәпләү гадәткә кергән. Болай исәпләгәндә дә 84 ел гомер үтелгән. Айлык басмалар арасында 1000 нче саны дөнья күргән башка журнал юк. Әйе, озын, катлаулы юл үтелгән. Чор-дәвере дә үтә четерекле, фажигаи төсмерләргә бик тә бай. Халык ниләр генә кичермәгән дә, нинди генә сынаулар үтмәгән бу гомер эчендә! Инкыйлаб-революция зилзиләләре дә; аклар, кызылларга аерылып, пычакка пычак килүләр дә; ачлыктан яки үләт чирләреннән нәсел-ыру белән кырылулар да; яңаны төзим дип, булганны юк итүләр дә; сыйныф-классларга бүленә-бүленә, диннәр белән көрәшә-көрәшә, алфавит-имляларны кат-кат алыштыра-алыштыра кыйбласыз, имансыз калулар да; сәяси авантюристлардан культ ясап, үзләре "шөреп-винт" хәленә калып, миллионнарның яуларда, лагерьларда һәлак булулары да; табигать кануннары һәм халык мәнфәгате белән исәпләшмичә, жир-суны мәсхәрә итеп, "бөек-бөек" төзелешләр, хәрби промышленность комплекслары корулар да; утопик хыял-коммунизмга фанатикларча ихлас ышанып, хакыйкатькә хилафлык кыла-кыла, физик көч һәм акыл сәләтен кирәкмәгәнгә исраф итүләр дә... һәммәсе, һәммәсе булган бу дәвердә!

Яңа, яшь буын вәкилләре бу катлаулы тарихны каян белә алыр соң? Әлбәттә, төп чыганаклар аша. Алар—архив документлары, көндәлек тормышны яктыртып барган газеталар, һәм дә... журнал төпләмәләре. Журналлар димәктән, татар рухын, әдәби-мәдәни тарихын өйрәнүчеләр өчен, безнең журнал, һичшиксез, алгы урында булыр. Гажәп түгел. Аңа шундый тарихи миссия йөкләнгән. Елъязмасында үз чоры идеологиясе чагылыш тапса да, ул, сәясидән бигрәк, беренче чиратта ижтимагый-әдәби журнал. Икенчедән, журналны тормыш елъязмасын гадел яза алырлык талант ияләре—язучылар, әдипләр чыгарган; өченчедән, журнал, гасыр дәвамында диярлек берөзлексез, тукталмыйча (кайчак, дистә еллар буе чыкмаган чорны да булганга санап, зур санлы юбилей бәйрәмнәре үткәргән басмалар да очрый) чыгып килгән. Президентның 1000 сан чыгу уңаеннан безгә юллаган котлавында бу хакта бик урынлы әйтелгән. Тагын шунысы да бар: заманның теге яки бу хәлләре, характерлы типажлары әдәби әсәрләрдә төгәлрәк һәм образлырак булып чагылып кала.

Журнал 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп шрифтында "Безнең юл" исеме белән чыккан. (Шунысын да искәртик: ул инде 1930 елларга кадәр үк шул ук исемдә ун көнгә бер чыга торган басма булган). Утызынчы елдан исә икегә бүленеп, "Яналиф" (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасы органы) һәм "Атака" (Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе органы) исемнәре белән басылган. Ә 1933 елдан 1965 елга кадәр—"Совет әдәбияты", соңгы дәвердә "Казан утлары" атамасы белән дөньяга чыгып килә. Заман сәясәте һәм аның шаукымнарына бәйле рәвештә журналның оештыручылары да (Татар социаль Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз Башкарма комитеты һәм халык комиссарлары Советы; Татарстан халык мәгарифе комиссариаты, РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты, Совет язучылары оешмасы; ТАПП һәм Кызыл Армия-флот язучыларының Татарстан оешмасы; Татарстан Язучылар берлеге, Татарстан Министрлар Кабинеты, редакциянең хезмәт коллективы...), титул билгеләмәләре дә (гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый журнал; сәясәт, сәнгать, экономика һәм әдәби тәнкыйть журналы; әдәби-гыйльми, иҗтимагый басма; әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы; әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал; әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал), структурасы да, редакциянең эш урыннары да үзгәреп, алышынып торды. Билгеләмә-атамалар төрле чорда төрле сүз тезмәләрендә бирелсәләр дә, аларда төп ике төшенчә һәрчак сакланып киленде—"әдәби" һәм "иҗтимагый".

Журналның "Безнең юл", "Яналиф", "Атака" исемнәре белән чыккан чоры 1922-1932 елларга карый. Чагыштырмача кыска булса да, ил тормышының үзенчә катлаулы чоры бу. Революциядән һәм гражданнар сугышыннан соңгы авыр вәзгыять, Сталин диктатурасының ныгый башлавы, интеллегенциянең аптыраулы халәте, диннәргә каршы актив һөҗүм, солтангалиевчелекне фаш итү шаукымы, күмәк хуҗалыклар төзү хәрәкәте, әдәби хәрәкәттәге чуарлык һәм таркаулык... Табигый, журнал битләрендә бик ачык чагыла бу хәлләр. Чын әдәби әсәрләргә караганда агымдагы сәясәткә бәйле материаллар күбрәк урын алган. Дөресен әйтергә кирәк, әдәбиятның алтын фондына керерлек әсәрләр мулдан түгел бу елларда. Шулай да, журнал битләрен зур исемнәр бизәп тора: Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, Ш. Камал, Ш. Усманов, Х. Туфан, К. Нәҗми, Г. Кутуй, Ф. Хөсни... Чын талантлы каләм иясенең әсәрендә, нинди генә чор, нинди генә сәяси шаукымнар тасвирланмасын, өлешчә булса да хакыйкатькә тугрылык сакланып кала ул...

Журналның "Совет әдәбияты" чоры 1933-1965 елларга туры килә. Ил тормышының янә бер катлаулы, драматик чоры. Хәер, Россиядә катлаулы булмаган чор юк та бугай... Халык хәтерендә тетрәндергеч фаҗига булып калган этаплы вакыйгаларны искәртү дә җитә: репрессия дәвере... Ватан сугышы... Халыкның икмәккә туймаган еллары... Соңрак бераз җинеллек—"Хрущев җепшеклеге", демократик чалымнарның тормышта чагыла башлавы... Мәгълүм булганча, репрессия һәм сугыш елларында күп басмалар чыгудан туктый яки ябыла. Әмма татарның әдәби журналы яшәвен дәвам итә. Язмыш тарафыннан нәселне саклап калырга тиешле таза күзәнәкле зат кебек, ул, сәяси катаклизмнарга бирешмичә, күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклап кала. Мәшһүр милләтпәрвәр Гали Акыш бу хакта тикмәгә генә болай язмагандыр: "Социаль-мәдәни тетрәнүләр фаҗигасен башыннан кичергәндә дә бирешмәгән, сау-сәламәт яшәргә тырышкан һәм шактый дәрәҗәдә шуңа ирешкән журналыбызның эшчәнлеген зур каһарманлык, могҗиза саныйм". Бу сүзләр журналның төрле исемнәрдә чыккан бөтен чорларына да карый дип уйлыйк.

Журнал һәрдаим халык тормышы мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәде. Ил язмышы—аның язмышы булды. Журнал авторларының күбесе фронтта катнашты, байтагы яу кырларында ятып калды. Журнал редакциясе фронтовик язучылар (М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Баян, А. Алиш, Г. Кутуй, Х. Мөҗәй,

М. Максуд, Г. Насрый, Ш. Мөдәррис, И. Гази, Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур, А. Шамов, Г. Галиев, Г. Бакиров, Р. Ишморат, Х. Госман, М. Садри, Ә. Маликов, З. Нури һ. б.) белән тыгыз элемтәдә тора, укучыларын аларның әсәрләре белән таныштырып бара.

Сугыш тәмамлангач, язучылар рухланып яна әсәрләр иҗат итәләр. Г. Әпсәләмовның "Ак төннәр"е (1947), "Алтын йолдыз"ы (1949), "Газинур"ы (1951), М. Җәлилнең "Моабит дәфтәре" циклына кергән шигырьләре (1953), Н. Дәүлинең "Яшәү белән үлем арасында" (1957), Ш. Маннурның "Муса" (1965), С. Баттал, С. Хәким, З. Нури һ. б. поэмалары журнал укучыларына житкерелә.

Илне төзекләндерү чорында халыкның күркәм әхлак сыйфатларын, аның тарихи үткәнен, хезмәт сөючәнлеген чагылдыручы яңа әсәрләр—Г. Бәшировның "Намус" (1948), К. Нәжмиҗнең "Язгы җилләр" (1948) романнары, И. Газиның "Онытылмас еллар"ы (1949), М. Әмирнең "Ялантау кешеләре" (1953), "Саф күңел"е (1959), Г. Әпсәләмовның "Сүнмәс утлар"ы (1959), Ф. Хөснинең "Җәяүле кеше сукмагы" (1961), Г. Гобәйнең "Без үскәндә"се (1963), Ә. Еникиның "Йөрәк сере" (1958), "Рәшә"се (1963), Г. Ахуновның "Хәзинә"се (1962), А. Расихның "Ике буйдак" романы (1964), шулай ук Х. Вахит, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов пьесалары, Х. Туфан, Н. Арсланов, С. Хәким поэмалары һәм шигырьләре журнал аша үз укучыларын тапты.

Соңгы ун-унбиш еллар эчендә җәмгыятьтә күзәтелә торган бер чиктән икенче чиккә ташланулар күренеше матбугатта да беркадәр чагылыш тапты. Сүз иреге килгәч, нинди генә газета-журналлар, нинди генә басмалар чыкмады! Укучылар күңелен яуламак булып, "бульвар" яки "вульгар" басмалар ишәйде. Шулай ук байлар һәм түрәләр акчасы бәрабәренә "түр басма" булырга омтылучылар пәйда булды, "Без—элит басма!" "Без—республиканың визит карточкасы!" "Без—академик басма!" кебек шапырынучылар да юк түгел бүген. Әйе, танышканда ялтыравыклы визит карточкасы да кирәк була, әмма тормыш иткәндә, хакыйкатьне ныклабрак белергә теләгәндә, хезмәт кеңәгәсе кирәк! Үтелгән юлның мәгънәсе анда язылган. Бу яктан, шөкер, "Казан утлары", үзенең күркәм традицияләрен дәвам итеп, вакланмыйча, очсыз реклама-шоудан, түбән инстинкт уята торган язмалардан өстен булып, акча кубызына биемичә, милләтебезнең әхлак кодексына лаек әсәрләр язып, халкыбызның төп житди журналы булып кала алды. "Казан утлары"—чын мәгънәсендә халык журналы—игенчеләр, укытучылар, укучы яшьләр, зыялылар журналы. Журнал рухы гади халык тормышын чагылдыра, аның язмышы халык язмышы белән тәңгәл бара. Юкса, ачлы-туклы елларда да, илне "боз суккан" чорларда да ул сакланып кала алыр идеме? Сугыш кырларында иң кадерле хатлар белән бергә поход сумкаларында йөртерләр идеме? Котып тарафларында яки чүлле Кара-ком якларында, шахта баракларында яки тайга кинлекләрендә күп санлы милләттәшләребез аны туган як сәламе, ана телебез аһәне итеп, зарыгып көтеп алырлар идеме? Ә инде балачакта ук үзен әдәбиятка багышларга, газета яки журналда беренче нәни мәкаләсен яки шигырен бастырырга хыялланган яшь җаннар өчен "Казан утлары"ның бәһасен әйтеп торасы да юк...

Бүген без 1000 нче сан уңаеннан журналыбызның абруен никадәр генә күтәрергә тырышсак та, танырга кирәк: адәм хатадан хали булмаган кебек, заман басымы астында хаклык юлыннан тайпылу очраклары да күзәтелгән... Гуманизм критерийларына, эстетик идеалларга хыянәт иткән сәхифәләр дә очраштыргалый. Олы талант ияләрен "буржуа ялчылары" дип бәяләүләр дә, чын милләт хадимнәрен «халык дошманнары» итеп фаш итүләр дә, «оборона әдәбиятының магнитостройлары өчен көрәш»ләр дә, коммунизмга алып баручы «юлбашчы»ларга мәдхия укулар да, жирле халыкның киләчәге өчен шикле һәм куркыныч АЭСларга дан җырлаулар да... Әмма шушы еллар эчендә һәрберсе шактый калын басма (җыелма бер том!) булып дөнья күргән 1000 санның

(барлык тиражын җыйсаң, үзе бер галәмәт зур тау булыр иде!) дәрәҗәсен һәм кыйммәтен әле әйтеп узган саташулар билгелиме соң? Юк, әлбәттә. Соңгы 80 ел эчендә бар булган иң күренекле әсәрләребез нәкъ менә шушы журналда дөнья күрде, укучыларга, халыкка барып иреште. Сугыштан соңгы әдәби хәзинәбезгә карата бигрәк тә рас килә бу. Йә, шушы журналга мөнәсәбәте булмаган яки әсәрен анда бастыруны дәрәҗә санамаган берәр татар әдибен табып була микән? Яки «Казан утлары» дигән Әдәбият Капкасын үтмичә, зур иҗат мәйданында танылу алган берәр язучы булдымы икән?

Журнал —әдәби-мәдәни тормышыбызның тарихи елъязмасы, дидек. Әйе, бу чынлап та шулай. Журнал, беренче нәүбәттә, татар язучыларының иң яхшы яңа әсәрләрен киң катлам укучыларга ирештерә. Бу—аның тарихи традициясе һәм бүгенге статусы буенча куелган бурычы. Әмма рухи тормышыбыз әдәбият белән генә чикләнми. Шуңа күрә дә журналга төрле тармакларга «таралып җигелергә» туры килә. Нәфис әдәбияттан тыш, мисалга, фән дөньясын гына алыйк: гуманитар өлкәдә, бигрәк тә әдәбият, тарих, тел белеме фәннәрендә академикларыбыз, йөзләгән фән кандидатлары һәм докторларыбыз бар икән, моңа кадәр аларның күбесе шушы журналда язышып, хезмәтләрен бастырып, гыйлем үрләрен яуладылар. Аяныч, әле моңарчы театр, музыка, рәсем сәнгате, гомумән, мәдәният тарихы буенча махсус басмаларыбыз булмады диярлек. Шуңа күрә, рәссамнар, композиторлар, артистлар иҗаты журналда шактый киң яктыртыла. Безнең республика шартларында бу вазифаны журнал үзенең бурычы дип санады һәм хәзер дә шул фикердә тора.

Табигый ки, бер генә халык та фәкать үз кабыгында, үз биләмәсендә генә яшәп тәрәккыятка ирешә алмый. Шуны истә тотып, журнал чит ил һәм күршетирә кардәш халыклар әдәбиятының гомумкешелеккә, гуманизмга хезмәт итә торган иң яхшы үрнәкләрен дә хәлкадәри яктыртып килә. Бездә чыккан Жоржи Амаду, Гарсиа Маркес, Акутагава һ. б. әсәрләре шуңа мисал.

1000 санның яртысы чамасы (476сы) соңгы 40 елда чыккан "Казан утлары" өлешенә керә. Еллар буенча исәпләгәндә, 1965 елдан бүгенгегә кадәр. Бу инде безнең заман, күпләребез шаһит булган заман, үзенчә кызыклы, гыйбрәтле, хәтта беркадәр аңлаешсыз заман. Нәрсә белән характерлы соң бу чор? Чагыштырмача тыныч чор: локаль бәрелешләр (сугышның тынып торганы юк аның!) туктамаса да, илкүләм гарасат—зур сугыш афәте булмады; торгынлык һәм үзгәртеп кору еллары кичерелде; СССР таркалды; совет хакимияте вакытында тупланган байлык бер тар даирә кулына күчте; "кыргый базар" мөнәсәбәтләре тамыр җәйде; социализм чорында шактый ук нык булган моральәхлак принциплары җимерелде... Яңа гасырга күчелде... Чор елъязмачылары саналучы язучы халкы өчен материалга бай искитмәле кызык чор. Иң мөһиме—сүз иреге бар, күңелеңдәгеен курыкмыйча әйтеп була, язып була. Бу кырык ел эчендә язучылар гаиләсе эчендә дә табигый алмашыну-яңару процессы барды. Гасыр башында туып, Ватан сугышларын кичергән буын (гаҗәеп колоритлы буын!) гомер һәм иҗат юлларын тәмамлап, фани дөньялыктан күчтеләр, алар урынын сугыш чорында үсмер булган буын алып, үтә бер үҗәтлек белән иҗат иттеләр (инде алар да сирәгәеп бара), төп мәйданны 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән буын тота хәзер, инде үкчәләренә басып, яңа буын аларны да алыштырып килә... Әдәбиятыбыз өчен ифрат бәрәкәтле чор. Бу кырык елның беренче яртысында, әлеге чор идеологиясе, социалистик реализм методы кысалары (хәер, талант кысаларга сыя алмый шул!) ирек биргән кадәр, үзләренең иң яхшы әсәрләрен иҗат иттеләр, ә соңгы 15-20 ел эчендә, демократик ирекләр киңәйгәч, төрле жанрларда байтак әдәби җәүһәрләр туа алды. Аларның бөтенесе диярлек иң әүвәл "Казан утлары"нда дөнья күрде. Тулылыкка һич тә дәгъва кылмыйча, шушы чорда төп жанрлар буенча кайбер әсәрләрне искә төшереп үтәсе килә: "Туган ягым яшел бишек" (Г. Бәширов), "Әйтелмәгән васыять" (Ә. Еники), "Ямашев" (А. Расих), "Әтил суы ака торур" (Н. Фәттах), "Тау ягы

повесте" (Ә. Баянов), "Фронтовиклар" (М. Мәһдиев), "Идел кызы" (Г. Ахунов), "Җиләкле аланнар" (Р. Төхфәтуллин), "Биектә калу" (М. Юныс), "Язгы аҗаган" (М. Хәсәнов), "Тайгак кичү" (И. Салахов), "Иртеш таннары" (Я. Зәнкиев), "Бер ананың биш улы" (Х. Сарьян), "Кубрат хан" (М. Хәбибуллин), "Безне өйдә көтәләр" (Х. Камал), "Йәгез, бер дога" (А. Гыйләҗев), "Божра" (Т. Әйди), "Батырша" (Ж. Рәхимов), "Шинельсез солдатлар" (В. Нуруллин), "Җилкәннәрне җилләр еккач" (Ф. Яруллин), "Хыянәт" (Ф. Латыйфи), "Сират күпере" (Р. Мөхәммәдиев), "Афәт" (Г. Тавлин), "Сөембикә" (Батулла), "Каргышлы этаплар" (Р. Кәрами), "Таң җиле" (Ф. Садриев), "Тәүбә" (Т. Галиуллин), "Караболак" (Ф. Бәйрәмова), "Гөлнәзирә" (М. Әмирханов),"Фидая" (М. Маликова), "Утлы божра" (В. Имамов), "Ат караклары" (З. Зәйнуллин), "Догалы еллар" (М. Галиев), "Ком сәгате" (К. Кәримов), "Албастылар" (Г. Гыйльманов), "Татар вакыты" (А. Хәлим), "Саташып аткан таң" (Ф. Сафин), "Терсәк сугышы" (З. Хөснияр)... Шуларга өстәп, С. Сабиров, М. Хуҗин, Р. Фәизов, Ж. Дәрзаманов, Р. Зәйдулла һ. б. повесть һәм хикәяләре... Татар прозасының үзенчәлекле бер антологиясе бит бу әсәрләр! Ә шагыйрьләр? Күп гасырлык татар әдәбиятының нигезен алар салмаганмы? "Әдәбиятның Әнкәсе—гомердән Шигърият" дип тикмәгә генә тәкърарламыйбыз ләбаса! Көчле шигърият һәрвакыт әдәбиятның үсеш дәрәҗәсен күрсәтеп килгән. Журналыбыз тарихында да ул шулай.

Бу урында журналыбызның поэзия елъязмасын бизәгән кайбер шагыйрьләребезнең исемнәрен атап үтик: Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Маннур, Ә. Исхак, Н. Арслан, Г. Афзал, И. Юзеев, Ш. Галиев, Ә Баян, С. Сөләйманова, Роб. Әхмәтҗанов, Рәш. Әхмәтҗанов, Г. Рәхим, Р. Мингалим, Р. Гаташ, Р. Харис, Ә. Рәшитов, К. Сибгатуллин, Зөлфәт, М. Әгъләм, Р. Вәлиев, Ф. Гыйззәтуллина, Х. Әюп, К. Булатова, Л. Шагыйрьҗан, Р. Миннуллин, З. Мансуров, Г. Морат, Р. Зәйдулла, И. Гыйләҗев, М. Мирза, Г. Мөхәммәтшин; яшьрәкләрдән И. Иксанова, Р. Аймәт, Л. Янсуарлар... Җөмләдән, журнал сәхифәләрендә урын тапкан кайбер күләмле шигъри әсәрләрне дә укучыларыбыз хәтерендә янартып узыйк: "Чирмешән буйларында (С. Баттал), "Могикан" (Х. Туфан), "Кырыгынчы бүлмә" (С. Хәким), "Йолдызстан" (Роберт Әхмәтҗанов), "Сәйдәш" (Р. Фәйзуллин), "Бүре күзе" (Р. Харис), "Иртәгә" (Р. Мингалим), "Биш таш" (Рәшит Әхмәтҗанов), "Мәңгелек дастан" (Зөлфәт), "Колшәриф" (Ә. Рәшитов), "Тукайдан хатлар" (М. Әгъләмов), "Ике еглау" (З. Мансуров), "Ике мөһаҗир" (Р. Низами), "...Америка фаҗигасе" (Л. Шагыйрьҗан) һ. б. поэмалар, шигъри цикллар...

"Казан утлары"ның актив авторлары—драматурглар Х. Вахит, Т. Миңнуллин, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин... Публицист язучыларыбыз—М. Зарипов, Т. Әйди, Р. Юныс, Р. Сибат, Р. Хисмәтуллин, Ф. Дунай, М. Әхмәтҗанов... Мәшһүр язучылар, шагыйрьләр белән беррәттән, журналның редколлегиясе әгъзалары булып торган яки үзләренең мәкаләләре, рецензияләре, бәяләмәләре белән әдәби хәрәкәттә актив катнашкан күренекле галимнәр: Р. Нәфыйгов, Х. Госман, Н. Юзиев, М. Хәсәнов, Ә. Кәримуллин, Ә. Борһанов, Ф. Хатипов, И. Надиров, Р. Әмирхан, Ф. Урманчиев, Н. Хисамов, А. Әхмәдуллин... Бүгенге редколлегия әгъзаларыннан—М. Госманов, М. Мәхмүтов, Т. Галиуллин, Х. Миңнегулов...

Ул замандагы әсәрләрне барлап чыкканда, аларны язган язучылар үзләре искә төште. Һәммәсе белән диярлек таныш икәнмен. Нәкъ 1965 елны "Совет әдәбияты""Казан утлары" булып чыга башлаганда мин редакциядә эшли идем инде. Кемнәр хезмәт куйды соң бу кырык ел эчендә редакциядә? Н. Арслан, Л. Ихсанова, И. Юзеев, Ә. Баян, Ф. Миңнуллин, Я. Халитов, М. Хәмитов, В. Нуруллин, К. Тимбикова, Г. Рәхим, Рәш. Әхмәтҗанов, Ф. Бәйрәмова, Т. Әйди, Мөд. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Х. Зарипов, Ә. Гаффар, М. Галиев, С. Шәмси, З. Мансуров, Р. Миннуллин, Ж. Миннуллин, Н. Акмал,

А. Сәләхетдинов, К. Сәгъдәтшин, Р. Низамиев, Ш. Маннапов, Ф. Латыйфи, М. Шабаев, Н. Гамбәр, М. Хуҗин, Ш. Мостафин, Ф. Сафин, Г. Гыйльманов... Аларның унга якыны инде арабызда юк...

Бу чорның баш мөхәррирләре—Р. Мостафин, З. Нури, Г. Ахунов, Р. Харис, Р. Фәйзуллин.

Бүгенге көндә дә журналыбыз редакциясендә танылган язучылар эшли. Р. Гаташ, Р. Юныс, Мансур Вәлиев, К. Кәримов, А. Гыймадиев, М. Закир, Ә. Рәшит, Р. Сәгъди... Шуларга өстәп, янә җиде кешелек тәҗрибәле гамәли хезмәткәребез бар. Шунысы характерлы: "Казан утлары"нда бер эшли башлаган кеше, хезмәт урынын алыштырырга җыенмый диярлек, еллар буе эшли бирә. Арабызда утыз-егерме еллар эшләгән хезмәттәшләребез бар. Үзем дә, шактый еллар бу журналда хезмәт итеп, әлеге 1000 санның 200 енә баш мөхәррир сыйфатында кул куеп чыгарганмын икән. Яшермим, эчке бер горурлык хисе уята торган сан бу минем өчен.

Тыелган яки онытылган әдәби мирасны халыкка кире кайтаруда журнал эшчәнлеген әйтми узсак, язмабыз тулы булмас иде. Бер генә исемне аерып әйтү дә күп нәрсәне аңлата булыр: бөек әдип Гаяз Исхакый. Аның төп зур әсәрләре бүгенге укучыларга иң әүвәл безнең журнал аша ирештерелде. Бу исемгә өстәп—С. Максуди, Й. Акчура, Г. Баттал-Таймас, Г. Газиз, С. Җәләл кебек олуг затларның иҗат үрнәкләрен искә төшереп үтәсе килә. Борынгы мирастан—"Йосыф кыйссасы", "Идегәй" дастаны... Саный китсәң, алар күп томлыкларга җыелыр...

Әйе, озын-озак еллар ераклыгыннан карaганда, халык тормышында журнал үзенең асыл функциясен үтәгән. Әмма "яңа заман, яңа җырлар" дигәндәй, һәр чор һәркем алдында яңа бурычлар, яңа таләпләр куя. Иҗтимагый тере организм буларак, журнал алдында да тора андый бурычлар: глобальләшү киң колач алган дәвердә үз халкыбызның кабатланмас йөзен, рухи мирасын саклау, аны цивилизацияле ил-халыклар рәтендә киләчәккә алып бару. Телне, әдәбият-сәнгатьне үстерү, әлбәттә, журналның төп бурычларыннан берсе. Шуңа күрә дә, Татарстанның дәүләтчелеген яклау, ныгыту һәм аны тормышка ашыруда ярдәм итүне "Казан утлары" иң җаваплы бурычларның берсе дип саный. Әгәр Казан бөтен дөньяга сибелгән татарларның тартылу кыйбласы булса, "Казан утлары" да туган телне хөрмәт иткән барлык милләттәшләребез өчен мәгърифәт, гыйлем учагы. Шунлыктан, милли бердәмлек сыналган, "кеше җаны өчен көрәш барган" заманда, китап сүзенә игътибар кими төшкән дәвердә без—язучылар бу журналда чорның югары таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр язарга тиешбез.

2006 ел Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителде. Бу айда горурлыгыбыз булган Муса Җәлилнең 100 еллык тантаналы юбилее үтә, апрель аенда бөек Тукайның 120 еллыгы зурлап уздырылачак. Шул олуг бәйрәмнәр арасында безнең журналыбызның 1000 саны чыгу үзе бер аерым мәгънәгә ия.

Юбилеебыз уңаеннан редакциягә тәбрикнамәләр күп килә. Аларның берсендә мондый юллар бар: "Татар дөньясының бердәнбер саллы журналын, милләтебез рухының кабатланмас елъязмасын, халыкның әдәбе сагында торучы каләм әһелләренең төп иҗади мәйданы булган басманы һәм аның тырыш хезмәткәрләрен олуг бәйрәмнәре белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез!"

Зур сүзләр, горурланырлык сүзләр, әмма зур җаваплылык та өсти торган сүзләр. Җавабыбыз шул: бай тәҗрибәгә, якты сәхифәләргә ия "Казан утлары" халкыбызның бу яңа гасырдагы яшәешенең дә гадел елъязмачысы, килер буыннарның рухи юлдашы булыр дип ышандырасы килә.




# Зилә Вәлиева

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары—
Мәдәният министры


Хөрмәтле редакция хезмәткәрләре!

“Казан утлары”ның 1000 саны, ягъни әдәби хәзинәбезнең 1000 нче томы чыгу татар халкының мәдәни тормышында гаять истәлекле вакыйга. Әле ярты ел элек кенә башкалабыз Казанның 1000 еллыгын ил-халыклар танырлык олуг бәйрәм итеп уздырган идек. “Казан утлары”ның 1000 саны чыгу да шушы тарихи олылыкның бер дәвамы. Димәк, Дөньяга күрсәтерлек борынгылыгыбыз, тарихи ядкарьләребез, рухи хәзинәбез, мәдәни байлыгыбыз бар.

“Казан утлары”—мәдәниятебез тарихында аерым урын тота торган басма. Ул бер гасырга якын диярлек татар халкының әдәби-мәдәни үсешен яктырткан бердәнбер төп басма булды. Шунысын да ассызыклап узарга кирәк: журнал язучыларыбызның иң яхшы әсәрләрен чыгару белән бергә, сәнгать казанышларын — композиторлар, артистлар, рәссамнар, архитекторлар, гомумән, зур талант ияләренең иҗатын һәрдаим пропагандалап килде.

“Казан утлары”—бөтенроссия күләмендә иң өлкән һәм иң абруйлы журналларның берсе. Шуны гына да әйтү җитә: ул үзенең яше буенча “Новый мир”, “Наш современник”, “Дружба народов” кебек журналлардан өлкәнрәк һәм тиражы буенча да күпкә югарырак.

Журналда гомер-гомергә талантлы каләм ияләре, олуг әдипләр эшләде, Галимҗан Ибраһимовтан башлап бүгенге баш мөхәррир Равил Фәйзуллинга кадәрге чорда хезмәт куйган язучы-шагыйрьләрне искә төшерсәң, шуңа инанасың: Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов...

2006 ел Татарстанда әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителде һәм беренче вакыйга булырлык әдәби бәйрәм—“Казан утлары” журналы белән бәйле. Сөенечле дә, горурланырлык та хәл бу.

“Казан утлары”ның тарихи миссиясе зур. Шуны тәкъдир итеп, бүгенге зурлыгын танып, киләчәген зур итеп күрергә теләп, олуг басмабызның 1000 саны чыгуы белән ихлас котлыйм. Киләчәктә дә бу журнал халкыбызның рух байлыгын күрсәтүче, киләчәк буыннарга ышаныч тудыручы басма булуына ышанам.



# Назиф Мириханов

Татарстан Республикасының
Россия Федерациясендәге
Тулы хокуклы вәкиле

*"Казан утлары" журналының
баш мөхәррире Равил Габдрахман улы
Фәйзуллинга һәм журнал коллективына*

Хөрмәтле дуслар!

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы хокуклы вәкиллеге "Казан утлары" коллективын журналның 1000 нче саны белән чын күңелдән котлый!

Казанның 1000 еллык юбилееннан соң күп тә үтми 1000 нче санызыз чыга. Бу татарстанлыларга гына түгел, бөтен татар халкы өчен дә зур вакыйга!

Республика, башкалабыз казанган уңышларда, шулай ук дөньякүләм вакыйгага әйләнгән юбилей тантанасы шатлык-сөенечләрендә сезнең дә өлеш бар. Чөнки, элгәрләрегез— "Шура" һәм "Аң" журналларын да кертеп, "Безнең юл" булып туган һәм "Яңалиф", "Атака", "Совет әдәбияты" булып дәвам иткән "Казан утлары" республикада һәм илдәге бөек тарихи үзгәрешләрнең турыдан-туры катнашучысы, шанлы, сөенечле, ә кайвакытта кайгылы-аянычлы да вакыйгаларның елъязмачысы булды.

Бүгенге "Казан утлары" журналы коллективы үзенең исеменә тап төшерми. Татарстанда чыгарылган күптөрле матбугат басмалары арасында сез флагман булып торасыз, татар халкы турында, аның тарихы, теле, борынгы әдәбияты турында, шулай ук заманча әсәрләрегезне дә эталон әдәби тел белән, тәмле сүз белән язасыз.

Сез—зур эшләр башкаручы, халкыбыз сагында торучы, аның тарихын, гореф-гадәтен, бөек уллары һәм кызларының исемнәрен саклаучылар, яңа милли язучылар һәм шагыйрьләрнең исемнәрен ачучылар. Зур рәхмәт сезгә, киләчәктә дә шул юлда нык торыгыз!

Шәхсән үземнән һәм Тулы хокуклы вәкиллек хезмәткәрләре исеменнән сезгә ныклы рухи көч, киләчәккә өмет белән карау, иҗат эшләрегездә илһам, әдәби иҗат өлкәсендә яңа энҗе бөртекләре эзләүдә зур уңышлар телим.

# «БЕЗНЕҢ ЮЛ»

1922—1930 ЕЛЛАРДА ЧЫГА



**ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ:**
Г. Мансуров (1922-1923, № 7), М. Бурундуков (1923, № 8-1924)—җаваплы мөхәррирләр; редколлегия (Г. Гали, Ш. Камал, Г. Толымбайский, Х. Туфан, Г. Сәгъди)—1925-1928, № 5; редколлегия (Г. Гали, Ш. Камал, Г. Толымбайский, Г. Сәгъди)—1928, № 6-1929, № 10; редколлегия—1929, № 11-1930, № 4.

## “Безнең юл” идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә *(сөючеләргә)*[1] МӨРӘҖӘГАТЬ

Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, “Безнең юл” журналын чыгара башладык. “Безнең юл”ның чыгуы Татар җөмһүриятенең мәркәзендә – Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып, эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән бу журналга булышсыннар иде.

Кульъязмалар өчен акча түләнә. Даими абүнә җыючылар, даими язучылар белән аерым мөгаһәдәләр *(килешүләр)* ясала. Эшче-крестьян гаммәсенең *(массасының)* азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар һәм шулай булышсыннар иде.

**“Безнең юл” идарәсе.**
*1922, № 1*

[1] Курсив белән җәяләр эчендә бирелгән аңлатма сүзләр текстларны гарәп имласыннан хәзерге алифбага күчереп басмага әзерләгән Р. Мәрданов тарафыннан өстәлде.

# ТӨП ҖИТӘКЧЕ Г. ИБРАҺИМОВ ИДЕ[1]

Билгеле булганча, бу елларда Казанда татар телендә "Безнең юл" исемле әдәби, иҗтимагый-политик, нәфис журнал чыгып килә иде. Журналның төп җитәкчесе, әлбәттә, Галимҗан Ибраһимов иде. Беркөнне, 1926 нчы елның башында булса кирәк, Галимҗан ага, партия өлкә комитетының матбугат бүлегенә килеп, журналның эчтәлегеннән канәгать булмавы һәм шуның өстенә тиражның кечкенәлеге турында бик борчылып сөйләде:



—Аңа катнашучы, үзләренең әсәрләрен бастыручы бер төркем язучылар яисә журналистлар журналы гына түгел ул,—диде.—Республика журналы ул, партия журналы! Дөресе, бөтен Советлар Союзындагы татарлар өчен чыгарыла торган бердәнбер әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал. Шуңа күрә аңа бик нык игътибар итәргә кирәк. Партия өлкә комитетының журналга игътибары җитәрлек түгел. Аның эчтәлеге, эше, торышы һәм планы белән чын-чынлап кызыксынмый. Хәтта аны тарату мәсьәләсе белән дә җитәрлек шөгыльләнми. Мәсәлән, шәһәрләрдә, шулай ук авылларда да, партия ячейкалары төрле журналлар яздыралар, ләкин шулар арасында "Безнең юл" юк.

Бу турыда ул бик борчылып, ләкин сабырлыгын югалтмыйча сөйләде. Хәтта безне орышып та алды.

Шуңа күрә бу мәсьәлә 1926 нчы елның 25 нче январенда матбугат бүлеге коллегиясендә каралды. Анда Галимҗан ага журнал турында доклад ясады, аның эчтәлеген яхшырту, материаль хәлен ныгыту һәм аны халык арасында күбрәк тарату чарасын күрү мәсьәләләрен куйды.

Утырышка чакырылган иптәшләрнең күбесе чыгып сөйләделәр, Галимҗан Ибраһимовның фикерен якладылар күп кенә яхшы тәкъдимнәр керттеләр. Сөйләүчеләр арасында Гомәр Галиев, Фатыйх Сәйфи, Ш.Фәхретдинов, Сәлах Атнагулов, Фәтхи Бурнаш һәм башка иптәшләр бар иде. Соңыннан карар кабул ителде. Түбәндә карарның бер өлешен күчереп үтәм:

а) журнал әдәби нәфис журнал булырга һәм анда гыйльми мәсьәләләр бүлеге дә сакланырга тиеш;

б) Мәгариф Комиссариаты журналны тәртипле рәвештә үз вакытында чыгарып баруны һәм вакытында подписчикларга җиткерүне тәэмин итәргә тиеш;

в) журналны арзанайтуга омтылырга;

г) партия өлкә комитетының матбугат бүлеге партоешмалар аркылы журналны күбрәк тарату һәм аның тиражын арттыру чарасын күрергә тиеш;

д) журналга татар язучыларының төрле агымнарын җәлеп итәргә һәм аларны "Безнең юл" журналы тирәсенә тупларга;

е) журналның редколлегиясен түбәндәгечә расларга: Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Галиев, Гаяз Максудов.

Редколлегиягә тагын ике әгъза өстәү мәсьәләсен өлкә комитетының секретариатына кертергә".

**Латыйф ГОМӘР,**

*Татарстан өлкә комитетының*
*матбугат бүлеге мөдире.*
*Журналист, җәмәгать эшлеклесе.*

---

[1] Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. Казан. Татар. кит. нәшр., 1966.

# "БЕЗНЕҢ ЮЛ" ТУРЫНДА

21 нче елның ахырында мине Мәркәз комитет Казанга эшләргә кайтарды. Өлкә комитетының агитация-пропаганда бүлегенә эшләргә керү белән, миңа ин элек матбугат эшләрен яхшыртуны алга куярга туры килде. Ул вакыттагы шартлар эчендә (ачлык, хуҗалык эшләренең таркаулыгы) татар вакытлы матбугатының хәле бик авыр иде. Ләкин без шул авыр шартларга карамастан, татар вакытлы матбугатын яхшыртырга, көчәйтергә тотындык. 22 нче елның башы белән партиялеләрдән мин, Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Гаяз Максуд, партиясезләрдән Садрый Җәлал, Газиз Гобәйдуллин фикер алышканнан соң "Безнең юл" журналы чыгарырга карар бирдек. Өлкә комитетыннан уздырып Совнаркомнан акчалар алганчы, журналның беренче номеры басылганчы байтак вакыт үтеп китте. Мартта чыгарга тиеш булган журнал майда гына чыкты. "Безнең юл" журналының программасы һәркемгә билгеле, ул турыда тукталырга хаҗәт юк. "Безнең юл" журналы, чыннан да, безнең юлны большевиклар, марксистлар юлын күрсәтә торган бер журнал булып чыкты. Анда басылган төрле гыйльми, сәяси, иҗтимагый һәм әдәби мәкаләләр моңа дәлил. "Безнең юл"да баштарак иске язучылар, Татарстан партия, совет оешмаларының башында торучылар гына катнашса да, соңга табан, 2-3 нче номерлардан башлап ук яшь язучылар да (Толымбайский, Зәйнәп Бәширова, Нигъмәт Хәким, Рәмзи) тартыла башлады.

Минемчә, "Безнең юл" журналы татар вакытлы матбугаты тарихында зур гына урын тотарга тиешле:

1) "Безнең юл"ның татар матбугатында тиңдәше булганы юк. Революциягә кадәр чыккан либераль татар буржуазиясенең органы "Аң" матурлык, күләм, әдәби парчаларга байлык ягыннан да "Безнең юл" журналыннан күп түбән иде. Тар милләтчеләр фикерен сөргән "Аң"ның зарарлы идеологиясе турында тукталып торасы да юк инде;

2) Революция шикелле кайнаган бер заманда татар телен бозылудан саклауда бик зур файда китерде. Беренче номердан алып "Безнең юл"ны тел ягыннан тикшереп чыксак, моны ачык күрербез;

3) "Безнең юл"да язышып бик күп яшь язучылар үзләренең каләмнәрен очладылар һәм шомарттылар. Бусы да инде күз алдыбыздан үткән нәрсәләр.

"Безнең юл"ның йомшак якларына килсәк, мин түбәндәге нәрсәләрне күрсәтер идем:

1) "Безнең юл" әдәби журнал була алганчы бик төрле типта чыккалады;

2) Әле хәзергә чаклы тәнкыйть бүлеге үзенә тиешле урынны ала алганы юк. "Безнең юл"га тәнкыйть бүлеген көчәйтергә, матур, тулы каләмле бик үткен тәнкыйть кирәк.

Теләкләрем:

1) "Безнең юл" Татарстан өчен генә түгел, Русиядә яшәүче бөтен татарларга каратып чыгарылырга тиеш;

2) Татарның бөтен эшче-крәстиян көчләре катнашырга тиешле. Редакция бу турыда чараларын күрергә тиеш;

3) Көз көне "Безнең юл"ны тарату кампаниясен уздырырга кирәк;

4) "Безнең юл"га рәсемнәр дә кертеп, вакытында чыгарырга тырышырга кирәк.

Сүз ахырында шуны әйтер идем: мин "Безнең юл"ның беренче редакторларыннан булсам да, ул вакыттагы авыр шартлар эчендә журналга күп көч куючы, эшләүче — журналның беренче секретаре иптәш Садрый Җәлал булды. Аның бу хезмәте, әлбәттә, истән чыгарылмаска тиеш.

**Гасыйм МАНСУРОВ**

*Мәскәү, 12 май.*

*1927, № 6-7*

---

Гасыйм МАНСУРОВ (1894–1955) — *тарихчы, педагог, җәмәгать эшлеклесе; 1922–23 елларда — журналның җаваплы мөхәррире.*

* * *

Соңгы көннәрдә генә татар әдәбияты мәйданында яңа бер имза заһир булды. Бу — яшь шагыйрь Һади Такташ. Аның беренче шигырьләре матбугат сәхифәләрендә чыгар-чыкмас, татар җәмәгатенең аңлы кыйсьме аңар игътибар итте. Татар әдәбиятын сөючеләр аның килеп чыгышында яңа бер хадисә *(хәл, күренеш)* сизеп, колакларын торгыздылар; аңар зур өметләр баглап, үзенә бер төрле (оригинальный) истигъдад күрделәр.

*Г. Рәхим. Нәләтләр шагыйре. 1923, №10-11*

Һади
Такташ

## МӘҢГЕЛЕК ӘКИЯТ

*Әкият сөйлим сезгә, таң җилләре!*
*Туктагыз да менә тыңлагыз!*
*Шул урманда булган бер әкиятне*
*Илдән илгә күчеп җырлагыз!*
*Менә урман, чиксез кара урман,*
*Мәңге шомлы, мәңге караңгы;*
*Җилләр белән ишелеп һаман, һаман*
*Улап торган үткән заманны.*
*Шул урманда яшрен бер урында*
*Ялгыз кабер тора.*
*Кем анда?*
*Нигә ялгыз анда адашкан да,*
*Нигә яшрен җирдә урманда?*
*Ул бер егет кабре,*
*Ул егетнең*
*Кайгы белән үткән көннәре,*
*Озын булган мәңге газап белән*
*Йоклый алмый үткән төннәре.*
*Ул күп, бик күп уйлап йөргән:*
*"Адәм кайдан килгән?—тагын да*
*Кайда китәр?" Ләкин моңа җавап*
*Табалмаган үзенең аңында.*
*Табалмагач, килеп тезләнгән дә*
*Мәңгелектән җавап сораган.*
*Озак көткән—*
*Җавап алалмагач,*
*Болай диеп егет җырлаган:*
*"Нәләт төшсен сезгә, нәләт төшсен!*
*Әй, урманнар, кырлар, далалар!*
*Мәңге телсез каты ташка әйләнгән*
*Җирләр, күкләр, фәннәр, аллалар!*
*Җавап көттем сездән, бирмәдегез,*
*Инде эзләп китәм—табармын;*
*Көчле кулым белән мәңгелекнең*
*Тимер ишекләрен ватармын.*
*Ватармын да илгә яшрен булган*
*Барлык серне чишәр, ачармын".*

*Шуннан соң ул яшрен урын сайлап,*
*Кабер казып җиргә күмелгән;*
*Мескен егет, кайтам, диеп киткән*
*Кайтмас җирдән—упкын төбеннән...*
*Мин әле дә аның кабрен эзлим*
*Урманнардан, яшрен җирләрдән,*
*Мин тавышын ишетәм, һәр көн иштәм*
*Таң алдында искән җилләрдән.*
*Ул киләчәк...*
*Мин дә кабрен табып,*
*Гөлне упкән кебек үбәрмен,*
*Зәңгәр күзләремнән, аямыйча,*
*Кайнар яшьләремне түгәрмен.*

*Зәңгәр күзле егет кабрең үбәр,*
*Яшьләр түгәр кабрең өстенә!*
*Гөлләр сибәр һәр көн таң алдында,*
*Җырлар җырлар синең исмеңә.*
*Син эзләгән яшрен, зур серләрне*
*Мин дә эзлим, егет,—*
*Тыныч бул!*
*Син күзләгән төпсез упкыннарны*
*Мин дә күзлим, егет,—*
*Тыныч бул!*

*1923, №6-7*



*Сулдан уңга: М. Гафури, Һ. Такташ, Г. Камал. 1929 нчы ел.*

Р. Сабиров

# ТАТАРСТАН ҖӨМҺҮРИЯТЕНЕҢ ИКЪТИСАДИ ХӘЛЕ ҺӘМ АЧЛЫК

... Русиядәге ачлык тарихы безгә 1024 нче елдан башлап мәгълүм. Тарихка караганда, уникенче гасырдан уналтынчы гасырга кадәр Русиядә һәр гасырда ачлык җидедән ким булмаган. 17 нче гасырдан 19 нчы гасырга кадәр аның саны ике өлеш арткан. 1230 нчы һәм 1231 нче елларда Новгородта бигрәк тә каты ачлыклар булган. Шушы ачлык елларның соңгысында халык гаять тә күп үлгән һәм Германиядән икмәк китерү аркасында гына халык бөтенләй үлеп бетүдән котылып калган. Моннан иске заманнарда да Русия халкына читтән ярдәм килгәнлеге аңлашыла.

Әгәр дә Русиядә соңгы еллардарак булган ачлыкларга карасак, 1872 нче елда Самарда гаять тә каты ачлык булганын күрәбез. Шушы Идел буе ачлыгы аңа кадәр Русияне туйдырып килгән вилайәтне *(губернаны)* аяктан җыккан. 1891 нче елда 29 вилайәтне чолгап алган чиксез көчле ачлыктан бирле Идел буендагы вилайәтләр һаман ачлыктан зарарланып киләләр. Егерменче гасыр эчендә Самар вилайәтендә 8 мәртәбә, Саратауда 9 мәртәбә ачлык булды. 1891 нче елгы ачлыктан соң 1892 нче елда мәркәз *(үзәк)* һәм җанүб шәркый *(көньяк-көнчыгыш)* вилайәтләрендә, 1897 һәм 1898 нче елларда тәхминән *(якынча)* шул ук төбәкләрдә ачлыклар булды. 1901 нче елгы ачлык мәркәздә, җанүбтә *(көньякта)* һәм шәрыктә *(көнчыгышта)* 17 вилайәтне чолгап алды. 1905 нче елның ачлыгы 22 вилайәттә булып, аннан соң шул ук ачлык 1906 нчы, 1907, 1908 һәм 1911 нче елларны Русиянең күп кенә җирләрендә яңадан тәкрәр итте *(кабатланды)*. Ниһаять, без, Идел буе халыклары, хәзерге көндә 21 нче елның коточыргыч зур бер ачлыгын башыбыздан кичерәбез.

Русиядәге бу ачлыкларның төп сәбәпләрен тикшергәндә, табигый, ирекле-ирексез башта илебездәге иҗтимагый вә икътисади шартларга тукталырга һәм шуның белән бергә Русиянең икълим *(климат)* вә һавасының да ачлыкны тудырырга зур гына ярдәм иткәнлеген күрсәтеп узарга туры килә. Ләкин шул ук югарыда зикер ителгән *(әйтелгән)* шартлар Русиянең төрле төбәкләрендә төрлечә җыелып, төрле җирдә төрле нәтиҗәләр тудыралар. 1921 нче елда Татарстан Җөмһүриятенә килгән зур ачлыкны алсак, моның үзенә генә махсус булган кайбер сәбәпләр аркасында тагы да көчәя төшкәнлеген әйтми узып булмый. Гомумән, Татарстан Җөмһүрияте (сабикъ *(элекке)* Казан вилайәте) ашлык уңмау ягыннан Самар шикелле вилайәтләр белән беррәттән тора. Ләкин монда һәркемнең күзенә аерымачык бәрелеп тора торган икенче бер нәрсә бар, ул да булса Татарстан Җөмһүриятенең төп халкы булган татарлар, шул ук Татарстанда тереклек итә торган башка халыкларга караганда, нык ачыгалар. Без кая гына бармыйк, татарларның ачлыктан азап чиккәннәрен, балалар йортларының ач татар балалары белән тулып калганлыгын, Җөмһүриятебездәге шәһәр урамнарында татарларның ачлыктан аунап ятканнарын, ниһаять татар авылларындагы йорт-җирләрнең ябылып, тәмам сүнгәнлекләрен күрәбез. Бу 1921 нче елны татарларның үзләре белән бергә яшәүче халыкларга караганда ныграк ачыгулары, шөбһәсез, татарларның үзләренә генә махсус булган иҗтимагый һәм икътисади сәбәпләрдән килә. Әгәр дә без халкыбызның тарихын тикшереп карасак, татарларның иске-искедән бирле зур бер кысынкылык астында яшәп килгәнлекләрен күрәбез. Иван Грозный тарафыннан Казан алыну белән татарлар үзләренең өстләрендә инде кысын-

Рәүф САБИРОВ (1894-1937) – *1921-24 елларда ТАССРның ҮБК Президиумы рәисе. 1925-32 еллардагы СССР ҮБКында милләтләр бүлегендә эшли. Репрессия корбаны.* Хәз.[1]

---

[1] Хәз. – хәзерге, ягъни 1000нче санны әзерләгәндә өстәлгән мәгълүмат.

кылыкның башланганлыгын сизделәр. Идел, Кама буйларындагы әлегә кадәр биләп килгән мөнбит *(уңдырышлы)* җирләрен татарлар урысларның тәзаййыкы *(кысуы)* астында ташлап китәргә мәҗбүр булдылар. Җүнсез һәм уңайсыз җир кайда бар – татарлар шунда утыртылды. Билгеле, бу хәл үзе генә татарларның иктисади яктан начарлануларына сәбәп булды. Икенче яктан, башыннан аягына кадәр православие рухы белән сугарылган Русия хөкүмәте, урыс поплары белән кулга-кул тотынып, Казанны алуга татарларны чукындыру, аларны урыслаштыру сәясәтенә кереште. Бу юлда татар халкына әллә никадәр үзенең җәбер-золымын салды. Шушы яман сәясәтнең яман нәтиҗәсе буларак, бичара татарлар үз кабыкларына яшеренергә, урысның начар яклары белән бергә, барлык яхшы якларына да кырын күз белән карарга, алардан файдалы һичбер яңа нәрсә алмаска мәҗбүр булдылар. Үз диннәрен, үз гореф-гадәтләрен саклап калырга тырыша торгач, татарлар урыслардагы иген игү, көн күрү эшләрендәге төрле файдалы яңалыкларга да дошманлык күзе белән карый башладылар. Еллар, гасырлар буенча татарлар урыс ашы дип, кәбестә, кыяр шикелле яшелчәләр җитештермәде. Шул ук сәбәп аркасында бакчачылык белән шөгыльләнмәде. Кәбестә, кыяр шикелле нәрсәләр әле хәзерге көндә дә татарлар арасында "урыс ашы" дип йөртелә. Татарлар арасында бакчачылык эше белән шөгыльләнү юк. Алар орлыклы ашлыктан башка бер нәрсә дә игә белмиләр. Хәлбуки орлыклы ашлыкларның уңышы бик үк ышанычлы түгел. Әгәр дә орлыклы ашлыкларның уңышы бик үк ышанычлы булып җитмәсә, ашлык уңмау куркынычыннан, бары тик иген игү эшендә яңа ысулга – игенне күп басу белән игүгә күчү һәм чәчү әйләнешенә санагать өчен кирәкле үсемлекләр кертү генә коткара алачак.

Бу яктан караганда татар крәстияннәренең хуҗалыклары бик әкерен үзгәрә. Халыкның ашамлык запасларын күп арттыра торган һәм аларга икмәктән башка да яшәргә имкян *(мөмкинлек)* бирә торган бәрәңге утырту татарлар арасына яхшы ук күп таралган. Ләкин коры бәрәңгегә генә ышанып торырга туры килми.

Бүгенгә кадәр татарларның күбесе игенне Нух заманыннан калган ысул белән игәләр. Шуңа күрә ачлык булган елларда аларның күберәк азап күрүләре гаҗәп түгел. Татарларның шушы тарика *(ысул)* мәдәният *(цивилизация)* ягыннан артта булулары – Татарстан Җөмһүриятендәге ачлыкның сәбәпләреннән берседер.

Хәерчелеккә төшкән татарлар күп вакытлардан бирле салым, иҗарә *(аренда)* хакын түләү һәм үз кирәкләрен алу өчен хуҗалыкларыннан хасил булган нәрсәләренең күбесен базарга чыгарып сатып килделәр. Шуның нәтиҗәсендә татарлар көз көнендә шул ук икмәкләрен базарга чыгаралар, яз көне ул икмәкне алар үзләре үк кыйбатрак бәһагә сатып алырга мәҗбүр булалар. Көзге һәм язгы бәһаләр арасында булган аерма шул ук фәкыйрьләр җилкәсенә төшә. Шулай итеп нинди дә булса бәла-казалар килгән вакытта алар иң әүвәл ачлык тозагына эләгеп, корбан булалар.

Ниһаять, ачлыкның килүенә яки килмәвенә мөһим сәбәпләрдән берсе – крәстиян хуҗалыгында игенгә башка кәсепләр белән акча таба торган юлларның булуы яки булмавыдыр. Авыл халыкларының башлыча доходлары иген мәхсулатыннан *(кеременнән)*, читкә йөреп кәсеп итүдән һәм кул һөнәрләре белән шөгыльләнүдән килә. Иген уңының алга китүе һәм икмәк бәһасенең күтәрелүе иген игүдән килә торган доходның әһәмиятен арттыра. Кул һөнәре санагате белән йорт санагате ашлык уңмаган елларда крәстиян хуҗалыкларының хаҗәтләренә кирәк нәрсәләрне табарга ярдәм итә. Шулай ук читкә йөреп кәсеп итүләрнең дә крәстиян хуҗалыклары өчен әһәмияте бик зур. Артык халыкларның завод- фабрикларга эшләргә китүләре авыл халыкларының азык белән тәэмин ителүләренә тәэсир итә, авылда ашап ятучыларның санын киметә һәм авылга акчаның килүенә сәбәп була. Ләкин тәәссефкә *(үкенечкә)* каршы, шушы һөнәр-кәсептән – иген мәхсулатыннан, читкә кәсепкә китүдән һәм кул һөнәре санагатеннән килә торган доходлар татарлар арасында бер дә юк диярлек. Менә шуның өчен дә алар ачлыктан күберәк зарарланалар һәм аның авырлыгын күберәк татыйлар.

Бу сүзләргә холәса *(нәтиҗә)* ясап шуны әйтергә мөмкин: халыкның аз җирдә тыгыз торуы, җирләрнең ябыгуы, Идел буеның һава ягыннан булган хәле, иген кәсебенә башка һөнәрләрнең аз тәрәккый итүе, игеннең иске ысул белән

игелүе, бигрәк тә Татарстан Җөмһүриятендәге халыкларның күпчелеген тәшкил иткән татарларның күршеләре урысларга караганда, мәдәният ягыннан арттa калулары болар арасында ачлыкның көчәюенә сәбәп булган.

Бөтен Татарстан Җөмһүриятенең ачлыкка булган мөнәсәбәтенә килсәк, аның тиз арада яхшыга таба үзгәрүендә хәзерге көндә өмид артык зур түгел. Авылның мәдәният ягыннан булган хәле әле һаман да бик түбән тора. Урысларның да, татарларның да байлыклары гаять тә түбән дәрәҗәдә, һөнәр-кәсеп аз тәрәкъкый иткән, иген игүдән башка кәсепләр белән акча табу әйтерлек юк, соңгы вакытта хайван асырау эшләре тәмам җимерелгән, крәстияннәрнең[1] хуҗалык эшләрендәге бөтен арка таянычлары иген игүдә генә.

Шуның өстенә соңгы елларда булган вакыйгалар – җиһангирлек *(бөтендөнья)* һәм граждан сугышлары, чехословак һәм Колчак бандаларының Татарстан Җөмһүрияте туфрагына һөҗүм итүләре һәм егерме беренче елда һич тә күз күрмәгән вә колак ишетмәгән гаять тә зур ачлык булуы – безнең өлкәнең икътисади байлыгын тәмам җимерде, бөтен халык диярлек, хәерчелеккә төште, хәтта алар үзләренең киләчәктә рәтле тормышка чыгуларыннан өмидләрен өзеп, һәлакәт чокырына тәмам якынайдылар.



*Ачлык. Л. Мендес рәсеме.*

Бу хәлләр һәммәсе дә шушы коточкыч дәһшәтле ачлыкка каршы ашыгыч рәвештә чаралар күрергә тиешлеген игътираф итәргә безне мәҗбүр итә. Юк исә, гомуми иҗтимагый-икътисади хәлләрдән килеп чыккан бу ачлык Татарстан Җөмһүриятен бик үк тиз ташлап китмәс диярга һәм шул югарыда күрсәтелгән шәраитләрне *(шартларны)* һәрвакыт күздә тотып, хозяйствоны иң соңгы дәрәҗәдә җимерелүдән саклау чараларына керешергә тиеш була.

*1922. № 1.*

*Журналыбыз турында*

Мөхәммәт Гали:

***—Хәзерге вакытта "Безнең юл" әдәбият сөючеләр өчен бөтен татар дөньясында бердәнбер нәфис әдәби журнал. Бер яктан ул хәзерге яшьләребезнең әдәби тойгыларын тәрбияләп, аларның гыйльми, иҗтимагый белемнәрен күтәрүдә булышлык итеп килсә, икенче яктан хәзерге яшь язучыларыбыз шуның аркылы үзләренең әдәби каләмнәрен очлыйлар һәм шомарталар...***

***Гомумән, тип ягыннан алганда, "Безнең юл"ның хәзерге бара торган юлы ярый торган. Тик шуны әчке һәм тышкы яктан ыспайларга, бизәкләргә һәм шомартырга гына кирәк. Иң башлап ничектер менә шуның тышкы кыяфәте һәм күренеше белән ниндидер бер учреждение тарафыннан чыгарылып килә торган бюллетеньне һәм отчетны хәтерләтә.***

*1927*

[1] Элек чыккан әйберләрне биргәндә шул заманның язылыш үзенчәлекләре сакланды. *Хәз.*



Шамил Усманов

# КРАСКОМ[1] МӘХӘББӘТЕ

ХИКӘЯ

I

Дивардагы[2] сәгать төнге икене сукса да, безнең беребез дә таралырга уйламыйча, зур бер ихлас белән Салихның сөйләгәнен тыңлап утыра идек.

Шагыйрь җанлы, тәмле телле Салихның башыннан үткәргәннәре салкын бүлмәнең зәңгәр төтен белән тулган һавасы тынчулыгын, барыбызның көн буе эштә йөреп арыганлыгын һәм иртәгә иртән үк торып, тагын да эшкә барырга кирәклекне оныттырып, безне әллә кая, еракларга—кошлар сайрап торган гөл бакчаларына, көзге төсле тигез диңгез өсләренә көймәгә, я булмаса, ямьле өйләргә алып китеп, анда берәр зәңгәр күзле, матур йөзле, нечкә билле туташ, я ханым белән очраштырып, аны бер караш белән сөйдереп, аннан да тизрәк биздерәдер иде.

Уйласаң, исең-акылың китәр! Шушы хәзерге тормышта ярдәмчесез калып, үз башына бер адым атларга гаҗиз булган бу назлы егет вакытында кемне генә сөймәгән! Кайсы гына бакчаның караңгы аллеялары, төрле шәһәрләрнең бай, зиннәтле салоннары аның серләрен белмиләр дә, ул вакытның кайсы гына ефәк күлмәкле нечкә биле аның кочагына кермәгән!

Салих бер вакыйганы сөйләп туктауга, өстәлнең бер почмагында утырган Хафиз чәчләрен артка сыпырып алды да:

—Әх, егетләр, болар барысы да алай түгел шул!—диде.—Синең сөйгәннәр, Салих, шөбһәсез, матур һәм ямьле. Әмма, синеке шикелле эшсез бер тормышта сөю сина, эч пошырмас өчен, су белән һава төсле үк кирәк бернәрсә булган. Яхшы гына, тук кына итеп ашаганнан соң, танца залында музыка астында яртылаш ялангач бер туташны күреп сөю, ул—яз көне бакчада матур чәчәк күрү, концертта скрипканың моңлы аһәңнәрен ишетү җәннәткә кергәч хур кызларын кочу төсле үк гади, табигый эш.

Ә менә минем баштан үткән бер вакыйганы ишетсәгез, ул вакытта үлем арасында, ут эчендә дә мәхәббәт барлыгына ышаныр идегез...

Без, әлбәттә, барыбыз да беравыздан Хафиздан шул вакыйганы сөйләвен үтендек; ул да, озак ялындырып тормастан, чәчләрен тагын артка сыпырып алып, унайлап кына утырды да түбәндәгечә сөйләргә керешә.

II

—Авыр көрәш көннәре,—дип башлады ул сүзен.—Госпитальгә ничек эләкәнемне белмим; өйгә ике атнага хәл җыярга дип кайткан җиремнән бик нык итеп сыпной тиф[3] белән авырып калганмын. Иптәшләр мине госпитальгә илтеп салганнар.

[1] Краском – кызыл командир.

[2] Дивар – стена.

[3] Сыпной тиф – тимгелле тиф.

Анда уң ягымдагы караватта ята торган яшь кенә бер егетнең, урыныннан торып, саташып әллә нәрсәләр сөйләнүен; берсендә аның караваты янына ата-аналары килеп кычкырып елашканнарын; егетне носилка белән күтәреп алып киткәннән соң, аның урынына ап-ак сакаллы бер картны китереп салганнарын; янына килгән доктор, сестраларга ул картның: "Мин дә уздыра алмам, ахрысы",— дип сөйләнгәнен төш арасында күргән шикелле генә хәтерлим.

Шулай мин берничә көн ятканмын. Беркөн иртә белән күземне ачып җибәрүгә, әллә ничек үземне җиңеләеп, тазарып киткән итеп сиздем. Янымда утырган сестра култык астыма кыстырылган термометрны алып карады да:

—Я, иптәш, шатланыгыз: инде кризисны үткәрдегез. Тиздән тәмам терелеп, ирекккә дә чыгарсыз,—диде.

"Ирекккә чыгарсыз" дигән сүзне мин төрмәдә яткан кешенең азатлык хәбәрен көткән төсле көтә идем. Ләкин бу юлы инде күптәннән бирле көткән хәбәргә ул кадәр игътибар итмәдем... Бөтен уем—янымда миңа елмаеп карап утырган шәфкать туташы сестрада иде.

Аның терелүемне тәбрик иткәндәге шатланган көләч йөзен күреп, мин саташкан вакытларымда бер караш белән хәлемне җиңеләйтүче, авыр вакытларымда янымда утырып, башымнан сыйпаучыны таныдым.

Бераз карап торгач, ул одеялым белән мине бөтен яктан диярлек томалады да:

—Хәзер тыныч кына, сөйләшмичә генә ятыгыз инде. Әгәр салкын тидереп куйсагыз, тагы да осложнение[1] булып җәфаланырсыз,—диде.

Мин, җылы сүз ишеткән яшь бала төсле, яңа бәхетемнән куанып, күземне йомдым...

Уянганда, ул һаман янымда утыра иде.

—Уяндыгыз. Менә яхшы. Бик нык, тыныч йокладыгыз. Менә, иптәшләрегез үзегезгә ашамлыклар китерделәр. Сезгә хәзер нык кына ашый башларга кирәк,— дип, ул, урыныннан торып, кычкырып азапланып ятучы бер авыру янына китте.

Китерелгән ашны капкалагач, хәлдән таеп, күземне йомдым. Уянганда, палатада ул күренми иде инде.

Электр лампасының көчсез саргылт нурлары зур палата эчен күнелсез генә яктырта. Почмакта яткан бер авыруның өзелеп-өзелеп ыңгырашуы, ишек янындагы караватта яткан бер кызыл гаскәринең янындагы иптәшенә һичтуктаусыз авылда калган авыру әнкәсе белән баласы турында сөйләп торуы нервларга тия иде.

Урынымнан күтәрелеп, караватка утырдым. Үземдә бераз хәл барлыгын сизгәнлектән, урынымнан торып, карават башындагы халатны киеп, коридорга чыктым.

Ярым карангылыкка баткан коридорга ике яктагы палаталардан ыңгырашу тавышлары килә. Әнә бер хатын, саташып булса кирәк, ыңгырашкан арада үзенең баласын чакыра, аның йөрәк өзгеч кызганыч тавышыннан, баласын мәңге кайтмаслык җирдән чакырганын белеп була иде.

Кулына савыт тотып, ашыгып баручы сиделка, яныма туктап, аптырап күзләремә карады.

—Әбәү! Кая чыктыгыз? Сез иртә белән генә кризис үткәрдегез ич!—диде ул.

Аның сүзләренә колак салмыйча, коридорның очына киттем. Анда коридорның иң читендәге бер бүлмәнең аз гына ачык ишегеннән күренгән ачык яктылык мине, өермәдә күренгән маяк шикелле, үзенә тарта иде.

Ишек янына килеп җиттем.

Ишекнең ачык җиреннән җыйнак кына бүлмәнең эче, стена буендагы, өстенә ару җәймә япкан караватның бер почмагы күренеп тора иде.

Бердән күзгә бәрелгән каты яктылык тәэсиреннәнме, яки озаграк аяк өсте басып торганнанмы—кинәт башым әйләнеп китте. Хәлсезлектән егылып китмәс өчен, ихтыярсыз ишеккә тотындым.

Берәү ишекне эчтән әкрен генә ачып җибәрде. Бу—"ул" иде.

—Карагыз әле, нишләп чыктыгыз? Сезгә урыннан торырга ярамый ич,—дип

---

[1] Осложнение—авыруның көчәеп китүе.

килеп кулларымнан тотты. Минем күз алларым карангылана башлады. Анын кулларына таянып, көч-хәл белән шундагы караватка килеп аудым.

Ак җәймәле, йомшак мендәрле карават, жыйнак якты бүлмә, барысыннан бигрәк янымда утырган туташ—болар барысы да ун көнләп каранғы палатада, таушалган урында яткан кеше өчен никадәр үзгәреш икәнен үзегез анларсыз дип уйлыйм. Туташ минем баш астымны яхшылап төзәтеп, өстемә япты да:

—Ни дип тордыгыз сон?! Болай йөрсәгез, сез һич шөбһәсез үпкә шешү авыруын эләктерерсез,—диде.

Мин кәефләнеп күзләремне йомдым. Ул тавышына шелтә аһәне бирергә тырышса да, булдыра алмый: сөйләве мина музыка шикелле генә ишетелә иде.

—Сөйләгез, туташ, сөйләгез, сезнен тавышыгызны ишетеп, бүлмәгездә яту өчен, мин һичкем авырмаган авыруга да риза булыр идем,—дидем.

Ул тагы да житдирәк итеп:

—Алай сөйләмәгез, сезгә тизрәк терелеп, фронтка китәргә кирәк,—диде.

—Мин бит, туташ, болай да фронттан киләм. Житәр, анда күп жәфаландым инде. Ә сез мине тагы да шунда, ут эченә жибәрергә тырышасыз,—дидем.

Ул бик жентекләп мина карап алды.

—Сез бу сүзләрне уйнап кына әйтәсез бит,—диде.—Мин сезнең саташкан вакытыгызда ниләр сөйләгәнегезне ишетеп тордым бит. Сез һаман фронтка—иптәшләрегез янына кайтырга ашыктыгыз. Гел шулар белән саташтыгыз. 12 нче палатада ятучы кызылармеецлар да сезне беләләр икән. Алар сезне мактыйлар, сез чын батыр икәнсез.

Мин җавап бирмәдем. Башкалар мактаганда унайсызлык сизенсәм дә, монын сүзләре нигәдер мине рәхәтләндерәләр генә иде.

—Сез бу госпитальдә күптән хезмәт итәсезме? —дип сорадым.

—Өч айга якын инде. Фронттан озатканда вакытлыча гына дигәннәр иде, ә моннан һаман жибәрмиләр. Әле кичә генә, фронтка кайтаруны сорап, тагын рапорт бирдем.

Житәрлек хәл кергәнен сизеп, анын ярдәме белән бүлмәдән чыгып, үз урыныма килеп яттым.

Өч көннән сон сәгать уникедә анын нәүбәте житкәнен дүрт күз белән көтеп алдым. Инде торып йөри ала идем. Шуна күрә анын килгәнен коридорга чыгып көтә башладым. Сәгать уники дә, бер дә булды. Ләкин ул һаман килмәде. Анын урынына палатабызга бер карчык керде.

—Ә теге сестра кайда?—дип соравыма карчык:

—Кичә 8 нче дивизия штабы белән фронтка китте,—дип җавап бирде.

## III

Көн кичкә таба авышып килә иде.

Безнең гаскәрләр кар бураны катыш яуган янгыр астында, тездән пычрак эчендә, тимер юл буйлап цепька таралып, алга баралар иде.

Көн буе өзлексез йөрү аркасында хәлсезләнгән аяклар көч-хәл белән атлыйлар; салкын янгыр, шинель аркылы тәнгә үтеп, ихтыярсыз калтырата; күңел бу җәһәннәмнән кая да булса берәр жылы, тыныч урынга омтыла иде.

Бу вакытта яныбыздан, тимер юл буйлап, артына унбишләп вагон таккан алгы санитария поезды үтеп китте. Тәрәзәләрен каплаган пәрдәләр арасыннан вагонның якты эче салкын янгыр астында йөргән бәндәләрегезгә җәннәтнен бер почмагы булып күренә иде.

Ул үтеп киткәндә, бер кызылармеец:

—Эх, малай, шунын эченә кереп ятар өчен берәр пуля алсан да жәл түгел,—дип куйды.

Поезд үтеп китте. Без алга—туп тавышы гөрләп торган жиргә омтылдык. Бераздан снарядлар еш кына төшкәли башлап, өстебездә өзлексез пулялар сызгырырга керешге. Үн канатта "ура!" тавышы ишетелде. Бу—үн флангтагы роталарыбызның дошманга якын килүләрен билгертә иде. Мин ротанын алдынарак чыгып:

—Алга, егетләр!—дип алга омтылдым. Каршыдан һаваны ярып якынаеп килгән

снарядларның сызгыруы ишетелде. Берсе уң ягыма төшеп ярылды. Башыма килеп сугылган җил белән җиргә авып киттем һән шунда ук исемне югалттым...

Берәүнең җылы иреннәре маңгаемнан суырып үпкәнне, йомшак куллар белән муенымнан кочаклаганны сизеп, әкрен генә күзләремне ачтым.

Яткан урыным—яхшы яктыртылган җылы вагон эче, янымдагы урындыкта "ул" утыра иде.

Төш була калса, озаграк барсын дип, киредән күзләремне йомсам, ул һаман минем күзләремнән, иреннәремнән үбә, үзе шат тавыш белән:

-—Тереләсез, тереләсез... менә, егет,—ди иде. Кулларым белән аның кулларын каты кыстым.

—Сез ничек монда эләктегез?—дидем.

—Сез ничек эләксәгез, мин дә шулай: бурычым китерде,—диде.

—Мин фәрештәләргә никадәр генә ышанмасам да, сезнең минем авыр вакытларымда ярдәм итәр өчен җибәрелгән сакчы фәрештә икәнегезгә ышана башладым,—дидем.—Әйтегез әле: миңа ни булды? Безнең гаскәрләр еракмы?

—Кайгырмагыз, гаскәрләрегез еракта инде. Сезгә снаряд җиле тиеп, контузия алгансыз, китерүче рота санитарларыгыз сезнең ротаның авылга беренче барып кергәнен сөйләделәр. Сез озак ятмассыз, бер-ике көннән чыгарсыз,—диде.

Бу юлы инде аның бу сөенече мине шатландырмады гына түгел, кайгыртып та алды. Шушы урында, аның кулы астында әллә никадәр озак ятасым килде.

—Ни өчен соң мин кеше төслерәк мәҗрүх булмаганмын икән; ичмасам, сезнең йөзегезне күреп, тавышыгызны ишетеп ятар идем,—дидем.

Кыз мангаен җыерды, аның йөзе җитдиләнде. Бу юлы ул чыннан ачуланмаса да, кәефе киткәнлеге аермачык беленә иде.

Мин һаман сүземдә дәвам иттем:

—Әйе, менә шулай көн, төн, айлар, еллар буе йөреп, рухың арыгач, сезнең шикелле бер җанның канаты астында ятып ял итәсе килә. Аз гына түгел, бер-ике көн түгел, айлар, еллар буена тынасы килә. Башка кешеләр шикелле үк, тыныч бер почмакта, җылы өйдә, гаилән янында яшисең килә...—дидем.

Кыз, һаман җитди кыяфәтен саклап:

—Әйе, егет, андый тынычлыкны сөйгән кызлар күптер. Әмма мин андыйлардан түгел. Мин тормышта рәхәт күргәннәрне сөймим, мин тормышның авырлыгына каршы күкрәк киереп көрәшүчеләрне, авырлыктан михнәт чиккән халыкны коткару юлында тырышучыларны сөям. Шуның өчен мин монда йөрим. Шуның өчен мин сезне сөям...—диде.

Ике көннән соң мин, тәмам терелеп, сәламәтләнеп, вагоннан чыктым. Киткәндә ул кәефле генә кулымны кысты. Минем: "Тагын күрешкәнгә кадәр!" диюемә ул:

—Юк, тиз арада тагын күрешүне теләмәгез инде,—диде.—Башлаган эшне сау-сәламәт килеш төгәлләгез!

Атыма атланып полк позицияләренә барганда, колагымда һаман аның: "Тагы күрешүне теләмәгез инде!"—дигән сүзе ишетелеп тора иде...

—Әйе!..—дип, Хафиз тирән бер сулыш алганнан соң, бераз сөйләшмичә торды да:—Ул кызны мин артык күрмәдем. Авыр көрәш көннәрендә исә ул—арыган җанны тынычландыра торган бер фәрештә—кар өстендә үскән бер чәчәк; аның тавышы—үлем авазлары арасында яңгыраган бер скрипкага охшый иде,—дип сүзен бетерде.

Барыбыз да, алган тәэссорат астында, бер сүзсез-нисез тын гына тора идек. Бары Салих кына, урыныннан торып:

— Синең мәхәббәтеңдә, Хафиз, бер тиенлек тә шигърият юк,—диде.

*1923, № 10-11*



Муса Җәлил

## ӘСИРЛЕКТӘ

*Җыланнар...*
*Телгәләп мәгъсум җанымны*
*Тагын нинди җуанычлар табарсыз?*
*Мәгез инде, тураклагыз тәнемне,*
*Җанымдагы җәрәхәтне ямарсыз!..*

*Бу каннар*
*Тик агып сеңәр дисезме?*
*Кибәрмени түгелгәчтен бу яшьләр?!.*
*Җитәр... Алда туләрсез бурчыгызны,*
*Җиңәр әл дә йөрәктәге бу аһлар.*

*Туганнар...*
*Саклагыз бу каннарымны.*
*Буярсыз ил әләмен шушы канга.*
*И илләр!.. Аңлагыз бу зарларымны,*
*Көрәш җыры булырлар анлар алда.*

*1923, № 6-7*

**Бу санда Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган махсус сәхифә бирелә.**



*"Шура" журналының җитәкчелек даирәсе. Уртада: Риза Фәхретдин һәм Дәрдеменд. XX гасыр башы фотосы.*



*1912 елда чыккан «Аң» журналы*



*Татарстан халык комиссариаты каршындагы Академик үзәк әгъзалары. Уртада: Галимҗан Ибраһимов, аның як-ягында—Шәһит Әхмәдиев, Фатих Сәйфи-Казанлы. 1925 ел.*



*Татар язучылары һәм сәнгать әһелләре. 1929 ел.*



*Үткән гасыр татар әдәбиятының яшь көчләре. Сулдан уңга— Г. Минский, Һ. Такташ, Г. Кутуй. 1928 ел.*



*Татар әдипләреннән бер төркем. Утызынчы еллар.*

Риза Ишморат

# ТАТАР СКУЛЬПТОРЫ МИРЗАҖАН БАЙКИЕВ

Һәрвакыт ачык йөзле, мөлаем табигатьле, яше алтмышка житеп, чәче-сакалы ап-ак агарган Мирзажан абый, СССР да сәнаигъ нәфисә *(сәнгать)* музейларыннан иң бае булган Ленинград Эрмитаж музеенда (элекке Императорский музей) скульптура реставраторы һәм татар дөньясында татарның Тукай, Фатих Әмирхан, Гаспринский кебек мәшһүр язучыларының һәйкәлен ясаучы беренче скульптор ул. Аның бу эштә бөтен гомере үткән, чәчләре агарган, тормышның бөтен ачысын-төчесен татыган, ниһаять, бүгенге көндә "Хезмәт каһарманы" дигән зур шәрәфле исемне алган.

Ләкин тәәссефкә *(кызганычка)* каршы, үзенең бәһа биреп бетерә алмаслык кыйммәтле эшләренә, татарлар арасында бердәнбер бөек мастер-реставратор һәм скульптор булуына карамастан, киң татар җәмәгатьчелегеннән читтә калганга күрә татар массасы арасында танылмаган, үзенең иҗатларын күрсәтә алмаган.

## Скульптура реставраторы

Реставраторлык вазыйфасы жинел эш түгел ул.

Ул зур осталык һәм скульптура эшендә күп белемне сорый. Бөтен жир шарында беренче дәрәжәдә булып танылган бөек художник-скульпторларның ватылган әсәрләрен төзәтү, кителгән жирләрен ялгау – реставратор үзе яхшы скульптор булганда гына мөмкин. Ә менә Мирзажан абый шул бөек вазыйфаны башкаручы. Башкаручы гына түгел, зур мастерларча, художник-авторларча эшен эшләп бетерүче. Син аның зур осталык белән эшләгән эшләрен, моннан берничә мең еллар элек яшәп, үзләренең скульптурадагы мастерлыклары белән бөтен жир шарында беренче урынны тоткан һәм хәзердә дә әле бер милләт, бер халык тарафыннан да узылмаган дип әйтерлек дәрәжәдә булган, юнанның *(грекларның)* мәшһүр скульпторларының ватык хәлдә (яисә аяксыз, я кулсыз, я булмаса башка бер жире кителгән) табылган статуяларын реставрировать иткәнен күреп хәйран каласың. Ул сина ялгаган төсле түгел, бәлки шул мәшһүр художникның үз кулы белән ясалып беткән дә, тик материалы житмәгәндә икенче бер материал белән бетереп куйган кебек тоела. Синең күз алдына моннан 2 мең ярым еллар элек яшәгән юнан скульпторлары үзләренең дөньяга карашлары, кайгылары, шатлыклары белән килеп баса. Мирзажан абый реставраторлык эшендә Ленинградта һичкем белән тиңләшми торган мастер ул. Шуның өчен дә башка музейләрдәге кыйммәтлерәк статуяларны реставрировать итәргә кирәк булганда аны чакыралар.



*Мирзаҗан Байкиев Эрмитажда скульптура төзәтә. 1926 ел.*

Шуның өчен дә Царское Село шәһәрендәге Екатерина II нченең сарае кебек

кыйммәтле тарихи памятникнын фасадындагы (сарай алдындагы) 120 ләп карийатидны (фигура-статуяларны) реставрировать итү Мирзажан абый карамагында була.

Шунын өчен дә шул музей администрациясе үзенең Мирзажан абыйга биргән отзывында аны: "мәсьүл *(жаваплы)* эшләрне башкарырлык, Ленинградта реставраторлык эшендә бердәнбер специалист" дип атый.

## Мирзаҗан абый сәнаигъ нәфисәнең тарихи памятникларын саклаучы

Екатерина II нче заманында ук төзелә башлаган Эрмитаж музеенда миллионнар белән генә бәһа биреп бетерә алмаслык, сәнаигъ нәфисәнең тарихи памятниклары саклана. Анда иске таш дәвереннән алып хәзергә кадәр булган сәнаигъ нәфисә памятниклары жыйналган.

Анда борынгы Мисырнын (моннан 3-4 мең еллар элекке) кабер ташлары, чокып ясалган рәсем (борынгы язу—һироглиф) белән зур таш ләхетләр, үзләренең табына торган аллалары тасвир ителгән һәйкәлләр, борынгы юнан, Румадагы мәшһүр скульптураларнын статуйлары. Шулай ук соңгы гасырның мәшһүр скульпторларнын әсәрләре картина бүлегендә Рафаэль, Леонардо да Винчи, Микель Анджело, Рембрандт, Рубенс, Веласкес кебек бөтен жир йөзе күләмендә мәшһүр художникларның кыйммәтле әсәрләре саклана. Мирзажан абый менә шул байлыкларны зур осталык белән саклаучы, үлчәүгә авыр булган памятникларны зур осталык кирәк вакытта бер урыннан икенче урынга күчертүче. Соң дәрәҗәдә мәсьүлиятле *(жаваплы)* булган бу эшен Эрмитажда эшчеләр фәкать анын карамагында гына, анын кушуы буенча гына эшлиләр. Музейдәге тарихи памятникларны, кыйммәтле статуяларны кузгату, бер урыннан икенче урынга күчерү жинел эш түгел ул—ул зур белгечне, бу эштә күп тәжрибәне һәм үзе белән яхшы мөгамәлә кыла белүне сорый. Шунын өчен дә шул, бу эшкә һәр вакытта, тәжрибәле карт Мирзажан абыйга мөрәжәгать итәләр.

Музей администрациясе дә күп вакытта бу Мирзажан абыйга тапшырыла торган мәсьүлиятле эшне анын иң зур хезмәтләреннән хисаплый. 1914 нче елны Яурупа сугышы башлангач Николай II Петербургнын немесләр кулына калуыннан куркып Петербургнын бөтен байлыкларын Мәскәүгә озаттыра башлый. Беренче чиратта озатыла торган әйберләр Эрмитаж музеендәге сәнаигъ нәфисәнең тарихи памятниклары була. Шушы соң дәрәҗәдә мәсьүлиятле эш Мирзажан абыйга тапшырыла. Шулай ук 20 нче елны инде бу байлыклар эшче-крәстиян хөкүмәтенә калгач, Мәскәүдән (Кремль) яңадан Ленинградка Эрмитаж музеена кайтару тагын да Мирзажан абый карамагыннан башка була алмый. Ул бу эштә житәкчелек итә. Музей администрациясе Мирзажан абыйнын бу хезмәтен аеруча тәкъдир кылып, аерым отзыв бирә һәм анда: "Музейнең соң дәрәҗәдә кыйммәтле памятниклары фәкать Мирзажан Байкиевнын фидакярлеге, тырышлыгы һәм осталыгы белән генә ватылмый, әләф-тәләф *(әрәм-шәрәм)* булмыйча гына шулай тулы рәвешендә сакланып кала алды",—ди.

## Мирзаҗан абый – скульптор

Мирзажан абый бөек мастер-реставратор гына түгел, ул – художник-скульптор да. Татар сәнаигъ дөньясынын һәрбер фронтында диярлек танылган күп кенә кешеләребез булса да, скульпторларыбыз юк иде әле. Бу яктан Мирзажан абый беренче карлыгачларыбыздан санала.

Ләкин ул күптәннән бирле ижат итеп килгән һәм хәзергә кадәр эшләгән күп кенә кыйммәтле һәйкәлләре булса да, киң татар массасына танылганы юк әле. Киң татар массасы түгел, хәтта татар укымышлылары, татар сәнаигъ нәфисә фронтында эшләүчеләре дә белми. Анын эшләре үзенең тора торган бүлмәсеннән, мастерскоеннан читкә чыгып, потребительгә барып житмәгән, шуна күрә дә үзенә тиешле бәһане бирдерә алмаган.

Билгеле, нинди генә ижат итүче художник булмасын, ул әсәрен үзе өчен түгел,

башкалар өчен эшли. Ул үзенең хисен, тойгысын баштан кичерүен башында тупланган сурәтләр аша гәүдәләндереп башкаларга йоктыра, тәэсир итә. Сурәтләрне гәүдәләндерү—сүз, тавыш, буяу, хәрәкәт, таш, балчык һәм башка шундый төрле санап бетермәслек материаллар ярдәме белән була.

Әгәр дә художник үзенең әсәре белән тәэсирләнүче бернинди дә объект булмаячагын белсә иде, һичбер вакыт бер нәрсә дә иҗат итмәс иде. Потребитель ул художникны тудыручы да, яшәтүче дә, үстерүче дә. Ләкин Мирзаҗан абый менә шул художник өчен һава белән су дәрәҗәсендә кирәкле булган киң потребительне табалмаган. Шуңа күрә дә аның иҗаты, скульптурада булган табигый талантын үстерү өчен кирәкле булган зәмин *(җирлек)* булмаган. Ләкин шуңа карамастан, аның зур мастерлык белән эшләгән Гаспринский, Шиһап Мәрҗани, Тукай, Фатих Әмирханнарның һәйкәлләре бар. Болар арасында Шиһап Мәрҗани белән Фатих Әмирханның әле соңгы айларда гына эшләнеп беткән һәйкәле зур осталык белән эшләнгәннәр.

Мирзаҗан абый татарның мәшһүр шагыйрьләрен, язучыларын һәм Шиһап Мәрҗани кебек реформаторларын гына түгел, бәлки татарның мәшһүр революционеры Мулланур Вахитовның да һәйкәлен ясаган, ләкин тәәссефкә каршы, бу соңгы кыйммәтле һәйкәлнең үзендә нөсхәсе калмаган. Берсе "Башкортстан" газите редакциясенә бүләк ителгән.

## Кыскача тәрҗемәи хәле

Мирзаҗан абый Байкиев 1868 нче елны Пенза губернасы Байки авылының ярлы крәстиян гаиләсендә дөньяга килә. 17 яшенә кадәр үз хуҗалыгында эшли һәм шул ук вакытта авыл мәктәбендә укый. 17 яшенә житкәч әтисе үлеп, тормышы авырая башлагач Мирзаҗан абый эш эзләп Петербурга килә һәм Петербурда Академия художество әгъзасы, художник-скульптор Чижовның мастерскоена хезмәтче малай булып эшләргә керә. Чижов моның скульптура белән кызыксынганын, скульптура эшенә дәрте һәм кабилияте *(сәләте)* бар икәнен күреп, аны барон Стиглейснең Мәркәз техника мәктәбенә укырга бирә. Шулай итеп Мирзаҗан абый Байкиев үзенең Чижов мастерскоеннан эшләп алган аз-маз акчасы белән көн күрә һәм тырышып укый башлый. 1893 нче елны ул югары күрсәтелгән мәктәпнең 7 сыйныфын бетергәч, шул ук Чижовның рекомендациясе белән Царское Село шәһәрендәге Екатерина сараена реставратор-скульптор булып эшләргә керә. Ул анда 1906 нчы елга кадәр эшли.

1906 нчы елны Эрмитажга шул ук эшкә күчә һәм анда хәзерге көнгә кадәр өзлексез эшләп килә. Мирзаҗан абый 1919 нчы елдан бирле союз әгъзасы. Быел Эрмитаж музеенең мескомы Мирзаҗан абыйга "Хезмәт каһарманы" дигән исем бирдерү мәсьәләсен күтәрә...

## Теләк

Мирзаҗан абый үзенең эшендә 35 ел буе армый-талмый эшләп килүче хезмәт батыры, шуның белән бергә, татарлар арасыннан беренче скульптор булганга аның хезмәтен тәкъдир итеп, быел киң күләмдә 35 еллык юбилей бәйрәме ясауны күтәрергә кирәк.

Мирзаҗан абыйның карамагында хәзерге вакытта үзеннән башка 5 җан семьясе бар. Аның Эрмитаждан ала торган 75 сум вазыйфасы, әлбәттә, житми. Шуның өчен дә аңа яшәү һәм иҗат эшен дәвам иттерү мөмкинлеген бирү, бигрәк тә, эшләгән эшләре белән киң татар массасын таныштыру өчен ясаган һәйкәлләрен Татарстан хөкүмәте сатып алып, аерым күргәзмә (выставка) ясасын иде.

*1928, № 10*

Шәриф Байчура

# ПАТША ХӨКҮМӘТЕ ВАКЫТЫНДА ТӨРКЕСТАНДА ТАТАР МӨГАЛЛИМНӘРЕ

Татар шәкертләре вә мөгаллимнәре хәятында *(тормышында)* яз көннәрендә казакъ далаларына барып балалар укыту вә шуннан кыш көнендә мәдрәсәдә укырлык "хосуль" *(керем, акча)* җыеп кайту аерым бер дәвер тәшкил итә. 19 нчы гасырның соңгы яртысында, бәлки, соңгы чирегендә, татарның иске ысулы кадим мәдрәсәсе шәкертләре вә хәлфәләре тарафыннан ясала торган бу сәфәрләрдә, бер яктан, иң мөһиме матди як – кыш көне мәдрәсәдә укырлык запас җыйнау булып, икенче яктан, ярым мөселман ярым мәҗүси булган казакъ халкының балаларына дин өйрәтү рәвешендә булган.

5 нче елдан соң бу агым тагын киңәебрәк "Галия", "Хөсәения" вә "Мөхәммәдия" шәкертләре тарафыннан якындарак казакъ далаларына гына тукталмастан, Төркестан өлкәсендәге казакъ-кыргыз, үзбәк вә хәтта төрекмәннәр эчендә йөри башлау юлына керә.

12-13 нче елларда бу эш тагын да киңәя төшеп, Сырдәрья, Җидесу вилайәтләрендә татар мөгаллиме булмаган кышлак (авыл) юк дип әйтерлек бер рәвешкә керә; Фәргәнә вә Сәмәрканд вилайәтләрендә дә татар мөгаллимнәренең саны арта.

Татар мөгаллимнәренең бу рәвештә Төркестанда күбәюләре ул вакытта Төркестан җир *(җирле)* халыкларының һәрбер хәрәкәтен, алар арасындагы һәрбер үзгәрешне нык тәгъкыйб итеп *(күзәтеп)* бара торган жандармерия идарәләренең, Победоносцев кебек мәшһүр урыс миссионерларының күзенә бәрелми үтә алмый. Бу хәрәкәтне аерым бер җитдият вә игътибар белән тикшереп бару башлана. Бу тикшерү бары Төркестан күләмендә, Төркестан жандармерия идарәсе даирәсендә генә тукталып калмыйча, эшне төптән алып бару өчен, татар мөгаллимнәренең чыккан урыннары – Уфа, Казан, Оренбур жандармерия идарәләре белән дә мөнәсәбәт тотылып, әтрафлы тикшерү юлында бара. Ниһаять, 1913 нче елларда Төркестан жандармерия идарәсе вә миссионер Победоносцевларның күрсәтүләре буенча, мәшһүр кадет Милюков тарафыннан Думада бу хакта доклад ясалып, татар мөгаллимнәренә Төркестанда укыту катгыйян мәныг ителә *(катгый тыела)* вә татар мөгаллимнәрен нык тәгъкыйб башлана.

Төркестанның уйгану тарихында вә ул дәвер татар мөгаллимнәренең хәятында зур әһәмиятле урын тоткан бу вакыйгаларның бер читен ачып бирә торган Төркестан жандармерия идарәсеннән алынган түбәндәге документны без "Безнең юл" укучыларына гарыз *(тәкъдим)* итәргә уйладык.

Бу мәсьәлә артык ачык булганга бу документка тәфсыйль биреп торырга хаҗәт күрелмәде.

• • •

*"Рәкым (номер) 5809 (Махсус шәгъбәнең (бүлекнең) полиция департаментына җибәргән доклады)*

*ЯШЕРЕН*

*4 август, 1913 ел.*

## Төркестан генерал-губернаторына

Шуның белән бергә Төркестан өлкәсендәге мәктәпләр назиренең *(инспекторының)* 1912 нче елдагы 11898 нче рәкымле доклад копиясен тәкъдим итеп, затe галиләрегезгә *(бөек затыгызга)* белдерәмен ки, махсус агентларның биргән хәбәре буенча, бөтен Төркестанда кыргыз-казакъ вә үзбәк халыкларының Русиядән килгән та-

тар мөгаллимнәре тарафыннан яңа ысул белән хөр вә мөстәкыйль рәвештә укытылганлыклары мәгълүм булды. Хосусан, Сырдәръя вилайәте, Акмәсҗед, Казалы өязләрендә Русиядән килгән татар мөгаллимнәре булмаган казакъ авылы һич юктыр.

Татар мөгаллимнәренең бу муаффәкыятьләренә *(уңышларына)* түбәндәге эшләр сәбәп булса кирәк: җирле халык яңа ысул белән укытканда, иске мәктәпләргә караганда балаларның җиңел рәвештә уку-язуга өйрәнеп, укыган нәрсәләренең җиңел төшенгәнлекләрен беләләр. Кыргызлар балаларын "русско-туземный" мәктәпләргә бирергә куркалар. Чөнки муллалар, балаларны "русско-туземный" мәктәпкә биргәндә, аларның христиан рухы белән рухланып, бөтенләй христиан диненә чыгып китәчәкләрен сөйләп халыкны куркыталар.

Кыргызларның татарларга булган мөнәсәбәтләре дә ул чаклы ышанычлы булмыйча, Яурупа киемендә килгән кайбер татарлардан, балаларыбызны аздыралар, аларда ислам диненә булган кадер-хөрмәт калмас дип, ибтидаи *(башлангыч)* мәктәп бетергәннән соң балаларын яңа ысул белән укыттырмыйча, ысулы кадим мәктәпләренә бирәләр.

Мөгаллимнәр байлыгы булган кыргыз яисә үзбәкләр тарафыннан махсус чакырылып, бер гаиләдә булган берничә баланы укыталар һәм моның өчен вазыйфа итеп алты ай мөддәтенә *(вакытына)* 90 белән 150 сум арасында акча алалар. Артык байлыклары булмаганнары байлар кулындагы мөгаллимнәр белән сөйләшеп, аларга мәзкүр *(әйтелгән)* мөддәт өчен 25-30 сум биреп, балаларын укырга йөртәләр. Укыту, гадәттә, мөгаллимне чакырып китергән кешенең өендә була. Әгәр дә мөгаллимне мулла яхуд *(яки)* башка рухани сыйныфыннан булган кеше китерсә, ул вакытта укыту мәсҗедтә булып, мөгаллим һәр бала башына айга бер сум илле тиеннән биш сумга чаклы акча ала.

Казакълар эченә килә торган мөгаллимнәр, гадәттә, 5 нче мартларга килеп житәләр. 5 нче марттан 20 нче мартка кадәрле вакыт мөгаллимнәрне тәгаен итү эшенә сарыф ителеп, аннан соң казакълар Сарысу буе, Каратау һәм Акмулла областьләренә җәйләүгә китәләр (Акмулла областенә азрак китәләр). Мөгаллимнәрне тәгаен итү, гадәттә, түбәндәге рәвештә була: мөгаллим кирәк булганда, волость һәм авыл башлыклары аркылы ишаннарга мөрәҗәгать итәләр, килгән мөгаллимнәр дә ишаннарга җибәреләләр. Халык тарафыннан булган мөрәҗәгать буенча, ишан килгән мөгаллимнәрне тәгаен итә. Казалы өязендә бу эш белән мәшгуль кеше мәшһүр ишан Хуҗамбирде ахундыр ки, анын Казалы шәһәрендә вә өязендә берничә мәсҗеде бардыр. Акмәсҗед өязендә мөгаллимнәр тәгаен итү эшен Әхмәд ишан Уразаев башкарадыр. Бу ишан шул өязнең Төгелем дигән бер урынында торып, җирле халык арасында һәртөрле могҗизалар күрсәтә торган изге кеше дип санала. Мөгаллимнәрнең күберәге Уфадагы "мәдрәсәи Галия", "мәдрәсәи Госмания", Оренбурдагы "мәдрәсәи Хөсәения" вә Казандагы "мәдрәсәи Мөхәммәдия"нең мөгаллимнәре вә шул мәдрәсәләрнең югары сыйныф шәкертләреннән булалар. Бу шәкертләр эчендә җирле халыктан булганнары да очрый.

Истанбул, Бәйрут, Мәдинә вә башка Төркиянең мәшһүр шәһәрләрендә Русия мөселманнарыннан берничә уннар *(дистәләр)* белән хисапланырлык санда шәкертләр укыйлар. Алар, анда укуларын тәмам иткәннән соң югарыда күрсәтелгән мәдрәсәләргә кайтып, мөгаллимлек итәләр ки, аларның тәрбиясе гаять тар милләтчелек вә панисламизм рухында була. Шулай итеп югарыда күрсәтелгән мәдрәсәләрнең панисламизм рухы белән сугарылган мөгаллим вә шәкертләре Төркестанга мөгаллим сыйфаты белән килеп, шунда бу мәсләкне таратучы булып хезмәт итәләр һәм балаларны Русия мәмләкәтенә каршы тәрбиялиләр.

Мәзкүр мәдрәсәләрнең эчендә Уфадагы "мәдрәсәи Галия" аерым урын тота. Анда дини гыйлемнәргә башка дөньяви гыйлемнәр дә бүтән мәдрәсәләрдән күп киң рәвештә укытыла. Шул сәбәпле бу мәдрәсәдә укып чыккан шәкертләр, башка яна мәдрәсәләрдән чыгучыларга караганда, галимерәк вә тугры фикерлерәк булалар. Шунын өчен "мәдрәсәи Галия"дә укыган кешеләрнең тәэсире, бигрәк тә кыргызларга булган тәэсире, бик зур. Шуны да әйтергә кирәк ки, кыргызлар (казакълар) татар халкын үзләренә караганда югары күрәләр, шул сәбәпле кыргызларнын татарлашулары бик тизлек белән бара.

Уфа вилайәте жандарма идарәсе начальнигының хәбәр итүенә караганда, "мәдрәсәи Галия"дә Төркестан өлкәсеннән түбәндәге шәкертләр укыйлар. Сырдәрья области Акмәсжед өязе Городов волосте Унынчы авылдан: 1) Баймөхәммәд Карнаин, 13 яшьтә, 2) Галибай Мөхәммәдев, 18 яшьтә, 3) Биржан Торсынов, 19 яшьтә, 4) Тынбай Калышев, 18 яшьтә, 5) Йосыфбай Исмәгыйлев, 18 яшьтә, 6) Мөхәммәдгали Уразаев, 24 яшьтә; Алтынчы авылдан: 7) Иргали Сәедбаев, 14 яшьтә; Сарский волость Унынчы авылдан: 8) Ширмөхәммәд Канчыкбаев, 20 яшьтә; Алтынчы авылдан: 9) Иргали Йосыпов; Телетол волосте Бишенче авылдан: 10) Колмөхәммәд Уразаев, 21 яшьтә; Жидесу вилайәте Епшен өязе Беренче авылдан: 11) Әбелгазый Юлчыбиков, 22 яшьтә, 12) Әбелгазый Чумиков, 21 яшьтә; Капал өязе Горно-Аксуский волость Бишенче авылдан: 13) Мирhан Ирмакташев, 23 яшендә, 14) Нигъмәт Мортазин, 20 яшендә; Арасан волосте 5 нче авылдан: 15) Әбүбәкер Чапчибиков, 21 яшьтә; Семипулат области Павлодар өязе Анакузинский волость, 4 нче авылдан: 16) Нигъмәтулла Күзәмбаев, 20 яшьтә, 17) Шәех Хажибиков, 26 яшьтә.

Оренбур вилайәте жандарма идарәсенен хәбәр итүенә күрә, яз көннәрендә мәдрәсә шәкертләренен бер бүлеге, хосусан, югарыгы сыйныф шәкертләре кин казакъ-кыргыз сахрасына таралып, анда аз вазыйфа бәрабәренә балалар укыталар. Аларның укытулары яна тәртип белән булып, күп урыннарда яна тәртип иске ысул укытуны жингән.

Казан вилайәте жандарма идарәсе начальнигының хәбәренә бинаән *(караганда)* Казан мәдрәсәләренен кайбер шәкертләре (шулар эчендә казак-кыргыз шәкертләре дә булганы хәлдә) яз көннәрендә казакъ далаларына таралып, анда казакъкыргыз балаларын укыталар да, шул хезмәтләренә каршы алган вазыйфалары белән кыш көннәрендә уку өчен үзләрен тәэмин итәләр.

Казакъ-кыргызлар эчендә таратыла торган казакъ телендәге китапларга килсәк, алар ике фирма тарафыннан нәшер ителә: берсе — Кәримевләр, икенчесе — Хөсәенев варисларының фирмасы. Бу ике фирма тарафыннан хәзергә чаклы житмешләп китап нәшер ителгән. Жандарма идарәсе тарафыннан бу китапларның һәммәсе каралып чыкты вә аларның эченнән әһәмияткә малик *(ия)* булганнары хакында Казандагы Матбугат эшләре комитетына хәбәр ителде. Бу китапларның списокы ошбуларга гыйлавә итеәдер *(беркетелә)* .

"Уян казакъ!" исемле китапның таратылуы Казандагы Матбугат эшләренен вакытлы комитеты тарафыннан мәныг ителде *(тыелды)* һәм монын мөхәррире Миръягкуб Дулатов Омски судебный палатасы тарафыннан бер ел мөддәткә хәбескә *(кулга алынып ябылуга)* хөкем ителде.

Яшерен тикшерүләрнең нәтиҗәсендә, Русиядән килеп казакъ, үзбәк балаларын укытып яткан түбәндәге татар мөгаллимнәренен барлыгы мәгълүм булды:

Пишпәк өязе Тинай волостендә Даса Уранбаев дигән кешенен карамагында Нәҗметдин Шиhабетдин угылы Ишмөхәммәдев-Салихов казакъ балаларын укытмакта һәм Тинайдагы русско-туземный школада дин укытмактадыр. Ул үзе Уфа вилайәте Эстәрлетамак өязе Кармыш волостенен бер крәстиян баласы. Пишпәк шәһәрендә вә ярминкә мәсжедләрендә татар мөгаллимнәре үзбәк вә кыргыз балаларын татар телендә укыталар. Пишпәктә яна ысул белән укытыла торган мәктәпнен мөгаллиме Әхмәд Габделбәдыйгов, Мамадыш өязе Нижний Сөн волосте татарыдыр. Шулай ук Пишпәктә мөгаллимлек итүче Хәсәнжан Галимжан угылы Баязитов та Уфа вилайәте Бирски өязе Әсән волосте Суык Күл авылы татары булып, "мәдрәсәи Галия" тәмам иткән кешедер.

Ташкәнд тимер юлы өстендәге "Бер Казала" стансасына якын авылда Госманбик Хужатов дигән казакъ өендә Садретдин дигән бер татар балалар укытмактадыр.

Шул ук юл буенда Чиле стансасыннан дүрт чакрым ераклыкта булган Скоблов авылында Харис Фәтхуллин дигән бер мөгаллим бар. Ул үзе Самар вилайәте Бозаулык өязеннән булып, "мәдрәсәи Галия" шәкерте.

Мөгалимнәр билгеләү эшендә Скоблов кышлагында сәүдә итеп торучы Вятка вилайәте, Малмыж өязе Кокшин волосте вә Кокшин *(хәзерге Кукмара районындагы Кукшел)* авылының крәстияне Хәбибрахман Гыйбадуллинның күп хезмәте тиеп,

бу кеше яңа килгән мөгаллимнәрне элек үз өенә кабул итеп, аннан акрынлап мөрәҗәгать иткән урыннарга аларны җибәреп тора. Хәзерге көндә Скоблов волостендә Гыйбадуллинның күрсәтүе белән тәгаен ителгән мөгаллимнәр бик күп булып, мәшһүррәкләре түбәндәгеләр: мөгаллим Габдессабур Дистанов – Уфа вилайәте Бәләбәй өязе Аксаков волостеннән булып, 3 нче авылда тормактадыр. Скоблов кышлагыннан унбиш чакрымлык җирдә Малый Кутум авылында "мәдрәсәи Галия"дән килгән мөгаллим Исмәгыйль Кибилов торадыр.

Ташкәнд тимер юлы буендагы Солы түбә стансасына якын җирдә татар мөгаллиме Закир Рәшидев бар. Аның хатыны Мөнәүвәрә дә мөгаллимә булып, Кабил Иркәбаев дигән бер кыргыз(казакъ)да торадыр ки, бу кыргыз сәясәттән хәбәрдар, Төркия файдасына һәр төрле ярдәмнәр җыя торган кешедер. Май ае уртасында Ташкәндтән Акмәсҗед һәм аның өязенә алты татар мөгаллиме үтеп китте.

Чиназ ягында татар мөгаллимнәреннән Хәеров һәм Һади Даутовлар мөгаллимлек иттеләр. Боларның соңгысы Иске Ташкәндтә Пагахан дигән кешегә күчеп килде.

Богородский кышлагына якын бер кыргыз авылында татар мөгаллимәсе Бибимәрьям Исхакова торадыр.

Хөҗәнд өязе Далвирзин дигән урында Бикбулат атлы татар мөгаллиме бар. Бу Әстерхан вилайәтеннән килгән кеше.

Хуканд өязендә – 6, Нәмәнган өязендә – 4, Шиpов стансасыннан 8 чакрымлык урында – ике татар мөгаллиме тора. Серов өязе Атамыш районы Кабил авылында ике татар мөгаллиме торып китте. Боларның берсе – Гыйбадулла Габидов, икенчесе мулла Солтан Абдин Хуҗа угылы.

Бакаш күле буендагы мәҗүси кыргызлар арасында татар мөгаллимнәре кыргыз балаларын укыту белән мәшгуль булып, аларның фикере – мәҗүси кыргызларны мөселман итүдер.

Пишпәк өязе Тимербулат волостендә "мәдрәсәи Галия" тәмам итеп кайткан кыргыз мөгаллимнәре, рөхсәт алмастан мәктәп ачтылар. Лакүл волостендә "мәдрәсәи Галия" тәмам иткән Ишангали Арабаев дигән кыргыз мөгаллим рөхсәтсез мәктәп ачты.

Соңгы вакытларда хөкүмәтнең нык тикшерүен игътибарга алып, татар мөгаллимнәре бераз саклык белән хәрәкәт итә башладылар һәм алар акрын-акрын Сырдәръя областеннән Фәрганә, Сәмәрканд, Закаспий областьләренә юнәлә башладылар.

Югарыда саналган кешеләрнең һәркайсы электән шәгъбәгә мәгълүм булган кешеләр түгел һәм аларның сәяси ышанычлыклары хакында һич мәгълүмат булганы юк.

Югарыда әйтелгәннәргә гыйлавә *(өстәмә)* итеп шуны әйтәмен ки, яшерен тәфтиш *(тикшерү)* эшләре, статский советник Миллерның тикшерүеннән хасил булган нәтиҗәләрне тасдыйк итәдер *(раслый)* һәм Сез җәнабе галиләрегез тарафыннан 1912 нче ел 25 нче гыйнварда Сырдәръя вилайәте мәктәпләр директоры вә халык мәктәбе инспекторларына бирелгән 844 рәкымле әсаси *(төп)* кагыйдәләргә хилаф булган эшләр белән көрәшмәклек кайбер мәэмүрләрнең *(чиновникларның)* ул эшләргә яхшы караулары вә бигрәк тә җирле халыктан булган тәрҗеманнарның һәр төрле яңа планнарны халыкка белдереп торулары сәбәбеннән бик авырлашадыр.

Асыл нөсхәсенә имза иттем: подполковник Сизых.
Тугры: ротмистр (имза)".

*1922, № 5*

# «ЯҢАЛИФ»

1927-32 ЕЛЛАРДА ЧЫГА

**ЖИТӘКЧЕЛӘРЕ:**
Ф. Сәйфи-Казанлы (1927, № 1-7, 1928, 3-4,—мәсьүл (җаваплы) мөдир; 1929, 7-9, 12-15, 21-24, 1930, 1, 2—җаваплы редактор); Г. Әлми (1927, 8-9—вакытлы мәсьүл мөдир, 1928, 1, 2—мәсьүл мөдир, 1928, 15—вакытлы редактор), Ф. Сәйфи (1927, 10-12—мәсьүл мөдир), 1928, 16-1929, 6—редакторлары Ф. Сәйфи, Г. Әлми, И. Рәми; С. Борһан (1929, 10—вакытлы редактор), И. Рәми (1929, 11—техник редактор), Г. Нигъмәти (1929, 16-20—вакытлы редактор, 1930, 3-1932, 10—җаваплы редактор).




Көләкәй

## ИСКЕ-МОСКЫ

КӨЛКЕ

*Яңа хәрефләр күрсәтеп*
*Шәрык халыкларына,*
*Күмәкләшеп сугыш ачтык*
*Гарәп хәрефләренә.*

*"Изге" гарәп хәрефләре*
*Ислам кебек искергән,*
*Ишан-мишан, казый, кузый*
*Шуның белән исергән.*

*Яңа хәреф шатлыгыннан*
*Көн дә бәйрәм, көн дә туй,*
*Диннәр белән туган булган*
*Тузган хәрефләр долой.*

*Һам-там! Тырам-та-та!*
*"Яңа дөнья" нишләтә?*
*Латин хәрефен алга атлата,*
*Гарәп хәрефен таптата.*

*Иске хәреф сынык, ярык,*
*Чистый утын арбасы.*
*Аны яклап маташканнар*
*Бар да милләт каргасы.*

*Аны яклый Шәрәф-мәрәф,*
*Галимҗаннар, Алкиннар,*
*Мулла, мәзин, мөфти, казый,*
*Нэпман, кулак, ахуннар.*

*Алпаров та Тулпаров,*
*Шакмакзадә Күкәев,*
*Кәкре шагыйрь, бөкре халфа,*
*Нинди хурлык! Ни кәеф!*

*Там-там, рата-там!*
*Гыйнаси Абдулкы и там*
*Гарәп хәрефен яклап чыга*
*Аксак-туксаклар гына.*

*Гарәп хәрефе харап кызык:*
*Килеш-килбәтсез бозык,*
*Башы да юк, арты да юк,*
*Туксан бормалы сызык.*

*Төртке белән чуарланган,*
*Кәкере-бөкере бормалы,*
*Берсе мисвәк, берсе тәсбих,*
*Берсе комган формалы.*

*Берсе кабер ташы кебек,*
*Берсе сәнәк формалы,*
*Берсе хәзрәт башы кебек –*
*Чуаланган чалмалы.*

*Берсе ялангач башлы,*
*Берсе чапан бөркәнгән.*
*Әйтмә инде – чүп галәмәт,*
*Бер дә харап әкәмәт!*

*Тагын тезик – берсе дога,*
*Берсе Акбай койрыгы,*
*Берсе әтәч, берсе ядәч,*
*Барсы да шул бер тәпәч!*

*Берсе кармак, имән ыргак,*
*Берсе һилал сурәте,*

*"Тамыр" эчкән карчыктай*
*Киткән эрәт-чираты.*

*Тәмам, тәмам, тәмәт тәмам,*
*Шуның белән вәссәлам,*
*"Гарәп хәрефен кимсетә" дип,*
*Ачуланма, Әпсәләм!*

*1927, № 11.*

---

# "БУЛАТ БАТЫР"

Совкино экспедициясе режиссеры Ю.В.Тарич иптәшнең "Булат батыр" картинасын алу турындагы доклады тыңлаучы халыкның дикъкатен нык җәлеп итте. Ул үзенең кереш сүзендә Татарстанның беренче милли, тарихи картинасын тудыру эшенә партия һәм совет оешмаларының нык булышлык күрсәткәннәрен һәм, шуның аркасында, эшнең шактый җиңеләйгәнен әйтә.

"Булат батыр" сценариесенең маузугы *(темасы)* казанлы Шакиров иптәш тарафыннан бирелеп, атаклы сценарияче Зархи аны сюжетлаштырган. Сюжетта качкыннар батыры Булат батырның ике улы бер-беренә каршы ике лагерьда булуыннан килеп чыккан шәхси драмасы, үсеп килә торган крәстияннәр хәрәкәте фонында бара.

Булатның бер улы Асфан була. Ул башта "матур сәнгать сөюче" – кеше асучы Державиннең каза экспедицияләрендә катнаша. Ахырда Пугачев ягына чыга. Икенче улы купец булырга уйлап йөрүче һәм Екатерина гаскәрләре ягына чыгучы Тимер, атасы Булат батыр кулыннан үлә.

Пугачев һәм Булат батырның берләшкән гаскәрләре Казанны алалар.

Картинаның төп рольләре өметле кулларда. Булат батыр ролен рус тормышыннан алынган бик күп картиналарда уңышлы уеннар биргән Ярославцев алып бара. Башка зурырак рольләрдә дә сыналган кешеләр уйныйлар.

Оператив як соңгы чорларның уңышлы картиналар белән атаклы Г.Гибир кулында, ә художество ягы художник-архитектор Уткингә бирелгән.




*«Булат-Батыр» фильмыннан кадр.*

Экспедициянең юлбашчылары картинаны алганда аның тарихи яктан дөрес булуын нык күзәттеләр. Пугачевның Казан өстенә килүенең чын юллары (Мамадыш юлы, Арча кырындагы кирпеч сарайлары, шәһәрнең татар бүлеге, Кремль һәм башкалар) төшерелделәр. Постоялый дворлагы, губернатор сараендагы күренешләр һәм Пугачев килгән вакытта дворяннарның рухларын күтәрү өчен Беренче гимназиядә ясалган спектакль Мәскәүдә павильоннарда алыначаклар.

Сүз актыгында Тарич иптәш массовкаларда үзләрен кызганмый катнашкан өчен Казан гарнизоны бүлекләренә рәхмәт әйтте.

Татарстан мәдәнияте тарихына кыйммәтле бүләк булган "БУЛАТ-БАТЫР" картинасын чыгару Октябрьнең ун еллыгы бәйрәменә багышлана.

Иң элек картина Казанда күрсәтелә башланачак.

*1927, № 7.*

М. Яушев

# БОЗ КУЗГАЛДЫ

Бу "Боз кузгалды" мәкаләсе үзенең эченә татар музыкасының үткәннәреннән хәтергә алынырлык һәм, мәкаләнең авторы әйткәнчә, татар музыкасы тарихын яза башлаганда бер материал булырлык хәлләрне алганлыгын искә алып, асыл нөсхәсеннән берникадәр кыскартылып басылды. Мәкалә иясе татар музыкасының тарихын яза башлау мәсьәләсен күтәрә. Бу турыда, әлбәттә, ике фикер булмас, эшләнергә тиеш эш. Әлегә, тик, идарә татар музыкасының үткәне, хәзергесе, киләчәге турында язучыларга журнал битләре ачык икәнен белдерә.

**Идарә.**

Бу ел "Красная Татария" газитендә Украина культурасы турында "Боз кузгалды" дигән мәкаләне укысак, хәзер татар музыкасы һәм музыкантлары турында 28-29 нчы елда язылган С.Фәйзуллин, Г.Кутуй, Госманов һәм башка иптәшләрнең мәкаләләрен укыган соңында да татар музыкасы һәм музыкантлары турында "боз кузгалды" дисәк, дөрес булыр кебек сизелә. Музыка яратучы кечкенә генә бер музыкант булу сыйфатым белән һәм элегрәк заманнарда карт татар музыкантлары арасында булып, утырышып, алар белән татар музыкасы, музыкантлары турында сөйләшкәләгәнем дә булганга күрә хәтергә калганнарны язып үтүне тиешле таптым.

## Татарда музыканың таралуы һәм татар музыкантлары турында

Татар музыкасы качып-посып яшәгән, яшерен почмакларда сакланып килгән музыка ул. 1905-6 нчы елларда яшьләр тарафыннан сирәк-сирәк кенә ясала торган театр-кичәләрдә татарның иң борын заманнан килгән моңнарын уйный башлаганнар. 1907-8 елларда Шәрык клубларында, әдәбият кичәләрендә уйный торган булганнар. 1907 нче елда әдәбият кичәсендә Гали Зайпин кечкенә генә бер салон оркестр да уйнатып караган. Ләкин татар музыкасына әһәмият бирелмәгән, татар халкын музыка сәнгатенә төшендерү кыен булган.

Шулай да, заманында булган татар музыкантлары, музыка осталары музыка сәнгатен халык арасына кертергә тырышканнар. Гариф Минкин, аның энесе һәм Гыйлаж Сәйфуллиннәр тарафыннан татар көйләре калай пластинкаларга кисеп таралганнар. Татар көйләре граммофон пластинкаларына да кергән. Әнә шул калай һәм граммофон пластинкалар аркылы татар музыкасының таралуын белсәк, Минкин, Зайпин, С.Рәхманколов, Сәйфуллин, Ахун, Шаһиәхмәтев, Әхмәдуллин, Хөсәеневләр онытылмаслык нәрсә калдырганнар дип әйтми китеп булмый.

Татарда музыка сәнгатенең күзгә күренеп таралуы 1909-10 нчы елларда башлана. Татарлар яши торган районнарда ачылган кинотеатр "Свет", "Буф" театрларында өзлексез рәвештә татар музыкантлары татар көйләрен уйныйлар. Музыка әкренләп гармун, пианино, скрипка, мандолина, гитара шикелле уен кораллары аркылы тарала. Татар яшьләре арасында музыкага мәхәббәт арта бара. Яшереп-яшереп кенә музыкага өйрәнә башлыйлар: чөнки музыка коралын кулга тоткан килеш Печән базарыннан, "Көфер почмагы"ннан үтеп китү кыен, арттан төрле кабәхәт сүзләр белән сүгеп калалар. Шуңа карамастан, уйнарга иң җиңел булган уен коралы — мандолинага өйрәнү көннән-көн алга китә. 1912-13 нче елларда "Сәйяр" труппасы башлыгы Г.Кариев музыка аркылы халыкны театрга җәлеп итүне үзенең алдына көндәлек бурыч итеп куя, татар музыкантларын еш-еш үзенә чакырып уйната торган була. Театрга музыка керү аркасында, электә 30-40 кешедән артмаган тамашачы, театрга килүче арта башлый. Шул ук елларда концерт һәм танцы кичәләре дә куела башлый. Татарның музыкант, җырчылары аерым-аерым номерлар үти башлыйлар. Шул ук елларда һәвәскәрләр труппасы дөньяга чыга. Яшьләр арасында музыкага омтылыш тагы да арта. 1915-16

---

Мөхәммәт ЯУШЕВ (1893–1969) — *скрипкачы. 1912 елдан милли музыкаль ансамбльләрдә, 1939–59 елларда театрларыбыз һәм Татарстан радиосы оркестрларында уйный. Хәз.*

нчы елларда укучылардан "Берек", яшь хезмәткәрләрдән "Тукай" исемендә түгәрәкләр төзелеп эшли башлый. Шулай итеп татар музыкасы, татар сәхнәсе белән берлектә, татар дөньясына керә.

## Татар көйләрен чыгаручылар-язучылар

Скрипкәче карт Мөхәммәтша абзыйның сөйләве буенча, көйләрнең күбесе авылларда, жыеннарда, монсу җирләрдә чыксалар да, аларны чыгаручылар да, чыгарырга тырышучылар да заманында булган. Бу карт хәтерендә калган Нижнийнең Хәбибуллине, анын сакланып калган "Хәбибулкин маршы"н, Саратовның Усмановны, Уфаның Ижбулдиннарны сөйли.

1914-15 нче елларда Казандагы көй чыгаручылардан Г.Сабитов һәм Яруллиннәрне дә искә алып үтәргә кирәк. Алар тарафыннан язылган көйләр татар музыкачылары тарафыннан уйнала, җырчылары тарафыннан җырлана.

Татар музыкасына караш (элек һәм хәзер)

Бу турыда надан татар муллаларының һәм татар фанатикларының йогынтысы астында татар халкы музыкага салкын караган диергә кирәк. Гәзитләрдә язучы-рецензиячеләребез дә татар музыкасына игътибар бирмәгәннәр, музыканың халыкка булган тәэсирен анламаганнар. Югарыда язылган концерт кичәләре турында гәзитләргә гомуми рәвештә язылса да, аерым татар музыкасы һәм музыкантлары турында кыйммәт *(бәя)* бирелми иде. Гомумән алганда, татар матбугаты музыкага әһәмият бирми иде. 1916-17 нче елларда "Зөләйха" пьесасының фәрештәләр пәрдәсе өчен язылган Габәши музыкасы кайбер драматургларны уятты диергә кирәк. Шул көннән башлап Мирхәйдәр Фәйзи, Тинчурин, Борнашлар музыканың театр пьесасына кирәк бер нәрсә икәнен анлап эшкә керештеләр.

Советлар Жөмһүриятнең 11 елы эчендә татар музыкасы үзенә бөек бер урын алды. Татар музыкасының кирәклеге һәм халыкка биргән тәэсире анлашылды.

Патша хөкүмәте вакытындагы музыка мәктәпләренә татарның кабилиятле һәм яхшы музыкант булу теләге белән янган татар жегетләре, югарыда сөйләнгән муллалар коткысы аркасында, керә алмадылар. Шул ук мәктәпләр эшче-крәстиян балаларына ябык булганлыктан, соңгылары да чын теләкләренә ирешә алмадылар. Тик аларның уттай ташкан йөрәкләреннән чыккан теләкләре Татарстан Советлар Жөмһүрияте барлыкка килү белән генә вөжүткә чыкты *(тормышка ашты)*.

Татарстан Советлар Жөмһүриятенең музыка мәктәбе (техникумында) татар эшче-крәстиян балалары укып ята. Татарстан Мәгариф Комиссарлыгы тарафыннан жибәрелеп Мәскәү консерваториясендә укып ята торган яшьләребез бар.

Татар музыкантлары арасыннан атылып чыккан пианист Салих Сәйдәшев зур бер талант иясе [булып] танылып композитор исемен алды. Арабыздан чыккан бу яшь өметле композиторның тагын да зур адымнар белән алга китүен көтәргә кала.

Татарда сәхнә тарихы эшләнде.

Инде татар музыкасы тарихын язу чараларын да күрергә кирәк. Ияләре *(белгечләре)* бу зур эшкә әһәмият биреп керешерләр һәм Гыйльми Үзәк якыннан торып ярдәмләшер дип уйлыйбыз.

*1929, № 12*

## Контрреволюцион яшерен “ҖИДЕГӘНЧЕЛӘР” турында Татар совет язучылары оешмасы

Шушы елның 13 нче августында “Башкортстан” гәзитендә Ченәкәй, “Кызыл Татарстан” редакциясенә җибәргән Минский хатларын һәм Г. Кутуйның ТАПП правлениесенә язган аңлатмасын укыганнан соң Татар совет язучылары оешмасының правлениесе карар кылды:

1. Пролетариат үзенең сыйнфый идеологиясе, шул идеологиянең тулы рәвештә гегемониясе башлык сөрүе өчен кискен көрәш алып барганда дошман сыйныфның да төрле юллар белән көрәшүе ят нәрсә түгел. “Җидегән”нәр оешмасы, шиксез, пролетариат идеологиясенә каршы көрәшүчеләрнең контрреволюцион бер формасы.

2. Без хәзер кискен сыйнфый көрәш чорында пролетариат сыйныфына, түгел актив рәвештә каршылык итүчеләргә, пролетариатның социализм тормышы төзүенә, аның үз идеологиясе өчен кызганычсыз көрәш алып баруына “без пассив, без сәясәткә катнашмыйбыз”, “без нейтраль торабыз” диючеләргә дә объектив буларак болар да пролетариат сыйныфына каршы дип, көрәш утын ачканда, актив контрреволюцион оешмаларга, аны төзүчеләргә пролетариат ныклыгы һәм кискенлеге, кызганычсызлыгы рәвешендә каты көрәш ачуны оешма үзенең бурычы дип белә.

Киләчәктә мондый хәлләр кабатланмасын өчен Татар совет язучылары оешмасы түбәндәге эшләрнең ныклы рәвештә үтәлүен кирәкле саный:

1. Пролетариат идеологиясенә каршы булган бөтен элементлар белән, аларның нинди дәрәҗәдә торуларына карамастан, һичбер төрле килешүчелеккә тайпылмыйча, кызганычсыз көрәш ачып, аларның чын йөзләрен пролетариат һәм совет җәмәгатьчелеге алдында ялангач рәвештә бастырырга. Шуның белән бергә үзара тәнкыйтьне көчәйтергә.

2. Матур әдәбият оешмаларындагы бөтен члennардан пролетариат идеологиясен үзләштерү юлында революцион активлык сорап, хуҗалык һәм төзү фронтларындагы темпы шикелле матур әдәбият фронтының темпын көчәйтүне бу көнге бурычлар итеп куярга, шулай ук пролетариат революциясе чорындагы иҗат методы—диалектик материализм методын үзләштерү өчен рәхимсез көрәш алып барырга.

3. Язучылар арасында пролетариат матур әдәбиятында гаиләчелек, карьеризм һәм массадан ераклашып, үз кабыгында бикләнеп эшләү кебек буржуа калдыкларын бетерер өчен, эшче массасы һәм хезмәт ияләре арасында эшләүне көчәйтергә.

Әлегә кадәр татар язучылары оешмасында член булып саналган Минский “Җидегән”нәр оешмасында эшләвен, узган Татар совет язучылар сафын пролетариат һәм совет язучысына чит элементлардан тазарту барганда үзенең шул контрреволюцион оешмада торуын әйтмичә, җидегәнчеләрдән Ченәкәй хат белән чыккач, рияланып тәүбә хатын язуы һичбер яктан да ана совет һәм пролетариат җәмәгатьчелегенең ышанычын казандыра алмый. Татар совет язучылары оешмасы Минскийне үз сафыннан чыгарып ташлавын белдерә.

*(Казан. 2/IX-1930 ел. “Татар совет язучылары оешмасы” правлениесе.)*

*1930, № 2.*

## Аныклагыч мәгълүмат

“Җидегәнчелек” мәсьәләсе Р. Вәлиев һәм М. Мәһдиев тарафыннан җентекләп өйрәнелеп, безнең журналда (Болганчык еллар авазы // Казан утлары, 1992. —№ 1.) тәфсилләп бәян ителде. Авторлар С. Батыевның, бернинди “Җидегән” булмаган, дигән сүзен инкяр итәләр. Г. Минскийның “Кызыл Татарстан” редакторы исеменә язган хатыннан күренгәнчә, Г. Минский һәм Г. Кутуй Уфада каләм әһелләре белән аралашкач, язучыларның үзара оешып җитә алмавы, бер-берсе белән бәйләнешләр начар булуны истә тотып һәм романтик бер шаукымга бирелеп, Г. Кутуй, Ченәкәй, Н. Исәнбәт, Г. Минский, С. Кудаш “Җидегән” дигән иҗади төркем булып оешалар. Төркем бу матур исемгә ярашлы булсын өчен тагын ике кешене соңрак табарга ниятлиләр. Г. Минский язуынча, “Җидегән” ул үз асасында (нигезендә) сәяси бер зур төс бирү аркасында түгел, бәлки, җиңелчә генә әдәбият мәйданында була торган каләмдәшлек, дуслык группачылыгы тәртибендә” оештырыла. Ләкин җәберчел тоталитар режим бу “чебен”нән “сәяси фил өреп кабарта һәм татар әдәбиятына бик көчле удар ясый.

# ҖАН УЧАГЫ

Җир йөзендә яшәүче һәр милләтнең рухи куәте язма әдәбият ядкарьләренең бөеклеге белән билгеләнә.

1922 елның май аенда тәүге тапкыр балкыган "Казан утлары" журналы тарихы да шул җәһәттән аеруча әһәмияткә ия. 84 ел эчендә аның битләрендә басылып чыккан, татар әдәбиятының олы казанышлары булырдай иң мөкаммәл тезмә һәм чәчмә әсәрләр Илдәге халәтне, "раушан көзгедәй", дөрес чагылдыра, гүяки вакыт агышы шулай мәңгегә ташка басылып бара. "Казан утлары" тора-бара Ил, Ватан утларына әверелеп, татар галәменә нурлар сирпеп, милләтне җылы, якты учагы тирәсенә җыеп, җылытып яши. Хәтәр җилләр чыгып, давыл купканда да мәҗмугабызның изге утлары сүнми балкый.

Әле күптән түгел 1000 еллык бәйрәмен билгеләп үткән мәһабәт мәркәзебезнең йөзек кашына тиң журнал ул—"Казан утлары"!

"Казан утлары"ның һәрбер санын мәгърур Аккошка тиңлисе килә. Һәр ел саен милләт күгенә 12 Аккош күтәрелә. Һәм, ниһаять, көткән көнебез килеп житте — милләтебез күгендә 1000 гүзәл Аккош йөзә!

Бүген бөтен татар милләтен, каләмдәшләребезне, бер-беребезне "Казан утлары"ның 1000 нче саны чыгу белән чын күңелдән кайнар котлыйбыз! Кадерле редакция хезмәткәрләре, фидакарь каләмдәшләребез! Сезнең белән бергә сөенәбез, Сезгә ихлас рәхмәтләребезне житкерәбез, чөнки без гомер-гомергә бергә яшәдек, ижат иттек, үстек, милләт сагында тордык. Шуңа күрә "Казан утлары"ның бәйрәме — Татарстан язучыларының да олы бәйрәме ул!


***Сезне ихтирам итеп, иң изге теләкләр белән,***
***Татарстан язучылары.***



# «АТАКА»

1930—1932 ЕЛЛАРДА ЧЫГА

**ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ:**
Г. Гали (1930, № 1-7), К. Нәҗми (1930, 8-1931, 4), З. Гали (1932, 9-10)—җаваплы редакторлар; редколлегия (1932, 11-1932, 20).




## "БЕЗНЕҢ ЮЛ" журналы укучыларына

Татарстан дәүләт нәшрияты тарафыннан чыгарыла торган әдәбият журналларыннан элек айга бер тапкыр чыгарылып килә торган "БЕЗНЕН ЮЛ" һәм декадага бер чыгып килә торган "ЯНАЛИФ" журналлары бетерелергә тиеш табылып, алар урынына ике яна журнал чыгарыла башлады. Хәзер:

1) Татарстан Пролетариат Язучылары Ассоциациясе (ТАПП) органы булып ике атналык "АТАКА" һәм

2) Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты органы булып айлык "ЯНАЛИФ" журналы чыгарылырга керешелде.

Хәзергә чаклы подписка сроклары тулмаган "БЕЗНЕҢ ЮЛ" подписчикларына моннан сон "АТАКА" журналы җибәрелә башлаячак.

**Татиздат һәм "Безнең юл" редакциясе.**
*1930, № 1.*

## Кем нәрсә яза?

* **Шәриф Камал** "Матур туганда" исемле роман яза. Бу роман кышка бастырылырга биреләчәк.

* **Гомәр Галиең** "Пролетариат әдәбияты өчен көрәшкәндә" исемендәге 5-6 табаклы китабы Татиздатта басылып ята.

* **Мирсәй Әмир** Кызыл Армия тормышыннан зур хикәя яза. Хикәя 8-9 табаклар чамасы булачак.

* **Газиз Иделле** "Күч" исемле хикәя яза. "Дингез" исемле поэмасын язуда дәвам итә (поэманын башы Татарстанның 10 еллыгына чыккан әдәби альманахта басылды).

* **Таһир Госман** "Очкыннар" исемендә өч китаптан гыйбарәт зур бер роман яза. Беренче китабын бетереп Татиздатка басарга бирде.

* **Һади Такташ** "Востоккино"га биргән "Камил" либреттосы буенча Татар Академия театрына шул исемдә бу елгы сезонга сәхнә әсәре эшли.

* Композитор **Салих Сәйдәшев** хәзерге көндә 3 пәрдәдән гыйбарәт опера язып ята. Операның мөндәриҗәсе (эчтәлеге) революция чорыннан алынган.

* **Габәши** һәм **Әлмөхәммәдев** Гыйльми тикшерү-экономика институты өчен халык көйләрен монографка алалар. Болар музей өчен бик кыйммәтле булачак.

* Мәскәүдә Олимпиада вакытында 20 татар көе граммофонга алынды. Шуларның 6-сы **С.Сәйдәшевнеке**, 1-се **Габәши** музыкасы. Көй алу эшендә **С.Сәйдәшев, Габәши,** җырчылардан **Айдаров, Г.Әлмөхәммәдев, Рәхманкулова, Кайбицкая, Төхфәтуллин** иптәшләр катнаштылар.

*1930, № 2.*

# Пролетариат Язучылары Ассоциацияләре янындагы бөтен татар секцияләренә һәм бөтен татар пролетариат язучыларына

Үткән ел Татарстан Партия Өлкә Комитетының татар матур әдәбияты турындагы тезисләрендә, шулай ук РАПП-ның 2-нче пленумының татар әдәбияты турындагы резолюциясендә Казанда ТАПП органы итеп махсус журнал чыгару кирәклеге әйтелгән иде. Хәзерге вакытта без шушы директивләрне эшкә ашырырга керештек.

Шушы елның июленнән башлап Казанда Татарстан Пролетариат Язучылары Ассоциациясе органы булып айга ике тапкыр "Атака" исемендә әдәбият, сәнгать, тәнкыйть журналы чыгарыла башлый. "Атака" журналы турыдан-туры татар пролетариат әдәбияты хәрәкәтенең үз журналы булып, татар пролетариат язучылары оешмаларыннан берсенең органы булып чыга. Шуның өчен дә монар без татар пролетариат әдәбияты үсешендә зур әһәмиятле бер эш дип карыйбыз. "Атака"ның төп бурычы – партиянең матур әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә тоткан сәясәтен тормышка үткәрү өчен, пролетариат әдәбиятының гегемониясе өчен көрәшкә кайтып кала. Интернациональ культура өчен көрәш юлында, буржуа милләтчелегенә, солтангалиевчелеккә, әдәбияттагы уңлык һәм аның белән килешүчәнлек күренешләренә, шулай ук "сул" бөгелешләргә каршы аяусыз атака алып баруны бу журнал үзенең үзәк бурычлары рәтенә кертә. Бу бурычларны үтәү юлындагы көрәшнең ничаклы зурлыгы һәм әһәмиятлелеге, әлбәттә, билгеләнә. Бу көрәш татар пролетариат әдәбияты көчләренең тагын да ныгырак берләшүләрен, ярдәмләшүләрен, пролетариат әдәбияты хәрәкәтенең кирәк оешу, оештыру эшләрендә, кирәк иҗат эшләрендә, кирәк теория һәм тәнкыйть мәсьәләләрендә булсын, шулай ук әдәбият өлкәсенә яңа кадрлар җитештерү мәсьәләсендә булсын – тагы да көчлерәк, җитезерәк, батырырак адымнарын сорый.

Социализм төзелешенең бөтен фронтларында реконструкция чоры булган бүгенге чор – пролетариат әдәбияты хәрәкәтенең үзенә җавап бирерлек хәлдә булуын, аның сафларында да кирәк темп, кирәк сыйфат һәм кадрлар мәсьәләсендә, шулай ук иң беренчедән пролетариат культурасының бөтен сыйнфый дошманнарына каршы кискен көрәш мәсьәләсендә булсын – ныклы эш, каты көрәш сорый. Бу эштә һәм көрәштә татар пролетариат әдәбияты хәрәкәтенең турыдан-туры үз трибунасы булган "Атака" журналы зур урын тотарга тиешле булачак. Ләкин "Атака" журналы татар пролетариат әдәбиятының СССР-ның төрле почмакларына сибелгән бөтен көчләренең, оешмаларының ярдәме, актив булышлыклары белән генә шундый урынны ала алачак. Менә шунар күрә дә без хәзер үк Мәскәүдә, Ленинградта, Уфада, Свердловскида, Новосибирск һәм башка урыннардагы (Баку, Ташкент, Самар, Саратов, Әстерхан, Оренбур һәм башка урыннарда) татар пролетариат язучыларының оешмаларын һәм аерым көчләрен "Атака" журналына актив рәвештә катнашырга, хәзердән үк әдәби әсәрләр, мәкаләләр, тәнкыйтьләр, очерклар җибәрә башларга чакырабыз. Шулай ук "Атака" журналының чыгып барган саннары турында матбугатта тәнкыйтьләр урнаштыру, журналны масса арасына таратышу турында да сезнең ярдәмне көтеп калабыз. Сездән әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләнгән эшләр, әдәби оешмаларыгыздагы эшләр, яңа чыккан китаплар, аерым язучыларның нинди әсәрләр өстендә эшләүләре һәм башка шундый турыларда да "Атака" журналына тәртипле рәвештә хәбәр биреп торуыгызны үтенәбез.

"Атака" журналы татар пролетариат әдәбияты хәрәкәтенең уртак журналы. Аның интересы – бөтен татар пролетариат әдәбиятының интересы булачак.

Сәлам һәм үтенеч белән:
***Татарстан Пролетариат Язучылары***
***Ассоциациясенең правлениесе***
***һәм "Атака" журналы редколлегиясе.***

*1930, № 1.*

## Литфондның Татарстан бүлеге төзелде

Мәскәүдә 1924 нче елдан бирле матур әдәбият язучыларына матди ярдәм күрсәтер өчен төзелгән Үзәк әдәбият фонды (Литфонд) оешмасы яшәп килә. Анда бөтен шагыйрь, әдип, тәнкыйтьче һәм драматурглар член булып торалар. Хәзерге вакытта Ленинград, Харьков, Ростов кебек зурырак үзәкләрдә аның бүлекләре дә оештырылган. Бер Мәскәүнең үзендә генә аның 3 меңләп члены бар.

Бу Литфондның төп тәртибе түбәндәгечә:

Литфонд — турыдан-туры федерация белән бәйләнгән оешма. Литфондның төп бурычы — совет язучыларына кире кайтарылмый торган һәм вакытлы ссудалар бирү; санатория, курорт, медицина һәм башка формада ярдәмнәр күрсәтү, язучыларның бытларын (көнкүрешләрен) яхшырту — менә шул.

Ләкин хәзергә кадәр әле безнең Татарстанда андый оешма төзелгәне юк иде. Менә шуны игътибарга алып, ТАПП совет язучылары һәм яшь язучылар оешмаларының вәкилләре 5 нче октябрьдә булган җыелышта Казанда Литфондның Татарстан бүлеген оештырып җибәрүне кирәкле табып карар чыгарды һәм вакытлы правлениесен сайлап, Кави Нәҗми (председатель), М.Гали һәм И.Газый иптәшләр сайландылар.

Правление каршында өч комиссия төзелде: дәвалау комиссиясе (членнары: Кави Нәҗми, Тинчурин, Малиновский), торак комиссиясе (членнары: Ф.Сәйфи, З.Гали, М.Гали) һәм материаль ярдәм, быт комиссиясе (членнары: Ибрай Газый, Халикъ Садрый, Исмәгыйль Рәми).

Бу оешмага ТАПП членнары, татар совет язучылары оешмасы членнары һәм бу оешмаларга кермәгән советчыл язучылар алыналар. Оешмага алынганда әдип, шагыйрь, драматург һәм тәнкыйтьчеләр алда тотылалар. Хәзердән үк "Кызыл Татарстан" редакциясендә М.Гали иптәш тарафыннан заявлениеләр кабул ителә. Оешмага керүчеләр бер сум керү взносы түләргә тиешләр. Соныннан аларның айлык хезмәт хакларыннан һәм гонорарларыннан чирек процент пай взносы алына. Вакытлы правление эшкә башлады. Яшь язучы Әсфәндияров һәм С.Фәйзуллин иптәшләр Сочига курортка җибәрелделәр, байтак язучыларга матди ярдәм күрсәтелде.

*1930, № 6-7.*

## ТАПП оешмасында

### ТАППның правлениесе

ТАПП членнарының тазарту йомгагына багышланган тулай җыелышы ТАППның 15 кешелек правлениесен төзеде. Правлениегә түбәндәге иптәшләр сайландылар: Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Сәгыйть Каратай, Якупов, Исхак Еникиев, Әхәт Әхмитов, Вольфсон, Ибрай Газый, Закир Гали, Толымбайский, Алакшин, Халикъ Садрый, Теләшев, Макаров, Имаметдинов, Җиһаншина.

Шул ук җыелышта ТАППның җаваплы секретаре итеп Кави иптәш Нәҗми сайланды.

### "Атака" журналының редколлегиясе

ТАПП правлениесе "Атака" журналының редколлегиясенә Кави Нәҗми, Толымбайский, Ибрай Газый, С.Каратай, Якупов иптәшләрне сайлады.

Җ. Иртуганов

# ДОНБАССТА ТАТАР МАТУР ӘДӘБИЯТЫ

*Донбасста татар телендә чыга торган "Пролетар" гәзите системный рәвештә әдәбият сәхифәләре урнаштырып, шахтерлар арасыннан дистәләрчә яна каләмнәрне матбугатка чыгарды. Хәзер инде бу гәзит каршында татар шахтерларының әдәби оешмасы да төзелеп эшкә керешә. Бу оешманың беренче альманахы җәй актыкларында Казанда басылып чыгачак.*

Хәзерге көндә Донбасс шахталарында 40 меңгә якын татар пролетариаты социализм төзелешендә эшли. Шуларның күп өлеше авыллардан килгән вакытлы эшчеләр. Бу шахтерлар арасында башка өлкәдәге эшләр белән бер яктан культура эшләре дә үсә.

Инде шахтерлар арасында матур әдәбият эшенең үсешенә килсәк, бу өлкәдә әле эшнең йомшак баруын күрәбез.

Шахтерлар арасында әдәбият белән кызыксынып, аңар катнашырга теләүчеләрнең саны байтак кына. Ләкин моңа чаклы аларны оештырып, тиешле юлбашчылык биреп баручы юк иде. Шуңа күрә алар күренекле рәвештә күтәрелеп, үсеп китә алмадылар. ТАПП һәм МАПП татар секциясе тарафыннан конкрет рәвештә даими ярдәм булмады дәрәҗәсендә.

Хәзер Донбасста татар шахтерлары өчен татар телендә "Пролетар" гәзите чыга. Менә бу гәзит забой төпләреннән күтәрелгән яшь шахтер язучыларны үз кочагына алып тәрбияли башлады. Аларның иҗатларын үстерүдә күп ярдәм итте. Әдәбият битләрендә яшь шахтер язучыларның әсәрләренә киң урын бирелеп, тиешле тәнкыйтьләр дә булгалады.

**Менә шул "Пролетар" гәзите тирәсенә оешкан язучылардан күптән түгел генә татар пролетариат язучылары секциясе төзелде.** Ул хәзер урыннарда түгәрәкләр төзеп җитәкчелек итү эшенә керешә.

Шахтер язучыларның пролетар гәзитендә басылган әсәрләре әле художество ягыннан башлап үсү баскычында гына булса да, идеология ягыннан нык тотнаклылар, үзләренең бөтен көчләрен бүгенге көннең бурычларын – күмер планын арттырып үтәүгә юнәлдергәннәр.

Мисал өчен "Пролетар" гәзитенең 24 нче санында чыккан яна күтәрелеп килүче шахтер Ш.Халикъ иптәшнең "Үсәбез" дигән шигырен алсак, ул үз шигырендә реконструкция чорының үзәк мәсьәләләреннән булган шахталарның машиналашуын күрсәтә. Шигыренең беренче юлларын ук:

*"Шахта, синең тормыш*
*Тиз арада үсте, үзгәрде" –*

дип башлап китә. Машиналар эшләвен:

*"Конвейерлар забойда*
*Сал-сал диеп күмер ташыйлар,*
*Машиналар күмер тауларын*
*Корыч тешләр белән ашыйлар", –*

дип күрсәтә.

Гомумән, "Пролетар" гәзите забойлардан күтәрелеп килгән язучыларга төрле яктан ярдәм итә.

Ләкин безгә ТАПП һәм МАПП татар секцияләренең бик зур ярдәмнәре кирәк әле.

*1932, № 5-6.*

*"Хәзер инде бар да беткән... Донбасс татарлары өченче буында телсез, хәтерсез кавемгә әйләнеп бара"*

*Ринат Закиров (М. Галиев әнгәмәсе, 2005, №8)*

Галим
Сәгыйди

# КАВКАЗ АРТЫНДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Шәрык бусагасы булган Кавказ артында үз өлкәләрен өйрәнү һәм күршеләр белән таныша бару канәгатьләндермичә, монда Советлар Союзынын төрле жирләренә жәелгән татар әдәбиятына да урын бирелә. Соңгы елларда Бакуда һәм Тифлистә татарчадан төрекчәгә һәм русчага тәржемә ителеп, берничә әсәр басылды. Ул тәржемәләрнен һәрберсенә аерым-аерым кыйммәт *(бәя)* биреп тормыйча, аларны исәпкә ала бару йөзеннән хәзергә кадәр басылып чыккан тәржемәләр турында кыска гына библиография бирергә кирәкле дип беләбез.

Төрекчәгә тәржемә ителеп Бакуда басылган әсәрләр:

**I. ГАЛИМЖАН ИБРАҺИМОВ** әсәрләреннән

**1. "Адәмнәр".** 1927 нче елда иске әлифба белән 3 мең данә, 1928 нче елда яңа әлифба белән 2 мең данә басылды.

**2. "Картлык көннәрендә".** Гайшә Шәмсетдинова тәржемәсе. **"Кожалык гүнләрендә"** исемендә 1928 нче елда иске әлифба белән 3 мең, яңа әлифба белән 2 мең данә басылды.

**3. "Кызыл чәчәкләр"**. Хәсән Рифгатев тәржемәсе. **"Кызыл чичәкләр"** исемендә 1928 нче елда иске әлифба белән 3 мең, яңа әлифба белән 2 мең басылды.

**II. КАВИ НӘҖМИ** әсәрләреннән **"Без түзәрбез әле"** дигән парчасы **"Без һәлә дөзәрик"** исемендә "Инкыйлаб вә мәдәният" журналынын 1929 елгы N7-8 (67-68)-дә басылды.

**III. КУТУЙ** шигырьләреннән **"Пулеметчылар"** русчага Л.Кринкин тәржемәсе "Пулеметчики" исемендә "Бакинский рабочий" газитенең 1929 нчы ел 20 нче августта чыккан N193 (2957)-дә һәм **"Мөржәче"**се Бугаевский тәржемәсе "Трубочист" исемендә Тифлистә чыга торган "На рубеже Востока" журналынын 1929 елгы 4 нче санында басылды.

**IV. ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ "Татар кызы"** (Г.Сәгыйди тәржемәсе) рус телендә "Татарка" исемендә Тифлис журналларыннан "На рубеже Востока" журналынын 1929 елгы 4 нче санында басылды.

**V. М.МАКСУТның "Кызым, кычкырып көлмә!"** дигән хикәясе "Дочка, не смейся громко!" исемендә Г.Сәгыйди тарафыннан тәржемә ителеп Тифлистәге "На рубеже Востока" журналының 1929 елгы N6-7дә басылды.

Эшчеләрдән язучылар хәзерләү максаты белән Бакуда Азәрбәйжан Пролетар Язучылары Ассоциациясе янында татар әдәбияты түгәрәге оештырылып, 1929 нчы елның ахырыннан бирле эшләп килә. Түгәрәк членнары районнарда хәбәрчеләр түгәрәкләрендә дә эшләшәләр.

Түгәрәкнең эш планында татарчадан төрекчәгә һәм русчага, шулай ук төрекчәдән татарчага тәржемә эшен кустарьчылыктан чыгарып, оешкан рәвештә алып бару күздә тотыла. Анын өчен ТАПП һәм МАППның татар секциясе белән бәйләныш алып барылачак.

**Баку.**

*1930, № 1.*

## Язучылар өчен ял йорты булырга тиеш!

Партия Үзәк Комитетының әдәбият-сәнгать оешмаларын яңадан төзү турында бу елның 23 нче апрелендә чыгарган тарихи карарын Татарстан совет язучылары зур бердәмлек белән тәбрикләп каршы алдылар. Шуның белән Татарстан совет язучылары Үзәк Комитетның бу карары язучылар җәмәгатьчелеге һәм язучылар оешмасы өстенә тагын да зурырак, тагын да җаваплырак бурычлар йөкләгәнне дә кат-кат күрсәтеп үттеләр. Бу зур бурычларның берсе, һичшиксез, язучыларның, матур әдәбият-сәнгать эшчеләренең тормыш-иҗат шартларын яхшырту мәсьәләсе. Бик билгеле, тиешле иҗат шартлары булганда гына совет язучылары үзләрендә булган иҗат мөмкинлекләрен бөтен киңлеге белән җәеп җибәрә алачаклар. Ләкин соңгы вакытларга чаклы бездә бу мәсьәлә бик начар торды.

Соңгы вакытта Татиздат һәм язучылар оештыру комитеты тарафыннан Зәңгәр күл дачасында язучылар өчен оештырылган ял йорты, әлбәттә, Татарстан совет язучыларының тормыш-иҗат шартларын яхшыртуда җитди кирәкле бер адым итеп исәпләнергә тиеш. Бу эшнең моңар чаклы Татиздат тарафыннан чамадан тыш сузылып килүен дә әйтергә кирәк. Ләкин, ничек кенә булмасын, хәзер инде Татарстан совет язучыларының ял йорты шушы берничә көн эчендә ачылачак. Ачык әйтергә кирәк, әле бөтен иптәшләр дә, бөтен хуҗалык-җәмәгать оешмалары да язучыларның, сәнгать-иҗат эшчеләренең тормыш якларын яхшыртуның әһәмиятен тиешенчә үк аңлап бетерәләр дип әйтеп булмый. Моннан соң инде без бу бетәр һәм бу яңабаштан эшне – Татарстан совет язучыларының ял йортын тиешенчә куеп җибәререгә бөтен хуҗалык-җәмәгать һәм профессиональ оешмалар нык ярдәм итәрләр дип уйлыйбыз.

Язучылар оештыру комитеты: З.Гали, М.Әмир, Шапошников, Нигъмәти, Г.Гали.

*1932, № 9-10.*

---



*Бу нийт безнең көннәрдә тормышка ашты. 2004 елның апреленнән Васильевода язучылар, рәссамнар, композиторлар һәм актерларның Иҗат йорты эшли башлады.*

# «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ»

1933-65 ЕЛЛАРДА ЧЫГА




**ЖАВАПЛЫ РЕДАКТОРЛАР:**
Г. Нигъмәти (1933, N 1), К. Нәжми (1933, 2-9, 1934, 1-11, 1947, 11-1949, 4), Г. Гали (1933, 10, 1935, 1-3; 1933, 11-12—вакытлы җаваплы редактор), Г. Разин (Г. Бәширов) (1937, 6-10, 1941, 7-11, 1942, 4-6, 9-10; 1937, 3, 11, 1938, 1-2, 1945, 1-4—вакытлы җаваплы редактор; 1942, 3-җаваплы редактор өчен), Г. Иделле (1937, 4-5, 1945, 5-1947, 6 Г. Ильяс (1937, 12), Т. Имаметдинов (1938, 3-1941, 6), И. Газый (1942, 7-8 - вакытлы җаваплы редактор), Г. Кашшаф (1942, 11- 1944, 4, 1944, 10-12; 1950, 5-1958, 2—вакытлы җаваплы редактор), Х. Хәйри (1944, 5-9—вакытлы җаваплы редактор), А. Шамов (1949, 5—1950, 4—вакытлы җаваплы редактор), А. Гомәров (1958, 3—1963, 3), Г. Мөхәммәтшин (1963, 4 - 1965, 5); 1947, 7-10—редколлегия.

## Совет язучыларының Беренче Бөтен Татарстан съезды

Шушы елның 25 нче июленнән 29 нчы июленә кадәр Совет язучыларының Беренче Бөтен Татарстан съезды булып үтте. Совет язучыларының һәм, гомумән, киң совет җәмәгатьчелегенең актив катнашы белән үткән бу тарихи съезд татар совет матур әдәбиятының хәленә, үсешенә йомгак ясау белән бергә, татар совет әдәбиятының төп көчләре белән эшләү, аларның иҗат активлыкларын тагы да күтәрү, киң эшче-колхозчы массадан күтәрелеп килә торган яшь язучылар кадрын тәрбияләү, бөек социализм эпохасына тиң булырлык матур әдәбият әсәрләре тудыру һ.б. буенча киң иҗат тикшерүе үткәреп, татар совет әдбиятының алдагы үсеше юлларын билгеләде, аның перспективаларын сызып үтте.

Бу съездда татар совет әдәбияты турында ип. Г.Ризванов, проза һәм поэзия өлкәсендәге бурычлар турында ип. Гомәр Гали, татар совет драматургиясе турында Г.Нигъмәти, Р.Ишморат, К.Тинчурин иптәшләр һәм балалар әдәбияты турында ип. Ф.Кәрим докладлары тыңланды.

Съезд бу докладлар буенча фикер алышулардан соң, Татарстан Совет язучылары союзы правлениесен һәм совет язучыларының Бөтенсоюз съездына делегатлар сайлап ябылды.

• • •

Без бу санда съездның көндәлеген һәм ВКП(б) ӨК-ты секретаре иптәш Б.Абдуллинның чыгышын урнаштырып, докладларның һәм речьләрнең стенограммаларын бирүне алдагы саннарга калдырабыз.

*1934, № 7.*



Гомәр
Бәширов

# УЙЛАНУЛАР

**Мин “Совет әдәбияты” журналының моннан утыз биш еллар элек чыккан саргылт битләрен актарып утырам. Бераз моңсу, бераз сагындыра, юксындыра. Яшь вакытлар бит...**

Мина менә шушы журнал хакында мәкалә язарга кирәк. Язмасаң, яхшы түгел. Мин бит журналда җаваплы секретарь булып та, вакытлы редактор һәм җаваплы редактор булып та, сугышка кадәр дә, аннан соң да берничә мәртәбә эшләгән кеше. Аннан да бигрәк, мине матур әдәбиятка алып кергән иң беренче сукмак шушы журналда башлана. Хикәяләрем һәм “Сиваш” повесте иң беренче шушы журналда басылды. Ләкин нинди мәкалә язарга? Кайсы еллар турында?

Менә шулар хакында картларча озын, озак итеп уйланып йөргәндә, элек бер бүлмәдә, бер союзда, бер партия оешмасында эшләгән өлкән иптәшләр, бере артыннан бере, күз алдыма килә башлады. Кыюсыз гына тамак кыргалап, үзеннән кечеләр янына да, хәтта бүлмә эче шау-гөр килеп торганда да ишек шакымыйча керми торган әдәпле Шәриф абзый Камал. Калын кара портфелен култык астына кыстырган хәлдә, матбугат йортының ыгы-зыгылы озын коридорларыннан бераз бөкерәя төшеп, беркемне дә күрмичә, ашыгыч адымнар белән атлый-йөгерә узып китүче, кырысрак кыяфәтле журнал редакторы Гомәр Гали. Озынча буйлы, сангыраурак тавышлы, басынкырак холыклы профессор Галимҗан Нигъмәти...

Ләкин бу күренешләр мәкаләгә сыймыйлар бит... Шунда мин икеләнә башладым. Бәлки, мина мәкалә язмаскадыр? Ул елларда нинди әсәрләр басылган, әдәбиятта нинди карашлар, нинди көрәшләр булган? Кайсы агым җиңеп чыккан да, кайсысы җиңелеп калган? Ул хакта галимнәр язар, бусы—аларның “икмәге”. Ә мин әдәбияттагы ул агымнарга бер вакытта да артык игътибар итмичә, гомер буена талантлы исәрләрнең үзләренә, совет чынбарлыгын олы итеп сурәтли белгән язучыларына сокланып яшәгән кеше. Әдәбиятта узган кырык ел гомер мине бер нәрсәгә өйрәтте: әдәбиятта төрле юнәлешләрнең һәммәсен дә бел, әмма үзеңчә яз. Галимҗанны да, Хемингуэйне дә өйрән, ләкин барыбер үзеңчә яз! Беркайчан да көчәнмә, күңелең ни тели, шуны яз! Фәкать шул вакытта гына яхшы әсәр чыгарга мөмкин. Нәрсә бу? Очеркмы? Истәлекме? Нәрсә язылса, шул булыр.

1936 елның көзендә бер көнне иртән, шактый ук дулкынланып, матбугат йортының бишенче катына менеп киттем. Гаҗәп кызык уеннар уйный бу язмыш. Моннан дүрт-биш ел элек халык тикшерүчесе һәм халык хакиме булып эшләгәндә, кем башына китерә алган бу хәлне? Бала чактан ук матур әдәбиятка, аны иҗат итүче әдипләргә гашыйк булып яшәгән бер кеше менә хәзер “Совет әдәбияты”ның җаваплы секретаре булып менеп бара. Бу бит әдәбиятның нәкъ үзәгенә, кайнап торган казанына барып керү дигән сүз.

Минем каршымда журнал редакциясенең дәрәҗәсе һәртөрле парламентлардан да, мәһабәт сарайлардан да югарырак иде. Дулкынланудан мин шундый ихтирамга лаек оешмага ни сәбәпледер шушы биш катлы мәһабәт йортның йөз сиксән биш бүлмәсе арасыннан, юньлерәк урыныннан кинрәк бүлмә табылмавына да, аның бишенче каттагы иң кечкенә бүлмәгә сыеп калуына да артык игътибар итмәдем.

Кайбер язучыларнын безнен бүлмәне "карлыгач оясы" дип атаулары да шаярту булып кына ишетелде. Редакциядә эшли башлаган көннәрдә минем күнелемне һәрвакыт бер сөаль бимазалап торды: нииндидер гали затлар дип, бүтәннәр буе житмәслек нииндидер бөек идеаллар белән рухланып яшәүчеләр итеп күз алдына китергән әдип һәм шагыйрьләр тормышнын үзендә дә шулаймы? Галәтемчә, мин аларны артык күпертеп, идеаллаштырып жибәрмәдемме икән? Минем матур хыялларым тәтен булып очмас микән?

Дөрес, мондагы шартлар күнелдәге хыялны шактый ук шиндерде. Редакциянен бүлмәсе фәкать берәү генә. Дүртебез дә—Гомәр Гали, Хәсән Туфан, Абдулла Гомәр һәм мин—бергә жыелганда эшләве бик кыен, бөтен игътибарны кульязмага туплап булмый, килгән кешеләр белән иркенләп сөйләшергә дә мөмкинлек юк иде.

Дөрес, тиздән үк шул бүлмә эченә, редакторнын махсус үзе өчен генә, пыяла белән фанердан тагын бер бүлмә әмәлләдек. Тик ана көн яктысы керми, йомыш белән килгән кеше генә кереп чыгарлык бик тар иде. Эшләнеп бетү белән үк ул бүлмәгә "Гомәр Гали кетәге" дип шаян исем дә тактылар.

Кыскасы, мондагы шартлар хыялдагы күтәренкелеккә бик үк муафикъ түгел иде. Тик мин, күрәсен, әдәбиятнын язмышы шулайдыр инде дигән фикергә килдем. Бөтен дөньяга мәгърифәт нуры тараткан борынгы китапларнын күбесе салкын мәгарәдә язылган. Габдулла Тукайнын бөтен чорны яктырткан шигъри энжеләре бер тәрәзәле кечкенә бүлмәдә барлыкка килгән.

Әмма мине иң мавыктырганы—бу кечкенә бүлмәдәге кешеләрнең зур ваем белән яшәүләре булды. Алар һәр унышлы әсәргә генә түгел, истә калырдай һәр яна образга куанып, әдәбиятнын якты киләчәге белән рухланып яшиләр, үзләрен тормышнын вак-төягеннән өстә тоталар иде. Шушы ук рух күтәренкелеге озакламыйча мина да йокты, мин дә һәртөрле унайсызлык белән эшнең кыенлыгына игътибар итмәс булдым.

Кешеләре белән дә, аларнын алга куйган якты максатлары белән дә күнелләргә тирән булып уелып калган гажәп дәрәжәдә катлаулы да, четерекле дә бер чор иде ул. Европа өстенә фашизмнын дәһшәтле карачкысы булып дар агачлары күтәрелгән, монархы мәдәниятнең алдынгы сафы дип саналган илләрдән яндырылган китапларнын көек исе килә башлаган чак. М. Горькийнын "Кем белән сез, культура осталары?" дип бөтен дөньяга ташлаган нидасы меңнәрчә зыялыны тирән уйга салган заман иде. Болар һәммәсе дә күнелләргә шом сала, уйландыра, борчый, сугыш куркынычынын якын-тирәдә генә йөрүе дә сизелми түгел иде инде.

Шулай да без әле ул вакытта шул котелгән сугышнын прелюдиясе һәм үзе ил өстенә шундый афәт булып ябырылачагын, миллионнарча корбан сораячагын һич тә ул кадәр итеп күз алдына да китерә алмый идек.

Язучылар союзы оешканга әле күп тә үтмәгән, 1934 елда булып узган беренче съездда матур әдәбиятнын киләчәгенә якты ишекләр ачылганнан сон язучыларнын һәрберсе үзен тулы хокуклы ижат кешесе итеп хис кыла иде. Кыскасы, тормышнын, көнкүрешнең төрле кыенлыклары чыгып торса да, без якты идеаллар белән яши идек.

Шулай да Шәриф абзыйнын 1936 елдагы бер тәнбиһен соңыннан гыйбрәтле бер хәл итеп күп мәртәбәләр хәтергә алгаладым. Шулай, һәрвакыттагыча, әдәпле генә килеп керде дә, сәламәтлек сорашып, озак кына күзләгән сөртеп, тамагын кыргалап алганнан сон "Гомәр Гали иптәш"нең кайдалыгын сорашты. Ул булмагач, мина мөрәжәгать итте. Журналда кайбер зат алмашлыклары зур хәрефтән киткән икән дә Шәриф абыйга шул ошамаган икән.

—Сез беләсездер, Гомәр иптәш, секретарь булгач, тел гыйльмендә андый кагыйдә юк бит.

—Әйе, беләм, Шәриф абзый...

—Шулайдыр, элек, мәсәлән, динчеләр алланы гына шулай зур хәрефтән язалар иде. Ходай тәгаләне генә... Анда да һәммә диндә дә түгел. Бу мина бик гажәп тоелды. Нигә хәзер дә шул искелекне кулланасыз икән?

Ул журналнын типографиядә мина кадәр үк жиелуын әйтергә, акланырга мөмкин иде. Ләкин мин акланырга унайсызландым. Анын мәгънәсе дә юк иде. Чөнки ул елларда аерым кешеләрне күкләргә чөю, аларга мәдхия уку галәте зат алмашлык-

ларын дөрес язу белән генә тукталачак түгел иде. Әмма Шәриф абзыйның әдәбиятта булсын, тормышта булсын, гомумән, мактау, мактануны җене сөйми, шунлыктан аның кинәшен игътибарсыз калдыру да мөмкин түгел иде. Мин аңа киләчәктә мондый хатаны берничек тә җибәрмәскә вәгъдә иттем. Әмма үзем бу сүзләремнең гамәлгә ашачагына бик үк ышанмый идем.

Шәриф абзый, журналда үз әсәрләрен бастырудан тыш, Казандагы иң өлкән һәм иң зур стажлы коммунист язучылардан, мөхтәрәм әдипләрдән берсе буларак (ул вакытта Галимҗан Ибраһимов Ялтада яши иде), редакция эшенә кинәшләре, рецензияләре белән дә якыннан катнашып килде. Редакция утырышына ул үзенең кайсыдыр юбилеенда бүләк ителгән әйбәт ак фетрын киеп, галстуклар тагып, гомумән, чакырылган мәҗлескә баргандагыдай, пөхтә киенеп, нәкъ вакытында килеп җитә дә бик әдәп белән тыңлап кына утыра иде. Әмма әгәр дә әдәби кыйммәте шикле булган берәр әсәрне журналга кертергә тәкъдим итүче булса, ул шунда ук кискен телле тәнкыйтьчегә әверелеп китә. Шәриф абзый кемнең дә булса хәтерен саклау дигән әйләнеч юлларны белми, ул гаделлек һәм чын хакыйкать кешесе иде.

Ул елларда журналны һәм, гомумән, татар совет әдәбиятын әйдәп баручылар журналның җаваплы редакторы Гомәр Гали, редколлегия членнары Галимҗан Нигъмәти, Гумир Толымбай (кайберәүләр язганча, Гомәр түгел), Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗми, Шәриф Камал булдылар.

Кәрим абзый Тинчурин барлык көчен, дәртен һәм зур иҗат талантын Татар академия театрына, үз әсәрләрен язуга сарыф иткәнлектән, пьесаларны укудан башкага вакыт таба алмый иде. Әмма бүтән жанрдагы әсәрләрнең язмышын хәл кылган вакытларда да Кәрим абзый беркайчан битараф калмады. Әсәрнең журналда басылырга тиешлегенә тәмам ышанып җиткәннән соң гына ул үзенең “мәслихәтен” әйтеп куяр иде.

Редактордан кала, минем аеруча игътибарымны җәлеп итүчеләрдән тагын берсе—профессор Галимҗан Нигъмәти булды. Бу хөрмәтле кешене мин редакциягә килгәнче үк беркадәр белә идем инде. Чөнки “Сиваш” повестен язган вакытта без аның белән Васильево ял йортында бергә булдык. Повестьның аерым бүлекләрен, бик дулкынланып, дөресен генә әйткәндә, шактый ук шүрләп һәм каушап, язучылардан иң беренче мин аңа укыдым. Үз көченә ышанып җитмәс борын әсәренне әдәбият профессоры хөкеменә китереп салу һич тә уен эш түгел ул. Дөрес, профессор, үзенең холкына хас рәвештә, минем әсәремне күккә чөеп мактамады. Әмма мин аның күз карашыннан, кайбер урыннарны укыганда, нәрсәнедер язып алырга омтылгандай, өстәлгә үрелеп куюыннан, бигрәк тә мәзәк кенә итеп иннәрен җыергалап алуыннан әсәрне ошатуын сиздем. Ул вакытта монысы да бик зур шатлык иде.

Ә инде кич белән наратлар арасындагы тар сукмакта сөйләшеп йөргәндә профессор миңа дөньяда иң яхшы күңелле, иң галим, иң изге кеше булып күренә башлады. Чөнки ул минем әсәремне гражданнар сугышы турында язылган башка кайбер китаплар белән чагыштырып, берничә җылы сүз әйтте. Яшь язучыны шуннан да зуррак тагын нинди бүләк күтәргә мөмкин?

Ана кадәр Галимҗан Нигъмәти безгә, бер төркем язучыларга, марксизм-ленинизм институтында укыган елларда, кичләрен әдәбияттан лекцияләр укып китүе белән дә бик истә калган иде. Шулай ук аның әдәбият мәсьәләләрен яктырткан мәкалә һәм китапларын заманында кем генә укымый калды икән? Редакциядә эшли башлагач, минем Г. Нигъмәтигә ихтирамым тагын да артты.

Журнал эшенә әсәрләре һәм кинәшләре белән иң актив катнашучылардан тагын берсе Толымбай булды. Зур, таза бәдәнле, төрпә телле бу кеше, күбесенчә ирония белән сөйләшеп, һәрвакыт нәрсәдәндер, кемнәндер көләр иде. Ифрат эшлекле, хәрәкәтчән кеше Толымбай. Бер үк вакытта ул авыл тормышыннан хикәяләр дә, әдәбият тарихыннан мәкаләләр дә, гыйльми хезмәтләр, рецензияләр дә яза, җыелышларда җаваплы докладлар белән чыгарга да, халык иҗатын җыярга да һәм аны матбугатта чыгарырга да өлгерә, гомумән, ул тик торуны белми, аның көче һәм иҗат дәрте ташып тора иде. Толымбай мине яшьләй үк катлаулы тормыш юлы узуы, бигрәк тә кыю холыклы булуы белән кызыксындырган иде. Ул уналты яшендә Петербурда извозчик булып эшләгән, унтугыз яшендә партия сафына алынган,

гражданнар сугышына ирекле булып киткән кеше. Толымбай, үзлегеннән укып, заманы өчен зур белем алган, Язучылар союзы идарәсендә, гажурда, китап нәшриятында җаваплы эшләр башкарган, ТКУда, пединститутта укыткан галим һәм язучы. Ниһаять, Мәскәүдә кызыл профессура институтын тәмамлап профессор исемен алып кайтканнан соң марксизм-ленинизм институтында һәм педагогия институтында яна көч, яна дәрт белән тагын әдәбият укытырга керешкән иде.

Г. Толымбайның әдәби язмышы миндә бер үк вакытта кызгану һәм гаҗәпләнү хисе уята. Таланты һәм гаҗәеп эшчәнлеге белән заманында беренче биш язучы исәбендә йөргән, барлы-юклы унбер-унике еллык иҗат гомере эчендә утыз биштән артык китап чыгарган бу галим һәм әдип әдәбиятта нигә сизелерлек эз калдырмады? Ничек ул шул кадәр тиз онытылып өлгерде? Аның әсәрләре вакыт сынавын үтә алмаслык сыек, зәгыйфь булды163лармы? Әллә алар ясалма иделәрме? Бәлки, шулайдыр? Ихтимал, Толымбайның сулагай якка кизәнүен, Фатих Әмирханны тартып-сузып һәм көчәнеп буржуаз язучысы ясавын, чамадан тыш кызарып китеп, телне сыйныфларга бүлеп ташлавын тарих гафу итә алмагандыр? Ихтимал, шулайдыр. Бу бик гыйбрәтле хәл. Һәм, минемчә, җентекләп өйрәнелергә тиешле мәсьәлә. Әдәбиятның һәм сәнгатьнең халык һәм ил тормышы белән табигый рәвештә үрелеп үсеше юлына, халыкның табигый мәнфәгатьләренә каршы нинди киртәләр өелмәсен, нинди генә ясалма буалар корылмасын, иртәме-соңмы иҗтимагый яшәеш хакыйкате аларны барыбер җимерә, барыбер үзенең табигый агымы белән китә. Бу бик тә гыйбрәтле сабак.

Мин журналда эшләгән вакытта исә Г. Толымбай редколлегиянең иң актив членнарыннан берсе иде.

Бу танылган әдип һәм галимнәрнең редколлегия утырышында теге яки бу әсәргә мөнәсәбәтләрен мин бер үк вакытта минем әдәби зәвыгыма имтихан итеп тә аңлый идем. Чөнки кульязмаларның күбесен редколлегия утырышына, журналның җаваплы секретаре буларак, мин хәзерли идем.

Шундый бер хәл бик нык истә калган. Янарак вакытта мин журналның кайсыдыр санына кемнеңдер чаңгы шуу хакында яна шигырен тәкъдим иттем, шигырьнең басылачагына җитди шигем булмаганлыктан, аның бик оригиналь булуын, җинел укыла торган матур шигырь икәнлеген дә әйтеп салдым. Хәзер ул шигырьнең кемнеке икәнлеген дә, исемен дә хәтерләмим. Әмма ул утырыштан алган сабак әле дә булса бик нык күңелдә калган.

Шигырьне яңадан укып чыкканнан соң, башта "һем" дигәләп, бер-берсенең кылын тарткалап байтак вакыт сүзсез генә утырдылар да, ниһаять, тора-бара, бөтенләй ачылып киттеләр. Сөйләшә торгач, мин тәкъдим иткән шигырьнең, бичараның, итен иткә, сөяген сөяккә аерып ташладылар да, аны бөтенләй оныттылар. Ул да түгел, хәзерге шигырьдә заман сулышының ничек чагылуы, аның интонациясе, андагы эчке байлык, гармония, фәлсәфи тирәнлекләргә кереп киттеләр, тагын әллә нәрсәләр кузгаттылар. Редактор өстәле артында әле Гомәр Галинең җанланган йөзе, елтыраган зәңгәр күзләре күренеп китә, әле Г. Нигъмәтинең саңгырау тавышы ишетелә. Ул да түгел, "ничек әйтергә мөмкин?" дип, Гомәр Хәям дип, Хәсән Туфан сөйли башлый. Аны тыңлап та бетермәстән, каударланып торып китә дә Г. Толымбай үз фикерен куәтли. Мин тәкъдим иткән шигырьне әдәпле генә, рәнҗетмичә шаяртып кына кире кагуларына да кимсенмим. Менә хәзер зуррак мәсьәлә дулкынландыра башлаган иде. Менә нәрсә икән бит ул чын шигырь! Мин шунда шигъриятнең берникадәр аристократия сыйфатлары барлыгын да, аның тел белән әйтеп булмастай гаҗәеп хасыятьләре, тылсымлы көче, монарчы күңелнең әллә кайсы яшерен бер урыны белән сиземләп кенә йөргән күкләргә күтәрү, яисә күз яше китерү дәрәҗәсендә дулкынландыру сәләтен, аларның сәбәбен дә беренче мәртәбә тирәнрәк итеп, бәлки, шунда төшенгәнмен.

Икенче бер кичне Мирсәй Әмирнең шул елны гына чыккан "Агыйдел" повесте хакында да истә калырдай кызыклы һәм ялкынлы әңгәмә булып алды. Ни сәбәпле бу әсәрне яшьләр куллан төшермичә укыйлар? Нәрсәдә аның көче? Ул повесть әдәбиятка нинди яңалыклар өстәде?

Бик тә кызык һәм файдалы иде мондый әңгәмәләрне тыңлавы. Андый утырыш-

лар эштән соң кичен генә уздырылып (чөнки редколлегия членнары кайда булса да эшлиләр иде), бик соң тәмамланганлыктан, ахырга таба һәммәбез дә ачыккан һәм арыган була идек. Шулай да төнлә белән япа-ялгыз Акком асты урамындагы кечкенә бүлмәмә кайтып барганда мин үземне дөньяның иң бәхетле кешесе итеп, жиде кат күктә итеп хис кылам. Чөнки мине нindидер гажәеп тирән һәм нәзакәтле нечкә хисләр дулкынландыра, моннан соң минем тагын да тирәнрәк мәгънәле, тагын да нәфисрәк, яхшырак итеп язарга көчем житәчәгенә ышанычым артканнан-арта бара, болар мине канатландыра иде. Әйтәчәкмен мин аларны, әйтәчәкмен, һичшиксез! Менә хәзер утыз биш ел вакыт узып, тормыш безне дәһшәтле сугышлары белән дә, башка фажигаләре белән дә төрлечә сынап караганнан соң, үземә дә житмеш тулып киткәч, күнелем белән янадан шул вакыйгаларга әйләнеп кайтам. Күптән үк безнең икенче туган өебезгә әверелгән шул матбугат йортының шау-шулы коридорларында да, эшлекле кабинетларында да туктамастан, мондагы йөз сиксән биш бүлмәнең иң гадиенә, әлеге "карлыгач оясы"на күтәреләм. Өстәл лампасының сүрән яктысы тирәсендә кич буе дөньяларын онытып бәхәсләшеп утыручы ул фидакарь кешеләр, аларның кайнар бәхәсләре янадан исемә төшә. Шунда башыма ап-ачык булып бер нәрсә килә. Алар, минемчә, бер-берсе белән шундый кайнар бәхәс ачып, хакыйкать эзләгәннәр, беренче съездан соң колачын тагын да кинрәк жәя башлаган яшь совет әдәбиятының яна казанышларын һәм төп кимчелекләрен тирәнрәк белеп, барысын да күреп торырга, шул хакта фикерләрен чарларга, иң дөрес юл сайларга тырышканнар. Чөнки ВКП(б) Үзәк Комитетының матур әдәбият хакындагы мәгълүм карарларын гамәлгә ашырганда, бер яктан, искелекнең кирәкмәс калдыкларыннан арына барырга кирәк булса, икенче яктан, янаның ничек үсәргә тиешлеген алдан ук күрә белергә кирәк иде бит. Шоп-шома такыр юлны берәү дә хәзерләп куймаган иде.

Журнал редакторы Г. Гали белән профессор Г. Нигъмәти әдәби хәрәкәтнең башында торучы күренекле галимнәр буларак, партия карарларын тормышка ашыруда зур тырышлык һәм принципиальлек күрсәттеләр, әдәбиятның үсешенә тоткарлык итә торган натурализм, формализм кебек зарарлы агымнарга каршы аяусыз көрәшеп килделәр. Аларның авторитеты ифрат зур иде. Әгәр язучылар жыелышында чыгулары көтелсә, зал һәрвакыт тулы була, аларның чыгышлары әдәбиятта житди бер вакыйгага әверелә, чөнки алар әдәбиятның һәрвакыт житди мәсьәләләрен күтәреп чыгаралар, яна фикер әйтәләр иде.

Г. Галинең безнең әдәбиятыбызга нинди таләпләр куюын бераз гына булса да күз алдына китерү өчен, аның 1936 елда булган бер жыелышта формализмга каршы юнәлтелгән чыгышыннан бер өзек китерүне кирәк саныйм:

"Безнең социалистик матур әдәбиятыбыз иң югары идеяле, үзенең формасы белән иң бай, иң матур әдәбият булырга тиеш. Шуның белән бергә, аның бу байлыгының, бу матурлыгының нигезендә халыкчыллык булырга, бу байлык һәм матурлык хезмәт халкы йөрәге белән тоташкан булырга тиеш"[1].

Минемчә, ифрат дөрес, жыйнак һәм матур әйтелгән. Ул вакыт өчен бу кечкенә эш түгел. Минемчә, бу фикер астына әле хәзер дә теләсә кайсы фәннәр докторы бик теләп имзасын куяр иде.

1937—38 елларга кадәр жыелышларда кәгазьгә карап сөйләү гадәте юк иде. Шунлыктан бу галимнәрнең күп чыгышлары бер жирдә дә теркәлмәгән. Шулай да Гомәр Галинең редколлегия утырышында яисә жыелышларда әйткән кайбер фикерләре, тирән мәгънәле афоризмнар кебек, әле хәзер дә онытылмый.

Журналда актив эшләү, гомумән, матур әдәбиятта әйдәп баручылар булу белән бергә, Г. Нигъмәти Казан дәүләт педагогия институтының профессоры, Г. Гали медицина институтында татар филологиясе доценты, ягъни педагоглар буларак та зур эшчәнлек күрсәттеләр. Алар әдәбиятка бөтен көчләрен, сәләтләрен бирделәр, үз өсләренә йөкләтелгән вазифаның катлаулы һәм хөрмәтлелеген тирән аңлап, халык һәм партия каршында үзләрен жаваплы санап эш иттеләр. Г. Нигъмәти житәкчелек иткән елларда педагогия институтында М. Мамин, Я. Агишев, Х. Ярми, Ж. Вәзиева кебек әдәбият

[1] "Совет әдәбияты" журналы, 1936 ел, 4 сан.

галимнәре хәзерләнеп чыкты. Г. Нигъмәтинен шәкертләре хәзер фән докторлары булдылар. Күренекле шагыйрь Сибгат Хәким һәм башка кайбер әдәбият әһелләре— шушы профессордан дәрес алган кешеләр. Ул елларда педагогия институтында яшь язучылар, яшь галимнәрне үзләренә җәлеп иткән әдәбият түгәрәкләре, семинарлар һәрвакыт эшли, институт болар белән гөрләп тора торган иде.

Журнал редакциясендә эшләгәндә элек әсәрләре белән таныш булган әдипләрнен үзләре белән очрашу миндә ифрат бер тирән кызыксыну уята торган иде. Чөнки автор турында әсәрен укыганнан сон туган фикерен белән анын үзен күргәч калдырган тәэсир кайвакыт бөтенләй туры килми торган була. Мәхмүт Галәүнен шул елларда чыккан мәшһүр әсәрләрен укыгач, мин аны зур талант иясе дип таныдым. Журналнын 1936 елгы бишенче санында Габдулла Тукайга илле яшь тулу унае белән язган кыска гына истәлеге бу фикеремне тагын да куәтләбрәк җибәрде. Г. Тукай турында язылган истәлекләрнен күбесендә анын йомыграк холыклы, шәкерт сыман кыюсызрак кеше булуына басым ясыйлар да анын әсәрләреннән алган тәэссорат белән шәхесе арасында зур аерма килеп чыга торган иде. М. Галәү шушы өч битлек истәлегендә Тукайның истә калырдай җанлы образын бирә алган, анын гадилегендә бөеклеген күрергә мөмкинлек тудырган иде.

Мәхмүт Галәү Мәскәүдә яшәсә дә, Казанда еш булгалый, килгән саен безнен редакциягә кермичә китми торган иде. Бу килүендә журналга нинди кульязма тәкъдим итүе хәзер исемдә калмаган. Ләкин килеп керүе белән үк ул миндә бик яхшы тәэсир тудырды. Ул да Казан артыннан, Ташкичү авылыннан булганлыктан, мин анын белән аеруча кызыксындым.

М. Галәү мәһабәт гәүдәле, кап-кара куе чәчле, каратут йөзле, бик пөхтә киенгән, ачык чырайлы, яхшы мөгамәләле кеше иде. Редактор үзенен бүлмәсендә юк иде шикелле. Сөйләшә торгач, кунакнын минем якка карап елмаюына игътибар иттем. Мина уңайсыз булып китте.

—Сезгә нәрсәдер мәзәк тоела, ахрысы?—дидем.

—Гаҗәеп бер совпадение, мин дә, нәкъ сезнен кебек, кул астына чиста кәгазь куеп язам. Әйбәт гадәт ул.

—Шулай дисезме? Рәхмәт инде, алайса.—Ул тагын көлеп куйды.

—Ни сәбәпле шулай димәкче булам? Чөнки алай язганда күнелен тыныч була. Пакь кәгазьгә гел саф фикерләр генә төшереп барам дип ышанасын. Шөбһәләнмичә язасын!

Мәскәү интеллигентынын шушы гади генә бер нәрсәгә мондый тирән мәгънә бирүе мина бик ошады, кәефне күтәреп җибәрде. Минем исә андый нечкәлекләр башыма да килгәне юк. Чиста кәгазьгә пөхтә итеп язуны тормыш үзе таләп итә иде. Чөнки редакциянен үз машинисткасы булмаганлыктан, кайбер материалларны без типографиягә кулдан язган килеш кенә төшереп бирә идек. Кульязман пөхтә булмаса, аннан кире менгерәләр. Фәкать шул гына.

Ул арада редактор кайтып керде дә безнен әнгәмә өзелде. Г. Гали яныннан чыкканда кунагыбыз каранғы чырайлы иде. Ул вакытта мин анын сәбәбен төпченмәдем, болай гына чамаладым. М. Галәү заманында "Кармак" исемле юмористик журнал чыгарган, нәширлек белән дә шөгыльләнгән, халык арасында мәгърифәт тарату максаты белән, аз-маз китаплар да саткалаган, диләр иде. Г. Гали исә, сыйнфый мәсьәләләргә бик сизгер һәм житди караучы ифрат туры коммунист булу сәбәпле, язучынын кайчандыр чит сыйныф әһелләренә хас эш белән шөгыльләнүен гафу итә алмагандыр, күрәсен.

Журналга язышучылардан Фатих Сәйфи-Казанлыда да кием-салымда пөхтәлек ягыннан М. Галәүгә охшашлык бар иде. Ул да шулай ук теләсә нинди шартларда да пөхтә киенеп йөри, мөстәкыйль фикерле, хөр күнелле кеше буларак, хәтта кызу бәхәс вакытларында да үзенен тәрбияле интеллигент икәнлеген беркайчан да онытмый, үзен ифрат горур тота иде.

Ул елларда хикәяләр, повестьлар бик аз языла иде. Журналнын киләчәк саннарында басарга хикәя булмау сәбәпле, башка язучылардан үтенгән кебек, Ф. Сәйфи-Казанлыга да мөрәҗәгать итәргә тиеш идем. Матбугат йортында берничә мәртәбә очраткаласам да, башта мин ана үтенечемне әйтергә кыенсыныбрак йөрдем.

Моның сәбәбе шул, берәр ел чамасы элек аның "Корби иптәш" дигән повесте тикшерелгәндә, кызулык белән фикеремне тупасрак, кискенрәк итеп әйтеп ташлавымны сизеп калган идем. Җыелышка житәкчелек итүче Г. Толымбай нинди усал телле, турыдан яра торган кеше инде. Бу чыгышымны хәтта ул да ошатмады. Эш шунда иде ки, Ф. Сәйфи-Казанлының элегрәк язган хикәяләреннән "Крушниклар" дигәненен аеруча яратып укыганлыктан, аның авторына ихтирамым бик зур иде. Грузчиклар эшенең кыенлыгын, аның нечкәлекләрен шул кадәр тирәнтен белеп, шундый тетрәткеч итеп язарга кирәк бит! Миндә хәтта ул кайчандыр үзе дә грузчик булып эшләмәде микән дигән фикер дә туган иде. Шуның өстенә хикәянең минем якташларым—Арча ягындагы Кәче егетләре тормышыннан алып язылган булуы да мине бик дулкынландырган иде...

Менә шундый талантлы әсәрнең авторы, минемчә, "Корби иптәш" дигән озын хикәясендә үзенә-үзе хыянәт иткән кебек тоелды. Минем карашымча, бу әсәрен язганда ул бөтен иҗат көчен файдаланмаган, күзгә бәрелеп торырдай тупас кимчелекләр җибәргән кебек иде.

Әмма соңыннан шушы кискенлегем өчен мин үземне байтак вакытлар шелтәләп йөрдем. Бу чыгышым күңелемдә җинел холыклы кешеләргә хас бер дорфалык булып уелып калды. Чыннан да үкенерлек бар иде шул. Ф. Сәйфи-Казанлы революциягә кадәр үк теоретик мәкаләләр язып чыгучы, югары уку йортларында дәрес бирүче күренекле тарихчы, әдәбиятчы, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе булып танылган илле яшьләрдәге мөхтәрәм бер кеше иде. Ә мин кем? Әле монарчы әдәбиятка бер житди әсәр дә бирмәгән, әдәбият дөньясында үзен бер яктан да чынлап торып танытмаган кечерәк кенә бер язучы кисәге...

Көтә торгач, Фатих абзый бер көнне кичкә таба редакциягә үзе килеп керде. Калын тавышы белән бөтен бүлмәне тутырып:

—Уф, редакцияне тагын да берничә кат өскәрәк күтәрә алмадыгызмы соң?— диде.

—Әле һаман да тиешле югарылыкка менеп житмәгәнмени?—дидем.

Әйбәт пальтосын ишек янындагы урындыкка салып элде дә ап-ак күлмәк якасын һәм шәп галстугын бүлмә пыяласына карап төзәтеп алды.

—Яна сәркатипмени? Бик хуп,—диде, исәнләште дә, Г. Галинең күрше бүлмәдән керүен көтеп, түргә барып утырды. Журналның җәйге саннарында аның "Зөбәрҗәт" исемле яна драмасы басылган иде, шуңа бәйләнешле хатлар юкмы, дип сорады.

Ул үзе сүз башлагач, мине борчыган әлеге мәсьәләгә киная ясаргамы, юкмы дип баш ватарга туры килмәде. Чөнки бу мөгътәбәр язучының кайчандыр, кемдер тарафыннан эшләнгән очраклы бер дорфалык өчен кинә тотучы вак кеше түгеллеген шунда ук аңладым. Чыраеның әледән-әле карангыланып китүенә, тынгысызлануына караганда, аны нидер борчый, ул редактор янына да нинди дә булса житди бер мәсьәлә хакында сөйләшергә яки бәхәсләшергә килгән иде булса кирәк. Ф. Сәйфи-Казанлы бәхәсләшмичә генә үз фикереннән кайта торган кеше түгел иде.

Минем үтенечемне ул хуплап каршы алды.

—Бар минем, бар журналга бирәсе әсәрләрем. Ләкин тәмамларга вакыт житми. Вакыт кисә муенны,—диде.

Тик шул вакыт бүлмәгә бернинди талант әсәре булмаса да төрле астыртын һәм әшәкелек сукмаклары белән әдәбиятка борынын тыгарга йөрүче бер җәнҗалчы килеп керде. Аның Фатих абзый әсәрләрендә дә казынганы бар, соңгы айларда җыелышларда да тел тидергәли башлаган иде. Фатих абзый кинәт торып басты да ишеккә таба китте. Теге кешегә карамыйча гына, шактый ук кырыс тонда:

—Гомәр кайтса әйтегез, мин союзда булырмын!—диде, пальтосын иненә салып чыгып та китте.

Әмма вәгъдә иткән әсәрен тәмамлап бирә алмый калды. Редакциягә бүтән килгәне булмады.

Аннан сон күп вакытлар үтте инде—утыз биш ел! Яшь чакларым яңадан күз алдыма килүгә дулкынланып, мин саргайган журнал битләрен актарам. Заманында татар совет әдәбиятын төпкә җигелеп сөйрәгән, шәхси мәнфәгатьләрен әдәбият наменә фида кылган, һәр талантлы әсәр өчен куанып, әдәбияттагы һәр кимчелек

өчен борчылып яшәгән ул фидакарь затлар күбесе юк инде. Бераз монсу, юксындыра, сагындыра.

Әмма шул ук вакытта күнелдә горурлык хисе дә уяна. Алар белән эшләвем бәхет булган икән. Минем бала чак хыялым ялгышмаган булып чыкты. Шунча еллар үтеп, тормышның шундый рәхимсез сынауларын узганнан соң да алар һаман да халык бәхете, туган ил, коммунистик идеаллар өчен көрәшүче фидакарь көрәшчеләр, чын коммунистлар булып калдылар. Гадел тарих аларны янәдан үз урыннарына кайтарды.

Әгәр мин үз гомеремдә әдәбиятка нидер бирә алган булсам, минем хезмәтләремдә бу затларның да өлеше бар.

Уйлана-уйлана журнал битләрен актарам... Шул саргайган битләр аша каршыма үрә басып торган каты кара чәчле, каратут йөзле, көләч күзле, хәрәкәтчән Фатих Кәрим килеп баса. 1936 елның соңгы саны чыгар алдыннан атнасына ничә мәртәбә генә кереп чыкмады икән ул! "Аникин" исемле поэмасының басылып чыгуын ул балаларча түземсезлек һәм шатлык белән көтеп алды.

—Журнал кайчан чыга? Ничегрәк чыга? Журналда поэма ничә бит булды икән?..

Поэманың иң соңгы юлларын ул болай тәмамлаган иде.

*Мин үзем дә батырларның юлын*
*Хыялымнан бик еш үткәрәм.*
*Алар биргән тойгы-ялкыннарын*
*Факел итеп өскә күтәрәм.*

Шагыйрьнең пәйгамбәрлеге, бервакыт килеп, хакыйкатькә әверелде. Шул факелны бөтен иҗаты буенча балкытып алып барды да, ниһаять, ул аны халыклар азатлыгы өчен барган изге сугыш мәйданында, мәңге сүнмәстәй итеп, немец җирендә кабындырып калдырды.

Күзләрем журналда, ә күңелем ерактагы шул юллардан безнең заманга сузылгач тагын шундый иҗат җепләрен эзли.

Журналның 1937 елгы 11 санында яшь шагыйрь Сибгат Хәкимнең зур әдәбият дөньясына аяк басканда иҗат ителгән "Йөрәккә язылган исем" дигән лирик шигыре бар.

*Алмагачлар чәчәк атты инде,*
*Яшел кием киде топольләр.*
*Салмак кына җилпеп канатларын*
*Кыр казлары җырлап үттеләр...—*

ди ул анда. Күптән түгел шагыйрьгә алтмыш тулды, аның күкрәгендә хәзер Ленин ордены балкый. Киек казлардан да өскәрәк күтәрелеп, хәзер бөтен ил өстендә яңгырый торган иркен сулышлы, киң канатлы шигъри аһәңе аның да башта журнал битләреннән күтәрелеп киткән иде бит.

Шул ук елда яшь язучы Габдрахман Әпсәләмовның журналда "Маһинур" дигән беренче хикәясе басылды. Хәзер ул 6—7 роман авторы, бөтен Советлар Союзына танылган мәшһүр язучы. Нинди сикереш! Нинди адымнар!

Әгәр хәзер әдәбият дөньясында берсеннән-берсе яхшы әсәрләр пәйда була икән, әгәр безнең әдәбиятыбыз тагын да югарырак баскычка күтәрелгән икән, бу күтәрелештә журналның да өлеше зур. "Казан утлары"н безнең әдәби әсәрләребезнең беренче бишеге дип атарга мөмкин. Чөнки нигезсез йорт, баганасыз капка була алмый. Орлык чәчелмәгән кысыр туфрактан берни дә тишелми.

Халыкның һәм аның әдәбиятының тарихын, аның көрәш юлын никадәр яхшырак белсәң, алга таба шул кадәр ышанычлырак атлыйсың. "Казан утлары" татар әдәбиятының йөзләрчә еллар элек үк башланып киткән гуманистлык, халыкчанлык кебек яхшы сыйфатларын өзлексез дәвам иттерде, аларны эстафета рәвешендә буыннан-буынга тапшырып килде.

Журналның киләчәге тагын да матуррак, барыр юлы яктырак, адымнары тагын да үрчемлерәк һәм кыюрак булсын!

*Казан утлары, 1972, № 4*

* * *



Ни гажәп, Сибгат Хәким иҗатына хас лиризм "кызыл шигърият" заманында да бәяләнгән. "С. Хәким лирикасының ясалмасыз, чын күңелдәнлекле, саф хиссиятле булуын беркем дә инкар итмәс дип уйлыйм. Аның лирикасы безнең күңелгә якын, ул безгә поэтик ләззәт бирә". (Х. Хәйри, 1940, № 1-2). *Хәз.*

# Сибгат Хәким

## I

*Еш кына искә алам мин*
*Туган авылны,—*
*Яшьлекнең серле төннәре*
*Шунда агылды.*
*Җәйге таң авыл өстендә*
*Сызылып килгәндә,*
*Гармонның моңы сибелде*
*Тыныч өйләргә.*
*Тыңладыңмы син ул җырны*
*Йокы аралаш,*
*Тордыңмы син, сиздермичә,*
*Түзә алмагач.*
*Көчердеңме без килер дип*
*Тәрәз гөлеңне,*
*Күтәрдеңме, күрермен дип*
*Ап-ак өлгеңне.*
*Төшмәдек сезгә табан без*
*Урам чатыннан.*
*Таралдык чыклар эченнән,*
*Ындыр артыннан...*
*Аннан бирле беләсеңме,*
*Күпме ел үтте,*
*Ләкин ул көннәр йөрәкне*
*Кабат җилкетте.*
*Ул чагында кем уйлаган,*
*Яр булырсың дип.*
*Тормышка бергә керерлек*
*Пар булырсың дип.*

*"Гомер яңа башлана" дигән шигырьдән. 1939, № 10-11.*

*Журналыбыз турында*

**Сибгат Хәким:**

***—Моннан соң да әдәбиятка яшь талантлар килер, моннан соң да әдәбиятыбызның көзгесе булган «Казан утлары»нда аларның әсәрләре басыла торыр. Безгә хәтле булган буын—зур буын, аның борынгыдан килгән зур традициясе бар. Шушы традицияне, зур традицияне яшьләр киләчәккә алып барсын, югалтмасын иде. «Казан утлары» аларга олы мәйдан.***

*1982 ел.*

## Халык дошманнарының һәм аларның калдыкларының йөзен ахырынача ачарга!

**Шушы елның 28 нче апрелендә башланып 5 нче майга кадәр сузылган Татарстан совет язучылары җыелышы Татарстан совет язучылары союзының тормышында борылыш җыелышы булды.**

Җыелышны ачып җибәрүче Ләбиб Гыйльми иптәш Партиянең Татарстан Өлкә Комитетының карарын игълан итеп, җыелышның зур әһәмиятле булуын ачык итеп әйтте. Татарстан совет язучылары союзының эшен тикшерү өчен Партия Өлкә Комитеты тарафыннан төзелгән комиссиянең председателе иптәш Имаметдинов үзенең докладында союз эшендә булган житешсез якларны тулысы белән ачып салды. (Бу доклад "Совет әдәбияты"ның 4 нче номерында басылды).

Татарстан совет язучылары союзы халыкның кабәхәт дошманнары өчен җылы оя булып әверелгән. Бу дошманнар союз җитәкчелегенә үрмәләп, турыдан-туры корткычлык, астыртын җимерү эше алып барганнар. Союз җитәкчелеге, аерым алганда правление председателе К.Нәжми, боларны күрмәү генә түгел, ә бу халык дошманнарына корткычлык эше алып бару өчен мораль һәм материаль ярдәм итеп килгәннәр.

Татарстан совет язучылары союзы җитәкчелегенә үрмәләгән милләтче-троцкийчы элементлар турында югарыдан да һәм түбәннән дә сигналлар булуга карамастан, союз җитәкчелеге, аерым алганда правление председателе К.Нәжми, бу сигналга аңлы рәвештә саботаж ясап килгәннәр. Алай гына да түгел, ВКП(б) Өлкә Комитетының 1936 елның 27 октябрендә, Татарстан совет язучылары союзы эше турында чыгарган карарын да үтәмәү өчен саботажлык юлына басканнар.

Халык дошманы Ф.Сәйфинең кабәхәт милләтче булуы ягыннан битлеге 1935 елда ук ертыла. Союз җитәкчелеге моннан тиешле нәтиҗә чыгарырга тиеш иде. Ләкин болардан берниндн нәтиҗә дә ясалмый. Союз җитәкчелеге күз буяу өчен Ф.Сәйфине союз членлыгыннан чыгара. Ләкин, озак та үтми, аны яңадан союзга алалар һәм аның шулай ук халык дошманнары Ш.Усмановларның, Г.Толымбайскиларның контрреволюцион әсәрләрен "Совет әдәбияты" журналында басып чыгаралар. Әлегә кадәр иҗаты һәм биографиясе караңгы булган Туфанның, Иптәш СТАЛИН биографиясеннән кабәхәт рәвештә көлә торган "Ант" поэмасы да "Совет әдәбияты" журналында урнаштырыла. Халык дошманнары Г.Галиләр, К.Нәжмиләр бу бозык әсәрне шедевр итеп мактарга тотыналар. Шул ук Г.Галинең һәм аның уң кулы булган Туфанның яшьләргә үсәргә ирек бирмичә, аларны буып килүләрен союз җитәкчелеге күреп торса да, аңлы рәвештә берниндн чаралар да күрмиләр. Союзның иҗат эшчәнлеге мәсьәләләре семьячелек нигезендә, ашау-эчү янында бер-беренә ошау һәм шәхси интереслар нигезендә хәл кылыналар. Тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть кысыла. Кыскача әйткәндә, союзның бөтен "эшчәнлеге" үзара яклашу нигезенә корыла.

Докладтан соң союз правлениесенең һәм, аерым алганда аның председателе К.Нәжминең, "эшчәнлеге" җыелыш тарафыннан кискен большевистик тәнкыйть уты астына алынды.

Иптәш Л.Гыйльми үзенең чыгышында Ф.Сәйфи, З.Гали, Г.Гали, В.Шәфигуллин һ.б. шундый дошманнарның татар әдәбиятында социализм өчен көрәш җәелдерүгә төрлечә комачаулыклар ясап килүләренә, татар совет матур әдәбиятына килә торган яшь көчләрне буууларына, партиягә, совет властенә каршы язылган "Миркәй белән Айсылу", "Зөбәрҗәт", "Ант" кебек бозык әсәрләрне матбугатка сөйрәүләренә һ.б.ларга тукталды.

Шулай ук башка сөйләүче иптәшләр дә, бөтенесе дә диярлек, иптәш Имамутдиновның ясаган йомгагын дөресләп, союз җитәкчелегенең яраксыз һәм черек булуы, язучыларның иҗат эшчәнлекләре белән җитәкчелек итә алмавы,

союзның контрреволюцион милләтчеләр оясына әверелүе турында яңа фактлар белән бу йомгакны тагын да тулыландырдылар.

Күп кенә иптәшләр үзләренең чыгышларында Татарстан совет язучылары союзында семьячелекнең кабәхәт рәвештә тамыр җәюе һәм шушы семьячелек нәтиҗәсендә большевистик тәнкыйтьнең гафу ителмәслек дәрәҗәдә кысылуы, алай гына да түгел, корткычлык һәм астыртын җимерү эшен алып баруны ачмау, халык дошманнарын фаш итмәс өчен үзара яклашу турында күп кенә фактлар китереп үттеләр. Аерым алганда бу мәсьәләгә Ш.Камал иптәш тукталды.

Шулай ук чыгыш ясаучы күп кенә иптәшләр аерым язучыларның иҗатларында булган дошман карашларына тукталып, аларны большевистик тәнкыйть уты астына алдылар. Иптәш Л.Гыйльми, Х.Туфанның "Ант", "Индустрия бизгәге", "Зәңгәр бүре" шигырьләренә, К.Нәҗминең "Кояшлы яңгыр" "Редактор" һ.б. әсәрләренә тукталып, бу әсәрнең зарарлы, турыдан-туры партиягә, советлар властенә каршы юнәлтелгән булуларын тулысы белән ачты. Хәзерге көндә халык дошманы булуда битлеге ертылган, әдәбиятка контрреволюцион кулак идеясен сөйрәгән Г.Толымбайскийның "Читән буе", "Мужик фәлсәфәсе", "Куян солдат" һ.б. әсәрләренә тукталып, бу әсәрләрнең дә турыдан-туры партиягә, советлар властенә каршы юнәлтелгән булуларын әйтте.

М.Җәлил, М.Әмир, Ш.Маннур һ.б. иптәшләр Татарстан совет язучылары союзы җитәкчелеге үзенең "эшендә" соңгы көннәргә кадәр ТАПП методын куллануын сөйләделәр.

Ип. Бубеннов, Елизарова һ.б. күп кенә иптәшләр Татарстан совет язучылары союзының башка милләт язучыларына булган мөнәсәбәтләренә тукталдылар. Бу чыгышларда иске правлениенең башка милләт язучыларына төкереп каравы, аларның иҗат эшчәнлекләренә шартлар тудырмавы, рус язучылары секциясенең, башында троцкийчы Гинзбург утырганы хәлендә, үсеп килә торган язучыларны бууы, ә һичбер төрле дә таланты булмаган кешеләргә ялган авторитет тудыруы күрсәтелде.

Чыгыш ясаучы иптәшләр, бөтенесе дә диярлек, халыкның кабәхәт дошманы Г.Галинең һәм, гомумән, союз җитәкчеләренең яшь язучыларны җинаятьчел рәвештә һәртөрлечә буып килүләренә, аларга карата түбәнсетү, төрлечә эзәрләүләр алып баруларына тукталып, бу турыда күп кенә конкрет фактлар китереп үттеләр.

Җыелышта тотнаксыз һәм җыелышны һичбер төрле канәгатьләндерми торган чыгышлар да булды. Х.Туфан, Ә.Фәез, Ф.Кәрим үзләренең чыгышларында җыелышның күзен буярга омтылыш ясадылар.

Туфан бик күп зарарлы әсәрләрнең авторы булуына карамастан, алдына куелган туры сорауларның берсенә дә канәгатьләнерлек итеп җавап бирмәде, үзен акларга маташты. Җыелышка катнашучы иптәшләр Туфанның чын йөзен белергә тырыштылар. Ләкин Туфан үзенең сәгатькә якын сөйләгән сүзендә иҗаты һәм биографиясе ягыннан караңгы кеше булуын тирәнәйтә генә төште. Ахырда җыелыштагы иптәшләр Имамутдинов иптәшнең Туфанга карата: "Туфанның үткән көннәре дә караңгы. Бу турыда Свердловскида чыга торган "Социализм юлы" газетасында бер мәкалә дә бар. Үзенең әйтүенә караганда, ул Колчак ягында да була. Ул үзе: "мин Колчак ягында булсам да, һәрвакыт кызыллар ягына чыгарга тырыштым" ди. Ләкин аның поезды нишләптер һаман да Читага таба китә" дигән характеристикасы белән тулысынча килештеләр.

Ә.Фәез татар милләте өстенә һич гафу ителмәслек дәрәҗәдә яла ягып чыкты. Халык дошманы Г.Гали белән бәйләнешен, троцкийчы хатынында банкетлар оештырып, Г.Гали белән бергә эчүен, Казанга килгәч тә системалы рәвештә Г.Гали квартирында булуын, җыелыш алдында үзенең ялгышларын ачып саласы урында, татар милләте өстенә намуссыз рәвештә яла якты. Бу соң кабәхәт милләтчеләр сүзен кабатлау түгелме? Ә.Фәез иҗатында ялгыш яклар азмыни соң? Ләкин ул бу турыда бер сүз дә әйтмәде. Ә.Фәез җыелышның ахырына кадәр торуны да кирәк тапмыйча, Мәскәүгә китеп барды. Киткән вакытта җыелыш исеменә хат язып калдырды. Бу хатында, җыелышта ясаган ялгышларын төзәтәсе урында, аларны тирәнәйтә генә төште. Җыелыш Ә.Фәезнең чыгышын да һәм язган хатын да

канәгатьләнерлек түгел дип табып, ана нык отпор бирде һәм Ә.Фәезнең эшен тикшерүне союзнын яна правлениесенә тапшырды.

Ф.Кәрим үзенең чыгышында тәлинкә тотарга, ялагайланырга яратуы, социаль чыгышын яшереп комсомолга керүе, әдәбиятка үрмәләве, халык дошманнары М.Сәгыйдуллин, Г.Гали, Ф.Сәйфи, П.Васильевлар белән бәйләнеше, Г.Гали кулга алынганнан сон Туфан квартирында оештырылган кичәдә Г.Галине кызганып, күз яшен түгеп бокал күтәрүе һәм үзенең иҗатындагы идеологик зарарлы әсәрләре турында сөйлисе урында, бу моментларнын һәммәсен томалап калдырырга тырышты. Халык дошманы П.Васильев белән очрашулары һәм аның әсәрләрен популярлаштерүе турында бер генә сүз дә әйтмәде.

Язучылар мондый чыгышларга, әлбәттә, нык отпор бирделәр һәм аларны нык тәнкыйть астына алдылар.

Жыелыш ябылыр алдыннан ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре ип. Мөхәммәтҗанов зур речь белән чыкты. Ул үзенең речендә союз эшендә булган бөтен житешсез якларны ачып, аларны нык тәнкыйть уты астына алды. (Ип. Мөхәммәтҗановнын речен 9 нчы биттән карагыз).

Жыелыш ВКП(б) Өлкә Комитеты тарафыннан төзелгән комиссиянең доклады һәм жыелыштагы фикер алышулар нигезендә элекке правлениенең халык дошманнары оясына әверелүен раслап, киләчәктә яна правлениегә, союзны савыктыру буенча эш алып бару өчен конкрет пунктлардан торган карар кабул итте. Шушы карардан соң яна правление сайланды. Яна правлениегә: Л.Гыйльми, Ш.Камал, Г.Иделле, Л.Пинхасик, К.Тинчурин, М.Әмир, Т.Гыйззәт иптәшләр сайландылар.

*1937, № 5.*

*Шигъри котлау*

## Роберт Әхмәтҗан

* * *

*Меңеңне инде яктырттың,*
*"Казан утлары", беләм:*
*Меңенче сан! Син тәңгәлсең*
*Казан утлары белән.*

*Казанга Мең Ел—искергән,*
*Ә безнең журнал—яңа.*
*Халкыбыз рухын балкытып,*
*Синең утларың яна…*

*Заманның "Казан утлары"н*
*Котлыйбыз алкыш белән:*
*Мең дә Беренче сан булып,*
*Кил*
*яңа*
*балкыш белән!*

Ибраһим
Салахов

# ТАЙГАК КИЧҮ

РОМАН-ХРОНИКА

...Камерага атылып ике хәрби кеше керде. Өсләрендә—озын соры шинель, яка очларында янып торган берәр шпал, димәк, майорлар. Башларында өр-яңа колакчын бүрекләр. Икесе дә урта яшьләрдә, тулы гәүдәле. Йөзләре суык. Күзләре бораулап ачу белән карый. Әле күптән түгел генә барлау ясаган төрмә башлыгы урынбасары бусага төбендә "смирно" баскан, өлкән түрәләрнең боерыкларын көтә.

—Тикшерү,—диде майорларның берсе, камераны сөзеп карап, ачулы тавыш белән.—Тизрәк! Берәм-берәм минем алга басыгыз да исем-фамилиягезне, кулга алынганчы кайда, кем булып эшләвегезне әйтеп, сәкеләргә менеп капланып ятыгыз. Кара, монда бүтән карыйсы булмагыз. Я, я, башладык. Син?

—Алкин, ВКП(б)ның Казан шәһәр комитеты секретаре.

—Марш! Син?

—Галимҗан Нигъмәти, профессор.

—Марш! Син?

—Сөббух Рәфиков, шагыйрь.

—Иманкулов Зариф, беренче татар полкы комиссары.

—Син?

Түбәнге сәкедән озын буйлы, таза гәүдәле кеше күтәрелде. Майор сискәнеп артка чигенде, күрәсең, сугып җибәрер дип курыкты һәм икенче тапкыр, бу юлы инде акрын гына эндәште:

—Сез?

—Камай Гыйлем, профессор, Владимир Ильич Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты ректоры.

Майор тагын артка чигенде.

—Стенага карап басыгыз! Следующий?

—Сәләх Атнагулов, профессор.

—Өскә! Син?

—Баһаутдинов Мәхмүт. Татарстан өлкә комсомол комитеты секретаре.

—Өскә!

—Менә алмыйм. Аякларым шешкән.

—Ярар алайса,—майор нәфрәтле караш ташлады.—Ярар, түбәнгә ят. Син?

—Акимов Николай Васильевич—Татпросвет секретаре.

—Син?

—Нижегородцев Ардалион Михайлович—комсомол өлкә комитетының бүлек мөдире.

—Ә син нәрсә анда менеп кунакладың? Төш!

Өске сәкедән җинел генә сикереп, атлет гәүдәле берәү төште.

---

*Өзек бирелә. Хәз.*

—Чанышев.

Әле һаман артта басып торып, килүчеләрне блокнотына язып торган майор, кинәт блокнотын төшереп җибәрә язып, кабаланып алга атлады:

—Якуп?

—Юк. Ул минем абыем. Ул комдив. Мин җайдаклар эскадроны командиры.

—Өскә!—Алда торган майор кашларын җыерды, йөзен чытты:—Барыгыз да елан Тухачевскийның койрыклары.

Чанышев нәрсәдер әйтергә дип авызын ачкан иде, бусагада басып торган төрмә башлыгы ярдәмчесе бармак янады:

—Тсс! Дәшмә!

Чанышев башын чайкады да бер сикереп ин өске сәндерәгә менеп китте.

—Син?

—Гомәр Гали, әдәбиятчы, редактор.

—Ә син, чулак?

—Мыскылламагыз,—Николай сул чулак кулын селкеп алды.—Тумыштан.

—Безгә барыбер. Фамилиян? Тизрәк.

—Борциковский Николай. Казан педагогия институты студенты.

—Син?

—Шәйхетдинов Касыйм—"Кызыл яшьләр" газетасы редакторы.

—Ильясов Гали—Татар академия театры режиссеры.

—Син нәрсә аптырап торасың?

Параша янында басып торган Габдулла сискәнеп китте.

—Мин? Мин бит комсомол райкомы секретаре. Мин...

—Ярар.—Майор әйтеп бетерергә бирмәде, бүлде:—Фамилиян?

—Әхмәдуллин Габдулла...

Аннан соң ике укытучы, бер прокурор, бер ВКП(б)ның авыл райкомы секретаре аваз бирде. Сәкедә урын булмагач, аларны стенага каратып бастырдылар. Мин дә шулар рәтенә эләктем. Башкалар әле сорау алудан кайтмаган иде.



*Шәхес культы елларында төрмә-сөргеннәрне кичкән татар әдипләре: сулдан уңга—язучы Сөббух Рәфиков, шагыйрь Хәсән Туфан, язучы Ибраһим Салахов. Озак еллар үткәч янә Казанда очрашу. 1956 нчы ел.*

Галәттә барлауда саныйлар да чыгалар иде, болай мәсхәрәләп яткырмыйлар, стенага терәмиләр иде бит. Бу ни бу? Бәйрәм алдыннан тагын нинди "яна тәртип" күрсәтәләр монда?

—Отбой. Ятыгыз. Тавышланмагыз,—диде алдагы майор, тикшерүне тәгәлләп, тагын бер тапкыр камераны сөзеп карап.

—Ә кичке аш?—кемдер югары сәкедән кычкыра салды.

—Бүген анысы юк,—диде дә башлык ярдәмчесе ишекне япты. Йозакны

юри, ахрысы, шалтыр-шолтыр китереп бикләде. Уйны уйга сузып очларын бәйли алмыйча җәфаланганда, тагын ишек ачылды, ашыгып надзиратель керде...

Бераздан Камайны, Галимҗан Нигъмәтине, Гомәр Галине, рәссам Зәбихне алдылар. Сәкедә урыннар бушады. Әмма бер генә тоткын да, аягүрә торудан хәлсезләнүләренә карамастан, ул урыннарны алырга ашыкмады.

Тынлык. Авыр, кара тынлык.

Ә коридорда һаман ыгы-зыгы. Нинди тынгысыз бу бәйрәм алды төне?

*"Казан утлары", 1988, №4*

*Журналыбыз турында*

## Аяз Гыйләҗев:

***—Журналның язмышы авыр булды, татар әдәбиятының да язмышы шулай иде. Әгәр ул хөр фикерләрне чыгара башласа, я Мәскәүдән, я Казаннан чукмар белән аның башын төеп тордылар. Аның хәтерен җимерделәр, әдипләребезне 37 елларда бер кырсалар, сугыш елларында алар икенче мәртәбә чалгы астында калып харап булдылар. Ләкин журнал чыга килде, журнал яшәде, журнал ул хәтәр җилләрнең уртасыннан барган очкыч кебек давылларга-җилләргә бирешмәде. Бусы хак. Булды, әлләниләр күрде безнең башлар. Ләкин без монда үзебезнең татарны зур хөрмәт белән искә алыйк. Журналны әдипләр генә түгел, журналны сәяси белгечләр генә түгел, журналны шагыйрьләр генә түгел, журналны татар яклады. Журналны татар ясады, татар рухсытты, татар яшәтте. Менә мин хәтерлим, сугыш елларында журнал ике мең, өч мең тираж белән чыга иде. Уйга калып, кайвакытта күз алдына китерәм, кемнәр язылды икән, кемнәр алды икән ул журналны, нинди хисләр, нинди уйлар белән кулларына тоттылар икән алар аны. Ничә буын татар «Казан утлары» журналын үзләренең канатлары итеп яшәп килде, татарлыкларын арттырдылар, татарлыкларын расладылар, журналны яшәттеләр һәм үзләре дә яшәделәр. Шушы уңайдан бер хәвефле уем белән уртаклашасы килә. Менә бүген журналга 70 ел. Әйдәгез әле тагын бер 70 еллыкка сикереп уйлап карыйк, 60 еллыгына, 50 еллыгына, 30 еллыгына, 10 еллыгына. 10 елда буыннар алмашына, 10 елда буыннар үзгәрә, 20 елдан язучыларның әсәрләре ике процент кына кала. Менә күз алдына китереп карыйк. Бүгенге татар кем ул? Нинди ул? Без бит тынычландыру сүзләре генә әйтергә яратабыз. Имеш, татар йоклаган иде, менә хәзер, имеш, татар уянды. Нинди татар уяна? Карт татар уянамы, яшь татар уянамы? Нигездә татарлыгы аның канында калган, тамырларында ага торган өлкән буын татар уяна. Әле дин аны беркадәр саклап калган, әле ул элеккеге замандагы яхшы игътибарлы, мәрхәмәтле, шәфкатьле изге татарларны күреп үскән. Ә хәзерге татар нәрсә күрә? Ул татар 10 елдан соң ничек булачак? Димәк, «Казан утлары» алдында бик күп бурычлар тора. Милли аңны үстерүдә ул бик зур эш башкарырга тиешле журнал. Ул әле шуны белергә тиеш, 20 елдан соң татарлар нинди булырга тиеш, 30 елдан соң нинди булырга тиеш, барсы турында кайгырту журнал өстендә. Чөнки без ваемсыз һәм гамьсез татарлар булмыйк инде. Дөнья безне нык өйрәтте бит. Без яратабыз юанырга һәм бер-беребезне юатырга, хәтта иппләп кенә шомартырга, алдашырга да. Ләкин милләт язмышы бервакытта да шомартуга мохтаҗ түгел һәм безнең алдагы мәсләгебез — еракка китеп карау. Шул ерактагы татарны күрә алсак, без татарны яшәтербез, һәм милләтнең дә эзе тарихта беркайчан да суынмас!***

*1992*

Фатих
Кәрим

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ЯРАЛЫ ҖАНЫ

Кереш сүз[1]

*1945 елның 18 февралендә Фатих Кәрим үз взводы белән соңгы сугышка керә. Взводның бу сугыштагы батырлыгы турында Ф. Кәрим хезмәт иткән частьтан Татарстан Язучылары союзына җибәрелгән хатта түбәндәге сүзләр бар:*

*"Ф. Кәримовка фашистларны 37,8 биеклегеннән бәреп чыгарырга һәм шунда ныгып калырга дигән бурыч куелды. Бу бурычны үтәүнең бөтен сугыш нәтиҗәсе өчен зур әһәмияте бар иде. Кече лейтенант Ф. Кәримов үзенә төп хәрби бурычны үтәү йөкләтелгәнне яхшы аңлады, ул үзенең взводы белән көчләре күп өлеш артыграк булган дошманга каршы кыю рәвештә сугышка ыргылды. Ул җитәкчелек иткән взвод дошманның көчен сындырды һәм биеклекне яулап алды. Фашист бандитлар, бу аз санлы кыюларны биеклектән куып төшерергә теләп, биш тапкыр каршы һөҗүмгә күчтеләр. Ләкин, зур югалтуларга дучар булып, артка тәгәрәделәр. 18 февральдән 19 февральгә каршы бер тәүлек эчендә фашистларның 45 солдат һәм офицеры үтерелде. 120 кешесе пленга алынды".*

*Фатих Кәрим шушы сугышта һәлак була. Соңгы батырлыгы өчен аңа икенче орден—"Беренче дәрәҗә Ватан сугышы" ордены бирелде.*

*Шагыйрьнең бу соңгы сугышта өч тапкыр яралануы турында мәгълүмат бар. Дошман угы аны тик өченче тиюендә генә үтерә. Бу да аның яшәүгә нык омтылышлы табигате турында сөйли кебек.*

*Ләкин Фатих Кәрим алган яраларның аз билгеле булганы, әмма шагыйрь җанын иң тирән җәрәхәтләгәннәре дә бар. Әле Казан Җир төзелеше техникумында укыган елларда ук ул, "мулла баласы" исеме тагылып, комсомолдан чыгарыла. Тик ВЛКСМ Өлкә комитеты катнашып кына аны комсомол сафында калдыралар. Икенче ярагы Ф. Кәримгә чордашларыннан берсе яшь шагыйрьнең беренче җыентыгына язган рецензиясендә ясый. Менә рецензент сүзләре: "Ф. Кәрим хәзерге көндә кызыл сүзләр кыстыргалап язып баручы, төптә буржуага хезмәт итәргә хәзерләнгән бер шагыйрь". "Аның күп шигырьләре яшьләр өчен иң зарарлы нәрсәләр", "Ул—солтангалиевче, җидегәнчеләрнең юлдашы" һ. б.*

*Ф. Кәрим өстенә килгән кара болыт 1936 елдан башлап тагын да куера. 1937 елда ул эшеннән чыгарыла һәм 1938 елның 3 гыйнварында, "халык дошманы" исеме тагылып, Кремль төрмәсенә озатыла. Шагыйрьнең төрмәләрдә, сөргеннәрдә күргәннәре әле өйрәнелмәгән. Әмма бу турыда мәгълүматлар да юк түгел. Аерым алганда, башта 10 елга хөкем ителгән шагыйрьнең 4 елдан соң яңадан суд ясалып, 1941 елның декабрь башында аклануы билгеле. Фатих Кәримне аклауга кемнәрнең ярдәме тигәнлеге дә якыннарына мәгълүм. Алар атаклы генералыбыз Якуб Чанышев һәм Ф. Кәримнең дусларыннан берсе Кави Нәҗми була.*

*4 елга сузылган газаплы төннәр һәм көннәрнең иң ышанычлы дәлилләре—шагыйрьнең үзе ясаган дәфтәрләрендә теркәлеп калган шигырьләре. Алар 1938-1941 еллар дәвамында кәгазьгә төшерелгәннәр. Күбесе каралама хәлендә калган.*

**Зәет Мәҗитов**

[1]Кереш сүз кыскартып басыла. Журналда 1989 елда чыккан 6 шигырьнең берсе бирелә. *Хәз.*

## КЫР КАЗЫ

*Тимер рәшәткәләр аша*
*Карыйм югары,*
*Челтәрләнә күкрәгемдә*
*Кояш нурлары.*

*Тынчу төрмәдә каршылыйм*
*Дүртенче язны,*
*Яз саен сагынып бу якка*
*Кайта кыр казы.*

*Кайта диңгез артындагы*
*Ерак илләрдән*
*Һәм яши ул төнбоеклы*
*Тонык күлләрдә.*

*Әй, кыр казы! Түбәнәйт тә*
*Очкан юлыңны,*
*Бүләк итеп китче миңа*
*Бер каурыеңны.*

*Каләм ясап каурыеңнан,*
*Язгы ялкында,*
*Каныма манчып языйм бер җыр*
*Сөйгән халкыма.*

*Җырым аша белсен халкым,*
*Айнытсын аңын,*
*Дошманнар богаулап куйган*
*Улы мин аның.*

*Атсалар да, ассалар да,*
*Сөйгән халкымның*
*Мин кояшым итеп үләм*
*Йөрәк ялкынын.*


*Атсыннар, куркытмый чөнки*
*Мине бу җәза,*
*Сабыйлар күз яше кебек*
*Вөҗданым таза.*

*Үлсәм җырларымда калыр*
*Сөю, сагышлар,*
*Кыр казы йөзгән күлләрдә*
*Шаулар камышлар.*

*1989, № 1*




СССР
Народный Комиссариат Внутренних Дел СССР
НКВД ТАТАРСКОЙ АССР
ОРДЕР № 781
Выдан ... декабря 193 г.
Действителен ... суток
Сотруднику
тов. Усманову
Вам поручается произвести обыск и
арест гр. Каримова Фатыха
Посвящается ... улица
Черниговская ... д. 2/ кв.
Всем органам Советской власти и гражданам СССР надлежит оказывать законное содействие пред'явителю ордера, при исполнении им возложенных на него ...



*Бу фотога шагыйрь төрмәдән чыккач, ашыгыч рәвештә, паспортка дип төшә. Галстукны күршеләре биреп тора. 1941 елның 3 декабрендә кайтып керә ул, 1 гыйнварда фронтка китеп бара. Әлеге фотоны да, "кара" ордер һәм Ф. Кәримнең фронттагы үзе ясаган шигырь китапчыгы күчермәләрен дә (матбугатта беренче тапкыр басылалар.) редакциягә шагыйрьнең кызы Ләйлә ханым китерде. Әтисе кулга алынганда (1938 елның 3 гыйнвары) аңа нибары 1,5 ай, фронтка киткәндә исә 4 яшь чамасы була. Хәз.*

## *Х Р О Н И К А*

### ФАТИХ КӘРИМ КАБЕРЕНЕҢ ТАБЫЛУЫ

Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган патриот шагыйрь Ф. Кәримнең кайда күмелүе моңа кадәр билгеле түгел иде. Шушы көннәрдә Татарстан АССР Язучылар союзы правлениесе исеменә Кызыл Байраклы Балтыйк флоты политуправлениесеннән түбәндәге хат килеп төште:

"Матрос Давыдов М. И. тарафыннан алып барылган күп һәм ныклы эзләнүләрдән соң, Бөек Ватан сугышында Кенгсберг шәһәрен һәм крепостен штурмлау вакытында, 1945 елның 19 февралендә батырларча һәлак булган танылган татар шагыйре лейтенант Фатих Кәрим күмелгән урын табылды.

Кызыл Байраклы Балтыйк флоты политуправлениесе вәкиле һәм совет властеның жирле органнары вәкилләре белән берлектә, матрос Давыдов М. И. шагыйрьнең каберен күреп кайтты.

Лейтенант Ф. Кәрим Калининград районында Владимир авыл советы каршындагы "Победа" поселогында туганнар каберлегенә күмелгән. Ф. Кәрим кабере өстенә мәрмәр обелиск урнаштырылган һәм анда "Ватаныбызның бәйсезлеге өчен көрәштә һәлак булган геройларга мәңгелек дан"—дип язылган. Бу язу астына "Лейтенант Фатих Кәрим, татар шагыйре, немец басып алучылары белән сугышта 19. 2. 1945 елда геройларча һәлак булды"—дип язылган таблица кадакланган.

Кабер өстенә мәрмәр кабер ташы куелган һәм киртә белән әйләндереп алынган. Авыл советы һәм аның председателе иптәш М. П. Юрлов шагыйрьнең каберенә карата даими рәвештә кайгыртучанлык күрсәтә.

Без совет властенең жирле органнарыннан шагыйрьнең истәлеген мәңгеләштерү өчен Калининград районындагы мәктәпкә, китапханәгә яки пионер отрядына Фатих Кәрим исеме бирүне сорадык.

Матрос М. И. Давыдовка шагыйрьнең каберен эзләп табуда күрсәткән мактаулы инициативасы өчен рәхмәт белдерелде".

*1957, № 1*



Кави
Нәҗми


# МӘҖИТ ГАФУРИ ҺӘМ ПАТША ЦЕНЗОРЛАРЫ

Мәҗит Гафуриның киң хезмәт ияләре белән, ярлылар, изелгән-кыерсытылган катлаулар белән нык бәйләнештә яшәве һәркемгә билгеле.

Менә шуңар күрә дә аның шушы катлауларның зарын җырлаган элекке шигырьләре дә әле монархиягә, капитализмга каршы көрәшне пролетариатча куюдан ерак булуларына карамастан, реакцион сыйныфлар өчен зур куркыныч тудырдылар. Эчке эшләр министрлыгы, Казан һәм Уфа губернаторлары, жандарм управлениеесе, цензорлар, миссионерлар, Ишми ишаннар—барысы да аңар каршы аякландылар. 1917 ел революциясенә хәтле аның иҗаты өзлексез эзәрлекләү астына эләкте. Патша цензурасының кара документларын бик ашыгыч кына күздән үткәрсәгез дә, бу эзәрлекләүнең өзлексез булуын, Мәҗит Гафуриның иҗат сулышын буу өчен әллә нихәтле тозаклар корылуын күрерсез.

Актарып карыйк 1911 елны.

4 нче мартта Казан губернасы жандарм управлениесенең начальнигы полковник Калинин Матбугат эшләре комитетына яшерен пакет белән Мәҗит Гафуриның "Милләт мәхәббәте" исемле шигырьләр җыентыгын җибәреп "җинаятьнең ни дәрәҗәдә булуын билгеләргә" куша. Комитет члены миссионер Н. Ф. Катанов, шулай ук яшерен рәвештә, бу җыентыкның 1907 елда басылуын һәм андагы "1906 елдан 1907 елга васыять"[1] исемле шигырь өчен авторның җинаятьләр уложениесендәге 129 статья буенча гаепләнүен белдерә.



Редакциядән:

„Совет әдәбияты" журналының 1937 елда чыккан номерларында язучы Кави Нәҗми иптәшне урынсызга халык дошманы, буржуаз милләтче дип атаулар булган. Тикшерү органнары Кави Нәҗми иптәшне акладылар (реабилитировать иттеләр). Кави Нәҗми иптәш Татарстан Совет Язучылары Союзы членлыгына кайтарылды.

Редакция шушы белдерү белән үзенең хатасын төзәтә.

*1940, № 1,2*

Шул ук елның июлендә жандарм управлениесе, Габдулла Тукай шигырьләрен һәм Мәҗит Гафуриның "Яшь гомер" (1908 елда басылган) җыентыгын җибәреп, цензура комитетыннан икесенә дә арест ясалганлык турында җавап ала. Жандарм начальнигы моның белән генә канәгатьләнми, кат-кат тикшереп, бу китапларның кайда, ничек таралуын, гаеплеләрнең нинди җәзага тартылуларын сораштырып тора. Бу турыда Казан тарихи архивында бик күп материаллар сакланган.

[1] Бу шигырь М. Гафури Сайланма әсәрләренең Таттосиздат тарафыннан 1932 елда басылган җыентыгына, 47 биткә кергән. *(К. Нәҗми искәрмәсе. Төз.).*

Килик 1915 елга. Монда инде без патша охранкасының "Яшь гомер" буенча бик зур эш кузгатуын, андагы шигырьләрне җентекләп русчага тәрҗемә иттерүен һәм 1908 елда басылган бу әсәре өчен 7 ел үткәннән соң да аны тынычлыкта калдырмавын күрәбез. Бу эшнең нәтиҗәсе Казан суд палатасы прокурорының түбәндәге карары белән тәгалләнә:

"...Казан суд палатасының 6 нчы марттагы билгеләве буенча, "Яшь гомер" брошюрасына арест расланды һәм минем тарафтан Казан округ суды прокурорына



*М. Гафури ял иткәндә.*

җинаятьләр уложениесенең 129 нчы статьясы, 6 нчы параграфында күрсәтелгән җинаять билгеләре буенча тикшерү ясарга кушылды".

Бу нинди җинаятьле әсәрләр соң? Профессор Катанов тарафыннан язылган тикшерү кәгазе моңар болай җавап бирә:

"...Җинаять билгеләре "Дума ачылу" (46—47 битләр) шигырендә һәм 57—58 битләрдәге исемсез шигырьләрдә күренәләр".

Беренче шигырьдә дума ачылу унае белән шатлык белдерелә һәм думага хәтле яшәгән хөкүмәтнең иске тәртипләре тәнкыйть ителә.

Һәм бераз түбәнрәк болай язылган:

"Хаким сыйныфларга мондый характеристика бирелүдә хөкүмәткә каршы дошманлык уяту теләге ята һәм ул эш җәзалар турындагы законның 1034 нче статьясы буенча хөкем ителергә тиеш".

Патша цензорларының игътибарын аеруча нык тарткан һәм бик күп документларда русча тәрҗемәләре китерелгән ул шигырьләрдән кайберләрен оригиналы буенча күчереп үтсәк, мәсьәлә тагын да ачыклана төшәр. "Ике кош" исемле шигырендә ул үз заманындагы язучылар өчен сирәк бер кыюлык күрсәтә:

*Хәзергә безнең әле өмет сынган,*
*Кылычлар чыгарылмый тора кынынннан.*
*Гомер булса, бер күрербез: килер заман,*
*Алырбыз залимнарның якасыннан.*

Ул бу заманга бару юлының авырлыгын бик яхшы белә. "1906 нчы елның васыяте" исемле шигырендә әйткәнчә:

*Җиңел түгел тиз аудару зур агачны!*
*Күп яшенле яңгырларны күрмәенчә,*
*Гүзәл, матур чәчәк атмас ал, кызыл гөл.*

Мәҗит Гафури әнә шул яшенле яңгырлар аркылы, каты эзәрлекләүләр аша, совет туфрагына килеп аяк басты һәм бу туфрак аның ал, кызыл гөлләре өчен бик яхшы булып чыкты. Сөекле шагыйребез Мәҗит Гафуридан вакытсыз аерылу кайгысын без аның әнә шул кызыл гөлләренә, "Кызыл йолдыз"ларына, "Кызыл тәлгәшләр"енә карап җиңеләйтәбез.

*1934, № 11*



# Мәҗит Гафури

## ТАТАР ЕГЕТЕНӘ

*Шуралар җөмһүриятен гамәлгә куючы егетләребезгә багышлана*

*Вакыт җитте, егет! Җаның булса,*
*Уян, сикереп күк буз атка мен!*
*Күрәсеңме, Идел буйларында*
*Матур, кызыл, ал таң атканын.*

*Урал тауларыннан күк таш алып,*
*Кайра кылычыңны шуңарга,*
*Таң җилләре искән матур чакта*
*Кит син дошманнарны куарга.*

*Бер нәрсәдән курыкмый, җан фәрманга*
*Алга чап син җирләр селкетеп,*
*"Дөнья безнең!" диеп кычкыр шунда*
*Гайрәт белән, йөрәк җилкетеп.*

*Шулай итеп вәхши ерткычларның*
*Котларын ал, салып куркыныч,*
*Кып-кызыл кан белән бизәкләнсен*
*Кулларыңа тоткан шул кылыч.*

*Шул вакытта чынлап тынычланыр*
*Күкрәгеңдә янган йөрәгең,*
*Шул вакытта биргән булырсың син*
*Мазлум илнең көткән теләген...*

*1920.*

*1949, № 10*

**Х Р О Н И К А**

### "ИДЕГЕ[1] ДАСТАНЫ"Н ӨЙРӘНҮ

Татарстан тел һәм әдәбият гыйлми-тикшеренү институты татар халык эпосы "Идеге дастаны"н өйрәнү өстендә эшли башлады...

Институт март ахырларында, "Идеге дастаны"н өйрәнүгә багышлап, язучылар һәм гыйлми эшчеләр катнашында, махсус киңәшмә үткәрде. Киңәшмә дастанның төз, төгәл текстын булдыру эшено керешергә карар бирде һәм эпосның монарчы билгеле булмаган вариантларын табу өчен экспедицияләр оештыру чараларын күрергә кирәк дип тапты. Киңәшмә инициатива комиссиясенә дастанга 500 ел тулуны билгеләп үтү турында ТАССР хөкүмәте каршында үтенеч кузгатырга тапшырды.

27 апрельдә Язучылар союзының фольклор секциясе язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында "Идеге дастаны" турында Н. Исәнбәт иптәшнең махсус докладын үткәрде. Тирән эрудицияле, бай эчтәлекле чыгышында докладчы "Идеге дастаны"ның тарихи ягына киң тукталды һәм аның өйрәнүчеләр өчен бай һәм кыйммәтле материаллар бирәсен әйтеп үтте.

*1940, №3*

---

1 "Идеге"–"Идегәй" исеме әйтелешенең бер варианты. *Хәз.*



Иҗат әһелләреннән бер төркем. Утырганнардан сулдан икенче—Бакый Урманче, өченче—Мирсәй Әмир. Үткән гасырның 30 нчы еллары.



Татарстанның мәшһүр шәхесләре: табиб Ә. Терегулов, химик А. Арбузов, язучы К. Нәҗми. 1951 ел.



Актриса Фатыйма Ильская, шагыйрьләр—Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Ерикәй, Муса Җәлил. 1934 ел.



Ш. Маннур

## ТАТАР ХАЛКЫ

*Син акланган инде әллә кайчан,*
*Минем яклау кирәк тә түгел.*
*Ә шулай да, әйтер сүзем әйтми*
*Тынгы тапмый тынгысыз күңел.*

*Гомер буе сине җәберсетеп,*
*Мәсхәрәләп килгән дошманнар,*
*Нинди начар исем табалсалар*
*Аны, халкым, сиңа кушканнар:*

*"Татар булган җирдә хәтәр бар" дип*
*Шик салганнар дуслар эченә.*
*Нахак яла ягып калдырганнар*
*Минем газиз халкым исменә.*

*"Чакырылмаган кунак—татардан да*
*Яман" диеп ялганлаганнар.*
*"Татар акылы төштән соң" дип алар*
*Көләргә дә оялмаганнар.*

*"Татар ашар, ашар да качар" дип,*
*Тупас-дорфа иткәннәр сине.*
*"Урыс—власть, татар—тылмач"*
*дип тә*
*Мыскыл итеп йөрткәннәр сине.*

*Юк, дусларым,*
*Дөрес түгел болар,*
*Дөрес түгел болар берсе дә!*
*Минем халкым—бөек татар халкы*
*Намуслы да, дус та, көчле дә.*

*Иптәш өчен утка-суга керү—*
*Гадәте ул бездә һәркемнең.*
*Куркыттымы безнең Батыршинны*
*Дулкыннары Хасан күленең?*

*Әрсез түгел минем туган халкым,*
*Тыйнаклык хас аңар һәр җирдә.*
*Кунак килсә, якты чырай белән*
*Урын түрдә бездә һәр өйдә.*

*Акыл безнең айнык һәр вакытта,*
*Тутыккан таш булып ятмый ул.*
*Гыйлем, сәнгать, иҗат мәйданында*
*Даһи нуры белән балкый ул!*

*Тупас, комсыз түгел минем халкым,*
*Ягымлы ул, кече күңелле.*
*Сугышта ул—юлбарыска ошый,*
*Хезмәттә ул—титан шикелле.*

*Ватаны бар аның, дәүләте бар,*
*Власте бар аның кулында.*
*Гөлстаннан гүзәл булып ята*
*Коммунизм—барыр юлында.*

*Һәй, сөекле илем Татарстан!*
*Бишегем син минем, җырым син.*
*Ил күзеннән җәбер яшен сөртеп,*
*Җан иңдергән кояш нурым син!*

*1940, № 5-6*

*Журналыбыз турында*

## Мостафа Өнәр (Төркия):

***—Миңа татар телен ике хәлфә өйрәтте. Беренчесе кечкенә Апуштан татарның зуп-зур улына әверелгән Габдулла Тукай иде. Ул 27 яшендә үлемсезләр дөньясына күчте. Зур иҗаты бүген дә сау-сәламәт. Икенче хәлфәм яшь буенча Тукайдан өлкәнрәк. Ул хәлфә - «Казан утлары». Бу журнал турында бик күп сөйләргә мөмкин булса да, мин беренче чиратта шуны әйтергә тиеш, ул мәктәп, татарның һәм татарлыкның мәктәбе. Бу мәктәп иң авыр вакытларда да Казаннан Америкага, Финляндиягә, Германиягә, Япониягә, Төркиягә, Австралиягә, Себергә, Питерга, Кытайга, димәк, әйтергә мөмкин, бөтен дөньяга ишек ачты. Татарның, татар теленең яктысы төшмәгән урыннарга «Казан утлары» үз нурларын сирпеде, татар дөньясын балкытып торды. Анда нәрсә генә язылса да, ул татар рухын яшәртте. Без төрекләр, башка төрки туганнарыбызның арасында озак вакытлы бер ялгызы ирекле дәүләт булып торган Төркиядә шул теләктә калабыз: татарлар да үзләренең бу матур, гүзәл илләрендә үз байлыкларына үзләре ия булып мәңге яшәсеннәр. Шул рәвешле «Казан утлары» журналы да күп санда басылып, аның таралу чикләре тагы да киңәйсен. Дөньяның төрле төбәкләрендә сибелеп яшәгән һәр татарга "Казан утлары»ның нур-иманы иңдерелсен.***

*1992*



А. Ключарев

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МУЗЫКА ИҖАТЫ[1]

Безгә—Казан музыка фольклоры кабинеты работникларына—татар музыка фольклорын җыю буенча алып барган практик эшебездә еш кына аерым "музыка тикшерүчеләр"нең сәер генә карашларына юлыгырга туры килгәләде. Алар татар халык музыкасын примитив һәм художество дәрәҗәсе ягыннан түбән тора дигән "фикер" әйтәләр һәм татар халкы музыкасы бер тавыштан һәм пентатоникадан узмый дип шушы "фикерләрен" расларга азапланалар (мәсәлән, Рыбаковның "Урал мөселманнары җырлары" дигән китабын карарга була,—Рыбаков,—"Песни Уральских мусульман", издании Академии Наук). Мондый җинел караш әлбәттә иң кискен отпор алырга тиеш. Мондый юл белән барганда музыка культура дәрәҗәсен билгеләп булмаячак иканен, кайбер күп тавышлылыкка караганда бер тавышлылык шактый күбрәк катлаулырак булуын һәм аның культура ягыннан чагыштырмаслык дәрәҗәдә югары булуын күрсәтүне ниһаять аңларга бик вакыт инде.

Бу очракта, пентатоника һәм бер тавышлылык татар яки башкорт музыка культураларының ярлылыгын күрсәтми, бәлки аларның специфик характерының күрсәткече булып тора. Борынгы дөньяның халыклары барсы да үз вакытларында пентатоника стадиясен үтүләре билгеле. Бары тик кайбер халыклар гына (Азиядә: кытайлар, монголлар, татарлар, башкортлар, марилар, чуашлар һәм бер өлешчә удмуртлар, Көнбатыш Европада: шотландецлар, финнар, Америкада—негрлар) төп тавыш рәте рәвешендә пентатониканы саклап калганнар, башка халыклар исә, зур күпчелекләрендә, диатоник тавыш рәтен кабул иткәннәр. Татарлар, башкортлар, чуашлар, марилар һ. б. халыклар патшалык Россиясенең урта бер җирендә тупланган хәлдә шулай да ничек итеп борынгы пентатоника нигезендә үзләренең музыкаль культуралары специфик үзенчәлекләрен саклап кына калмаганнар, бәлки аны үстергәннәр дә дигән мәсьәлә хәзер бик нык тикшерелә. Кызганычка каршы, гәрчә читләтеп кенә булса да, бу мәсьәләгә кагылып үткән нинди дә булса гыйльми хезмәткә безнең очраганыбыз юк әле. Фольклор кабинетының тикшеренүләре бу мәсьәләне һәм аның белән бәйләнешле булган бүтән мәсьәләләрне гыйльми яктан өйрәнә башлауга бары тик нигез салалар гына дияргә була. Алай да, татарлар, чуашлар, башкортлар һәм мариларның музыка культуралары тарихи яктан үзара бәйләнештә булуларына карамастан, бу халыкларның һәрберсенең музыкасы, тавыш рәте уртак булган хәлдә, бөтенләй үзенә аерым культура булып торуы факты бәхәссез. Нинди дә булса күңелле популяр рус җыры шәһәр татарлары көнкүрешенә кереп, бу татарларның ул җырны татар текстлары белән үтәүләре (мәсәлән, "Как на горке малина", "Коробочка" һ. б. ш.) кебек бик очраклы күренешләрне искә алмаганда, шулай ук рус музыкасы да татар музыкасына йогынты ясау элементлары кертмәгән. Татар көйләре кинәт рус авылларында таралып китүе кебек (мәсәлән, "Хазбулат удалой" "Тәфтиләү"дән туган) икенче бер күренешләр булса да, бу фактларны рус һәм татар халык музыкаларының үзара җитди бәйләнешләре дип атап булмый.

Башкорт халык музыкасы татар халык музыкасына бик якын тора. Хәтта бу ике халыкның көнкүрешендә тигез хокуклы урын алган шактый күп кенә җырлар да бар. Шундыйлардан, мәсәлән, "Сакмар", "Уел", "Ашказар" җырларын һ. б. күп

[1] Кыскартып басыла. *Хәз.*

кенәләрне күрсәтеп була. Аларның күпчелеген, һич шиксез, башкорт фольклоры санарга кирәк. Ләкин болар белән рәттән башкорт халкы арасында киң таралган һәм һичшиксез татар халкыныкы булган ике дистәгә якын җырларны күрсәтергә була (мәсәлән, "Ак каен", "Шахта", "Тәзкирә", "Зиләйлүк" һ. б. ш.). Мондый күренешне, беренче чиратта, бу халыкларның географик, экономик һәм культура ягыннан бер-берсенә якын торулары белән аңлатырга кирәк. Алай да, менә карамастан, татар музыка культурасы башкорт музыка культурасыннан бик сизелерлек рәвештә аерылып тора. Монда иң башта татар җырының музыка телен күрсәтергә кирәк. Әгәр дә башкорт җыры өчен пентатоника баскычларының бер кадәр иркенрәк чиратлашуы һәм вак бизәкләрнең (мелизмнәрнең) чагыштырмача уртача кулланулы характерлы булса, татар җыры өчен көйләрнең житди—баскычланып баруы (пентатоника баскычларының эзлекле рәвештә чиратлашуы) һәм мелизм чәкәннәренең бик бай булуы характерлы. Сузынкы башкорт җырларының импровизациялылыклары һәм эпик булулары да татар мәхәббәт җырларының ачык ритмикасыннан, формаларының квадратлыгыннан һәм якты лирикасыннан кискен рәвештә аерылып тора.

Октябрьдән соң туган яңа татар җырлары һәм эчтәлек, һәм форма ягыннан бөтенләй аерылып торалар. Үткән заманнар культура мирасы традицияләреннән совет фольклорына йогынты ясавы турында без әйткән идек инде. Шулай да, фольклор кабинеты материалларында иске җырлардан форма ягыннан кискен рәвештә аерылып тора торган яңа җырлар да бар.

Хор җырлары, яшьләрнең кулга тотынып әйлән-бәйлән уйнау җырлары тууын күрсәтеп үтәргә кирәк (мәсәлән, "Комсомолка" көе, "Ил мактау", "Җырлап бию" һ. б. ш.). Бу җырлар белән рәттән романс яки массовый, политик актуаль җыр формасына якынлаша торган кушымта формалы җырлар да туды. Эчтәлекләре һәм формалары белән композиторлар әсәрләреннән калышмый торган "Удар ил", "Ату кырлары" һәм башка күп кенә гүзәл җырларны шулар рәтенә кертергә була...

*1939, № 5*

* * *

Татар музыка сәнгатендә беркайчан җуелмаслык тирән эз калдырган бу рус кешесе Казанда туа, Казан музыка техникумын тәмамлый. 1926 елдан ул—Казан театр техникумының музыка бүлеге мөдире. Техникум студентлары белән Урал һәм Себер якларына гастрольләргә чыгып йөри. Татар халкының музыкаль иҗатын өйрәнеп, "Директор Җәмилев", "Сүнгән йолдызлар" кебек пьесаларга музыка яза. Яшь-яшь композитор шушы вакытта ук С. Сәйдәшев М. Мозаффаров, Ф. Туишев, Г. Сөләйманова, З. Хәбибуллин белән аралаша башлый. 1928 елда Мәскәү Дәүләт консерваториясенә укырга керә. Мәскәүдә татар драма театрының музыка бүлеге мөдире булып эшли, 20 дән артык спектакльгә, шул исәптән, "Зәңгәр шәл", "Галиябану", "Ил"гә музыка яза, "Галиябану" дигән беренче симфоник сюитасын иҗат итә.

1934 елда Ключарев Уфага килә, анда Башкорт милли культурасы фәнни-тикшеренү институтының фольклор секторы мөдире һәм Башкортстан радиокомитетының музыкаль радиотапшырулар редакторы булып эшли, "Салават" һәм "Урал" дигән симфоник поэмалар яза.

1937 елда композитор Казанга кайта, биредә музыкаль фольклор кабинеты мөдире була, татар халык җырларын өйрәнер өчен күп кенә экспедицияләр оештыра. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1941 елда татар халык җырларының беренче басмасы дөнья күрә. Шушы чорда татар халык җырларын татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә күп тавыш белән башкару өчен эшкәртеп, бу хәл татар халык җырларын баету өчен зур мөмкинлекләр ача. 1934-40, 1968-70 елларда ул—әлеге ансамбльнең, 1940-42, 1951-53 елларда исә татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе була. Күп кенә симфоник әсәрләр, җырлар иҗат итә...

**Бу айда күренекле композитор Александр Сергеевич Ключаревның тууына 100 ел тула.**



## Илсур Метшин

Казан шәһәре
хакимияте башлыгы

Кадерле дуслар!

Узган ел татар халкына Казаныбызның мең еллыгын бәйрәм итү бәхете насыйп булды. Быел "Казан утлары" журналының меңенче саны дөнья күрә. "Казан—шагыйрьләр каласы!"— диләр. Бөек Мөхәммәдьяр, Колшәриф, Тукай, Такташ, Җәлилләр Ватаны бит ул!

"Казан утлары"—татар халкының төп журналы дип санала икән, дөньяның төрле тарафларында яшәүче милләттәшләребез үз күргән басманың нәкъ менә мең яшьлек башкалабызда нәшер ителүе күңелләрдә горурлык хисе уята.

Казан һәм аның "утлары"—бер-берсеннән аерылгысыз. Тарихыбыз да, бүгенгебез дә, киләчәгебез дә—бергә. Димәк, яшәешебез өчен шарт булып торган социаль, мәдәни һәм икътисадый мәсьәләләрне дә бергә-бергә хәл итәргә бурычлыбыз. Журналның абунәчеләр санын арттыру да—уртак бурычыбыз. Казан шәһәре белән "Казан утлары" журналы халкыбызның пакь-чиста көзгесе булсын иде.

"Казан утлары" журналын мин саллы, затлы, әдәпле, чиста-пакь журнал, дип әйтә алам. Журнал айлар, еллар үткәч тә, кайта-кайта укыла торган әчтәлеккә, тарту көченә ия. Тарихи һәм фәлсәфи тирәнлеккә, әдәби кыйммәткә ия әсәрләре, халкыбыз язмышын кайгырткан язмалары белән кадерле дә ул.

"Казан утлары"ның берөзлексез дөнья күреп, меңенче санына килеп житүе—аның халкыбыз өчен тансык җан азыгы булуына олуг дәлил.

Мең еллык башкалабыз мең санлык "Казан утлары" белән киләчәккә атлый!



## Ринат Закиров

Бөтендөнья татар конгрессы
Башкарма комитеты рәисе

Хөрмәтле «Казан утлары» журналын нәшер итүчеләр һәм аның укучылары!

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты исеменнән Сезне журналның 1000нче саны дөнья күрү уңаеннан чын күңелдән тәбрик итәм.

«Казан утлары» — халкыбыз мәнфәгатен кайгыртучы, милләт тормышын тулысы белән яктыртучы, яшьләр иҗатына фатыйха бирүче «аксакал» басма. Үзенең тәүге санынннан алып бүгенге көнгә кадәр журнал Бөтентатар дөньясын берләштерүче, милләтебезне оештыручы, халкыбызның бай мирасы белән таныштырып баручы, мәдәни яңалыкларны җиткерүче ролен үти һәм дөнья буйлап сибелгән татарның иң яратып укый торган матбагасы булып тора. Моның шулай булуы табигый хәл. Һәр санын укучы теләкләрен истә тотып, чын мәгънәсендә иҗат утында янып, тырышып эшләүче каләм осталары җыелган бу коллектива.

Җир шарының төрле почмакларына таралып яшәгән татар халкы бүгенге көндә дә борынгы бабаларыбыздан якты мирас булып калган телен, моңын, күркәм бәйрәмнәрен, матур гореф-гадәтләрен саклап, олы бер милләт булып яши икән, моның нигезендә «Казан утлары»ның хезмәте дә әйтеп бетергесез зур. Журнал киләчәктә дә халкыбызның мөхтәрәм, зыялы язучы, шагыйрьләренең саллы әсәрләре, затлы шигырьләре, кыю тәнкыйте, файдалы киңәшләре белән сөендереп яшәр дип ышанам.

Ихлас күңелдән милләтебезнең киләчәген кайгыртып яшәвегезне телим. Сезнең барчагызга да иҗади уңышлар, ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете юлдаш булсын. Татар халкының үткәнен, бүгенгесен, киләчәген дөрес яктыртучы «Казан утлары» булып калыгыз!

Гази
Кашшаф



# НИГЕЗ ТАШЛАРЫН САЛГАНДА

Һәрбер редакциянең үзенең "ломовой аты", авыр йөк тартып баручы хезмәткәре була. "Казан утлары" журналы редакциясендә дә андый хезмәткәрләр булды. Редакциянең бүгенге көнен телгә алмаска да мөмкин, чөнки илнең гомуми икътисадый куәте үсү белән бергә журналның аппараты да киңәйде. Бүген эш төрләре хезмәткәрләр арасында тигез бүленгән. Барыннан да бигрәк журналга материал эзләп төрле якка чабасы юк. Хәзер роман, повестьларны эзләмиләр, калын-калын кульязмалар басылырга чират көтеп ята. Язучылар санының көннән-көн арта баруы калынайганнан-калыная барган шушы журналның мәйданын тарайтып җибәрде. Әле бит без күптән түгел генә тиешле югарылыктагы материалны каян алырга интегә идек. Бөек Ватан сугышы еллары хәтердә нык уелып калган. Партиянең Татарстан өлкә комитеты "Совет әдәбияты" журналын саклап калырга булды. Шул ук вакытта аппараттагы әдәби хезмәткәр штаты кыскартылды. Ул чакта журналны Гомәр Бәширов редакцияли иде. Озак та узмастан, партия оешмасы Гомәр Бәшировны фронтка, озак сроклы командировкага җибәрде. Бөтен эш Абдулла Гомәр җилкәсенә авып калды. 1942 нче елны Гомәр Бәшировны мин алыштырдым. Гомәр Бәширов Татарстан радиосының баш мөхәррире итеп билгеләнде. Журналда хәл авырлыгына котып салкыннары килеп кушылды. 1941 нче елның кышыннан бирле матбугат йорты ягылмый иде. Менә без Абдулла Гомәр белән икәү "Совет әдәбияты" журналының нәүбәттәге санын әзерлибез. Бүлмәдә бер сәгатьтән артык утырып булмый. Салкын үзәккә үтә. Һәм без урамнан әйләнеп керәбез. Матбугат йортына караганда урамда җылырак шикелле тоела безгә. Менә шундый авыр шартларда кемнең нәрсәгә сәләтле һәм ни дәрәҗәдә чыдам икәнен күрәсең. Абдулла Гомәр журналга барлык энергиясен салып эшләде. Сугыш сузылган саен кыенлыклар арта бара: кәгазь кытлыгы, типографиядәге авырлык, кульязмалар җитмәү һәм башкалар. Өстәвенә баш мөхәррир айлар буе чәчү, урып-җыю компанияләрендә йөри. 1943 нче елның җәендә типографиядә җыелмыйча хәрәкәтсез яткан журналларыбызның саны җидегә җитте. Димәк, җиде ай буе без укучыларыбызга журналны җибәрә алмыйча тордык. Бу өзеклекне бетерү өчен, билгеле, партия оешмалары күп тырыштылар. Ләкин типографиянең эшен, сугыш заказларын үтәүне тыярга кемнең кулы күтәрелсен. Ул чакта Абдулла Гомәр дә нәшрияткә күчерелде. Без башта Әнәс Камал белән калдык. Бераздан Фатих Хөсни килеп кушылды. 1943 нче елның октябрендә миңа тагын бер эш йөкләделәр. Мөхәррирлектән бушатмыйча гына Татарстан Язучылар оешмасының җитәкчесе итеп сайладылар. Бер көнне кич белән мине җитәкче итеп сайладылар, икенче көнне Мәскәүгә юл алдык. Тажи Гыйззәт, Кави Нәҗми, Нәкый Исәнбәт һәм мин Мәскәүгә китәргә һәм СССР Язучылар союзының президиум утырышында Татарстан язучылары Союзының эше турында хисап бирергә тиеш идек. Язучылар союзы президиумында хисап докладын мин ясадым. Безнең эшебез мактанырлык түгел иде. Шуңа күрә кимчелекләрне һәм аның сәбәпләрен тукми-чәчми сөйләп бирдем. Утырышны Александр Фадеев алып барды. Моңа кадәр ул Казанда ике тапкыр булып киткән һәм безнең хәлләр белән яхшы таныш иде. Бу безнең мәсьәләне президиум утырышына куеп, кулдан килгәнчә гамәли ярдәм күрсәтү, булышу теләге белән эшләнгән иде. Президиумда

ачыктан-ачык житди сөйләшү булды. Әйбәт, эшлекле тәкъдимнәр әйтелде. Ләкин Александр Фадеевны мондый сөйләшүләр генә канәгатьләндермәде. Шушындагы сөйләшүләрнең гамәли нәтиҗәсе булсын өчен ул безне Партиянең Үзәк комитетына алып барырга теләгән әйтте. Икенче көнне Таҗи Гыйззәт, Кави Нәҗми һәм мин Александр Фадеев белән Үзәк комитетка юнәлдек. Үзәк комитетның пропаганда бүлегендә мина шактый зур хисап доклады сөйләргә туры килде: Татарстандагы әдәби хәрәкәтнең торышы, нәшрият эшләре, язучы кадрларның барсы диярлек фронтның алгы ут сызыгында булуы, аларның солдат хезмәтен үтәү белән бергә язучылык эшен дә алып барулары, үзебезнең дә бик авыр шартларда яшәвебез хакында сөйләдем. "Уңышлар турында сөйләмим, кимчелекләр турында әйтәсе килә", дип башлаган идем сүзне. Кызып киткәч, берләнбер әдәби журналыбызның бик мөшкел хәле турында да сөйләргә туры килде. Кинәт мине сөйләүдән бүлдерделәр. "Ничек, сездә журнал чыгамени?" Фадеев мин утырган урындык артында басып тора иде. Сорауны аңа да бирделәр: "Ә сез, Александр Александрович, бу хәлне беләсезме?" Миңа Фадеевның йөзе күренми, ул һаман кулын минем җилкәмә куеп басып тора һәм бик гади нәрсәне раслаган төсле үзенең ягымлы тавышы белән: "А как же, без житәклибез",—диде. Фадеев чыннан да бу хәлне белә иде. Шуна күрә анын сүзе "Бу шулай һәм шулай булырга тиеш" дигән мәгънәдә яңгырады. Казанда вакытлыча туктаган хәрби эшелоннардан бер генә данә булса да журнал бирегез дип килүче офицерлар турында, үзем командировкада йөргәндә күрше Башкортстан районнарыннан берәр журнал сорап кеше җибәргән колхоз рәисләре турында, редакциягә килгән хатлар турында сөйләдем. Үзәк комитеттагы иптәшләр безнең хәлне яхшы аңладылар, авырлык белән булса да журналны туктатмыйча чыгарып килүебезне хупладылар. Бу сезнең "подвиг" диделәр. Бу мактауны без Татарстан өлкә комитетының һәм журналда актив катнашучы барлык язучыларның уртак казанышы дип кабул иттек.

***

*Мин рядовой солдат бу сугышта,*
*Тик бер нәрсә белән аерылам*
*Рядовойлар төнен йоклаганда*
*Мин йокламыйм, шатлык-кайгыдан*
*Бер минут та башка тынгы бирми*
*Окоп почмагында утырам.*
*Аламын да куен дәфтәремне*
*Язып җыр язарга тотынам".*

Фатих Кәримнең бу шигыре татар фронтовик язучыларының күмәк портретын дөрес сурәтли. Шәрәф Мөдәррис, Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Әхмәт Ерикәй, Ибраһим Гази, Шәйхи Маннур, Гадел Кутуй, Мөхәммәт Садри, Хатыйп Госман, Гали Хуҗи, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Әхмәт Исхак, Абдулла Әхмәт һәм башка фронтовик язучыларның эзлекле ярдәмнәре булмаса, журналны чыгару мөмкин булмас иде.

"Совет әдәбияты"ның һәрбер саны, кимчелекләре булуга да карамастан, теткәләнеп беткәнче укыла, кулдан кулга күчә. Тылдан бик кадерле бүләк төсендә, фронтка юнәлә. Хәрби частьләрдән махсус соратып алалар, кичектерми фәлән-фәлән саннарын җибәрегез дип таләп итәләр. Әгәр дә алар сораган саннар барып җитмәсә, шактый каты шелтәле сүзләр белән хат җибәрәләр. Мондый хатларны без тылдан да ала идек, очрашу вакытларында да шушы мәсьәлә күтәрелә иде. Шул рәвешчә, "Совет әдәбияты" журналы сугыш елларында халыкның юлдашы, сердәше, юанычы һәм куанычы булды.

*1972, № 5*

А. Шакир

# ГАДЕЛ КУТУЙ БЕЛӘН БЕРГӘ

ТУУЫНА 55 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН

Гадел Кутуй белән бергә булган көннәр миндә онытылмаслык тирән истәлекләр калдырды.

Мин ул чакта "Красная Армия" исемле фронт газетасында Политуправление вәкиле булып эшли идем. 1944 нче елның яз айларында ук безнең фронтта да татарча газета чыгару хәл ителгән иде. Ләкин фронт шартларының төрле сәбәпләре белән ул көзгә кадәр чыга алмады. Шулай да аңа сотрудниклар тупланды. Тагын да берәү көтелә иде.



Без инде—яңа гына фашистлардан азат ителгән Польша җирендә. Редакция урнашкан махсус поезд урман эчендә тора. Сентябрь ае. Бездә күтәренке рух, поляк халкында чиксез зур шатлык...

1944 нче елның 11 нче сентябренә каршы төндә безнең редакциягә Гадел Кутуй килеп төште. Мине аның белән язучы Гариф Галиев таныштырды. Иртә белән алар ашханәдән чыгып киләләр иде. Гадел Кутуй хакында, аны элек күрмәгәнлектән, башкачарак уйлый идем. Ә ул бик тыйнак, гади икән. Ул бик житез, тоскә яшь чырайлы, кара озын чәчле, какча яаклы; сипкелле сыман шат йөзендә сизелер-сизелмәслек ниндидер бер саргылтлык бар. Анарда һәр кешене үзенә тарта, әсир итә торган яшерен бер көч бар кебек. Шуңа күрә дә яңа коллективта ул үзен бик тиз танытты һәм берничә телдә чыга торган фронт газетасы редакциясенең күп милләтле сотрудниклары арасында зур ихтирам казанды; алар арасындагы язучылар, журналистлар, шагыйрьләр, Кутуйның үз сүзе белән әйткәндә, "Мәскәүдәге дуслары" булып чыктылар. Сталинград өчен батырларча сугышып, үзен таныткан һәм дан казанган җырчы-сугышчы, ялкынлы журналист Кутуй яңа эшкә кучкәннең икенче көнендә үк фронт газетасының махсус хәбәрчесе булып алдынгы сызыкка китте. Ул батыр совет солдатлары белән бер окопта яши, аларга шигырьләрен сөйли, газеталар укый, солдатларга һәм командирларга иң якын кеше булып китә һәм кирәкле материалларны теләгән урында үз вакытында ала белә. Тыныч минутларда солдатларга хатлар язышкан Кутуй һөҗүм вакытларында, автоматын алып алдынгы сафта була. Ләкин ул үзенең бу эшләрен берәүгә дә сөйләми, аның шундый куркусыз һәм батыр журналист-сугышчы булуы турында башка иптәшләре сөйлиләр һәм аерым часть командирлары редакциягә хәбәр итәләр...

Безне Гадел Кутуйның ару-талуны белмәгән түземле эшчәнлеге сокландыра иде. Ул барысына да өлгерә иде. Мәкаләләре, очерклары, шигырьләре рус, татар, казакъ һәм үзбәк телләрендә чыга торган фронт газеталарында өзлексез басыла килде. Ул сугыш беткәч зур әсәрләр язу турында хыяллана иде. "Рөстәм мажаралары"ның икенче, өченче кисәкләрен һәм совет солдатлары турында роман язу өчен ул материал туплый, сызмалар ясый иде.

Гадел Кутуйның шулкадәр бирелеп эшләвенә анарда кайнаган илгә булган мәхәббәте илһам бирде. "Сагыну" әсәре өстендә эшләгәндә Гадел Кутуй күпме хыялланмады һәм йөрәгеннән нинди генә кичерешләрне үткәрмәде икән!

Чит ил күге. Дошманны җиңеп алга барабыз; туып үскән җирләр, каз бәбкәләре котеп үскән көмеш сулы күл буйлары ераклашкан саен, йөрәкләрдә изге юксыну ялкыннары арта гына. Ә Гадел Кутуйда ул юксынулар тирән ярсу белән аралашып, илне сөюче бөек көчкә әверелә һәм ул:

*И туган ил, и матур ил,*
*Калдың бездән еракта,*
*Калсаң да бездән еракта*
*Күңелдә син һәрчакта,—*

дигән, әле язылмаган шигырьнең башында өлгергән юлларын аерым җылылык белән кабатлый торган иде...

Апрель урталарында Г. Кутуй госпитальгә керде. Редакция урнашкан поезд 18 нче апрельдә Германия җирендәге Топпер станциясе янына күчте. 22 нче апрельдә мина Познаньга самолетта кире очарга туры килде. Типографиядә йомышларымны бетердем дә, аннан ерак булмаган бер бакча эчендәге Гадел яткан госпитальгә ашыктым. Озын коридордагы 7 нче бүлмәне күрсәттеләр. Керүем белән мин аның кроватена таба ашыктым, без кочаклаштык. Палатадагы башка авырулар тынып калдылар, алар барысы да эчке ак бельедан, тик Гадел генә буйлы халат-костюмнан. Мин кергәндә, ул кроватенда мендәргә сөялеп утыра иде. Кәефе күтәрелеп китте, елмаеп җибәрде. Минем кулларымны тоткан килеш, чын күңелдән шатланып, ул нәрсәләрне генә сорашмады! Берлингә барырга ашыгуын, тик врачлар гына рөхсәт итмәвенә зарланды. Без, җайлап, озын коридор буйлап бакчага чыктык, скамьягә утырдык. Көн аяз, җылы, матур. Күктән төрле якка безнең самолетлар үтеп тора. ...Ул көнчыгышка очкан самолетларга карап, балаларча елмаю белән, миңа туган якларына һәм Галимә, Рөстәмнәр исеменә сәлам тапшырырга куша, туган илен, якыннарын, дус-ишләрен сагынуын сөйли... Хәзер инде Кутуйның тавышында ниндидер басынкылык сизелә, ләкин күңеле шат. Аның ышаныч белән янган күзләре никтер түбән таба карыйлар. Ул әле генә нәрсәдер хакында сөйләп бетергән сыман: "Әйе",—дип тора да, әкрен генә тавыш белән:

*Безне озаткан сукмакларны*
*Капламасын үләннәр,*
*Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,*
*Сез көтегез, сөйгәннәр!—*

дигән юлларын кабатлый...

Безнең янга инде сестралар килеп китте, ә без һаман утырабыз. Ул Самед Вургунның шигырьләреннән "Ах, гомер ничек кыска, ничек юл озын!"—дигән сүзләрен хәтерләп ала һәм ике-өч көннән, врачлар сүзенә карамастан, госпитальне ташлап, Берлинне алуда катнашачагын әйтә...

Гадел, чыннан да, 27 апрельдә автоматын ала (автоматын ул газета исеменнән командировкаларга чыкканда да калдырмый иде), үтеп баручы бер машинага утыра да, илләр язмышы хәл ителгән җиргә килә, Берлинне алу һөҗүмнәрендә катнаша һәм шунда җиңү тантанасына үзенең барлык көчен, күкрәк сулышын һәм йөрәк ялкыннарын биреп, бөтенләйгә хәлдән тая...

Шул вакытта Берлин өстендә җиңү байрагы җилфердәде. Гариф Галиев белән бергә рейхстагның җимерек стеналары буйлап йөргәндә, ташларга язылган меңләгән исемнәр арасында "Кутуй" дигән исемне укыдык. Аны кем язганы билгесез иде. Әмма кем генә булмасын, ул—"Без—Сталинградчылар", "Сагыну", "Тапшырылмаган хатлар" белән рухланып, халыкларны фашизмнан азат итә-итә Берлингәчә килеп җиткән совет солдаты иде...

*1946, № 6*

Гадел Кутуй

# САГЫНУ

НӘСЕР[1]

Мин чит илдә гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава житми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнен энже чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген мина шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып, сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Невасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларнын суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнен бер йотым суын да мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин Карпат тауларына мендем, Финляндия күлләре янында ял иттем. Ләкин Эльбрус шикелле мәһабәт, Казбек шикелле гүзәл тауларны, үз илемдәге Аккош күледәй сихри күлләрне очратмадым.

Синдәгедәй илаһи матурлык, синдәгедәй шагыйранә мәһабәтлек бер жирдә юк, туган ил!

Мин чит авыллар һәм чит шәһәрләр аша узам. Жину мине Берлинга алып бара. Чит ил балалары мина бәйләм-бәйләм чәчәкләр сузалар, чит ил картлары мина хәмер тәкъдим итәләр, чит ил кызлары мина, жимеш өндәп елмаялар һәм ялваралар:

— Син безне үлемнән коткардын, инде кил, чибәр егет, кунак бул, бездә кал! — диләр.

Әмма мин елмая алмыйм, чөнки хәмерләре исертми, елмаюлары жылытмый. Мин юлымда дәвам итәм.

Мин газиз илемне, аның ямьле бәйрәмнәрен, аның талган аякларны да биетә торган хәмерләрен, йөрәккә жылы өргән нечкә билләрен сагынам, гөнаһсыз балаларын күргәндәй булам.

Сагынам, бик сагынам сине, туган ил!

Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, жинүче булып йөрим. Мина һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба нигез корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм шунда тизрәк кайтып керер өчен, Берлинга ашыгам. Берлинга мин илем белән аерылышу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен чиксез ачу белән барам. Ачуым шул кадәр көчле, сагынуым шундый татлы ки, мин түзмим, жырлап жибәрәм:

*Иле ямьсез, суы тәмсез,*
*Өйгә кайтасым килә!*

Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренен иң матур жырларын жырлыйлар. Әмма минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл Мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән, сагынасыңмы, дип сорыйлар. Минем бугазыма төен тыгыла. Мин төенне йота-йота жавап язам:

*Телеграм баганасы—олы юлда маяк ул,*
*Сагынасыңмы дип сорыйсың—сагынмаган кая ул!*

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Сине сагынган саен миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп мин ачык аңладым: совет кешесе өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк һәм үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине,

Изге туган ил!

[1] Г. Кутуйның бу нәсере үз вакытында радио аркылы тапшырылган иде. Матбугатта беренче тапкыр чыга. Ред.

*1946, № 6*

## Зәки Нури:

***—Ничектер туры килеп, без журнал белән бер тирәдәрәк туганбыз: инде менә илле яшьтәгеләр булып чыктык... Ләкин дөресе шул: журналга мин инде сугышка чаклы елларда ук шигырьләр, ә соңыннан исә шигырьләр белән беррәттән тәрҗемәләр, рецензияләр, мәкаләләр һәм очерклар җибәрүдән һәм 1968—1971 елларда аның баш редакторы булып эшләүдән башка, бернәрсә дә бирмәдем кебек. Киресенчә, ул үзе миңа, барыбызга да биргәнчә, бик күпне бирде. Саный калсаң, чыннан да аз түгел бит! Беренчедән, әдәбиятыбызның иң яңа һәм иң яхшы әсәрләрен ай саен килеп торган яңа саннардан вакытында укып бару мөмкинлеген безгә шул журнал бирде һәм бирә. Икенчедән, миңа, әле башлап кына язучы бер үсмергә, язучылар исеменнән Кави Нәҗми, Гомәр Бәшир, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Сибгат Хәким имзалары куелган хатлар алу бәхетен шул журнал китерде. Өченчедән, берәр язганың басылып чыкса—түбәләремне күккә тидереп шатлану минутларын мин шул журналны алгач кичердем. Дүртенчедән—минем өчен, бәлки, аеруча истәлекледер бу—Белоруссиягә, Константин Заслонов җитәкләгән партизаннар берләшмәсенә, самолет белән килеп төшкән берничә журналны поход биштәремә салып, патрон белән бер дәрәҗәдә кадерле итеп йөрткән куанычлы көннәр һәм атналар гомер-гомергә онытылмастыр шикелле...***

*1972*



Афзал Шамов

# ЖУРНАЛНЫҢ БЕР НӨСХӘСЕ[1]

Бөек Ватан сугышы елларында без, фронттагы язучылар, “Совет әдәбияты” журналының һәр санын бик сагынып, зарыгып көтеп ала идек. Безнең өчен бик кадерле кунак иде ул. Аның яңа саны килгән саен көннәр күңелле бер бәйрәмгә әверелә иде дисәм дә, арттыру булмас.

Кызганычка каршы, журналны тәртипле рәвештә ала алмый идек. Хәрәкәттәге армиядә подписка юк иде. Бары бандероль белән генә килә иде ул безгә. Ул еллардагы журнал редакциясе коллективына һәм Язучылар союзы җитәкчеләренә рәхмәт, алар фронттагы татар газеталарын онытып бетермиләр, журналның яңа саннарын җибәргәләп торалар иде.

Шулай да 1943 елны журналны алдыруда шактый зур өзеклек булды. Тылга, каләмдәш иптәшләребезгә хатлар язып, ялынып, ялварып та алдыра алмаган чакларыбыз булгалады. Андый вакытларда журналның яңа санын гына түгел, хәтта күптәнге саннарын күрү өчен дә әллә ни бирергә әзер идек без.

Журналның чираттагы саннарын күрергә сусап йөргән шундый айларның берендә, әле дә хәтердә, сентябрьдә, хәзер Бөек Ватан сугышы тарихында “1943

[1] Кыскартып басыла. *Хәз.*

елдагы Смоленск операциясе" дип аталган каты сугышлар барган көннәрдә, алгы сызыкта бер лейтенант мина, сүз ара сүз чыгып:

—Безгә моннан бер ай чамасы элек "Совет әдәбияты" журналы килде,—диде. Бу хәбәр мине бик кызыксындырды: "Аларга килгән, ә безгә юк".

—Кайсы саны?

—Май саны.

Бу санны күргәнем юк иде. Мин сорашуымда дәвам иттем:

—Кемгә килә соң ул сездә?

—Мәхмүд Максудов дигән сугышчыга килгән булган.

Бусы инде минем өчен чамадан тыш гаҗәп хәбәр булды. Мин, лейтенантым янымнан китеп бармасын дигәндәй, аның портупеясыннан тотып алдым.

—Кем соң ул Максудов? Язучы Мәхмүд Максуд түгелдер бит? Капитан?

Егет гамьсез генә җавап кайтарды:

—Кем белгән аны.

Ә минем сорауларым артканнан-арта бара иде: кайда ул Максудов? Кем булып хезмәт итә? Күргәнең бармы? Төсе-бите, кыяфәте ничегрәк?

Дустым Мәхмүд Максудтан күптән хат юк иде. Аның тылдагы хәрби частьтан фронтка киткәнен ишеткән идем, ләкин кайсы фронтка икәнен белми идем. Шуңа күрә бу исем мине бик кызыксындырды. "Безнең фронттамы икән әллә?"—дип уйлап алдым мин.

Лейтенант бу юлы да сорауларыма күңелне канәгатьләндерерлек җавап бирмәде.

—Батальоныбызда андый офицер юк,—диде ул һәм шунда ук өстәп әйтеп куйды:—Хәер, кем белә аны? Бәлки, булгандыр да. Мондый каты сугышларда бүген киләләр, иртәгә китеп тә баралар. Күбесе дөньядан ук китә. Нишлисең, сугыш.

—Батальоныгызда булмаса, полкыгызда яисә дивизиягездә Максудов дигән офицер юкмы?

Егет батальондагы офицерларны гына белә икән.

Ахырда мин, Мәхмүд Максудовның кем икәнен, аның хәзер кайдалыгын полк яисә дивизия штабында ачыкнармын дип уйлап, соңгы соравымны бирдем:

—Ул журнал кайда соң? Мина биреп тора алмыйсынмы?

Кызганычка каршы, биреп тора алмый икән. Оборонада торганда журнал батальондагы татар сугышчылары арасында кулдан-кулга күчеп йөргән, аны аерым-аерым да, җыйнаулашып та укыганнар. Ә хәзер ул күрше батальондагы татар сугышчыларында икән.

Лейтенантның әйтүенә караганда, сугышчылар аны бик кызыксынып, яратып укыганнар, хәтта ул татар сугышчылары арасында хәрби-политик тәрбия алып бару өчен кулланма булып та хезмәт иткән. Сугышчылар аны тылдан, туганнарыннан, әти- әниләреннән килгән хат кебек итеп укыганнар.


Эзли торгач, ул журналны мин күрше батальоннарның берсеннән таптым. Табуы ансат булмады. Дөресен әйтергә кирәк: бик авыр булды. Каты һөҗүм сугышлары барган көннәрдә аерым сугышчыларны гына түгел, хәтта син күрергә теләгән офицерларны табуы да, алар янына бару да бик читен иде. Ике арада өзлексез ут астында тотылган, снарядлар, миналар белән актарылып, пулялар белән мыжлап торган территория ята иде.

Шулай да мин әлеге журналны табу бәхетенә ирештем. 1943 елда чыккан 5 нче санның бер нөсхәсе иде ул.

Гадәттәге нөсхә. Сугыш елларындагы начар сыйфатлы саргылтсу кәгазьгә басылган. Буявы шактый тонык. Хәреф хаталары да җитәрлек. Шулай да аның тышкы күренеше, торышы һәм язмышы кызык иде.

Тышлыгын ертып алганнар. Әлеге лейтенантның әйтүенә караганда, аның эчке ягы буш булган, ягъни анда бернәрсә дә басылмаган. Кәгазь юклыктан йөдәгән сугышчылар моңа бик шатланганнар, шунда ук аны ертып алып, тылга, әти-әниләренә, туганнарына хат язганнар. Ике хатка җиткән, ике кешене бәхетле иткән.

Журналның текстлы өлеше беренче битеннән алып соңгы битенә кадәр тулысынча сакланган. Әмма ул, укыла-укыла, кулдан-кулга йөри-йөри, шул кадәр тузган, таушалган, күпереп, калынаеп киткән, аерым юллары хәтта танымаслык


„Совет әдәбияты" № 5. 1943 ел. XI нче ел чыга

ЭЧТӘЛЕК


| | Бит |
|---|---|
| Верховный Баш Командующий приказы № 195. Май, 1943 ел. Москва шәһәре | 3 |
| *Шигырьләр, хикәяләр, пьесалар, поэмалар* | |
| Нурый Арсланов шигырьләре. 1. Яз жыры. 2. Ышаныч. 3. Сугышчы төше | 7 |
| Хатип Госман. Мәче баласы. Хикәя | 9 |
| Г. Бәшир. Мунча. Хикәя | 12 |
| Фатих Кәрим. 1. Үлем уены. Поэма. 2. Дулкын белән сөйләшү. Шигырь | 16 |
| Фатих Хөсни. Чүлмәк түбәле өйдә. Хикәя | 21 |
| Сибгать Хәким шигырьләре. 1. Йолдыз. 2. Урман | 23 |
| Әхмәт Юнус шигырьләре. 1. Воронеж фронты гаскәрләре. 2. Кыз. 3. Бала хаты. 4. Язгы тойгы. 5. Юл жыры. 6. Гөл жыры. 7. Партизан жыры | 24 |
| Әнәс Камал. Беренче апрель. Пьеса 1 пәрдәдә | 29 |
| Ж. Тәржеманов. Ике хат. Шигырь | 42 |
| Гази Кашшаф — Ижтимагый моннар жырчысы | 43 |
| *Ватан сугышы кырларында* | |
| Жәүдәт Хәбибуллин. Белоруссия урманнарында. Партизан язмалары. (Дәвамы) | 50 |
| Риза Ишморат хикәяләре. 1. Зөбәйдә. 2. Изге хис. | 56 |
| М. Максуд. Чериднен хатлары. Очерк | 62 |
| Э. Виленский. Белоруссия улы. (Дәвамы) | 66 |
| Х. Гимади. Урта Идел буе халыкларының татар-монгол игосына каршы көрәше тарихыннан | 71 |
| Ш. Рамазанов. Гыйкад Нугайбек | 85 |


Редколлегия: Шәриф Камал, Тажи Гыйззәт, Гомәр Разин, Хәсән Хәйри һәм Гази Кашшаф

Җаваплы редактор: Гази Кашшаф

Техник редактор: Әнәс Камал

хәлгә житкән иде,—кыскасы, иң бәхетле, иң укылган китап язмышын башыннан кичергән иде ул...

Соңыннан билгеле булды: редакция чыннан да бу журналны көньяк фронтларның берсендә хезмәт итүче язучы Мәхмүд Максудка жибәргән булган икән (бу санда аның "Фәриднең хатлары" исемле очеркы да басылган иде), ләкин полевая почтаны күрсәткән цифрларның берсе ялгыш язылу аркасында ул әдип кулына барып кермәгән, ә бөтенләй икенче якка китеп, Калинин фронтындагы бер батальонга эләккән һәм шунда аның бик кызыклы язмышы башланган.

*1972, № 5*

***1943 елгы шул 5 нче санның "Афзал Шамов китапханәсе" дип штамп сугылган нөсхәсе редакция архивында саклана. Әдипнең кызы Әлфия ханым бүләге бу.***

***Хәзер сезгә "фронт күчтәнәче"— фронтта язылып, шул санда басылган бер хикәя тәкъдим итәбез.*** Хәз.

# Хатип Госман

## МӘЧЕ БАЛАСЫ

ХИКӘЯ

Төн. Мохтар сугышчан сакчылыкта. Табигать ваемсыз йокыга талган. Әмма сугыш тынмый: әле анда, әле монда кинәт пулемет яки автомат тыкылдап куя.

Мохтар яшеренгән һәм аның бурычы—күзәтү. Ул шылт кына иткән тавышка да, үләннең аз гына селкенеп куюына да сискәнеп китә: дошман—елан шикелле, аның шуышып килүе мөмкин...

Үлән селкенеп куйды. Мохтарның тәненнән эссе дулкын жилпенеп үткән кебек булды. Ул мылтыгын ныклабрак тотып, тирә-ягын тагын да нечкәләбрәк күзәтергә кереште.

Үләннәрне иплән кенә аера-аера, аларга саклык белән генә таяна-таяна, чыннан да кемдер килә иде... Мохтар, аның хәрәкәтләнүен озак кына тыңлап яткач, "монда кеше барлыгын сизмәде, тереләй алам,"—дип карар кылды.

Теге һаман якыная бара иде. Менә бер заман ул тукталды. Берничә секунд үләннәр дә селкенмичә тордылар, вакыт тынычлыкта үтте.

Кинәт теге, зарлы гына итеп, мәче булып кычкырып жибәрде:

—Мыяу! Мыяу!..

—Бу ни тагын? Башкаларына сигнал бирәме?

Мохтар куркып китте, чөнки аның каршына кинәт зур кара шәүлә килеп чыкты. Мохтар мылтык курогын, күз ачып күз йомганчы, атар җайга корып өлгерде. Әмма шәүлә шул заман баягыдан да зарлырак итеп, тагын мыяулап куйды.

Мохтар игътибар беләнрәк караса, аның алдында зур кара шәүлә түгел, бәлки салкын чыкка чыланган тәпиен "Өшеде!" дигән төсле бик кызганыч төстә аз гына күтәреп, мәче баласы басып тора иде. Ул, кеше барлыгын сизгәч, тагын да кызганычлырак итеп, нәни авызын сузып ача-ача:

—Мыяу! Мыяу!—дип кабатлады. Мохтарның хәләте кинәт үзгәреп китте, ул үзен эсседән кисәк суыкка ташланган кебек хис итте—тәнендә салкын тир тоеп, чирканып, "эвв" дип, суыксып куйды. Ул, мәче баласын орышып, эченнән генә: "Ах, котымны алдың, мәхлүкъ,"—диде. Шулай да ул аны үзенә ымлады. Мәче баласы үләннәр арасыннан бик нәзакәтле, пөхтә генә атлап килде дә, исним дип нәни һәм салкын борынын Мохтарның кулына, иркә генә итеп, берничә кабат төртеп-төртеп алды.

Мохтар аның янадан мыяулый башлап, дошман игътибарын җәлеп итүеннән курыкты, аны тотып алып, тиз генә җылы куенына тыкты. Мәче баласы куанып, бик тәмләп "мыр-мыр" итә башлады һәм, озак та үтмәстән, йокыга китте...

Көндезен, блиндажга кайткач, Мохтар аны тезенә алып, бик яхшылап туйдырды. Командир, аны күргәч:

—Каян алдың?—дип, гаҗәпләнеп сорады.

—Секреттә торганда, яныма килеп чыкты.

—Ә! Наратлыдандыр...

Наратлы моннан 300 метрда гына, немецлар кулындагы авыл иде. Бу авылны алар тетеп, туздырып бетерделәр. Тик авылның түбән очында гына, нишләптер, әлегә кадәр ике-өч өй бөтен килеш исән торалар иде.

Мәче баласы бик арык; аның көл төсле, күгелҗем-соргылт җоннары киезләнеп беткән иде. Берничә көн эчендә ул көрәйде, җоннары да тәртипләнеп, елкылдап тора башладылар. Ул, блиндаж эчен ду күчереп, көннәр буе уйный торган булып китте. Аның нинди дә булса йомычканы тырнакларына эләктереп алып, идәндә ауный-ауный уйнавын, аннан аны кинәт атып бәреп, сикереп торуын һәм койрыгын орчыктай чәнечеп, бер читкә чабып китүләрен Мохтар буш вакытларында сәгатьләр буе карап утыра торган булды. Мондый чакларда ул сөйләшми дә, кешеләрнең сүзләрен дә ишетми. Аның күз алдында бик чиста итеп җыештырылган өй күренеше ачыла, уртада ап-ак мич утыра. Мич тирәләй аның яшь ярымлык Зөбәере белән мәче баласы чабышып уйныйлар. Зөбәер бау өстерәп йөгерә. Мәче баласы, бер почмакка посып, бауның очын күзәткән хәлендә, идәнгә ышкынып, сабырсызланып утыра да, кинәт сикереп чыгып бау очына һөҗүм итә, аны эләктереп ала, тешли. Ул, шулай бауга ябышып, идәннән өстерәлеп бара. Ә Зөбәер көлә, буылып-буылып көлә, ана кызык була. Ул: "Эти, күрдеңме?"—дигән төсле итеп, чиксез шатлык белә атасына карый. Аның шомырт кебек кара, нәни күзләре бөтенләй йомылып бетә язалар, ул, нәни авызыннан энҗе бөртекләре сибелгән төсле итеп, һаман көлә. Аның көлүе ата күңеленең иң тирән җирләренә үтеп, аның шатлык, соклану һәм бәхет хисләрен уяталар. Ата: "Улым..."—дип үзенең киләчәккә булган иң яхшы өметләре турында уйлый. Ә мәче баласы баудан кинәт ычкынып, сикереп тора да, койрык чәнечеп, Зөбәерне тагын узып китә. Зөбәер, бавын өстерәп, тагын аның артыннан чаба... Ата баласының ике бөртек ахак төймә төсле нәни үкчәләрен, кыска һәм нәни җилкәсен елмаеп карап кала...

Кемдер берничә кабат,

—Мохтар!.. Мохтар!.. Мохтар дим! Командир чакыра!—диде.

Мохтар хыялларыннан кинәт уянып китте. Хыялый картиналардан бары уйнап йөргән мәче баласы гына калды. Өй сурәте блиндаж күренеше белән алмашынды, ә Зөбәере аннан меңнәрчә километрларда икәне исенә төште.

Мәче баласы үзенең шуклыгы белән бөтен бүлемчәгә танылды. Ул һәркайда булырга өлгерә. Кайчакларда немецлар белән безнең ике арадагы зонага чыгып йөри, үләннәрне селкетеп үтә. Үләннәр селкенүе немецларны шиккә төшерә ахыры,

алар мәче баласы үткән җирләргә мина яудырырга, автоматлардан, пулеметлардан атарга тотыналар. Ә мәче баласы чабып китә дә, берәр окоп яки траншея өстенә чыгып, бик сөйкемле кыяфәт алып утыра, башын кыңгыррак салып, колакларын торгызып, эз калдыргыч пуляларның очуын күзәтә. Алар аның яныннан үтеп киткәндә, аларны тотарга омтылып, бик җитез генә, сыңар тәпие белән һаваны көрәп ала. Ул аларны сары күбәләкләр дип уйлый булса кирәк...

Шау-шу басылгач, блиндажларда мәче баласының батырлыгы турында көлә-көлә сөйлиләр. Ә ул, кемнеңдер ишек ачкан чагында, аның аяк араларыннан сиздерми генә эчкә үтә дә, бик әдәпле, бик тыйнак кына булып, Мохтарның тезенә менеп утыра. Ул арыган һәм гаепле бер кыяфәт белән, акыртын гына:

—Мәәәәү!—дип, ашарга сорый. Үзе турында барган сүзләргә аның бер генә дә исе китми, ул акыртын гына күзләрен йома башлый...

Кинәт мәче баласы югалды. Бер көн кайтмады, ике көн кайтмады... Мохтарның күңеле кителгән кебек булды. Аның сөекле Зөбәерен исенә төшерә торган бердәнбер җан иясе юкка чыкты. Мохтар көннәрен яшертен бер сагыш эчендә үткәрде. Бер көн һөҗүмгә күчү турында приказ алынды, тик шул гына Мохтарга яңадан дәрт кертеп җибәрде.

Беренче атака ясалгач ук, немецлар Наратлыны ташлап кача башладылар. Түбән очтагы өйләр дөрләргә тотынды—аларга немецлар ут төртеп киттеләр. Мохтар, мылтыгын атар яки кадар җайга тотып, янган өйләргә таба чапты. Ул аларга якынлашкан да иде инде, шул чак чыбылдыктай зур ялкын кинәт Мохтар өстенә җилпенеп куйды. Мохтарның каш һәм керфекләре чытырдап киттеләр. Ул, битенкүзен беләге белән каплап, бөгелә төште һәм тиз генә кире чигенде. Ул, утны кырыйлап үтеп, өйнең теге ягына барып чыкты һәм кинәт тукталып калды: аның каршысына чәчләре тузгыган, шашынган бер хатын чабып килә һәм йөрәк өзгеч итеп кычкыра иде:

—Баламны!.. Баламны үтерделәр!.. Баламны!..

Мохтар анар ярдәмгә йөгерде. Хатын кочагында ак биләүсәгә төргән бала, ә ак биләүсә аркылы, киң җәелеп, кып-кызыл кан саркылып тора иде.

— Немецлармы?

Хатын җылап җибәрде:

—Өеңнән чык, яндырам дип җикеренде... Чыкмагач, балама атты... Баламны...

Хатын күз яшенә буылды. Мохтар: “бәлки үлмәгәндер әле,”—дип, баланы үз кулына алды һәм биләүсәне чишеп җибәрде. Ачылган күренеш Мохтарга кинәт яшен суккан кебек тәэсир итте: сабый әлеге мәче баласын кочаклап үлгән; немец пулясы мәченең башыннан, баланың күкрәгеннән үтеп чыккан иде. Мохтарның, “кылт” итеп, Зөбәере исенә килеп төште. Аның йөрәген сызландырып, ачуы кайнап чыкты:

—Кай якка китте? Каның эчәм мин ул бәдбәхетнең! Кай якка китте?—Хатын немецлар качкан якка кулын изәде. Мохтар баланы хатын кулына тапшырды да, немецларны куа китте. Ул ашыга, аның тыны буыла, ләкин ул берүк сүзләрне кабатлый-кабатлый, чабуында дәвам итә иде:

—Сабыйлар каны коткармас!.. Минем улыма да үрелергә тели торгансыздыр әле... Булмас!.. Сабыйлар каны коткармас сезне, кара йөрәкле бәдбәхетләр!..

*Хәрәкәттәге армия*
*Апрель, 1943.*

*1943, № 5*

Илья Эренбург



# ТАТАРЛАР[1]

Донда артиллерист Хәсәнов Татарстанны яклый. Аның бите янган, көйгән. Дошман безнең батареяны тупка тота иде. Сугыш припаслары саклана торган сарай яна башлады. Хәсәнов уйлап-нитеп тормады. Ул йөзләп снарядны читкә алып китте. Ут аның битен һәм кулларын яндырды. Ә Хәсәнов әйтә: "Иң кирәге—снарядлар... Инде немецларны без көйдерәбез..."

Алар Татарстаннан, Башкортстаннан, Уралдан, Идел буйларыннан килгәннәр—һәйбәт солдатлар, кыюлар һәм хәйләкәрләр. Фронтта: "Бу—татар, сынатмас ул",—дигән сүзләрне еш ишетәсең.

Гафиятулла Нигъмәтуллин—снайпер. Ул әйтә: "Мин гади фрицны да кыйныйм, әмма офицерларны һәм корректировщикларны кыйнау аерата куанычлы. Болар—ләгънәт төшкән шайтаннар..."

Иптәшләре анардан: «Нәрсә соң ул шайтан!"—дип сорыйлар. Гафиятулла көлә: "Фриц ни, шайтан ни—икесе бер—фашист".

"Ал кирәгеңне, шайтан",—дип кычкырып җибәрде дә Мөхәммәтшәриф Хафизов немецның башына приклад белән ямады. Кулга кул килеп сугышканда татар ачулы, һәм немец ефрейторы Рудольф Вольгангның үзенең кардәшләренә зарлануы юкка гына түгел: "Монда безгә каршы татар күп. Болар шашкан халык, һәм мин татар белән хәтта төшемдә дә очрашырга теләмәс идем".

Әбүбәкиров үзенең кәләше Зөһрәгә: "һәр көн саен бер немец үтерергә сина сүз бирәм",—дип язды. Зөһрә белә: аның сөйгәне алдамас. Татар гвардеецлар—татар кызларының намусы өчен сугышка баралар. Татар егетләренең зәңгәр шәл турында үзләренең җырлары бар. Һәм Байкузин җырлый:

*Бибкәй матур суга бара,*
*Зәңгәр шәлен ябынган,*
*Яратса да, күзен салмый*
*Узып китә янымнан.*

Юк, егет сугыштан кайтып: "Мин Ленинград янында сугыштым. Без шәһәрне саклап калдык. Без сине саклап калдык, чибәр Бибкәй",—дигәч, Бибкәй Байкузинга карар.

Татар карты Сөнгат Гыйниятуллин улын сугышка озатканда: "Батыр бул, улым, Гыйниятуллиннар семьясын кешеләр хөрмәт итәрлек булсын",—диде.

Зиннәт Гыйниятуллин Ленинград янында сугышты. Немецлар йөз, безнекеләр тугыз кеше иде. Зиннәт Гыйниятуллин чигенмәде. Ул батырларча корбан булды. Аның батырлыгын Ленинград исендә саклый, һәм бөек шәһәр карт Сөнгат Гыйниятуллинга әйтә: "Синең хәсрәтең—минем хәсрәт һәм синең горурлыгың—минем горурлык".

Татар егете Нурый Хәлиуллин нәрсә өчен сугыша? Ул сугышка кадәр ничек торганлыгын бик куанып сөйли: "Яхшы тордым... Бездә бодай менә нинди була!.. Ике сыер. Колхоз ат бүләк итте. Яхшы ат, аксыл кола ат..." Нурый Хәлиуллин нәрсә өчен сугыша? Ул уйчан гына итеп әсти: "Татарлар—горур халык. Без немец коллыгын теләмибез, азатлык сөябез".

Менә сугышчылар атакага баралар. Нурый Хәлиуллин белән беррәттән рус бара, чуваш Ларионов һәм Нурыйның дусты—немецлар пленлыгындагы Конотоптан килгән Гриценко бара. Алар һәммәсе дә немец өстенә баралар. Һәммәсенең дә баш

[1] И. Эренбургның бу мәкаләсен журналга А. Айнетдинов тәкъдим итте.

очында, яшендәй булып, рус "ура"сы күкри. Иртәнге кояштан озын шәүләләр төшә, һәм сугышчылар белән бергә, шәүләләр сыман булып, аларның якыннары да баралар төсле тоела. Ә анда нәрсә шәүләсе? Азатлык шәүләсе. Горур кешеләр азатлык өчен һәм Ватан өчен сугышалар. Нурый Хәлиуллин татар егете һәм ул сынатмас.

Йөрәкне сүзләрдән дә көчлерәк ялкынландыра торган саннар бар: 85—Садыйк Гомәров сиксән биш фрицны үтерде. 56—Әхмәт Иштирәков сугыш кырыннан яраланган илле алты сугышчыны һәм илле алты мылтык алып чыкты. Ике гвардеец ничәмә рус кешесенең тормышларын коткарып калды!

Сержант Алексей Федорович Сибатилов миңа яза: "Гади рус сүзләре өчен сезгә рәхмәт, алар йөрәккә барып житәләр. Безнең Ватаныбыз нинди куркыныч эчендә икәнен без беләбез. Немецларга без пуля кызганмыйбыз. Ләгънәт төшкән немецларны без кырып бетерербез". Һәм минем сержант Сибатиловка җавап бирәсем килә: аның сүзләре минем йөрәгемә килеп життеләр, һәм мин аның пулялары немец йөрәгенә житәчәкләренә ышанам.

Бар иде ике дус: Гобәй Гафиятуллин һәм Алеша Огородников—ике кыю пулеметчы. Алеша—Смоленск ягыннан, ә Гобәй—Татарстанның Карамалы авылыннан. Алар турында иптәшләре: "Хәзер аларны ут та, су да аера алмас",—диләр иде. Немецлар һөҗүм иттеләр. Алеша Огородниковны пуля аяктан екты. Гобәй ялгызы калды. Ә немецлар инде биш саженьда гына. Гобәй сөйли: "Мин Алешага карап алдым. Ул ята. Юк, совет кешеләре чигенмиләр! Минем дисклар бетте. Мин, сүгендем дә, гранаталарга тотындым. Немецлар белән мин озак сугыштым. Ахырда фрицлар чыдый алмадылар, качтылар..." Траншея каршында утыз немец үләксәсе ятып калган иде: Гобәй Гафиятуллин Алеша өчен үч алды.

Аларны хәзер ут та, су да аера алмас... Дуслык—бөек хис. Турылыклы дус һәммәсеннән кыйммәтле. Руслар белән татарлар гасырларча бергә яшәделәр, бергә хәсрәт чиктеләр, бергәләп шатлык күрделәр, дөньяның ачысын-төчесен бергә татыдылар һәм аларны хәзер инде ут та, су да аера алмас. Сугыш—каты, дәһшәтле эш. Без, немецлар кебек, сугышны: "Иң яхшы эш",—димибез. Без тыныч хезмәт яратабыз, безнең гербта урак һәм чүкеч. Әмма безнең халкыбыз—батыр халык, ул тыныч кырларын кулына корал тотып яклый. Ул хәзер уракны кызга, чүкечне хатынга тапшырды, ул рус мылтыгыннан аерылмый. Ул ләгънәт төшкән басып алучыларны кырып бетерергә карар бирде, һәм ул аларны кырып бетерәчәк. Сугышта күп нәрсәнең асылы ачыклана. Сугыш—ул кешеләрнең хисләрен тикшерә торган лаборатория. Сугыш—югары дәрәҗәле дуслык чоры. Окоптагы кешеләр—дуслар, һәммәсеннән дә—якыннарыннан да, кардәшләреңнән дә кадерлерәк. Дустың өчен үз тормышыңны бирерсең һәм, икенче тормышым булса, анысын да дустым өчен бирер идем дип, икенче тормышың булмаганга үкенерсең. Шайтан-фрицлар өстенә дуслар—рус һәм татар баралар. Аларның дуслыгы утта сыналган. Аларның дуслыгы—немецларның үлеме ул[1].

*"Казан утлары", 1970, № 5*

*Журналыбыз турында*

## Габдрахман Әпсәләмов:

***—Мин журналга бөек Ватан сугышы алдыннан килдем һәм аның аппаратында эшли башладым. Журналны халык никадәр яратканын сугыш елларында үз күзем белән күрдем. Бу хакта фронттан кайткач, "Кызыл Татарстан" газетасында "Совет әдәбияты" журналы турында "Солдат хатлары" дигән мәкалә дә бастырган идем. Гаҗәп ул хатлар! Куе урман эчләрендә хәрәкәт иткән безнең подразделениеларга почтаны да самолеттан гына ташлыйлар иде. Бер вакытны почта капчыгы "битараф" җиргә килеп төшә. Безнең сугышчылар дошманның көчле уты астында аны үзләренә алып кайталар, аннары саз суында чыланган "Совет әдәбияты"ның һәр битен учак яктысында киптереп, солдатларга кычкырып укыйлар...***

*1972*

[1] "Ватан өчен" газетасы. 1942 ел, 3 ноябрь.

# ТАТАР ЯЗМЫШЫНА КИЗӘНГӘН КАРАР

Ватан сугышында уңышларга ирешә башлау белән Сталин канатланып, тагын үзенең яраткан кәсебенә — репрессияләү эшенә тотына. Аерым кешеләрне утырту, үтерү белән чикләнмичә, кайбер халыкларны тоталь рәвештә җәзалау юлына баса: рус-славян булмаган кайбер халыклар үз җирләреннән сөрелә.

Идел буе татарлары да чиратта булган. Ләкин биш миллионнан артык, өстәвенә бөтен СССР буйлап таралган халыкны җыеп алу мөмкин булмый. Большевиклар атасы барыбер үз ниятеннән кайтмый: физик юк итү мөмкин булмагач, халыкны рухи яктан җәзалау юлын сайлый ул. ВКП (б) Үзәк комитетының 1944 елгы мәкерле карары шулай барлыкка килә.

Карардан максат халык тарихына балта чабу аркылы аның тамырларын корыту иде. Аның төп мәгънәсе бер кечкенә абзацтагы "Алтын Урданы үз заманының алдынгы дәүләте итеп бизәп күрсәтергә маташуны" тыярга дигән, нигездән ялган дәлилгә корылган хөкемгә кайтып кала. Идегәйдән карачкы ясап, тарихи шәхес белән фольклор образы буташтырыла.

Китә шуннан болай да начар өйрәнелгән тарихны тагын да ныграк бозулар. Менә исә "татарлар алар кыргый халыклар, явыз илбасарлар, русларны җәберләүчеләр" дигән уйдырмалар аша ирешелә. Йөз меңләгән тиражлы тарих дәреслекләре, кинофильмнар, "әдәби" әсәрләр, газит-журналларда тукып торулар эшкә җигелә.


ПРОПАГАНДИСТ

ЖУРНАЛ ЦК, МК и МГК ВКП(б)

АВГУСТ — № 15–16 1944 г.

СОДЕРЖАНИЕ

[illegible]

В ЦЕНТРАЛЬНОМ КОМИТЕТЕ ВКП(б)

[illegible]


Татарларның да бер өлеше әлеге басым астында, "без татар түгел" дигән карашка биреләләр, халык тарихын бер чорга гына кайтару, тарайту, димәк, бозып аңлату барлыкка килә. Шул рәвешчә халыкны үз асылыннан биздерүнең башка нәтиҗәләре җимеш бирә: татар балаларының тарих дәресләреннән соң "мин татар булырга теләмим!" дип елап кайтулары ни тора!

Тарихын белмәгән, белергә теләмәгән халык бер милләт булып яшәү сәләтен югалта — башкалар арасына кереп эреп бетә, юкка чыга.

"Халыклар атасы" татарлар өчен менә шундый явыз язмыш әзерли...

Ләкин тарих, кем әйтмешли, "куласа ул: бер әйләнә, бер баса".

Киләчәкле булырга теләсәк, тарихны гадел яктыртырга тиешбез.


[illegible] для целей радиовещания все телефонные установки в сельсоветах.

ЦК ВКП(б) обязал Татарский обком ВКП(б) организовать научную разработку истории Татарии, устранить допущенные отдельными историками и литераторами серьёзные недостатки и ошибки националистического характера в освещении истории Татарии (приукрашивание Золотой Орды, популяризация ханско-феодального эпоса об Идегее), обратить особое внимание на исследование и освещение истории совместной борьбы русского, татарского и других народов СССР против чужеземных захватчиков, против царизма и помещичье-капиталистического гнёта, а также на историю социалистического преобразования Татарии в период советской власти и популяризацию выдающихся деятелей, учёных и революционеров татарского народа и его сынов — героев Отечественной войны.

ЦК ВКП(б) обязал также Татарский обком ВКП(б) серьёзно улучшить руководство [illegible]

**М. ГОСМАНОВ**

*тарих фәннәре докторы,*
*КДУ профессоры.*

*2006.*



ТАТАР ХАЛЫК ДАСТАНЫ

ИДЕГӘЙ

Н. ИСӘНБӘТ ЖЫЙНАМАСЫ

Туктамыш хан белән Аксак Тимер [illegible] һәм Котлыкыя би белән углы Идегәйнең үлемгә хөкем ителгәне

[illegible]


«Идегәй» эпосы [illegible] 1940 ичы елда [illegible] «Совет әдәбияты» журналының 1940 ел 11, 12 саннарында, «Татар халык [illegible] «Идегәй» дастанының 500 еллыгы» [illegible] басылып чыкты.

*"Идегәй" дастаны (1940, №11) һәм ... ул тудырган шау-шу.*



Нәкый Исәнбәт

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕМНӘРЕНДӘ ТАРИХИЛЫК ҺӘМ ҮТКӘН БЕЛӘН ХӘЗЕРГЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

## КАЗАН АЛЫНГАННАН СОҢ, 1552—1700 ЕЛЛАР АРАСЫН ЧАГЫЛДЫРГАН ӘЙТЕМНӘРДӘН КАЙБЕР МИСАЛЛАР

АК ПАТША. Эпитет. Рус чары, рус патшасы димәк. Великорус дворяннарының Көньяк һәм Идел-Урал, Себер халыкларына патша булып, жир-суын теләгәнчә изептәлап яшәгәндә һәм Русиянең төп закон чыгару аппаратларында үзләре генә утырып, патшалык итеп торганда, башка халыклар алдында үзләренең аерым шәп ак тәнле, югары затлы расадан яратылган һәм шуңа күрә Россиядән башка төстәге, башка нәселдәге барлык халыкларга ак патша булырга үзләрен генә хаклы дип күрсәтү өчен таккан исемнәре.

АЛПАК ТА КЫСТЫЙ, КАЛПАК ТА КЫСТЫЙ. Ике яктан ике патшалык, икесе дә үз кул астына керергә я үзе яклы булырга кыстый димәктән. XVII-XVIII гасырларда Пугачев явына кадәр төрле-төрле исемдә халыклар күтәрелеше барганда, татар, башкортлар үз ягына, калмык-зангарлар үзенә, рус патшалыгы, казаклар яки поляклар үз ягына кушылырга өндәү алып барган заманнарда чыккан әйтем. Ягъни ике якның кайсына ышанырга, кайсы якта булырга белми торуга мисалдан әйтелә.

КЫРДЫН ПЫЧАГЫМНЫ! ПЫЧАК КЫРУ. Татарда пычак кыруга һәм гомумән пычакка бәйләнешле төрле әйтемнәр күп һәм бу сүзнең мондый формаларда кулланышы бик сәер. Мәсәлән:—Я, ни пычагым кырып килдегез анда? Ягъни, ни булдырып килдегез? (Дөресрәге, булдыра алмыйча килдегез мәгънәсендә.) Кырдын пычак! (Булдыра алмадын!) Күрден пычак! (Пычагымны да күрмәден! Ягъни бер ни дә күрмәден!) Мисал: "*Сиражетдин.* Күрдең пычак! Ул вакытта ул акчалар күптән кладовойда яталар иде". (Г. Камал.)

Кыру—монда бу сүз бер-берсенә каршы ике мәгънәдә: 1) кыру, вату-жимерү; 2) юнып-кырып агачтан, тимердән әйбер ясау. Кырмачы—борын бездә балта остасы (столяр)—агачтан кырып ясаучы һәм тимер кыручы (токарь). Борынгы болгарда металлургия (тимер, чуен, корыч кою) югары үскәндә, корычны кырып үткен пычак-кылыч ясау зур һөнәр саналып, эш булдыруга мисалдан эш кыру, пычак кыру мәгънәсендә әйтемнәр ясалган. Ягъни, кыру—вату, жимерү мәгънәсендә түгел, киресенчә, эш кырып йөрү—эш булдыру димәк. Урта гасырларда Идел буе болгарларының металлургиядә бу зур мәдәниятләре Европа халыкларына һәм күршеләре русларга тәэсирсез калмый, билгеле. Кузнец сүзе болгар-татарча утлы күмер, учак мәгънәсендәге куз, утлы куз сүзеннән, шулай ук русчадагы чугун сүзенен дә турыдан-туры татарча чуен сүзеннән алынган булуын, ягъни шул сүзләр белән бергә металлургия эшләре үзе дә болгарлардан күреп алынган булуын күрсәтә бу мисал.

Әмма хәзерге телдә "кырдын пычагымны" әйтеме элеккечә булмаганны булдыру түгел, бәлки булганны вату, кыру дигән тискәре һәм ироник мәгънә алып китүенең сәбәбе шул: Казан алынганнан сон татарга пычак-кылыч кебек кораллар йөртү тыела. Булган пычаклары кулларыннан тартып алынып, сындырыла, ватып-кырып ташлана

һәм һәр өйгә икмәк кисү өчен бер генә пычак калдырып, ул да стенага чылбыр белән кагып куела, татар икмәген шунда барып кына кисеп алырга хаклы була. Соныннан патша хөкүмәте тарафыннан бу хөкем бераз йомшартылып, кәсеп өчен балта-пычак тотарга рөхсәт ителсә дә, металлургия татарга тыелган килеш кала. Хәтта ат дагалау кебек иң гади тимерчелек һөнәре дә татар авылларында Октябрь революциясенә кадәр рус кузнецлары кулында булып килде. Шулай итеп, кайчандыр Россиягә металлургия һөнәре кертешкән, чуен-корыч койган болгар-татар балалары патша хөкүмәте кулында колонизацияләшү гасырларында үзләре балта-пычак, кылыч ясау түгел, әзер ясалганны да үз иркенчә тотарлык кодрәтләре дә калдырылмаганда, "пычак кыру" әйтеме дә бездә ироник тискәре мәгънә алып киткән. Пычагымамыни! Пычагыма кирәк! Пычагым калган, тагын анда барып йөрергә! Кырдың пычак! Күрдең пычагымны! һ. б.

ИШЕТМӘСӘҢ ИШЕТ, УРМАН АСТЫ КИШЕТ! Иске Кишет, Яна Кишет Казанга якын Дөбьяз як авыллары. Кайчандыр бу авыллар патшага баш бирмәгән, чукынмаган өчен җәза отрядлары китерелеп, розгалар суктырылып, төрлечә җәзалангач, татар арасына бу хәбәр һәркайда киң таралып, монарча нык билгеле булмаган Кишетләр кинәт мәшһүр булудан әйтем булып киткән сүз. Хәзер дә көтелмәгән яңалык булып телләрдә сөйләнгән ят бер хәбәр ишеткәндә: "—Менә, ишетмәсәң ишет, урман асты Кишет!" дип куялар.

ИШТЕН ИШЕК БАВЫН! Зур эш кырыр кебек өстенә эш алып тотынып та юк эш эшләп куйган кешегә карата—булдыксыз икәнсең, юкка көчәндең димәктән әйтем. Ишек бавы: Казан алынгач һәм татарларга тимерчелек эше һәм корал йөртү бөтенләй тыелгач, кичәге чуен-корыч койган һәм алтын-көмеш акча суккан болгар-татар балалары байтак вакытлар ишекләренә тимер тотка коюдан да мәхрүм ителгәч, тотка урынына ишеккә бер тишек тишеп, шуңа бау ишеп тагып, ике башыннан төенләп куелган. Бер як төенне тотып тартканда икенче як төен белән ишек тартылып ачылган һәм ябылган. Шуннан ишек бавы сүзе таралган. Белеп булмый, мондый баулы ишек бәлки тимерне башлап куллануга кадәр бик борынгы заманнарда да булып, татарлар шул гасырлар хәленә кайтарылганнан соң телдә дә кирегә кайтып яңадан активланган...

Иштең ишек бавын—ягъни шуны да булдыра алмадың, юк эш эшләдең димәктән. "Ишек бавы бер алтын, безнең апай мең алтын" (Г. Тукай). Кияү кергәндә бүләк сорап керту йоласы.

ПАДИШАҺЫМ СОЛТАНЫМ, ИСКЕ КӘВЕШ ОЛТАНЫМ! Әкиятләрдә патшаларга эндәшү алымы булган әйтем. Легендаларга караганда, Болгар-Казан ханлыгы алынгач һәм бер төркем татар әсирләренә Иван Грозный алдында бүреген салып "падишаһым солтаным" дип баш орып эндәшергә кушылгач, татарлар бүреген салган салуын, әмма ләкин түбәтәен салмаган һәм "падишаһым солтаным" дигәннең артыннан ук бу сүзгә ялгап, тиз генә йөзен аска бер яккарак чәвереп, "иске кәвеш олтаным!" дип әйтеп куйган һәм шуны гадәткә керткән булалар. Ягъни моның мәгънәсе: болгар-татарлар үзләре электән үгез күненнән болгарый олтан ясый белә торган халык, безне син тиз генә олтан ясый алмассың дигән сүз, имеш. Шуннан бирле татар әкиятләрендә геройлар патша алдына кереп бүрек салып "падишаһым солтаным" дип эндәшкәндә, бу сүзгә ялгап, "иске кәвеш олтаным" дигәнен дә төшереп калдырмыйча кушып әйтеп сөйләү гадәткә кергән.

*Казан утлары, 1979, № 12*

## Х Р О Н И К А

### КАЗАН ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫНДА ӘДӘБИ ТҮГӘРӘК

Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт Университеты каршында яшәп килгән әдәби түгәрәк 15 сентябрьдә үзенең быелгы беренче утырышын үткәрде. Утырышта түгәрәк бюросының, председателе иптәш И. Нуруллинның отчет доклады тыңланды, аннары яңа бюро сайланды. Яңа бюрога М. Хөсәен, И. Нуруллин, Л. Ихсанова, М. Сәгыйтов һәм Тимергалин иптәшләр керде. Түгәрәкнең беренче утырышында язучы Г. Кашшаф катнашты.

21 сентябрьдә түгәрәкнең чираттагы утырышында Л. Ихсанованың яңа әсәре—"Күңелле сәяхәт" исемле хикәясе укылды. Түгәрәк утырышында язучы Г. Бәширов катнашты.

*1947, № 9*

# Татарстан Совет язучыларының гомуми шәһәр җыелышы резолюциясе[1]

**Шушы елның 3 октябрендә, Казанда, Татарстан Совет язучыларының гомуми шәһәр җыелышы булды. Җыелышта, «ВКП(б) Үзәк комитетының «Звезда» һәм «Ленинград» журналлары турындагы карары һәм идеологик эшнең бурычлары» турында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Гафаров докладаы тыңланды. Доклад буенча киң һәм җанлы рәвештә фикер алышканнан соң, җыелыш түбәндәге карарны кабул итте:**

Совет язучыларының гомуми шәһәр җыелышы ВКП (б) Үзәк Комитетының әдәбият һәм сәнгать турындагы тарихи карарларын тулысынча яхшы дип таба һәм аларны язучыларның барлык иҗат эшчәнлеге өчен сугышчан программа итеп бертавыштан кабул итә.

Татарстан АССР ның Совет язучылары бу гаять мөһим документларда бөек Сталинның һәм туган большевистик партиябезнең социалистик җәмгыять культурасының үсеше турында, безнең әдәбиятыбызның идея-художество ягыннан өзлексез үсүе турында кайгыртучанлыкларының ачык чагылышын күрәләр.

Идея ягыннан ят булган, политикадан читләшкән, түбән сыйфатлы әсәрләрнең совет әдәбиятына һәм сәнгатенә үтеп керүләре турында ВКП (б) Үзәк Комитеты ачкан фактлар Татарстандагы күп кенә язучыларның иҗатларында да булды.

"Совет әдәбияты" журналының һәм Татарстан Совет язучылары Союзының эшендә булган мондый ялгышларны һәм җитешсезлекләрне ВКП (б) Өлкә Комитеты бюросы бик дөрес ачып салды. Соңгы елда "Совет әдәбияты" журналы битләрендә, идея ягыннан тотнаклы һәм уңышлы әсәрләр белән беррәттән, Ф. Хөснинең "Апрель", "Әти кайтты", "Янып бетмәгән йөрәк" исемле хикәяләре кебек политик ялгыш һәм идеологик зарарлы әсәрләр басылып чыкты.

Соңгы вакытларда журналда Г. Кашшафның "Мендәр", Г. Закировның "Яшәү чишмәсе" исемле хикәяләре, Ә. Исхакның "Ертык белән тишек" исемле мәсәле, И. Нуруллинның "Рәхмәтулла абзый", Г. Насриның "Кайту" исемле хикәяләре кебек түбән сыйфатлы, идея ягыннан ярлы һәм художество ягыннан зәгыйфь булган, безнең чынбарлыкны бозып күрсәтә торган әсәрләр, Ш. Маннурның "Ышану" исемле пессимистик шигыре, С. Батталның, С. Урайскийның идея һәм художество ягыннан түбән булган шигырьләре һәм шулай ук Ә. Ерикәйнең идея-художество җитешсезлекләре булган кайбер шигырьләре басылып чыкты.

Партия тарафыннан хөкем ителгән зарарлы, политик ялгышлар Татарстан театрлары репертуарына да үтеп кергәннәр. Н. Исәнбәтнең үткән заманга багышлап һәм татар фольклоры буенча язган, ханнарның һәм вельможаларның тормышларын идеаллаштыруга корылган пьесалары тарихи вакыйгаларны идеологик ялгыш дип бозып күрсәтәләр. Драматург Әнәс Камал, соңгы елларда, безнең чынбарлыкны һәм совет кешеләрен бозып, яла ягып күрсәтелгән пьесалары ("Буран", "Табыштылар") белән театрларның репертуарын чүпләде.

---

[1] Кыскартып басыла. *Хәз.*

Бу һәм шуларга ошашлы әсәрләр бары тик аларның авторларының совет халкы алдындагы җаваплылыкны онытулары нәтиҗәсендә генә, совет строеның тормыш нигезе булган совет дәүләте политикасын пропагандалаудан читләшүләре нәтиҗәсендә генә, большевистик принципиальлекнең, политик үткен әдәби тәнкыйтьнең булмавы нәтиҗәсендә генә килеп чыга алганнар. Татарстан Совет Язучылары Союзы Правлениесе һәм "Совет әдәбияты" журналы редакциясе ВКП (б) Үзәк Комитетының, "Татарстан Партия оешмасында массаполитик һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында"гы (1944 ел, 9 август) карарын үтәү өчен системалы көрәш алып бармаганнар, Татарстанның социалистик нигезгә корылып үсүе турында, республиканың атаклы кешеләре—геройлары турында, русларның һәм татарларның күп гасырлар буе килгән дуслыгы турында, аларның патшалыкка, капиталистик изүгә һәм чит ил баскыннарына каршы бергәләп көрәшүләре турында язучыларның художестволы әсәрләр тудыруы буенча иҗат эшчәнлекләренә бөтенләй канәгатьләнмәслек җитәкчелек иткәннәр.

Татарстан Совет Язучылары Союзы үз эшен ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросының күрсәтмәләре нигезендә янабаштан кормаган. Күп кенә язучылар үзләренең идея-теоретик белемнәрен күтәрү һәм әдәби квалификацияләрен камилләштерү өстендә эшләмиләр, хәзерге заманның төп мәсьәләләреннән читтә торалар, совет кешеләренең Бөек Ватан сугышы фронтларында күрсәткән һәм хәзер, тыныч шартларда, бөек сталинчыл бишьеллык планны тормышка ашыруда күрсәтә торган батырлыкларын, аларның иң яхшы якларын һәм сыйфатларын үз әсәрләрендә бик йомшак һәм өстән-өстән генә күрсәтәләр.

Җыелыш Татарстан Совет Язучылары Союзы Правлениесенең һәм аның председателе иптәш Ерикеевнең эшен канәгатьләнмәслек дип таба һәм, ВКП(б) Үзәк Комитеты карарларын һәм иптәш Ждановның Ленинград журналлары турындагы докладын эштә кулланма итеп алып, булган ялгышларны төзәтергә тәкъдим итә...

*1946, № 10*

## Х Р О Н И К А

### БЕРЛИНДА ТАКТАШНЫ ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Татар халкының сөекле шагыйре Һади Такташның үлүенә 15 ел тулган көнне Берлинда татар сугышчылары шагыйрьне искә алу кичәсе үткәрделәр.

Кичәне гвардия сержанты Сиражетдинов ачты һәм шагыйрь иҗаты турында доклад ясады.

Әдәби кичәнең икенче бүлегендә ефрейтор Ягъфаров Һади Такташның "Атлы сугышчыга" һәм "Байрак тегәбез" исемле шигырьләрен, сержант Үзбеков "Мокамай" шигырен укыдылар. Лейтенант Сафиуллин аккордионда "Урман кызы" көен уйнады, аның иптәше Суфия аккордионга кушылып шул көйгә җырлады. Кичәгә катнашучылар "Киләчәккә хатлар"ны зур күтәренкелек белән тыңладылар.

Туган илдән читтә, җимерелгән Берлинда, бөек шагыйрьне хөрмәт белән искә алу кичәсе тыңлаучыларда көчле тәэсир калдырды.

*1946, №11-12*

Мидхәт
Фәйзуллин

# МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ КӨНДӘЛЕКЛӘРЕННӘН

...Үзенә язган некрологны беркемнең дә укып караганы юк. Ә Мирхәйдәр Фәйзи укыды. Китапханәгә килгән бер кичемдә ул миңа шундый вакыйганы сөйләде.



Бу хәл 1921 елны булган. Мирхәйдәр Фәйзи тиф белән авырып саташып ята икән. Врачлар бу йогышлы каты чиргә Мирхәйдәр абыйның йөрәге түзә алмас дип уйлаганнар. Кемдер "драматург үлде" дигән хәбәр таратырга ашыккан. "Оренбург тормышы" газетасында некролог басылып чыга. Хәле яхшыра төшкәч, соңгы хәбәрләр белән танышырга теләгән Мирхәйдәр Фәйзигә газета-журналлар китергәннәр. Шунда ул үзенә язылган әлеге некрологны күрә. Башта күзләренә ышанмый, кат-кат укып карый, төшем түгелме бу дип, тәннәрен чеметә, палатага кергән хатыннан: "Апа, мин исәнме, әллә үлдемме?" дип сорый. Ә хатын, бу бичара тагын саташа башлады дип уйлап, аның башына сулы чүпрәк куя. Мирхәйдәр, кулларын сөрткәч: "Әнә мине газетада үлгән дип язалар",—ди.

Ә соңыннан көндәлегенә: "Мине беләләр икән әле, иҗатыма әһәмият бирәләр икән",—дип язып куя.

Ул чактагы тормыш җайсызлыклары Мирхәйдәрнең сәламәтлеген нык какшата. 1924 елның язынннан ул үзен бик начар сизә, врачларга еш күренә башлый. Аңа авылда яшәргә киңәш бирәләр. Мирхәйдәр авылга китәргә җыена, эшләрен тапшыра, ләкин Казан белән аерылуны бик авыр кичерә. Дәфтәренә ул:

*Татарстан илләрендә*
*Татарлар арасында,*
*Баллары бар гөлләрендә,*
*Күңелемнең ярасына,*

*Җаннарыма ямь бирәдер,*
*Казан шәһәре күренеше,*
*Йөрәгемә ял буладыр,*
*Татар авылы тормышы,*

—дип рифмалы юллар язып куя. Шәһәр белән саубуллашып, соң мәртәбә урамнарны әйләнеп чыга, Ташаякка хәтле килә, ләкин беркемгә дә керми, китәсен берәүгә дә әйтми.

Унынчы июнь иртәсендә ул шәһәрдән чыгып китә. "Ике кулым, дүрт кисәк багажым да авыру йөрәгем бар—ничек барып җитәрмен... кесәм такыр булса да "Раскольников" теплоходының III классына билет алдым",—дип яза ул.

Юлда сөйләшеп барырлык кешеләр очрамый. Аның янына спекулянтлар утырган була. Язучы палубага чыга һәм шунда тәбәнәк буйлы, нык бәдәнле яшь егетнең дә пароходка утыруына игътибар итә.

Менә пароход кузгалып китә. Палубага баскан Мирхәйдәр Казанның һәм, шуның белән бергә, бу борынгы шәһәргә бәйле хыялларының да әкрен-әкрен чигенә баруын күзәтә. Казанда ул иҗат планнарының барын да тормышка ашырып бетерә алмады шул.

"Хуш, Казан. Үзем китсәм дә, йөрәгем калды. Бүләгем булсын ул сиңа. Әлегә хәтле мин бары тик алга таба гына атладым. Сине ташлап китәргә мәҗбүр булуым—артка таба бер адымым ул",—дип яза Мирхәйдәр.

---

Мидхәт ФӘЙЗУЛЛИН (1908–90) — *нейрорентгентолог, медицина фәннәре докторы, профессор. Композитор Җәүдәт Фәйзинең бертуган абыйсы (ике яшькә олы). Мирхәйдәр Фәйзигә дә туган тия.* Хәз.

Йөрәктә нидер таш булып ята, күңелдә монсулык, янда уйларын бүлешер кеше юк... Иркен Идел ярларына тагын бер әйләнеп кайтырмы әле ул, Казан урамнарын таптап йөри алырмы?

Шулай күңелсезләнеп барганда, бер-ике кеше аша гына басып торган әлеге егетне күрә. Ул да уйланып кына шәһәр силуэтына карап тора икән. Мирхәйдәр аның янына килә, сөйләшеп китәләр, танышалар. Берсенең драматург Мирхәйдәр Фәйзи, икенчесенең шагыйрь Муса Җәлил икәнен белгәч шатланышалар. Икесенең дә Оренбургка барышы икән. Муса өлкән каләмдәше белән барырга туры килүенә чын күңелдән шатлана.

Бу ике язучы Оренбургка каләрниләр турында гына сөйләшеп бармаганнардыр?! Үкенечкә каршы, Мусага багышланган берничә юлдан соң көндәлектәге язулар өзелә...

1924 елның 7 сентябрендә, бик күңелсезләнгән бер вакытында, Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләренең кайберләрен юкка чыгара. Бер дәфтәренә: "Бүген күп язмаларымны яндырдым, җырларымны Абдулла Палатовка бирдем—әйдә, гармунда уйнап, минем җырларымны җырласын",—дип язып куя.

Яндырылган биш дәфтәр белән бергә Казаннан Орскига барган вакыттагы тәэссоратлары, шул җөмләдән, Муса белән әңгәмәләре дә эзсез югала...

*«Казан утлары», 1977, № 1*

---

*Юмор-сатира*

Шәрәф Мөдәррис

# ПАРОДИЯЛӘР

**Салих Баттал:**

*Мин "Олы юл буйлап" юл тотам*
*инде менә ун ел буенча.*
*Чөнки мин аны*
*төзәтә башлаган ул ел*
*калды минем истә бик шәп*
*булды. Тик эчне кыра*
*әлеге янмый торган хис белән*
*сүнми торган чыра.*

**Сибгат Хәким:**

*Рәшит, Шәүкәт, әйдә, тик беразга*
*Зинһар өчен мине онтыгыз,—*
*Мине дә бит буган бер үк үлчәү —*
*"Сигез-җиде" белән "Ун-тугыз"!*

**Мөхәммәт Садри:**

*Ультра-кызыл юллар язам*
*Һәм тыныч минем күңел:*
*Чөнки минем шигырьләргә*
*Пародия мөмкин түгел.*

**Шәйхи Маннур:**

*Тулбай ягна йөгрә, ашга туллар,*
*Чыңграп иштлә шөлдер тавшы да.*
*Сагна-сагна язла, агла шигрем,—*
*Җрыма йотла авлым камшы да...*

**Нәби Дәүли:**

*Сәбәп бар шул! Үзем күп язсам да*
*Юрамалый мине күрмиләр...*
*Сукыр тиен торган чүп язсам да*
*Чыгармыйлар. Беләм! Шүрлиләр!*

*1955, № 9*

*Журналыбыз турында*

## Фатих Хөсни:

***—Аңа тикле "Яшь ленинчы", "Кызыл яшьләр" газеталарында вак-төяк "көйле иманнар" бастырып, чак-чак кына кыюлык җыйгач, 1927 елда, ниһаять, "Безнең юл" журналының ишеген шакып карарга җөрьәт иттем. Алып барган өч-дүрт шигырьдән берсен журналның ул чактагы редакторы Гомәр Гали, иптәшләре белән сөйләшкәннән соң, бер шарт белән басарга булганлыгын әйтте. Ләкин куйган шарты бераз аптыраткыч иде. Мин шигыремнең астына "Мөхәммәтфатих Хөснетдинов" дип имза куйган идем, Гомәр Галигә бу ошамаган. "Только имзаңны бик озын куйгансың, моның башыннан алып азагына барып чыкканчы утырып ял итеп алырга кирәк. Әгәр үзең риза булсаң, без аны болай итәбез. Башындагы "Мөхәммәт"не кыеп атабыз, койрыгындагы "ов" белән шулай ук бәхилләшергә туры килер, каласың "Фатих Хөсни" булып..." Бары тик бассыннар гына, мин бөтенесенә риза идем. Уенмыни, мин "Безнең юл"га аяк басам бит. Хәерле сәгатьтә, дөньяга алып чыксын мине "Безнең юл"!***

***Һәм горурлык хисе белән шуны әйтә алам: алып чыкты ул мине. Һәрвакыт һәм бөтен әйберләрем өчен гел башымнан гына сыйпап торды дип әйтә алмыйм, башыма сугулар да, алып барган язмаларны кочаклатып, кире борып җибәргән чаклары да, әлбәттә, булды. Ләкин бу яратып, үз кешеләрең тарафыннан борылу, яхшыракны күрергә теләп, минем яхшыракка да көчем җитәрлек булуына ышанып, кире бору булды...***

***"Безнең юл", "Атака", "Совет әдәбияты" һәм ниһаять, "Казан утлары" — образлап әйткәндә, болар бөтенесе безнең юл, безнең ышанычлы юл, хәтта юл гына да түгел, безне үстергән "яшел бишегебез" булды. Бу журналда басылу, аңда үзеңнең имзаңны күрү, дөресен әйткәндә, безнең барыбыз өчен дә, олыларыбыз өчен дә, кечеләребез өчен бигрәк тә бәйрәм иде. Элек тә шулай булды, хәзер дә шулайдыр дип уйларга кирәк. Җыеп кына әйткәндә, безнең әдәбиятыбызның күзгә күренердәй барлык әсәрләре дә иң элек журналда беренче чыныгу алды бит...***

***Әсәрләремне бастыру белән бергә, төрле елларда һәм төрле срокларда мин үзем дә журнал редакциясендә гади әдәби сотрудник булып, кулымнан килгәнчә, журналны чыгарышуда өлешемне керттем. Гази Кашшаф, Газиз Иделле, Ибраһим Гази, Кави Нәҗми, тагын бер мәртәбә Гази Кашшаф, Габдулла Гомәр, Гариф Ахунов, Зәки Нури, минем редакторларым буларак, болар белән күп вакыт якынтын очрашып, алардан киңәш сүзләре ишетеп, шундый яхшы иптәшләрем булганлыгы өчен куанып яшәдем. Мине теге яки бу дәрәҗәдә иҗатка очындыруда аларның да өлеше, әлбәттә, бар. Кыскасы, барысы өчен дә, барысы өчен дә бөтенесенә рәхмәт, дөньяга рәхмәт, мине шундый кызыклы мәйданга китергәнлеге өчен язмышыма да рәхмәт әйтмичә кала алмыйм.***

*1982*

# Муса Җәлилнең тууына 100 ел



## Җырларым

*Җырларым, сез шытып йөрәгемдә*
*Ил кырында чәчәк атыгыз!*
*Күпме булса сездә көч һәм ялкын,*
*Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!*

*Сездә минем бөтен тойгыларым,*
*Сездә минем керсез яшьләрем.*
*Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,*
*Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.*

*Мин кабыздым җырда ялкын итеп*
*Йөрәгем һәм халык кушканны.*
*Җырым белән дусны иркәләдем,*
*Җырым белән җиңдем дошманны.*

*Алдый алмас мине түбән ләззәт,*
*Вак тормышның чуар пәрдәсе.*
*Шигыремдәге чынлык, ут һәм сөю –*
*Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.*

*Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр*
*Шигыремдәге изге антына.*
*Бар җырымны илгә багышладым,*
*Гомеремне дә бирәм халкыма.*

*Җырлап үттем даулы көрәш кырын,*
*Җырлап килдем тормыш язына.*
*Соңгы җырым палач балтасына*
*Башны тоткан килеш языла.*

*Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә*
*Һәм үләргә кыю ир булып.*
*Гомерем минем моңлы бер җыр иде,*
*Үлемем дә яңрар җыр булып.*

# МУСА ҖӘЛИЛ ШИГЫРЬЛӘРЕ

Үзенең патриотик шигырьләре, героик поэмалары, нәфис җырлары белән хезмәт ияләре массасына бик яхшы таныш булган коммунист шагыйрь Муса Җәлил 1942 елда Волхов фронтында чолганышта кала һәм, сугышта каты яраланып, пленга эләгә. Ул соңыннан бу турыда "Кичер, илем!" исемле шигырендә яза, "изге сугыш антын соң чиккәчә керсез сакладым",—дип белдерә, тик соңгы минутта пистолеты хыянәт итүен әйтә.

Муса Җәлил концлагерьда яши һәм анда качу оештыру өчен Берлинга күчерелә һәм Моабит төрмәсенә ябыла. Блокнотына берничә җиргә ул, "Германиядә политик эш алып барганы өчен ябылган һәм үлемгә хөкем ителгән М. Җәлил", дип язып калдырган. Моабит төрмәсендә М. Җәлил, үлем хөкеменең җиренә җиткерелүен көтеп, бер елга якын утыра. Шул вакыт эчендә 125 шигырь һәм поэма иҗат иткәнлеген, тик аларның барысын да кәгазьгә язарга мөмкинлек булмаганлыгын әйтә.

1944 елның башында М. Җәлилне фашистлар җәзалап үтерәннәр. Үләр алдыннан ул шигырьләре теркәлгән блокнотны күрше камерада утыручы дустына—Бельгия партизанына—биреп калдырган. Берлинны алганда Совет Армиясе тарафыннан төрмәдән азат ителгән бу партизан Муса Җәлил шигырьләрен Брюссельдәге Совет Консульствосына тапшырган.

Без Муса Җәлилнең үлем хөкеме көтеп төрмәдә утырганда язган шигырьләрен шушы саннан бастыра башлыйбыз. Алар талантлы шагыйрьнең соклангыч поэтик көче турында сөйлиләр, совет кешесенең иң каты газаплар кичереп һәм үлем каршында торып та ныклы ихтыяри көч саклавын, рухы белән һаман батыр, җиңелмәс булып калуын күрсәтәләр, туган илгә булган мәхәббәт хисенең тирәнлеген һәм "яраланган лачын йөрәгеннән" шигырь булып чыккан үч ялкынын сурәтлиләр. Хезмәт ияләренең сөекле шагыйре иң авыр газапларны, фашистларның ерткычлыгын түземлелек белән кичерә һәм туган иленә, совет халкына турылыклы булып кала. Ул үлемне батырларча каршы ала, бәхет, шатлык, җиңү турында җырлый, совет халкының җиңү тантанасы белән шатлана.

## *КИЧЕР, ИЛЕМ!*

*Кичер мине, илем, синең бөек*
*Исемең белән килеп сугышка,*
*Данлы үлем белән күмәлмәдем*
*Бу тәнемне соңгы сулышта.*
*Юк, мин сине тузан бөртегедәй*
*Сансыз гомрем өчен сатмадым.*
*Волхов шаһит, изге сугыш антын*
*Соң чиккәчә керсез сакладым.*
*Мин курыкмадым өстән яңгыр төсле*
*Яуганда да туплар, ядрәләр,*
*Каушамадым кан һәм үлек белән*
*Тулганда да тирә-әйләнәм.*
*Алда, артта, уңда һәм сулымда*
*Киселсә дә юлым, күкрәгем*
*Яраланып канга төренсә дә,*
*Көчсезләнеп мин яшь түкмәдем.*

Мин алдымда күрдем шыр сөяктән
Котылгысыз үлем шәүләсен.
Кил син миңа, үлем, бары гомрем
Коллык белән тәгалләнмәсен!
Мин түгелме дуска хат язучы,
“Борчылма, дип, тормыш юлдашым,
Соңгы тамчы каным тамса тамсын,
Тик антыма таплар кунмасын!”
Мин түгелме шигырь утым белән
Ант итүче канлы сугышта? -
“Үлемгә, дип, ачы нәфрәт белән
Елмаермын соңгы сулышта”.
“Соң чиктә, дип, синең мәхәббәтең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын”.
“Тыныч булыр йокы, тормышымны
Бирсәм, диеп, туган ил өчен”.
Ышан, илем, шушы ант сугарды
йөрәгемнең соңгы тибешен!
Язмыш көлде, үлем кагылмыйча
Үтте яннан минем тирәләп.
Нишлим, нишлим, соңгы минутымда
Пистолетым итте хыянәт!
Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.
Мин соң бөркет түгел идеммени,
Баш ияргә шуннан башкага!
Ышан, илем, шундый бөркет идем
Мин дә соңгы минут килгәндә,
Әзер идем, мәгърур канат җәеп
Ташланырга ярдан түбәнгә.
Нишлим, сугыш дустым-пистолетым
Соңгы сүздән кинәт баш тартты.
Богау салды дошман кулларыма
һәм хурлыклы юлдан атлатты.
Тоткынлыкта хәзер мин... һәр көнне
Көн чыгышын комсыз күзәтәм.
Шигырь булып чыга үч ялкыны
Яраланган лачын йөрәктән.
Көн чыгышы дуслар кулындагы
Байрак булып көн дә кызара.
Белмисез лә, дуслар, тоткын күңел
Күкрәктәге җәрәхәттән түгел,
Канлы үчтән шулай кыза ла!
Тик бер өмет: кара август төне
Илтер мине шунда җитәкләп.
Өстен килер түбән әсирлеккә
Үч һәм илгә керсез мәхәббәт.
Тик бер өмет, дуслар, сезнең сафта
Табар соңгы көрәш теләген,
Яраланган, ләкин тар коллыкка
Баш имәгән керсез йөрәгем.

*VII. 1942.*

*1953, № 5*



# Константин Симонов

## БЕР КАМЕРАДА

*Шагыйрьләрнең халыкара фестивале 1952 елның сентябрендә, "Журнал де поэт" исемле Бельгия журналының инициативасы буенча үткәрелде. Ике елдан соң Бельгиядә үк икенче фестиваль булып узды. Һәм менә быел сентябрь башында Брюссельдән 118 км. ераклыкта, Төньяк диңгез буендагы Кнокке ле Зутт исемле матур курорт шәһәрчегендә, шагыйрьләр өченче тапкыр очраштылар. Зур залда 33 илнең өч йөз вәкиле җыйналды. СССРдан делегат булып П. Антокольский, С.Михалков, К.Симоновлар катнашты. Конференцияне кыскача кереш сүз белән Бельгиянең мәгариф министры Лео Коллор, шагыйрьләрнең халыкара очрашуларының президенты Жан Кассу ачып җибәрде. Фашистлар тарафыннан атып үтерелгән Испан революционеры—шагыйрь Гарсиа Лорканы Англия шагыйре Мирон Гриндинең тәкъдиме буенча бөтен зал аягүрә басып искә алды. Фашизмга каршы геройларча көрәштә һәлак булган татар совет шагыйре Муса Җәлилнең дә якты истәлеген халыкара фестивальдә катнашучылар аягүрә басып, кайгылы тынлыкта билгеләп үттеләр. Аннан соң совет шагыйре К. Симонов конференция президиумына М. Җәлилнең тормыш иптәше Әминә ханым Җәлилованың шагыйрьнең Моабит циклы шигырьләрен саклап калган һәм аны Совет иленә тапшырган Бельгия патриоты Андре Тиммерманга һәм Бельгия шагыйрьләренә атап язган рәхмәт хатын тапшырды. Хатның французча тәрҗемәсен Бельгия шагыйре, шагыйрьләр конгрессын оештыручыларның берсе—Артюр Оло укыды. Артюр Оло да М. Җәлил булган Дахау концлагеренда өч ел утырган. Шагыйрьләр хатны зур игътибар белән тыңладылар. Бельгиядә үткәрелгән менә шушы шагыйрьләр конгрессы М. Җәлил турында яңа мәгълүматлар ачуга, герой шагыйрьнең төрмәдәге язмышын ачыкларга, Андре Тиммерманның үзен эзләп табарга ярдәм итте. Түбәндә без совет делегаты Константин Симоновның Тиммерман[1] белән очрашуы турындагы язмаларын бирәбез.*

***Редакция.***

* * *

Сентябрь башларында, Бельгиянең Кнокке исемле курортлар шәһәрчегендә халыкара поэзия фестивалендә, мина, совет язучылары делегациясе члены сыйфатында, фестиваль трибунасыннан, Муса Җәлил хатынының хатын укырга туры килде. Бу хатында ул Муса Җәлил белән Берлин төрмәсендә бергә булган, бу гүзәл татар шагыйренең төрмәдә язган шигырьләрен әдәбият өчен саклап калган Бельгия патриоты Андре Тиммерманның мактаулы эше турында яза һәм Тиммерманның ватандашлары—Бельгия шагыйрьләренә Җәлилнең шигырьләр китапларын бүләк итүен әйтә.

Фестиваль тәмамланып ике көн үткәч, мин Бельгиянең танылган шагыйре, Бельгия фәннәр академиясе члены Роже Бодар белән очраштым һәм аңардан Андре Тиммерманны табуда миңа ярдәм итүен үтендем.

Андре Тиммерман турында мәгълүматларыбыз аз: бары тик аның 1944 елда Берлинда немец төрмәсендә утырган булуы, сугыштан соң Җәлилнең шигырьләр дәфтәрен совет кешеләренә тапшыруы һәм фамилиясенең, бездәге Петров яисә Кузнецов фамилияләре кебек үк, Бельгиядә бик таралган булуы гына билгеле иде.

[1] *Дөресе Тиммерманс. Биредә "ЛГ"дагы вариант саклаңган. Ныгытып танышасылар алда әле... Хәз.*

Роже Бодар, эзләүнен унышлы чыгачагына бераз шикләнеп кенә һәм бу хәлгә басым ясап, Андре Тиммерманны табу өчен кулыннан килгәннен барын да эшләячәген белдерде.

—Бәлки сез, чама белән генә булса да, аның ничә яшьтә булуын беләсездер? Бу хәл эзләүне бик нык жиңеләйтер иде,—диде Бодар.

Ләкин мин Тиммерманның яшен белми идем. Жәлилнең "Моабит дәфтәре"ндә Тиммерманга багышланган шигырьләр булса да, аларда аның яше турында бер сүз дә әйтелми.

—Ярый ла ул чакта Тиммерман яшь булган булса,—диде Бодар.—Ни әйтсәң дә, 1944 елдан бирле унике ел үтте, ә кешеләр, кызганычка каршы, үлүчән булалар.

Бу очрашудан соң ике көн үткәч, мин Бельгиядә безнең илчелек аша Бельгия тышкы эшләр министрлыгының сотрудницы М. Р. Харреманстан бик жылы хат алдым. Бу хатында ул Роже Бодар үтенече буенча мәгълүматлар туплавын һәм мин эзләгән Тиммерманның 1917 елның 5 декабрендә Франциядә туган, бельгияле, 1942 елда гестапо тарафыннан кулга алынып, Берлин төрмәләренең берсенә ябылган Андре Тиммерман булып чыгуы бик ихтимал икәнлеген яза. Бу Андре Тиммерман моннан биш ел элек Бельгиядә Тирлемон шәһәрендә, Виктор Бодуэн урамындагы 51 номерлы йортта яшәгән икән. Хатының азагында Харреманс әфәнде эзләвемнең унышлы чыгачагына ышаныч белдерә.

Миңа ярдәм итәргә ашыккан бу кешегә һәм Роже Бодарга рәхмәт хисе белән мин икенче көнне иртән үк Брюссельдән кырык километр чамасындагы Тирлемон шәһәренә киттем. Бу кечкенә борынгы шәһәрнең тар тыкрыклары буйлап бераз йөргәннән соң без Виктор Бодуэн урамындагы 51 нче номерлы йортны эзләп таптык.

Әйе, безгә шуны белергә кирәк: моннан биш ел элек монда яшәгән Тиммерман әле дә шунда яшиме һәм, әгәр яшәсә, ул мин эзләгән кешеме? Икенче бер сорауга—бу шаһит авызыннан без Муса Жәлил турында берәр нәрсә белә алырбызмы яисә шагыйрьнең соңгы еллары турында сөйләүче бердәнбер нәрсә булып, элеккечә, аның "Моабит дәфтәре" генә калырмы?—дигән сорауга җавап та менә шуларга бәйле иде.

Ике катлы кечерәк кенә йорт. Тәрәзәләренә шешәләр тезеп куелган, тар агач прилавкалы кибеткә бердәнбер ишек алып керә. Бу—эчемлек кибете.

Керү белән без прилавка артында торучы мөлаем йөзле хатынны күрдек. Безнең сорауга ул: Андре Тиммерман монда яши, ул минем ирем, әле кыз туганының кызы белән йөрергә чыгып китте, хәзер кайтып житәргә тиеш,—диде.

Берничә минут та үтмәде, Тиммерман чыннан да кайтып житте. Без ана ни өчен килүебезне әйттек һәм аның беренче сүзләреннән үк нәкъ шул Андре Тиммерман булуын аңладык: ул Муса Жәлил белән бергә төрмәдә утырган, аны белә һәм аның турында үзе хәтерләгәннең барысын да сөйләргә хәзер тора.

Без, Тиммерман белән бергәләп, кибет артындагы бер бүлмәгә үттек. Мин блокнотымны чыгардым да минем сорауларга җавап йөзеннән Тиммерман исенә төшереп сөйләгәннәрнең барысын да, бер сүзен дә төшереп калдырмаска тырышып, иске журналистлык гадәте буенча стенографистларча тизлек белән диярлек яза башладым.

Ләкин башта—сөйләүче турында.

Андре Тиммерман, озын буйлы, ябык йөзле, кара чәчле, аз гына иелебрәк йөрүчән, тыйнак, хәтта, мөгаен, бераз оялчанрак та кеше, Муса Жәлилгә бәйле булган һәр нәрсәне эчке киеренкелек белән бик тырышып исенә төшерә-төшерә сөйли, ә шул ук вакытта үзе турында теләр-теләмәс кенә һәм бик аз сүз белән әйтә: әйе, ул каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашкан, әйе, фашизмга каршы булган һәм хәзер дә шулай, ләкин берниндә дә партиядә тормаган һәм тормый. 1942 елда, аны берәр кешенең әйтүе буенча булса кирәк, немецлар кулга алганнар. Хәзер ул клерк булып эшли, ә хатыны һәм аның туганнары менә әле генә без үткән кечкенә кибетне тоталар.

Аның үзе турында сөйләгәннәреннән Муса Жәлил белән бәйле булмаган өлеше

менә шул гына бугай. Калганнарын без сүз уңаенда, ул Җәлил турындагы истәлекләрен сөйләгәндә беләбез.

Муса Җәлилнең тормышы—безнең әдәбиятыбыз тарихына кергән тормыш. Аның героик тормышының соңгы айлары турындагы сүзләрне тыңлаганда никадәр дулкынлану кичерүемне һәркем аңлар. Ләкин минем уемча, бу дулкынлануларымнан һәм кичерешләремнән бигрәк укучыны фактлар үзләре күбрәк кызыксындырадыр, чөнки алар үзләре бер тарих. Шуңа күрә Муса Җәлил турындагы сорауларыма Андре Тиммерманның җавапларын әдәби бизәкләүләрсез турыдан-туры укучыга җиткерү, минемчә дөресрәк булыр. Мин аларны әңгәмәбез барышында үзем язып алганча бирәм. Алай гына да түгел, язып алынган тәртиптә үк бирәм. Шулай иткәндә бу әңгәмә укучы күз алдына җанлырак һәм тулырак килеп басар.

* * *

Менә ул сөйләшү:

**Мин:** Муса Җәлил белән сез кайчан таныштыгыз?

**Тиммерман:** Мин Җәлил белән 1943 елның азагында, яки, мөгаен, 1944 елның башында таныштым. Бу хәл Берлинда, Лертерштрассе урамында булды.

**Мин:** Җәлил камерага сездән элегрәкме, соңракмы килде?

**Тиммерман:** Немецлар мине камерага алып килгәндә, Җәлил анда иде инде. Ул анда Польшада, Силезиядә туып үскән немец солдаты белән утыра иде. Нииндидер башка бер төрмәдә кухняда эшләгәнгә, бу солдат камерадан көн буена китеп тора—аны иртән алып китәләр һәм кичләрен алып киләләр иде. Шунлыктан без көн буена Җәлил белән икәү генә кала идек.

**Мин:** Җәлил белән ничек аңлаша идегез соң?

**Тиммерман:** Мин французча һәм бераз гына немецча, ә Муса Җәлил рус һәм татар телләрен генә белгәнгә, аңлашу безгә бик кыен иде, ләкин безнең берберебез белән сөйләшәсе бик килә, һәм без моны эшләргә тырыша идек. Төрмәгә “Фелькишер беобахтер” газетасы килә, аны тоткыннарга тараталар иде. Бу газетаның кырлары бик киң иде. Без аларны кисеп алып беркетә һәм алардан тар гына дәфтәрләр ясый идек. (Тиммерман бу дәфтәрләрнең нинди киңлектә булуын бармаклары белән күрсәтә.) Җәлил һәм мин бу дәфтәрләргә төрле әйберләрнең рәсемен ясыйбыз да һәр очракта бу әйберләрнең исемен әйтәбез: Җәлил—русча, ә мин французча, һәм һәр икебез бу сүзләрне ятлыйбыз. Хәер, башта дәфтәрләр ясамадык, бәлки әйбер рәсемнәрен һәм сүзләрне аерым кәгазь кисәкләренә яза, аннары гына аларны тәржемәсе белән дәфтәрләргә күчерә идек. Минем бу дәфтәрләрем соңрак, немецлар мине башка төрмәгә күчергәндә, югалдылар.

Мина укырга җиңелрәк булсын өчен Җәлил сүзләрнең русча тәржемәсен латин хәрефләре белән яза иде. Абстракт төшенчәләр белән эш кыенрак иде, ләкин монда безгә кичләрен эшеннән кайткач, поляк ярдәм итә иде. Поляк Җәлил белән полякча сөйләшә, алар бер-берсен бераз аңлыйлар, аннары поляк боларны мина немецча аңлатырга тырыша иде. Мин, инде сезгә әйткәнчә, немецча бераз аңлыйм. Шулай итеп, без поляк һәм немец телләре ярдәмендә, абстракт төшенчәләрне русчадан французчага һәм французчадан русчага тәржемә итә идек.

**Мин:** Сез Җәлил белән бер камерада күпме вакыт булдыгыз?

**Тиммерман:** Өзеп кенә әйтә алмыйм, берничә ай бугай. Төрмә көннәре берберсенә бик охшаганнар, һәм аларның күпме булуын әйтүе кыен.

**Мин:** Бу төрмәдә Җәлилдән башка тагын совет кешеләре бар идеме?

**Тиммерман:** Төрмә зур булганга, мин тоткыннарның барын да белә алмадым, ләкин безнең белән күрше ике камерада—уңда һәм сулда—тагын ике татар утыра иде. Берсенең исеме Габдулла Булатов[1], ә икенчесенеке—Алишев. Бу Алишев, әгәр хәтерем ялгышмаса, элек, сугышка кадәр, балалар өчен әкиятләр язган бугай. Мина

---

[1] Тиммерман Булатовның исемен Алишев (Абдулла) исеме белән бутый булса кирәк. М. Җәлилнең Моабит дәфтәрендә Булатов Фоат (Казан) дип язылган. *Ред.*

бу турыда Муса Җәлил сөйләде. Бу татарлар белән бергә һәр камерада берәр бельгияле бар иде. Бу бельгиялеләр минем танышларым, аларның икесе дә минем белән бер үк көнне, минем белән бер үк эш өчен кулга алындылар. Минем алар белән, ә Җәлилнең үз иптәшләре—татарлар белән ничек тә булса элемтә урнаштырасыбыз килде. Без стенада язулы кәгазьләр үткәреп булырлык кечкенә тишек тишәргә теләдек, ләкин моның өчен бернинди дә инструментыбыз юк иде.

Безнең төрмәдә тоткыннарга, әгәр алар үзләре сорасалар, кайчак эш һәм эш өчен кирәкле инструментлар бирәләр иде. Стенаны тишәрдәй берәр инструмент алырга ниятләнеп, Җәлил белән без дә үзебезгә эш сорадык. Безнең өмет акланды, безгә түгәрәк агач капкачларга ырмаулар ясарга куштылар. (Бу детальләрнең нәрсә өчен һәм кая киткәнен белмим.) Эш өчен безгә берничә инструмент, шул исәптән, кечерәк кенә яссы өтерге бирделәр. Менә шул өтерге белән без стенаны тишәргә тотындык.

Башта Булатов утырган камерадан безне аерып торучы стенаны тишә башладык. Бу стена буенда өч агач аяклы төрмә лаканы тора иде. Шуның бер аягы стенага якын ук килгән һәм аның бер өлешен каплап тора. Без стенаны нәкъ менә шул лакан аягы каплаган урыннан, тишек күренмәслек итеп чокырга тотындык. Эшебез уңышлы барды—башта ук ике кирпеч арасындагы ярыкка туры килдек. Стена ярты метр чамасы калынлыкта иде, без аны күпме тишкәнбездер, анысын хәтерләмим. Прогулкага чыккан саен без стена тишү вакытында чыккан таш валчыкларын учыбызга тотырып алып чыга һәм төрмә ишек алдында кеше сизмәслек итеп әз-әзләп кенә чәчеп калдыра идек. Ниһаять, без тар гына тишек тиштек, шул көннән башлап мин бельгияле иптәшем белән, ә Җәлил—Булатов белән сөйләшә башладык.

Без камерага тишек тишүдән соң бераз ял иттек тә, берничә көннән соң икенчесенә тишек ясый башладык. Бу стенада жылыту трубалары куелган иде, һәм эшләве бик кыен булса да, без бу трубалар артыннан күренмәслек итеп тишек тишәргә тырыштык. Җәлил белән безгә икенче стена беренчесенә караганда катырак төсле тоелды, ә бәлки, без арыган гына булганбыздыр. Бу стенаның теге ягында утыручы Алишев белән сөйләшәсем бик килә, ди иде Җәлил. Ләкин без эшне азагына кадәр җиткерә алмадык. Бервакыт конвойчылар кереп, Җәлилне Дрезденга—судка алып киттеләр.

**Мин:** Бу көнне Җәлилне соңгы күрүегез булдымы? Ул төрмәгә кире кайтмадымы?

**Тиммерман:** Әйе, ул яңадан кайтмады, ләкин мин аны соңрак Шпандаудагы төрмәдә тагын күрдем. Без утырган төрмә гомумән гражданский кешеләр өчен булса да, бер канаты—без утырганы—тикшерү астында булган кешеләрне тоту өчен хәрби төрмә ителгән иде. Күрше камерада утырган татарлар да Дрезденга судка җибәрелделәр. Җәлил миңа аларның да үзе белән бер үк эш буенча утыруларын әйтте.

**Мин:** Сез Шпандау төрмәсендә Җәлил белән ничек һәм кайчан очраштыгыз?

**Тиммерман:** Хәзер ачык хәтерли алмыйм инде, ләкин 1944 елның августында булса кирәк. Гитлерга һөҗүм ителү уңае белән, барлык политик тоткыннар, без утырган Берлин төрмәсеннән алынып, Шпандауга күчерелделәр. Шпандауга элэгүемнән соң берничә көн үткәч, иртән, төрмә ишек алдында йөргәндә, мин кемнеңдер тавышын ишеттем. Кемдер пышылдап кына "Пст... пст..." дип минем игътибарны үзенә тартырга тырыша иде. Мин шактый озак вакыт як-ягыма каранып йөрдем, ләкин беркемне дә күрә алмадым. Бер көн үткәч, прогулка вакытында мин бу тавышны яңадан ишеттем. Төрмәнең аскы кат тәрәзәләре чагыштырмача түбән урнашканнар һәм тар гына ярык калдырып, эчкә таба ачылалар иде. Мин кинәт әнә шундый ярыкта Җәлилнең башын күреп калдым, дөресрәге, бөтен башын түгел, ә битенең бер өлешен генә—чөнки ярык бик тар иде. Мин әйләнә буйлап йөрүемдә дәвам иттем—туктап торырга ярамый. Бер тапкыр әйләнеп үткәч, мин тагын теге тәрәзә белән тигезләндем һәм, ботинкамның шнурын бәйләгән булып, иелдем. Мин иелгән хәлдә тордым һәм бу минутта

Җәлилнең үзен күрмәсәм дә, аның тавышын ишеттем. Ул немецча, пышылдап кына судның булуын һәм үзенең башын кисәчәкләрен әйтте.

**Мин:** Җәлил белән сезнең бу соңгы очрашуыгыз булдымы?

**Тиммерман:** Юк, минем аның белән күрешәсем, сөйләшәсем бик килде, һәм мин иптәшләрем аркылы Җәлил торган баштагы тоткыннарның нинди көндә душка йөрүләрен белергә тырыштым. Бу вакыт, Гитлерга һөҗүм итүдән соң, төрмәдә кеше бик күп иде, һәм анда тәртипсезлек хөкем сөрде. Башка очта утырсам да, мин төрмә душына икенче очтагы тоткыннар юынган көндә һәм сәгатьтә эләгә алдым. Анда мин Җәлилне күрдем һәм, без бер-беребезгә бик якын торып юынган арада, аның белән ун минут буе сөйләштем. Җәлил миңа үзенең һәм татар иптәшләренең үлем җәзасына хөкем ителгән булуларын әйтте.

**Мин:** Сез Җәлил белән тагын ниләр турында сөйләштегез соң?

**Тиммерман**: Башка берни турында да сөйләшмәдек. Аның белән ун минут буе бергә басып торсак та сөйләшергә мөмкин түгел диярлек иде, әйләнә-тирәбездә кешеләр бар, алар безгә комачаулыйлар иде.

**Мин:** Җәлил сезгә үзе һәм татар иптәшләре турында әйткән; аларны үлем җәзасына хөкем иткән процесс буенча, мөгаен, татарлар гына утырганнардыр?

Тиммерман: Әйе, минем уемча, бу процесс буенча хөкем ителгәннәр бары да татарлар булган, чөнки мин Җәлилдән башка беркем турында да ишетмәдем.

**Мин:** Төрмә мунчасында бу күрешүегездән соң сез Җәлилне башка күрмәдегезме?

**Тиммерман:** Юк. Берничә көннән соң мин Луккау шәһәренә лагерьга күчерелдем.

**Мин:** Сез саклап калган дәфтәрне Җәлил сезгә кайчан тапшырды?

**Тиммерман:** Бу хәл аны Дрезденга судка җибәрүдән ярты ай чамасы элегрәк булды. Ул миңа төрмә кибетендә сатыла торган почта кәгазеннән эшләнгән кечкенә дәфтәрен бирде.

**Мин:** Нигә ул аны сезгә нәкъ шул вакытта бирде? Ул шул вакытта ук, үзен җәзалаячакларын көтә идемени?

**Тиммерман:** Әйе. Суд булудан шактый күп элек үк ул үзен җәзалаячакларына ышана иде. Моңа аз гына да шикләнмәве турында ул берничә тапкыр миңа бик тыныч кына әйтте. Миңа дәфтәрен тапшырган көнне Җәлилне төрмә начальнигына чакырдылар. Ни өчен икәнен атап кына әйтә алмыйм, ләкин ниндидер кәгазьгә кул куюын таләп иткәннәр бугай. Төрмә конторасыннан кайткач, ул минем янга килде һәм миңа дәфтәрен биреп, исән калып өемә кайта алсам, аны саклавымны, сугыштан соң мин яшәячәк илдәге Совет консуллыгына тапшыруымны үтенде.

**Мин:** Сез дәфтәрне ничек саклый һәм тапшыра алдыгыз соң?

**Тиммерман:** Мине Шпандауга күчергәндә мин аны үзем белән алдым—киемнәрем эченә яшердем, ә миңа биш ел каторгага җибәрү турында яңа хөкем карары игълан ителгәч, мин бу карар чыгуның икенче көнендә, башкалар кебек үк, төрмә конторасына барып, артык әйберләремне тапшырырга тиеш идем. Безнең эш тикшерелеп беткән булганга, безгә артык әйберләр тоту тыела иде. Мәсәлән, ике пар оекбашым бар икән, мин шуның берсен генә, ике күлмәгем булса—берсен генә калдырырга тиеш идем. Моннан тыш, гомумән безнең барлык вак-төяк әйберләрне алалар иде. Мин тапшырырга тиеш булган әйберләремне җыйдым да Җәлилнең дәфтәрен, башта ук күзгә ташланып тормаслык, ләкин шул ук вакытта, бу аны махсус рәвештә яшергән икән, диган фикер тумаслык итеп, шулар арасына тыктым. Аның белән бергә миңа Берлин төрмәсендә немец священнигы биргән догалык китабын да тыктым. Бу догалыкның беренче ике битендә Җәлилнең миңа бүләк итеп язган шигырьләре бар иде.

Немецлар әйберләрнең инвентарь исемлеген төзи башладылар. Алар башка әйберләр арасында догалыкны һәм дәфтәрне күреп, аларны да яздылар. Миннән дәфтәр турында: "Нәрсә бар анда?" дип сорадылар. Мин, бу минем көндәлегем, дидем, ә алар, юләрләр, минем бәхеткә каршы, дәфтәрдәге язуларның немецча

да, французча да булмыйча, башка бер телдә булуына игътибар итмәделәр. Хәер, ул көнне бик күп кеше җибәрелгәнгә, алар ашыгалар иде.

Шунда ук дәфтәр һәм догалык белән бергә, кырыну әйберләре һәм башка вак-төяк нәрсәләр дә бар иде. Шуларның барысын да, инвентарь язуы белән бергә, немецлар, урнашкан тәртип буенча, минем өйгә, әниемә җибәрделәр. Ул инвентарь язуы миндә кайдадыр саклана әле, бәлки мин аны табармын да. (Тиммерман саргаеп беткән төрле кәгазьләр салынган папка алып килә һәм анда озак кына актарына, ләкин шулай да ул инвентарь кәгазен таба алмый). Минем әйберләр, догалык һәм Җәлил дәфтәре салынган посылка әниемә килеп җитә, һәм ул аларның барысын да сугыш бетеп мин өйгә кайтканчы саклый. Мине төрмәдән концлагерьга җибәргәндә, мина әниемә хат язарга рөхсәт иттеләр. Мин ана турыдан-туры яза алмасам да, бу дәфтәрне һәм догалыкны ничек тә булса сакларга кирәклеген аңлатырга тырыштым.

Ничек болай килеп чыккандыр, белмим, ләкин мин кайтканда догалык югалган иде, ә дәфтәр сакланган, һәм мин аны Совет илчелегенә тапшырттым. Мин аны үзем тапшыра алмадым, чөнки концлагерьдан соң озак вакыт авырдым, ләкин мин Брюссельдә булгалый торган бер иптәшемнән дәфтәрне Совет илчелегенә илтеп бирүен үтендем. Ул дәфтәрне алды һәм кайткач, йомышымны үтәгәнлеген әйтте.

**Мин:** Сез Җәлилнең төрмәдә ни өчен утырганлыгын, фашистларның аны нәрсәдә гаепләүләрен белмисезме?

**Тиммерман:** Камерада үзе белән бергә немецлар тарафыннан махсус рәвештә җибәрелгән кешеләр булудан куркып, төрмәдә беркем дә, кагыйдә буларак, үз эшләре турында башкаларга сөйләми иде. Ләкин без Җәлил белән бер-беребезгә ышана һәм үз эшләребез турында сөйләшә идек. Шулай да, бер-беребезнең телен бик аз белгәнлектән, сүзләрне ымлаулар белән тулыландырып сөйләшкәндә һәрвакыт һәм һәр нәрсәне аңлап бетереп булмый. Шуна күрә, бәлки мин Җәлил сөйләгәннәрне төгәл үк аңлап та житкермәгәнмендер. Сезгә үзем аңлый алган кадәресен генә сөйлим. Җәлилнең минем белән һәм Булатов белән (аның белән ул, минемчә, русча сөйләшә иде, чөнки аларның сөйләшүләреннән мин кайбер нәрсәләрне аңлый идем) сөйләшүләреннән аңлавымча, Җәлил төрмәгә эләккәнче, немец концлагерьнда утырган. Лагерьга алар янына баш мөфти (мин кабат сорыйм, һәм Тиммерман кабатлый: баш мөфти) килгән. Анда, лагерьда Җәлилнең язучы булуы билгеле булган, һәм мөфти анардан Мусаның һәм башка берничә татарның, татар хәрби пленныйларын генерал Власов армиясенә керергә өндәп, мөрәҗәгать язуларын таләп иткән. Җәлилнең сүзләреннән аңлавымча, алар күз буяу өчен моны эшләргә риза булганнар, ләкин шул ук вакытта лагерьда үзләре чыгарган яшерен листовкаларында нәкъ шуның киресен язганнар һәм татарларны генерал Власов армиясенә кермәскә өндәгәннәр. Җәлилнең мина сөйләвенчә, аларның листовка чыгара торган яшерен оешмаларында татарлардан барлыгы унике кеше булган[1]. Соңыннан алар тагын берәүне—унөченче кешене тартканнар, һәм бу унөченче кеше аларны тоттырган. Хәтерләвемчә, алар бу турыда Булатов белән стена аша еш сөйләшәләр иде. Әгәр мин Җәлил белән бергә тагын ике-өч ай утырган булсам, мин телне күп яхшырак белгән булыр идем һәм Җәлилне нәрсә өчен җәзалаулары һәм аның татар иптәшләре белән ни булуы турында күбрәк сөйли алган булыр идем. Ә хәзер үзем аңлаганнарны гына сөйли алам, болары да тулысынча төгәлләр, дип әйтә алмыйм: ни генә әйтсән дә, мин дә, ул да—икебез дә бер-беребезне бик начар аңлый идек.

**Мин:** Әйтегезче, сезгә тапшырган шигырьләрен Җәлил ничек яза иде?

[1] Муса Җәлилнең Моабит дәфтәрендә, политик гаепләнеп, фашистлар төрмәсенә утыртылган кешеләрнең исемлеге язылган. Анда без түбәндәгеләрне укыйбыз:

"Сәяси гаепләнеп утыручы татар егетләре: Гариф Шабаев—Үзбәкстан, бухгалтер; Муса Җәлил—шагыйрь, Казан; Әхмәт Симай—Мәскәү, журналист; Габдулла Баттал—Казан; Курмаш Х.—Казан; А. Алиш—язучы, Казан; Булатов Фоат—Казан; Сәйфелмелоков—Үзбәкстан; Хисаметдинов—Үзбәкстан; Мичурин—юрист, Үзбәкстан; Әмиров—Казан, җырчы; Шәрипов—Казан." Шушы 12 кешенең исеменнән тыш хыянәтченең исеме аерым язылган. *Ред.*

**Тиммерман:** Безнең буш вакытыбыз күп иде, мин аны тизрәк үткәрү өчен көн саен иртән озак-озак, берәр сәгать, хәтта күбрәк тә кырына идем. Хәтерем ялгышмаса, Җәлилнең сакалы акрынрак үсә иде, һәм ул сирәк кырына иде. Көн саен иртән мин кырынган арада, Муса гадәттә "Фелькишер беобахтер" газетасыннан ертып алынган кәгазь кисәкләренә нидер яза, ертып ташлый һәм янәдән яза иде. Мин кырынып бетергәч, ул язуыннан туктый, һәм без рәсемнәр ярдәмендә сөйләшә башлый идек. Ярты көнгә кадәр вакыт шулай үтә иде. Көн уртасында без төшке аш дип атый торган нәрсә була иде. Төшке аштан соң без янадан тел өйрәнә башлый идек, ә сәгать дүртләрдә Җәлил янадан язарга тотына иде.

**Мин:** Сез Муса Җәлилнең шагыйрь икәнен белә идегезме соң?

**Тиммерман:** Әйе, башта ук булмаса да мин моны белдем. Мин беренче тапкыр камерага килеп Җәлилдән фамилиясен сорагач, ул, фамилиям Гумеров диде, һәм мин, фамилиясе "ов"ка тәмамлангач, бу рустыр инде, дип уйлап алдым. Аннары без рәсемнәр ярдәмендә аңлаша башладык. Бервакыт, без инде берберебезне бераз аңлый башлагач, Җәлил Гитлер турында сүз кузгатты һәм, рус телендә "һ" хәрефе әйтелми, диде. Һәр хәлдә мин аны шулай аңладым һәм аны Гумеров дип түгел, ә Умеров дип йөртә башладым. Аннары Умеров сүзенең шагыйрь Гомер исеменә охшавын күрдем. Һәм менә шул вакытта Җәлил үзенең дә шагыйрь икәнен әйтте.

**Мин:** Төрмә надзирательләре Җәлилгә язарга комачауламыйлар идеме?

**Тиммерман:** Юк. Төрмәдәге сакчылар профессиональ төрмәчеләр түгел иде. Хәрби хезмәттәге бу картлар үз бурычларына салкын караучы ярыйсы гына кешеләр иде. Без камерада үз иркебезгә куелган идек, һәм шуна күрә Муса яза ала иде, һәм безнең аның белән бергә стена тишәргә дә мөмкинлегебез булды.

**Мин:** Әйтегезче, Муса сезгә үзенең татар иптәшләре турында ни сөйләде?

**Тиммерман:** Без соңгы тапкыр төрмә душында очрашкан вакытта Муса мина үзләрен тоттырган хыянәтчене дә кертеп, унөч кешенең барысының да үлем җәзасына хөкем ителгән булуларын әйтте. Ләкин мин аларның барысының да җәзалап үтерелгән яки үтерелмәгән булуын белмим,—бу инде соңрак булды. Мине Луккауга күчергәндә Муса һәм үлемгә хөкем ителгән башка татарлар әле Шпандауда калдылар.

**Мин:** Үзен җәзалаячаклары турында Җәлил сезгә беренче тапкыр кайчан әйтте? Аны алып китеп, аңардан нинди дә документка кул кую таләп ителгән көннеме?

**Тиммерман:** Әйе, шул көнне, миңа дәфтәрен тапшырганда, ул, мине җәзалаячаклар, диде. Ләкин ул бу турыда инде беренче генә тапкыр әйтми иде. Ул мина бу турыда элек тә берничә тапкыр әйткән иде. Аның моңа ышануы сөйләшүендә дә, хәрәкәтендә дә сизелә иде. Ул моңа бик нык ышана һәм бик тыныч иде.

**Мин:** Муса Җәлил белән тагын нәрсә турында сөйләшүегезне хәтерли алмыйсызмы?

**Тиммерман:** Төрмәдә кешеләр нәрсә турында сөйләшсеннәр соң: безне ачлык газаплый, шуна күрә без кайчак ашау турында сөйләшә идек, мин үзебезнең Бельгиядә, Җәлил үзләрендә, Татарстанда нәрсә ашавыбыз турында бер-беребезгә сөйли идек. Семьяларыбыз, туганнарыбыз турында күп сөйләштек. Барысын да яхшы ук аңлаган булуыма ышанмыйм, ләкин Җәлил әтисенең крестьян булуы, кыз туганнарыннан берсенең инженер-химик булуы турында сөйләде бугай. Ә икенче кыз туганының кем булуы турында аңлатырга никадәр генә тырышса да мин аңлый алмадым. Ул хатыны турында күп сөйли иде, һәм әгәр мин бутамасам, ул мина биргән дәфтәренең дә хатынына тапшырылырга тиешлеген әйтте. Ни турында гына сөйләмәсен, ул һәрвакыт бик тыныч һәм шул ягы белән ул мине сокландыра иде.

**Мин:** Әйтегезче, сез Җәлилне соңгы тапкыр төрмә душында күргән вакытта ул сезнең белән үзенең дәфтәре турында, сездән аны саклауны үтенүе турында янадан сөйләшмәдеме?

**Тиммерман:** Юк, ул бу турыда башка минем исемә төшермәде. Ул мина бер

тапкыр әйтте һәм, мөгаен, вәгъдә биргәч, ул эшләр инде, дип ышангандыр. Мин кабатлап әйтәм—ул бик тыныч һәм батыр кеше иде. Мин аның үтенечен үтәми кала алмый идем. Үзегезне минем урынга куеп карагыз: мина белмәгән телдә язылган дәфтәр тапшыралар, мин аны укый алмыйм, мин анда нәрсә язылганын белмим. Мин үз дәфтәрен мина биргән кешенен шагыйрь икәнлеген беләм. Мин аның нинди шагыйрь, яхшымы, яисә начармы икәнлеген белмим, ләкин мин аның яхшы кеше булуын беләм, тыныч булуы һәм батырлыгы өчен мин аны бик ихтирам итәм, һәм шундый кеше—бер камерада утырган иптәш миннән ни дә булса эшләвемне үтенә икән, мин аны эшләргә кирәк икәнлеген беләм. Минем фикеремчә, ул бу турыда минем онытмавымны белгәнгә күрә, соңгы көрешүебез вакытында мина үзенең үтенече турында кабат әйтмәде.

Тиммерман тагын бер папка таба, аны озак кына актара һәм, ниһаять, элегрәк хәтеренә төшергән исемлекне, кайчандыр, 1944 елда немецлар аның ата-анасына җибәргән әйберләр исемлеген таба. Ул—машинкада немец телендә басылган җиде яисә сигез пункттан торган реестр: бритва, оекбаш, күлмәк, дүртенче яисә бишенче пункт булып "брифташе"—почта сумкасы дигән сүз тора.

—Догалык һәм Җәлилнең дәфтәре төрелгән пакет, мөгаен, шушы пунктта язылган булгандыр,—ди Тиммерман.

Җәлил турында сөйләү тәмам. Тиммерман инде үзе сөйләгән нәрсәләргә берничә кат кире әйләнеп кайта һәм киеренке уйланып, берәр нәрсә оныттадым микән, дип хәтеренә төшерергә тырыша. Ләкин юк, ул башка бернәрсәне дә исенә төшерә алмый. Ул шушы сөйләгәннәреннән артыкны белми.

Тиммерманның үзенең тормышы турында бераз тулырак ишетәсем килә. Башта ул үзе турында кыска һәм теләр-теләмәс кенә сөйләде һәм шунда ук Җәлил турында сөйләүгә күчте. Ләкин хәзер мин үз сорауларымны янадан кабатлыйм, һәм Тиммерман үзе турында тыйнаклык белән, аз сүзле итеп, ләкин шулай да баштагыга караганда бераз тулырак сөйли.

Сугыш башында ул суд башкаручысы конторасында клерк булып эшләгән. Аны бирдә, шушы ук Тирлемон шәһәрчегендә, кулга алганнар. Каршылык хәрәкәте әле берничек дип тә аталмаган вакытта ул бу хәрәкәтнең беренче членнарыннан булган. Аннары бу хәрәкәтне "Бәйсезлек фронты" дип атаганнар. Тирлемондагы каршылык хәрәкәте членнарының һәркайсының үзенең кечкенә генә эше булган. Тиммерманга исә коллаборационистлар исемлеген төзү тапшырылган. Ул аларның һәркайсына аерым картотека булдырган һәм шуларга аларның фашистлар белән хезмәттәшлеге турында үзе тапкан бөтен мәгълүматны яза барган. Моннан тыш, ул аларның фоторәсемнәрен табарга тырышкан. Акрынлап бу картотекага янадан-яна мәгълүматлар кертелә барган. Ул бу картотеканы үзендә тотмаган, бәлки әнисенең дусты булган карт кына ялгыз бер хатын өендә яшереп куйган. Ул кайчакларда, бу хатыннан картотеканы ана яна мәгълүматлар кертү өчен алып, аны янадан шунда илтеп куя торган булган. Соңрак Тиммерманның әнисе Җәлилнең дәфтәрен дә шушы хатында саклаган.

Кырык дүртенче елның азагында ул үзе немец төрмәсендә инде өченче елын утырганда, ә Тирлемон шәһәре фашистлардан азат ителгәч, Бельгия патриотлары кырык икенче елда ул алып барган бу картотеканы әлеге карчыктан алалар һәм аның буенча күп кенә коллаборационистларны табалар. Шулай итеп, аның эше әрәмгә китми. Бу эштән тыш, ул тагын әле яшерен газета тарату белән дә шөгыльләнгән. Аны, тагын алтмыш дүрт кеше белән, шул исәптән кыз туганының ире белән бер үк көнне, төнлә, урын өстендә вакытта кулга алганнар. Аларны, дошманга ярдәм итүдә гаепләп, Брюссель төрмәсенә җибәргәннәр. Кыз туганының ирен үлем җәзасына хөкем иткәннәр, ә ана һәм аның иптәшләренә өч елдан биш елга кадәр биргәннәр. Моннан соң аны Вестфалиягә җибәргәннәр. Аннан янадан Брюссельгә, ә аннан инде Берлинга җибәргәннәр, һәм шунда ул Муса Җәлил белән очрашкан. Аннары аларны икенче кат хөкем иткәннәр һәм, дошманга ярдәм итүләре, фашизмга каршы әдәбият таратулары һәм Өченче рейхка лояль

булган кешеләрнең исемлеген төзүләре өчен барысына да үлем җәзасы бирүне таләп иткәннәр. Нәтиҗәдә, баштагы өч ел төрмә урынына, ул биш ел каторга алган. Алар соңгы вакытта утырган лагерь Эльба елгасы янында булган. Бу лагерьга бер үк вакытта ике яктан руслар һәм америкалылар якынлаша башлаганнар. Немец сакчылары качканнар. Руслар лагерьга якын ук килгәннәр, һәм Тиммерман берничә көн буена аларда булган, хәтта медицина тикшерүе дә үткән. (Тиммерман папкасыннан "М. П."—медпункт печате сугылган һәм безнең нииндидер-хәрби врачыбызның танымаслык имзасы куелган кечкенә генә саргайган кәгазь кисәген чыгара).

Берничә көн үткәч, руслар аны һәм башка бельгиялеләрне, туган җирләренә җибәрү өчен, америкалыларга тапшырганнар.

Сугыш беткәннән соң ул һәрвакыт Тирлемонда яши, өйләнгән, страховой конторада клерк булып эшли. Менә шул гына. Тиммерманка ул болай да инде үзе турында кирәгеннән артык күп сөйләде кебек тоела. Мин аңа аның татар әдәбияты һәм гомумән бөтен совет әдәбияты каршында бик зур хезмәте барлыгы турында әйтәм. Сез бу әдәбият өчен Муса Җәлилнең соңгы әсәрләрен коткарып калдыгыз, дим һәм Муса Җәлилгә үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелүен сөйләп бирәм.

—Ул бик тыныч һәм бик батыр кеше иде, мин аны һәрвакыт ихтирам итә идем,—бу сүзләрне ул инде ничәнче тапкыр зур эчке кичереш белән кабатлый.

Саубуллашу өчен урынымнан кузгалгач, мин Тиммерманга безнең аңа бик зур рәхмәт әйтүебезне тагы бер тапкыр белдерәм. Көтмәгәндә генә ул кашларын җыера һәм бу сүзгә каршы килү ишарәсе ясый.

—Мин аның нинди дәфтәр икәнен белмәдем дә ич,—ди ул бик җитди итеп.— Мин аның ниндидер искитәрлек нәрсә булуын белмәдем, мин иптәшемнең үтенечен генә җиренә җиткердем. Мин сезнең үзем турында, мин искитәрлек нәрсә эшләдем, дип саный бу, дип уйлавыгызны теләмәс идем. Ул дәфтәр бик мөһим дәфтәр булып чыккан икән—бик әйбәт, ләкин моны минем хезмәтем дип санарга ярамый, мин аны белмәдем, мин аңарга андый зур әһәмият бирмәдем... Боларның барысы да бик гади эш иде, һәм хәзер дә минем өчен ул шундый ук гади нәрсә булып кала. Мин кешене ихтирам итә идем һәм аның өчен кулымнан килгәнне эшләдем. Муса Җәлилнең хатынын күргәндә,—дип өсти ул,—аңа әйтегез, мин аның ирен бик нык, бик нык ихтирам итә идем. Сез аңарга моны һичшиксез әйтегез...

Без саубуллашабыз. Мин урамга чыгам һәм машинага утырам. Машина кузгалып китә. Кечкенә генә эчемлек кибетенең ачык ишеге янында, ишек яңагына сөялгән хәлдә, кулын кесәләренә тыккан, озын буйлы, аз гына иелеп йөрүчән, елмаймый торган, тыйнак ир кеше, үзенең әнисе һәм тагын бер тыйнак бельгияле карчык белән бергә әдәбият өчен Муса Җәлилнең "Моабит дәфтәре"н коткарып калган, бурычын үтәгән кеше, Андре Тиммерман басып тора.

**Тирлемон—Москва.**

*("Литературная газета", 13 октябрь, 1956 ел)*

*1956, №11*

# *М. Җәлил турында совет язучылары*

* * *

Муса Җәлил шигырьләрен мин һәрвакыт каушау һәм дулкынлану хисе тоеп тәрҗемә иттем. Бу сокландыргыч кешенең һәм яхшы шагыйрьнең фаҗигале язмышы хакында уйламыйча, аның әсәрләренә кагылырга ярамый.

**Анна АХМАТОВА**

* * *

...Муса Җәлилгә—беренче шагыйрьгә—бөтенхалык Ленин премиясенең бирелүе югары гаделлек, безнең барлык шагыйрьләребез өчен югары үрнәк булды.

Муса Җәлилнең зур исеме—совет поэзиясенең горурлыгы һәм даны!

*Гомерем минем моңлы бер җыр иде,*
*Үлемем дә яңгырар җыр булып!*

Чыннан да шулай—Җәлил җыры, Җәлил тормышы җыр булып мәңге яңгырар!

**Николай ТИХОНОВ**

* * *

Ул минем күңелемә иң якын кешеләрнең һәм сөекле шагыйрьләрнең берсе буларак керде.

Мин Җәлилне укыганда һәм уйлаганда, аның бөтен гомере батырлык булып килеп баса. Аның белән замандашларыбыз горурлана һәм килер буын кешеләре дә аңа охшарга тырышырлар.

Аның "Моабит дәфтәре" Памирның иң ерак кышлакларына хәтле килеп җитте. Кем җиңеп үлә, ул—үлемсез. Муса Җәлил венгр халык шагыйре Петефи һәм чехословакия улы Юлиус Фучик белән беррәттә, Җәлилнең тормышны раслый торган героик поэзиясе халыкларны якты киләчәк өчен көрәшкә чакыра, ул гасырлар буе балкып торыр.

**Мирза ТУРСУН-ЗАДЕ**

* * *

Палач балтасы каршында шундый зирәк, Ватанга чиксез мәхәббәт, ә фашистларга җимергеч нәфрәт тулы, ялкынлы юллар язу өчен тимер, сыгылмас ихтыярлы, якты акыллы, зур һәм кайнар йөрәкле кеше булырга кирәк. Муса Җәлил әнә шундый шигъри юллар язды.

Шагыйрь җиңүгә нык ышанды, һәм ул җиңү килде. Ватан тантанасы өчен тормышларын биргән күп санлы геройлар арасында Муса Җәлил исеме сүнмәс йолдыз булып һәрвакыт янар.

**Петрусь БРОВКА**


* * *

Мин аның белән 1936 елда таныштым. Тиз арада "Джим" поэмасын—фашистлар Германиясе турындагы, төрмәләр, шуларның берсендә шагыйрь үзе дә һәлак булачак төрмәләр турындагы әсәрен тәрҗемә иттем. Тәрҗемә өстендә автор белән даими иҗат бәйләнеше тотып эшләдем. Ул чакта шагыйрь Мәскәүдә тора, ул миндә була, ә мин аның Столешников тыкрыгындагы квартирында була торган идем.

Ул мөлаем, нечкә хисле, бөтен табигате белән музыкаль кеше иде.

**Семен ЛИПКИН**

*"Казан утлары", 1966 №2*



*М. Җәлилнең корреспондент таныклыгы. 1925 ел.*



*М. Җәлил һәм С. Баттал. 1929 ел*



*"Моабит дәфтәрләре".*



СОЮЗ СОВЕТСКИХ СОЦИАЛИСТИЧЕСКИХ РЕСПУБЛИК

ГЕРОЮ СОВЕТСКОГО СОЮЗА

ПРЕЗИДИУМ ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР

УКАЗОМ от

ЗА


ПРИСВОИЛ

ЗВАНИЕ ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.

ПРЕДСЕДАТЕЛЬ ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР

СЕКРЕТАРЬ ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР

Москва – Кремль.



*М. Җәлилнең тууына 80 ел тулу уңаеннан уткәрелгән тантаналы җыелыш күренеше. Мәскәү. Колонналы зал. 1986 ел.*



Постановлением Комитета по Ленинским премиям в области литературы и искусства при Совете Министров СССР от 22 апреля 1957 года присуждена Ленинская премия

*Мусе Джалилю (Залилову Мусе Мустафовичу), поэту, – за цикл стихотворений „Моабитская тетрадь“.*



*Казандагы М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры.*

## Самед Вургун

әзәрбәйҗан шагыйре

### МУСА ҖӘЛИЛГӘ

*Котырды палачлар шашкан эт кебек—*
*Хаксызга түгелде мөкатдәс каның,*
*Яртысында килеш калды өзелеп*
*Шигырь юлларың, тормыш юлларың.*

*Кешеләрдә сүнмәс сиңа мәхәббәт,*
*Чөнки син чын күңелдән сөйдең кешеләрне,*
*Җырладың сазыңда безнең кайнар дәрт,*
*Безнең омтылыш һәм безнең эшләрне.*
*Туган, син чын күңелдән сөйдең кешеләрне.*

*Тудың, яшәдең син шанлы көннәрдә,*
*Сүзеңне йолдыздай сиптең ил күгенә,*
*Илем бакчасында шиңмәс гөлләрдә*
*Чәчәктәй синең сүзләрең күренә,*
*Синең хатирәң гөлләрдәй үрелә.*

*Синең теләкләрнең үсентеләрен*
*Иркәләп үстерә Ватан кырлары,*
*Яңгырата сине сагыну көйләрен*
*Идел буйларының татар кызлары.*

*Минем шагыйрь дустым, шагыйрь кардәшем,*
*Даның синең Кавказ тавыдай бөек,*
*Шул дан белән бергә минем дә эшем*
*Күтәрелде өскә, бер байрак кебек.*

*Илләрне гизә шигырь, чикләрне аша,*
*Яңгырый ул ничә мең йөрәктә, җанда,*
*Сиңа улым дип, балам дип дәшә*
*Минем туган йортым Әзәрбәйҗан да.*

***Әнвәр Давыдов тәрҗемәсе***
*1954, № 4*

## Семен Данилов

якут шагыйре

### СОЛДАТ-ШАГЫЙРЬНЕҢ ГОРУР КАРАШЫ

*Үлем угы тиеп җиргә аугач,*
*Кул-аягын каерып, богаулап,*
*Караңгы һәм тынчу, тар зинданга*
*Ыргыттылар аны җыйнаулап.*

*Кан төкергән хәлдә: "Канга—кан" дип*
*Кычкырды ул бөтен көчен...*
*Күрде гүя шул чак алсу байрак*
*Элуләрен рейхстаг өстенә.*

*Баш идермәк булып кыйнауларның*
*Чыгарлыкмы икән санына?!*
*Сүзләрендә тоеп аның көчен,*
*Теләделәр сатып алырга.*

*Сатылмады! Көрәш җырыннан тыш*
*Җирдә яшәү мөмкин түгелгә*
*Горур карап барды солдат-шагыйрь*
*Авыр, ләкин матур үлемгә.*

*Үлеме белән җиңде үлемне ул,*
*Үлемсезлек шушы түгелме!*
*Җирдә мәңге исән калыр өчен*
*Халкы йөрәгендә тирелде...*

*Тормышта да, инде соңгы тапкыр*
*Күргәндә дә кояш нурларын,*
*Без җырларбыз!*
*Соңгы сулышта да*
*Без җырларбыз көрәш җырларын!*

***Рәшит Гәрәй тәрҗемәсе***
*1976, №2*

Михаил
Дудин
*рус шагыйре*

## *МӘҢГЕЛЕК ҖЫР*

*Изсәләр дә таптап шагыйрь җырын,*
*Атсалар да төбәп йөрәккә,*
*Ул җыр, илче булып, ирек нурын*
*Тузан аша илтә еракка.*

*Җыр югалмый, ул мәңгегә туган.*
*Юк азагы аның, юк башы.*
*Пушкинга да эстафета булган*
*Билгесез бер җырчы юлдашы.*

*Җаным өшеп китә үткәннәргә,*
*Хәтер төер булып буа бик:*
*Юксына күк аһ-зар Тукайларны,*
*Җәлилләрне шомлы Моабит.*

*Әнә палач баскан баш очына,*
*Зәһәрлесен ата ул укның.*
*Карга аккан каннан төтен чыга,*
*Ыңгыраша ташы Машукның.*

*Палач чаба Фучик-батыр ирне,*
*Җанын ала шагыйрь-Мусаның.*
*Шулай да җыр алга өнди җирне,*
*Канатыннан кагып тузанын.*

*Тәрҗемә дә кирәк түгел аңа,*
*Яшәү юлы ачык, нык аның:*
*Ул халык һәм синең язмышыңда,*
*Язмышында азат дөньяның!*

***Мөхәммәт Садри тәрҗемәсе***
*1966, №2*

## *М. Җәлил турында совет язучылары*

* * *

Һәр шагыйрьнең үз язмышы була. Муса Җәлил–героик язмышлы шагыйрь. Героиканың мәгънәсен белгән грузин халкы ерак Татарстанның мәшһүр улы Муса образын кайнар ярата. Ватаныбызның барлык халыклары кебек үк, без дә куркусызлыгы һәм батырлыгы белән бөтен дөньяны таң калдырган яшь һәм сокландыргыч шагыйрьне үзебезнең йөрәкләребездә сакларбыз.

**Георгий ЛЕОНИДЗЕ**

* * *

Шагыйрь–кешедән аерылгысыз. Аның тормышы һәм иҗаты бер эздән ага. Әгәр шагыйрьнең шигырьләре күкрәүләрдә һәм давылларда туса, бу хәл аеруча әһәмият казана.

Поэзиянең куркусыз батыры үлемне җиңгән, өстендә палач балтасы күтәрелеп торган бер вакытта, кара фашист тоткынлыгында, каты кул һәм нык рух белән үзенең "Моабит дәфтәре"н иҗат иткән. Кешеләргә тугрылык, Ватанга тугрылык турындагы шигъри ант аның тиздән тибүдән тукталачак йөрәгендә мәңгелек чишмәсе төсле ургыла.

Ул үзенең кыска, ләкин якты поэтик юлында, үз каны белән беркетелгән иҗат батырлыгында безгә тынгысыз васыять һәм наказ калдырган. Моны киләчәк буыннар исләрендә изге бурыч итеп тотарлар.

Әсир ителгән, ләкин буйсынмаган сугышчы-шагыйрьнең чәнечкеле юлы Литва җире аркылы да узган. Тик үлемсез геройның безгә шулай кадерле булуы моның белән генә аңлатылмый. Легендалар белән бизәлгән, яктылыгын һичкайчан җуймаячак дан белән бүләкләнгән герой хәзер дә үзенең рухланып язылган шигъри юллары белән туган Татарстанына эндәшкән кебек, Неман буе халкына, безнең бөтен Ватаныбызга, ирек сөюче кешеләргә, Поэзиянең һәм Азатлыкның бөтен дөньядагы барлык дусларына мөрәҗәгать итә.

**Эдуардас МЕЖЕЛАЙТИС**

*1966, № 2*

## *М. Җәлил турында дөнья язучылары*

* * *

Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты белән немец халкын киң рәвештә таныштыруны без үзебезнең бурычыбыз итеп саныйбыз.

**Макс ЦИММЕРИНГ**
***немец язучысы***

*1957, № 11*

* * *

Безнең халык герое Юлиус Фучик белән татар шагыйре Муса Җәлил арасында зур охшашлык бар. Икесе дә коммунист, икесе дә гомерләренең актык көннәренә кадәр курку белмәгәннәр. 1944–1945 нче елларның авыр көннәрендә алар, бер-берсен белмәгән хәлдә, үзләренең җырлары аша очраштылар.

Күрәсең, шушы үзенә бер төрле туганлык охшашлыгы аркасындадыр, Муса Җәлилнең исеме бездә һәрвакыт Юлиус Фучик исеме белән бергә яңгырый.

**Ярослав КАБЧИЕК**
***Чехословакия шагыйре***

*1957, №11*

## М. ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ПОЭМА

Казакъ совет әдәбиятынын күренекле язучысы Жубан Молдагалиев Муса Җәлилгә багышлап язган поэмасын тәмамлады. "Казакъ әдәбияты" газетасында (1956 ел, 28 сентябрь) поэмадан өзекләр басылды. Анда Муса Җәлилнең фашист тоткынлыгындагы батырлыгы образлы итеп тасвирланган.

*1956, №12*

## "МОАБИТ ТОТКЫНЫ"

Герой шагыйрь Муса Җәлил образы СССР халыклары әдәбиятында елдан-ел кинрәк урын ала. Быел калмык шагыйре Давыт Кугултинов Муса Җәлилгә багышланган "Моабит тоткыны" исемле поэмасын язды. КПССның Калмык Өлкә Комитеты секретаре Б. Жимбинов әсәргә бәя биреп: "Теленең образлылыгы һәм әдәби осталыгы ягыннан Д. Кугултиновның "Моабит тоткыны" поэмасы калмык совет поэзиясенең иң күренекле әсәрләреннән берсе",—ди ("Литература и жизнь" газетасының быелгы 20 август санынннан).

*1958, № 10*

## МУСА ҖӘЛИЛ ШИГЫРЬЛӘРЕ ЧЕХ ТЕЛЕНДӘ

Чехословакия язучылары союзы органы "Литерарни новины" журналы хәбәренә караганда, Чехословакия—Совет дуслыгы җәмгыяте нәшрияты Прагада герой шагыйрь Муса Җәлилнең "Моабит дәфтәре" исемле шигырьләр җыентыгын чех телендә басып чыгарган.

Чехословакия хезмәт ияләре татар шагыйре Муса Җәлил әсәрләрен яратып укыйлар. Аның шигырьләре газета һәм журнал битләрендә әледән-әле басылып тора. "Прага—Мәскәү" журналында Ярослав Кабичекның Муса Җәлил иҗатына багышланган зур гына мәкаләсе урнаштырылган.

*1958, № 11*

## "МОАБИТ ДӘФТӘРЕ" ЛАТЫШ ТЕЛЕНДӘ

Күптән түгел Латвия дәүләт нәшрияты Муса Җәлилнең "Моабит дәфтәре" исемле шигырьләр җыентыгын латыш телендә бастырып чыгарды. Җыентыкны тәрҗемә итүдә Латвиянең өлкән шагыйрь һәм тәрҗемәчеләреннән Андрис Веян, Янис Лусис, Арвид Скабле, Мирдза Кемне, Андрей Балодис һ. б.лар катнашкан.

Җыентыкның кереш сүзен Андрис Веян язган.

*1958, № 12*

## ҖӘЛИЛ ӘСӘРЛӘРЕ—НЕМЕЦ ТЕЛЕНДӘ


Берлиндагы "Фольк унд Вельт" нәшриятында "Интернациональ лирика китапханәсе" сериясеннән Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең Моабит шигырьләре тупланган җыентык немец телендә басылып чыкты. Бу—татар шагыйренең Германия Демократик Республикасында чыгарылган шигырьләренең өченче басмасы инде. Китап монарчы дөнья күргән ике җыентыктан да күләмлерәк. Шигырьләр турыдан-туры оригиналдан—татарчадан тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәчеләре—Вильгельм Ткачик һәм Хельмут Прайслер. Кайбер әсәрләр татар телендә дә урнаштырылган. Җыентыкка кереш сүзне Әминә ханым Җәлил язган. Китапның соңгы битләрендә Рафаэль Мостафинның Җәлил иҗаты турындагы мәкаләсе дә бирелгән.

*1978, № 7*

## МУСА ҖӘЛИЛ УРАМЫ

Шушы елның августында Төзүчеләр көне хөрмәтенә БАМдагы Беркакит поселогының үзәк урамына герой-шагыйрь Муса Җәлил исеме бирелде.

*1978, № 12*



Рафаэль Мостафин

# ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ, ХАЛЫК КАҺАРМАНЫ

## Кайсы исем җайлырак?

Үткән гасырның сиксәненче еллары башында без өчәүләшеп (Әминә Җәлил, Сибгат Хәким һәм мин) Германия демократик республикасына барган идек. Берлинның Дуслык йортында Җәлилгә багышланган кичә булды. Немец язучысы Леон Небенцаль доклад белән чыкты. Башка немец язучылары, галимнәре, журналистлары да чыгыш ясады.

Бу вакытта инде Җәлил шигырьләре немец телендә өч мәртәбә басылып чыккан, татар шагыйренең батырлыгы турында Берлин киностудиясе "Ди Роте камилла" ("Кызыл ромашка") исемле тулы метражлы нәфис фильм төшергән, фильм немец телевидениесе аша берничә мәртәбә күрсәтелгән иде. Газета-журналларда басылган Җәлил шигырьләрен, аңа багышланган мәкаләләрне әйткән дә юк! Шуңа күрә немец дусларыбыз Җәлил исемен яхшы беләләр, аны кабатлаганда ялгышмадылар. Хәтта "ж" авазын да бик матур, йомшак итеп, татарчага охшатып әйтәләр иде.

Ә менә Тукай исемен әйткәндә тотлыктылар: йә Токай, йә Тукка дип ялгыштылар. Югыйсә, исеме дә бик гади, Җәлилнекеннән җиңелрәк. Шул чак Сибгат абый, мөлаем гына елмаеп, колагыма пышылдады:

—Җәлил исеме боларга килеп җиткән... Тукайларыбызны да җиткерәсе иде...

Чыннан да, Муса Җәлил исеме, аның иҗаты бер Алман илендә генә түгел, башка чит илләрдә дә укымышлылар өчен яхшы таныш. Аның шигырьләре инглиз телендә аерым китап булып басылып чыкты, француз, испан, румын, болгар һәм башка бик күп телләргә тәрҗемә ителде (барысы илледән артык). Һич икеләнмичә Муса Җәлилне дөнья күләмендә иң күп таралган, иң билгеле татар шагыйре дип атап була.

## 2691 исем... Азмы, күпме?

Кулымда—Җәлил иҗатына багышланган библиографик күрсәткеч. Ул Казан университеты нәшриятында 1976 елда басылган. Монда Җәлил иҗатына һәм аның тормыш юлына багышланган китаплар, мәкаләләр һәм рецензияләрнең исемнәре күрсәтелгән. Аз да түгел, күп тә түгел, барлыгы 2691! Библиографик күрсәткеч үзе дә шагыйрьнең исән чакта басылган китапларыннан күпкә калынрак. Күрсәткеч чыкканнан соң үткән утыз ел дәвер эчендә Җәлилгә багышланып чыккан китапларны, монографияләрне, диссертацияләрне һәм аерым мәкаләләрне дә кушсаң, китап икеләтә калынрак булыр иде.

Әйе, Җәлил иҗаты, аның тормыш юлы өйрәнелмәгән дип әйтеп булмый. Бу изге эшне заманында аның якын дусты, тәнкыйтьче Гази ага Кашшаф башлап җибәргән иде. Аңа Нил Юзиев, Әхмәт Исхак, Роберт Бикмөхәммәтов, Шәмси Хамматов, Исхак Зәбиров, Әмир Мәхмүдов һәм башкалар кушылды. Татар телендә Җәлилнең батырлыгын тасвирлаучы беренче китап—Ш. Рахманкуловның "Патриот-шагыйрь Муса Җәлил" дигән брошюрасы. Бу утыз битлек кенә китапчык Казанда 1954 елда ук дөнья күрде. Шуннан соң рус телендә дә Җәлилгә багышлап китаплар

чыга башлады (Ю. Корольков, К. Барская, К. Жаманаклы һ.б. хезмәтләре). Бу юлларның авторы да Гази ага Кашшаф житәкчелегендә шул чорларда ук эзләнүләр алып бара башлады, чит ил архивларында казынды, беренче мәкаләләрен бастырды.

Болай булгач, Жәлил турында нинди дә яңа сүз, тапталмаган фикер әйтеп буламы? Патриот-шагыйрьнең йөз еллыгы якынлашып килгән көннәрдә мин менә шул турыда уйландым.

## "Ярлы крәстиан гаиләсеннән..."

Совет чорында чыккан басмаларда Жәлилнең тормыш юлын бераз шомартып, ижатын күтәрә төшергә тырышып, кимчелекләренә күз йомып язу тенденциясе сизелә. Әмма Жәлил болай да бөек шәхес. Ул мондый ташламаларга мохтаж түгел. Ләкин аның тормыш юлы да, ижаты да шактый катлаулы, каршылыклы, хәтта сикәлтәле булды.

Сүзне чыгышыннан башлыйк. Бик күп басмаларда "Муса ярлы крәстиан гаиләсендә туып-үскән" дип әйтелә. Менә, әйтик, атаклы тәнкыйтьче Роберт Бикмөхәммәтовның Жәлилнең чираттагы жыентыгына язган кереш сүзе (Муса Джалиль. В последний бой. Перевод с татарского. Москва. 1981. Издательство Министерства обороны СССР.) Монда болай дип язылган (7 бит):

"Муса Джалиль родился 15 февраля 1906 года в деревне Мустафино Шарлыкского района нынешней Оренбургской области. Его дед Абубакир пас скот. Отец Мусы Мустафа и сеял, и прирабатывал, но не вылезал из бедности. В 1919 году он умирает..."

Башка бик күп басмаларда да мондый караш әледән-әле кабатланып килә. Чынлыкта исә Мусаның әтисе Мостафа абзый шактый нык тормышлы сәүдәгәр була. Туган авылында ул кызыл мал, азык-төлек белән сәүдә итүче кибет тоткан. Бу кибетнең таштан салынган аскы каты алтмышынчы елларга хәтле туган авылында сакланды. Икенче, агачтан салынган катында хужалар үзләре торган. Бу турыда авылдашлары да сөйли, Мусаның абыйсы Ибраһим да язып калдырган:

"Безнең әти авыл хужалыгы белән бик мавыкмады. Ашарга кирәк кадәр генә иген икте. Тирә-як базарларга сәүдә белән йөрү өчен ике ат асрады. Бер-ике сыеры була торган иде, ләкин вак мал асрамады. Төп кәсебе вак сәүдә булды".

Болай булгач, аны ярлы дип әйтеп буламени? Дөрес, Мостафа абзый әлләни баеп, тернәкләнеп китә алмый. Моңа бигрәк тә аның аракы белән артык дус булуы комачаулый. Бу турыда да элекке елларда язудан тыелалар иде. Язган тәкъдирдә дә редактор яки цензорлар сызып ташлыйлар иде. Янәсе, герой-шагыйрьнең әтисе эчкече була алмый. Югыйсә, Муса үзе бөтенләй диярлек эчмәгән. Хәтта тәмәке дә тартмаган.

Мусаның әнисе исә, Рәхимә апа, мулла кызы була, дини рухта тәрбияләнеп үсә. Балаларын да шул ук рухта тәрбияләп үстерә. Аларның өйләрендә дини китаплар шактый күп була.

## Жәлилнең остазы

Жәлилнең ижат юлында моңача читләтебрәк үтелгән тагы бер момент бар: ул да булса аның башлангыч чор ижатына Чәнәкәй йогынтысы.

Төхфәт Чәнәкәй (Төхфәтулла Гыйззәтуллин, 1893—1959) – хәзерге вакытта бөтенләй диярлек онытылган шагыйрь. Аның исеме "Совет татар язучылары" исемле библиографик белешмәгә дә (Казан, ТКН, 1986) кертелмәгән. Югыйсә ул Октябрь инкыйлабына чаклы ук яза башлап, совет чорында берничә шигырь жыентыгы чыгара ("Өмет очкыннары",—1918, "Карагайлы каен урманында",—1928, "Көрәш кылларында",—1928, һ.б.) Утызынчы елларда репрессиягә эләгеп, нинди дер могжиза белән исән кала, соңыннан тулысынча аклана. Әмма татар әдәбиятыннан читләшеп, Урта Азия якларына китә, шунда вафат була. Порнографик рухта язуда гаепләп, аны гомере буе санга сукмадылар. Шулай да, бүгенге күзлектән караганда, мондый әсәрләрне "порнография" түгел, "эротика" дип атыйлар. Кайберәүләр бүген хәтта эротик поэмалар да бастыралар. Һәм бу аларның дәрәжәсен төшерми.

Үз ижатына караш нинди генә булмасын, Төхфәт Чәнәкәй Муса Жәлилнең ижат юлында зур роль уйный. Чынлыкта ул аның беренче һәм иң абруйлы остазы була. Алар Оренбургта, Муса "Хөсәения" мәдрәсәсендә укыганда очрашалар. Мусага

ул вакытта нибары унбер-унике яшь. Ченәкәй Муса каләме белән язылган һәр әсәрне җентекләп укый, кимчелекләрен күрсәтә, акыллы киңәшләрен бирә. Мусаның әдәби зәвыгын тәрбияләүдә аның йогынтысы искиткеч зур була. Ченәкәй Мусага беренче әдәби адымнарын ясарга булыша, аны зур иҗат юлына чыгара. Җәлил үзенең остазы белән шулкадәр дуслашып китә ки, хәтта мәдрәсәнең тулай торагыннан китеп, берара Ченәкәйнең Оренбургтагы фатирында яшәп ала. Ченәкәй дә аңа үз улына карагандай карый.

Дөрес, бу йогынтының кире яклары да булмый калмагандыр. Ченәкәй хатын-кызлар белән артык мавыгып, кайвакыт чыгырыннан да чыга. Мусага да бу чир, күрәсең, йокмый калмагандыр. Һәрхәлдә, Җәлилнең тормыш иптәше Әминә ханымның бу турыда ачынып сөйләгәне бар.

## "Кызыл авыз"

Бүгенге көндә Муса Җәлил хаклы рәвештә халык шагыйре, классик шагыйрь дип исәпләнә. Әмма классик булгач та, аның һәрбер юлы да камил, үрнәк рәвештә язылган дигән сүз түгел әле.

Мусаның дүрттомлыгында башлангыч чор шигырьләре басылган. Бу шигырьләр аның "Революционный җырлар төргәге" дип аталган дәфтәрендә теркәлеп калган. Нигездә бу—өндәмә-лозунг рухындагы шигырьләр. Тиз тәэсирләнүчән, яңалыкка омтылучан яшь шагыйрь чорның идеалларын үзләштерергә, заман белән бергә атларга тырыша. Бу турыда шигырьләрнең исемнәре үк "кычкырып" тора: "Кызыл әләмгә", "Кызыл таң нурлары", "Кызыл каһарман", "Кызыл гаскәр", "Кызыл юл", "Кызыл бәйрәм" һ.б. Кыскасы, яшь автор артык "кызылланып" китә. Болай сөйләүчеләрне халыкта "кызыл авыз" дип атыйлар.

Бу шигырьләрдә революцион рух, яңа чынбарлыкны чын күңелдән яклау, искелектән ваз кичү теләге, ялкынлы пафос ярылып ята. Әмма революция өндәмәләрен рифмалаштырып кына чын шагыйрь булып булмый. Тиздән Муса үзе дә моны яхшы аңлый һәм башкача язарга омтыла. Җәлил иҗаты турында язучы авторлар күп очракта мондый шигырьләрнең "турысызыклыгын", алардагы коры агитация, революцион лозунгларын, сурәт һәм чагыштыруларның сыеклыгын күрмәмешкә салышалар. Әмма Җәлилнең иҗат юлын ясалма рәвештә турайтырга кирәкми. Югарыда әйткәнебезчә, ул моңа мохтаҗ түгел.

Җәлил башлангыч чорында өч дәвер үтә. Башта артык гади һәм сыек, аннан соң артык катлаулы, ясалма сурәтле һәм шулай ук йомшак шигырьләр яза. Һәм ниһаять, авырлык белән генә, дөрес юлга чыга: гади һәм эмоциональ яктан бай, тәэсирле, үтемле әсәрләр иҗат итә.

Берара Муса, остазы Һади Такташка ияреп, гыйсъянчылык чире белән авырып ала. Гыйсъянчылык—милли әдәбият җирлегендә заман ихтыяҗы белән туган әдәби күренеш иде. Гыйсъянчы каһарман барыннан да бигрәк фетнәче, иске тормышка карата ризасызлык белдерүче кеше. Аның дөньяга карата мөнәсәбәтендә беренче чиратта инкарьлык пафосы өстенлек итә. Ул көрәш уты белән яна. Башканы күрми дә, күрәсе дә килми. Җәлилнең "Үлем алдыннан", "Янчы, дөнья", "Әсирлектә" һ.б. шигырьләре нәкъ шундыйлар. Шагыйрь төрмә, ачлык-ялангачлык, ятимлек, читлектәге тормыш, хәерчелек күренешләре аша иске тормышны фаш итә, анардан баш тарта. Әмма, әдәби осталыгы җитмәү аркасында образларны артык катлауландырып җибәрә, коры риторикага бирелә.

Җәлилнең башлангыч чор иҗатына мелодраматик мотивлар да хас. Алар аеруча аның үзешчән сәнгать өчен язылган "Каз канаты", "Бибкәй кыз" кебек музыкаль мелодрамаларында күренә. Шуңа да карамастан (ә бәлки, нәкъ шуңа күрәдер) яшь Мусаның бу башлангыч пьесалары бөтен Татарстан, Башкортстан, Оренбург, Ташкент өлкәләре үзешчәннәре тарафыннан яратып уйналдылар, хәтта профессиональ театрларда да куелдылар.

## Үсү юлында

Җәлил иҗаты бер яктан артык гади, икенче яктан куе һәм шартлы романтик сурәтләрдән арынып, психологик реализм юлы белән үсте. Әмма егерменче еллар ахыры—утызынчы елларда язылган шигырьләрнең дә барысын да уңышлы дип

әйтеп булмый. Җәлил үткән юл, чыннан да, югарыда әйтелгәнчә, шактый сикәлтәле булды.

Такташка ияреп, ул шигырьне сөйләм теленә күчерергә талпыныш ясап карый. Мондый шигырьләр күпчелек очракта төссез проза юлларыннан әллә ни аерылмый:

*Укы!*
*Укы!*
*—Өйгәме әллә, Локман абзый?!*
*—Ашыкма әле,*
*—Утыр, тыңла!*

*("Гәзит", 1925)*

Сәбәп монда әдәби сәләтнең чарланып житмәвендә генә түгел, шактый тирәнрәк. Җәлил үз иҗади йөзен, шигърияттәге юлын ачыклап җитмәгән. Сөйләм шигыренен яңа мөмкинлекләрен эзләү белән беррәттән, шагыйрь музыкаль нәфислеккә, лирик агымның табигыйлегенә ирешергә тырыша. Әмма ул чын шигъри образлылыкка, поэтик яңгырашка шактый авырлык белән ирешә. Моңа чор кануннары, беренче чиратта социалистик реализм методы комачаулык итә.

Җәлилнең утызынчы еллардагы иҗатының төп үзенчәлеге шунда — шагыйрьгә социализм идеяләренең җиңүенә чын күңелдән ышанудан туган оптимистик рух хас. Заман узу белән бу идеяләрнең ялгыш, алдакчы мираж булуы ачыкланды. Әмма шагыйрьне чорыннан һичничек аерып булмый. Ул заман идеологиясенә мөкиббән китеп, җитди хаталар да ясый.

Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, ул үзен "кискен сыйнфый көрәш" тарафдары итеп тоя. Кайчандыр совет тәнкыйтьчеләре аның бу сыйфаты белән сокланалар иде. Хәзер исә без шагыйрьнең чикләнгән булуын да күрәбез. Мәсәлән, Җәлил үзенең шигъриятендә дә, публицистик мәкаләләрендә дә ислам диненә каршы чыгышлар ясый, мулла-мәзиннәрне, кулакларны, буржуйларны, башка төрле "корткычларны" нәфрәтләнеп фаш итә. Бүгенге көндә исә без моның ише һөҗүмнәрне чорның идеологик күрсәтмәләренә ияру дип кенә кабул итәбез.

Дәвернең башка әдипләре шикелле, Җәлил дә "бөек юлбашчы" Сталинны мактап мәдхияләр яза, социализм төзелешләренә дан җырлый. Бүген исә без мондый шигырьләргә яңа күзлектән карап, алардагы ялган пафосны, чынбарлыкны кирәгеннән артык бизәп, тормышны берьяклырак итеп сурәтләвен дә күрәбез.

Социалистик реализм таләпләренә ярарга тырышып, шагыйрь кайвакыт тормыш чынбарлыгына каршы бара. Әйтик, "Сәрвәр" исемле поэмасында (1929) шагыйрь шул исемдәге төп персонажның эчке кичерешләрен турыдан-туры сыйнфый көрәш белән бәйли, бу фикерне "маңгайга бәреп", декларатив төстә үткәрә:

*Көрәшченең һәрбер эчке эше*
*Сыйнфый эше белән бәйләнсен,*
*Семья тормышы да*
*Шул көрәшнең*
*Җанлы кисәгенә әйләнсен!*

Комсомолка Сәрвәр дә башта шулай уйлый. Әмма кияүгә чыккач, мещан саэлыгына батып, ир колына әверелә. Җыелышларга йөрми, өйдә генә ята, комсомол эшләренә катнашмый. Поэманың уңай геройлары исә башкача фикер йөртә:

*Без сөюне, семья төзүне дә*
*Көрәш белән бәйләү кирәген*
*Аңлый алдык...*

Бу сүзләрдә авторның идеологик позициясе бик ачык чагыла. Поэманың төп фикере: гаилә дә, мәхәббәт-сөю дә сыйнфый көрәш таләпләренә буйсынган булырга тиеш. М.Җәлил Һ.Такташның "Мәхәббәт тәүбәсе" поэмасы белән бәхәскә кереп, хатын-кызның төп вазыйфасын фәкать революцион көрәштә күрә, аның гаиләдәге ролен санга сукмый. Такташ исә анага дан җырлый:

*Ана—бөек исем.*
*Нәрсә җитә ана булуга?*
*Хатын-кызның бөтен матурлыгы,*
*Бөтен күрке ана булуда.*

Еллар үтү белән бу бәхәстә Һ.Такташның хаклырак булуы ачыкланды.

"Иптәшкә" шигырендә Җәлилнең лирик герое сөйгән кызының "чәчәкле

керфегеннән" элек аның "КИМ" значогы таккан түшенә игътибар итә. (КИМ – Коммунистический интернационал молодежи). Әйтерсең, андый значок булмаса, кызны сөяргә дә ярамаган булыр иде...

"Зәйнәп" поэмасында (1932) төп каһарман Зәйнәпнең бөтен гаебе шунда—ул социалистик ярышта артта калган, эш нормасын бары тик 82 процентка үтәгән. Шуның аркасында өзелеп сөйгән егете дә аңардан баш тарта. Зәйнәп шуннан соң бар көчен туплап эшли һәм социалистик ярышта җиңеп чыга. Шуның белән ул үзенең мәхәббәтен дә кире яулап ала. Шулай итеп, поэмада кешелек дөньясының иң саф, иң матур хисләре тырыш хезмәтнең бер чарасы гына булып кала:

*Мин сагынам да сине,*
*сөям дә...*
*Ә сөюем бары көрәш өчен*
*Кирәк төсле...*
*Бергә җиңәргә!*

Шундый ук кимчелекләрне Җәлилнең "Сердәшкә", "Безнең сөю" һ.б. әсәрләрендә дә күреп була. Шул рәвешле социалистик реализм методы шагыйрьнең иҗат мөмкинлекләрен чикли, талантына бөтен тулылыгы белән ачылып җитәргә ирек бирми.

Әйтүләре мөмкин: ни өчен әле без юбилей вакытында Җәлилнең кимчелекләрендә казынабыз? Киресенчә, аны тагы да югарырак күтәрергә кирәк! Менә шул артык күтәрергә тырышудан әлегәчә иҗатындагы кимчелекләренә күз йомып килдек тә! Әйе, сугышка кадәр дә Җәлилнең халык кабул иткән, әдәбият тарихына алтын хәрефләр белән язылырлык әсәрләре аз булмаган. "Алтынчәч" либреттосын, "Хат ташучы" поэмасын, "Сагыну" җырын гына искә төшерү дә җитә. Алар турында шактый күп язылды инде. Шуна күрә мин бу әсәрләргә тукталып тормыйм.

## Тәнкыйть уты астында

Әлбәттә, зур талант иясе буларак, Җәлил чор таләпләре кысасына гына сыешып бетми. Матбугат өчен язылган әсәрләрендә шагыйрь мәхәббәт хисләрен турыдан-туры социалистик идеология һәм сыйнфый көрәш белән бәйләсә, үзе өчен язган, җаны таләп иткән шигырьләрендә ул моныңише заман кануннарын санга сукмый. Утызынчы елларда Җәлил күңеленнән ташып чыккан мәхәббәт-сөю шигырьләре өчен махсус дәфтәр тота. Ул "Лирика көндәлеге" дип атала. Бу дәфтәрдә аның саф хисләре, бай эчке дөньясы шактый тулы чагыла ("Зәйтүнәгә", "Без аерылдык", "Исемдә", "Соңгы кич" һ.б.) Соңыннан, шагыйрьнең вафатыннан соң, алар барысы да Җәлил җыентыкларына кертелде. Шагыйрьнең үзендә аларны язарга куәтле эчке ихтыяҗ булган, күрәсең. Шуңа күрә укучы да аларны яратып кабул итте.

Матбугатта чыккан әсәрләре дә идеология кысаларына сыешып бетми. Иң яхшы әсәрләрендә шагыйрь гомум кешелек идеалларына таяна, партиялелек таләпләренә җавап биреп бетерми. Нәкъ шуның өчен ул заманның "курчак идеологлары" тарафыннан берничә мәртәбә кискен тәнкыйть утына дучар була.

"Чаян" журналында (1923 ел, 5-6 саннар) унҗиде яшьлек Муса үзенең "Яна тарихи Әнбия" исемле шактый зур күләмле поэмасын бастыра. Дөресрәге, бастыра башлый гына, чөнки алдагы саннарда поэманың дәвамы, игълан ителгән булса да, басылмый кала. Шагыйрь аны үзе редакциядән алып китә, хәтта кульязмасын да юк итә. Әлбәттә, бу очраклы түгел. Пәйгамбәрләр тарихы турында бераз шаяртыбрак, шул исемдәге дини әсәргә пародия рухында язылган поэма кискен тәнкыйть утына эләгә. Мусаны ислам динен пропагандалауда гаеплиләр. Яшь Муса моны бик авыр кичерә.

1925 елның 11 гыйнварында Татар дәүләт театры (Г. Камал исемендәге Академия театрының башлангычы) Казанда Муса Җәлилнең "Бибкәй кыз" исемле пьесасын куя. Премьера бик уңышлы үтә, соңыннан да бу әсәр театр сәхнәсендә аншлаг белән бара. Әмма берничә көннән, шул ук елның 15 гыйнварында, "Кызыл Татарстан" газетасында бу әсәргә үтергеч рецензия басыла. "Алтынчы урындык" дип имза куйган билгесез автор шагыйрьне идеологик тотнаксызлыкта, идеясезлектә гаепли, аның пьесасында сөюшү-үбешүдән башка бернинди җитди эчтәлек юк дип яза. Шуннан соң унтугыз яшьлек Муса нишли? Тота да матбугат аша үзенең "Бибкәй

кыз" һәм элегрәк язылган башка пьесаларыннан баш тарта, аларны бүтән беркемгә дә куярга рөхсәт бирми (Муса Җәлил. "Редакциягә хат" "Кызыл Татарстан", 1925 ел, 17 гыйнвар).

Әмма иң авыр, иң куркыныч тәнкыйть утын Җәлил 1937 елда кичерә. Усал телле һәм партия таләпләренә тулысынча таянып эш итүче тәнкыйтьче Фатыйх Мөсәгыйть "Кызыл Татарстан" газетасында басылган "Редакциягә хат. Татар опера студиясе турында" исемле мәкаләсендә (1937 ел, 21 август) Муса Җәлилнең опера студиясендәге эшчәнлеген һәм соңгы елларда язылган әсәрләрен кискен тәнкыйть итеп чыга. Тәнкыйтьче "Балыкчы кыз" һәм "Алтынчәч" әсәрләрен пыран-заран китерә, аларда "буржуаз караш калдыкларын" күрә, Җәлилне идеологик тотнаксызлыкта гаепли. Гадәттә моның ише тәнкыйтьтән соң ул чорда авторны партиядән һәм Язучылар берлегеннән чыгарганнар, ә бераздан "Черек күл"гә алып китеп, физик яктан да юк иткәннәр.

Әмма Җәлил дәшми калмый. Шул ук елның августында "Кызыл Татарстан" газетасы шагыйрьнең җавап хатын бастыра. Бу мәкаләдә Җәлил "саботажлык", "дошманнарга яраклашу" ише гаепләүләрне кискен рәвештә инкарь итә, тәнкыйтьнең нигезсез булуын күрсәтә. Чөнки "Балыкчы кыз" либреттосы ул вакытта әле язылып бетмәгән, "Алтынчәч"нең дә беренче кисәге генә әзер була. Димәк, тәнкыйтьче әсәрне тулаем укымыйча гына тәнкыйть иткән булып чыга.

Шуна да карамастан, бәлки Җәлилне дә, башка атаклы татар язучыларны кебек, кулга алган булырлар иде. Ул Мәскәүгә китеп кенә котыла.

## "Моабит дәфтәрләре" тарихыннан

Җәлил иҗатының иң югары ноктасы—аның үлемсез "Моабит дәфтәрләре". Алар күптән инде халкыбызның изге рухи хәзинәсенә әверелде.

Һәр елның 15 февралендә—Муса Җәлил туган көндә—җөмһүриятебезнең Милли музеенда "Моабит дәфтәрләре", корыч сейфтан чыгарылып, тамашачылар карамагына куела. Музейга килүчеләр нәни бала учыдай кечкенә генә бу куен дәфтәрләренә аеруча дулкынлану белән карый. Аларда — шагыйрьнең изге тойгылары, керсез күз яшьләре. Саргаеп-таушалып беткән кәгазь битләре аның йөрәк тибешен, кул җылысын әлегәчә саклыйлар сыман.

Әлеге дәфтәрләрнең исән-имин илгә кайтулары—үзе бер могҗиза. Миллионнарча совет кешеләре, әсирлеккә төшкәннән соң, суга баткан сыман, эзсез, хәбәрсез югалды. Ә Муса җырлары, куллардан-кулларга күчеп, утлар-сулар кичеп, илгә кайтты.

Беренче дәфтәрне Казанга 1946 елның март аенда Нигъмәт Терегулов алып кайта. Төрле кәгазь кисәкләреннән үзе тегеп ясаган һәм гарәп хәрефләре белән язылган бу дәфтәрнең соңгы битендә шагыйрь түбәндәге васыятен теркәп калдырган:

"Татарча язу танучы һәм бу дәфтәрне укучы дуска!

Моны татарның билгеле шагыйре Муса Җәлил язды. Аның тарихы болай: ул 1906 елда туган. Квартиры Казанда һәм Мәскәүдә. Илдә зур шагыйрьләрдән санала. 1942 елны сугышка китте һәм әсир төште. Әсирлектә күп газаплар чигеп, кырык үлемнән калып, ахырында Берлинга китерелде. Берлинда сәяси яшерен оешмада катнашуда, совет пропагандасын таратуда гаепләнеп, кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлки, аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра. Шуның өчен 115 нең 60 ын гына булса да күчереп калдырырга тырышты. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, шигырьләрне яхшылап, дикъкать белән акка күчер, сакла һәм сугыштан соң, Казанга хәбәр итеп, үлгән татар халык шагыйренең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул.

Муса Җәлил. 1943. Декабрь."

Васыятьтән соң Җәлил "сәяси гаепләнеп утыручы татар егетләре"нең исемлеген язган. Алар 12 кеше (шагыйрь үзе дә шул санга керә). "Болар татар легионын таркатуда, совет фикерен таратуда, күмәк качу оештыруда гаепләнәләр", - диелгән. Күз буяу өчен шагыйрь дәфтәрнең тышлыгына немец хәрефләре белән "Немецча-төрекчә-русча сүзлек" дип язган.

Бер елдан соң Бельгиядәге Брюссель шәһәрендә урнашкан Совет илчелеге Казанга Мусаның тагын бер дәфтәрен җибәрә. Аны илчелеккә Бельгиядә яшәүче Андре Тиммерманс тапшыра. Ул Җәлил белән Моабит төрмәсенең бер камерасында утырган, аның кушуы буенча дәфтәрне алып чыккан. Бу дәфтәр латин хәрефләре белән язылган, соры катыргы белән тышланган. Катыргыда мондый юллар бар:

"Бу төптә—33 шигырь.

Әсирлектә һәм тоткынлыкта—1942. IX—1943. XI арасында язганнарым—125 шигырь һәм поэма. Ләкин кая язйым? Үзем белән бергә үләләр.

М. Җәлил."

Ныклап тегелгән дәфтәр тулганнан соң, шагыйрь, күрәсең, тагын бераз кәгазь тапкан һәм бөкләп дәфтәргә өстәгән. Бу өстәмәдә тагы 17 шигырь язылган. Илгә Җәлилнең барысы 93 шигыре һәм ике парчасы кайта. (Егермеләп шигыре ике дәфтәрдә дә кабатлана.) Дисталәрчә шигырьләренең һәм бер поэмасының әлегәчә табылганы юк.

Шулай итеп, Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре" илгә кайта. Ләкин алар шактый гына вакыт басылмыйча ята бирә. Ул елларда китабын чыгару түгел, шагыйрьнең исемен дә әйтергә ярамый. Тоталитаризм чорының катгый кагыйдәләре буенча, әсирлеккә эләккән һәркем халык дошманы булып санала. Легионда булучыларны исә фашистлар белән тиңлиләр. Менә ни өчен Җәлил сүзләренә язылган җырлар, радио аша яки концертларда башкарылганда, сүзләрен кем язганы әйтелми, аларны "халыкныкы" дип кенә җибәрәләр. (Бер уйласаң, алар чыннан да халыкныкы – аның рухи байлыгы). Җәлил либреттосы буенча язылган "Алтынчәч" операсын башкарганда да либретто авторы күрсәтелми. Хәтта бу әсәргә Сталин премиясен биргәндә дә либретто авторы телгә алынмый. Җәлил әсәрләре мәктәп дәреслекләреннән һәм югары уку йортлары программасыннан сызып ташлана.

Соңгы елларда гына билгеле булганча, СССРның Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты "Муса Җәлилнең иленә хыянәт итүе турында" эш башлаган булган. Җәлилнең кайда һәм ничек һәлак булганы ул чорда әле билгесез. Шуңа күрә куркынычсызлык органы хезмәткәрләре Җәлилне ил буенча гына түгел, бөтен дөнья буйлап эзлиләр. Хатыны Әминә Җәлилне көн саен диярлек Лубянкага чыкыртып, иренең кайдалыгын сорыйлар, "хыянәтче шагыйрь"не таптыралар. Әминә ханым хәзер дә бу вакыйгалар турында елый-елый сөйли.

Сталин вафатыннан соң гына мондый эзәрлекләүләргә чик куела. 1953 елның 25 апрель көнен Җәлилнең икенче туган көне дип исәпләргә мөмкин. Бу көнне илебездә беренче мәртәбә Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре"ннән берничә шигыре Мәскәүдәге "Литературная газета" битләрендә басылып чыга. Басылып чыгу белән үк шигырьләр халык күңелен яулап ала. Ниһаять, бу шигырьләр татар телендә дә вакытлы матбугат битләрендә дөнья күрә. Шул ук елның ахырында "Моабит дәфтәрләре" Казанда аерым китап булып басыла. Җәлил шигырьләре матбугатта зур шау-шу куптара. Илебезнең үзәк газетасы "Правда"дан башлап иң кечкенә район газеталарына хәтле Җәлил батырлыгы турында мәкаләләр бастыра, шигырьләрен урнаштыра. Берничә ел эчендә "Моабит дәфтәрләре" илебезнең дисталәрчә милли телләренә һәм бик күп чит ил телләренә тәрҗемә ителә. Җәлилне "татар Фучигы" дип атыйлар, аның даны бөтен дөнья буйлап тарала.

"Дөнья һәм дөнья әдәбияты,—дип язды ул елларда атаклы әзәрбәйҗан шагыйре Сәмәд Вургун,—үз исемнәрен бетмәс дан белән үлемсезләштергән күп шагыйрьләрне белә. Ләкин үз исемнәрен үлемсез иҗаты белән дә, батырларча үлеме белән дә мәңгеләштергән шагыйрьләр әллә ни күп түгел. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең халык шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил".

Бу сүзләр әйтелгәннән соң ярты гасыр вакыт узса да, алар үз әһәмиятен югалтмады. Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре" әле бүген дә күп гасырлык татар әдәбиятының горурлыгы һәм даны булып санала. Шагыйрьнең гражданлык тойгысы, кешелек дәрте, поэтик көче әлегәчә барыбыз өчен дә үрнәк булып тора.

"Моабит дәфтәрләре"нең сәнгатьчә байлыгы һәм тәэсир итү көче шагыйрь характерының ныклыгы, фидакарьлеге һәм кеше буларак мөлаемлыгы белән аерылгысыз бәйләнгән. Укучы алдында уйлана, моңлана, шатлана, кайгыра белә торган, гаҗәеп кешелекле зат пәйда була. Шигърият аның өчен көрәш чарасы, рухи корал булып хезмәт итә.

## Берлиндагы мемориаль такта тарихы

Җәлилчеләр истәлегенә мемориаль такта (яки нинди дә булса берәр һәйкәл) кую турындагы мәсьәлә моннан күп еллар элек кузгатылган иде. Ул чакта җәлилчеләрнең Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелүе хакында беренче документлар табылган гына иде әле. Әлеге эш алга да киткән булыр иде. Әмма бөтен хикмәт әлеге төрмәнең Көнбатыш Берлинда булуына бәйле булып чыкты. Шуңа күрә дә ГДРдагы дусларыбыз, ничаклы ярдәм итәргә тырышсалар да, юлда яткан "авыр ташны" кузгата алмадылар.

Ә инде безнең Көнбатыш Берлин сенатына юллаган күпсанлы хат-сорау, мөрәҗәгатьләребез җавапсыз калды. Шөкер дип әйтик, шулай да туксанынчы еллар башында, ике Германия бергә кушылгач, ниһаять, теге "авыр таш" кузгалды. Берлин сенатының җаваплы бер вәкиле, телдән генә булса да, мемориаль такта кую белән килеште: "Үзегез ясагыз да, үзегез Берлинга алып килегез" — диде. Шуңардан соң Казан предприятиеләренең берсендә төсле металлдан җәлилчеләр исеме латин хәрефләре белән татар телендә язылган истәлек тактасы коелды. Сүз уңаеннан әйтик, бу эш турыдан-туры Илбашы М. Ш. Шәймиев катнашы белән башкарылды.

1995 елның маенда, Җиңүнең 50 еллыгында, җөмһүриятебездән бер төркем ветераннар Алман иленә бәйрәмгә бардылар. Әлеге истәлек тактасын үзләре белән Берлинга алып килделәр. 7 майда тантаналы рәвештә аны Плетцензее төрмәсенең Мемориаль комплексына тапшырдылар. Тиешле кәгазьләргә тиешле имзалар куелды.

Еллар уза торды, ләкин такта гына куелмады. Янә биш елдан соң, Җиңүнең 55 еллыгында тагы бер Татарстан делегациясе Берлинга килде. Анда мин фәкыйрегез дә бар идем. 9 майда Плетцензее төрмәсенә барып, җәлилчеләрне җәзалап дөньядан озаткан урынга чәчәкләр куйдык. Истәлек тактасының әле һаман да куелмавы өчен борчылдык. Әмма аның исән-аман килеш янкорма йортында саклануын белдек.

Мемориаль комплекс житәкчеләре белән очрашкач, шул нәрсә ачыкланды: Берлинның яна түрәләре Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен җәзалап үтергән баракны истәлек урыны—ягъни аерым игътибарда торучы зона итеп калдыру турында карар чыгарганнар. Әлеге корылма сугыш елларында ничек булса, хәзер дә шулай үзгәрешсез калырга тиеш икән. Шуңа күрә ана нинди дә булса үзгәреш кертү, димәк, мемориаль такта кую да катгый тыелган. Безгә мемориаль тактаны Фашизмга каршылык күрсәтү музеена тапшырырга киңәш иттеләр.

Безнең белән бергә әлеге очрашуда Мәскәүнең халыкара мөнәсәбәтләр институты профессоры Әбделхан Әхтәмҗан да катнашты. Ул шушы музей директоры Иоһаннес Тухель белән мәсьәләне уңай хәл итү юлын җайлады. Әхтәмҗан әфәнденең һәр сүзе, һәр җөмләсе төпле, саллы икәнен тоеп, шуларның рәсми документлар белән расланганын күреп, Тухель болай диде: "Сез аларның чынлап та фашизмга каршы көрәшкәннәрен ничек исбат итә аласыз?"

Чыннан да, монарчы Берлин штандесамптында (бездәге никах йортына тиң оешмада) сакланып калган документларда фәкать совет гражданнарын җәзалап үтерү хакында гына язылган иде. Аларны нәрсә өчен җәзалап үтерүгәннәр—бу хакта ләм-мим. Тухельнең әйтүенә караганда, ул вакытта караклык өчен дә, алман кызы белән "дуслашкан" өчен дә, башка төрле вак-төяк җинаять өчен дә җәзалап үтерү алымын кулланганнар. Мәгълүм булганча, җәлилчеләрне фашизм рейхының Дрезден каласындагы Өченче империя суды хөкем итә. Ләкин сугыш ахырында әлеге суд бинасы, Америка авиациясе бомбага тоту сәбәпле, бөтенләй тар-мар ителә. Йорт үзе дә, андагы барча документлар да янып бетә.

Әнә шул очрашуда Әхтәмҗан әфәнде Тухельдән кирәк документларны эзләп табуда үзенең дә катнашуын үтенде. Музей хезмәткәрләре, Германия белән генә чикләнеп калмыйча, күрше илләрнең архивларына да мөрәҗәгать иттеләр. Көтмәгәндә могҗиза: Прага архивында җәлилчеләрне җәзалап үтерү турында яңа документ табылды. Анда акка кара белән болай дип язылган: җәлилчеләрне "астыртын эш йөрткәннәре" һәм "немец рейхының хәрби куәтен җимергәннәре өчен" хөкем иткәннәр. Шушы документ беренче дә шикләнүгә урын калдырмады. Фашизмга каршылык күрсәтү музее дирекциясе шушы бинада мемориаль такта

ачу хакында, ә җәлилчеләрне җәзалап үтергән урында аларның каһарманлыгын тасвирлаган стенд кую турында карар чыгарды.

Мемориаль такта музейның конференц-залында бөтен кеше күреп тора алырлык урынга куелды. Такта матәм төсендәге кара тасма белән уралган. Шунда ук җәлилчеләрнең исемлеге алман телендә язып куелган. Янәшәдә явыз җәза кылынган Плетцензее төрмәсенең фоторәсеме дә урын алган... Музей хезмәткәрләре әлеге истәлек тактасының изге нәрсәгә әверелүе турында сөйлиләр. Күпләр аның нигә һәм кемнәргә багышлап куелуы белән кызыксыналар икән. Әнә шул чагында аларга җәлилчеләр хакындагы электрон мәгълүматлар белән танышырга тәкъдим итәләр. Бу мәгълүматлар исә Казаннан җибәрелгән, бер өлешен музей хезмәткәрләре үзләре эзләп тапкан документлардан тупланган. Шунысын да әйтү зарурдыр: мондый мәгълүматлар базасы хәзергәчә Татарстанда да юк әле.

## Җәлил язмышы белән аваздаш немец шагыйре

Бәлкем кем дә булса: "Сез бу юлы Берлинда яна мәгълүматлар таптыгызмы?"— дип сорар. Мин, әлбәттә, мондый сорауның бик табигый икәнлеген аңлыйм. Ләкин, Җәлилчеләр батырлыгы никадәрле зур булуына карамастан, мондый каһарманлыкның сирәк түгеллеген әйтергә кирәк. Чехлар Җәлилне "татар Фучигы" дип әйтсәләр, немецлар исә аны "татар Һаусхоферы" дип саныйлар.

Һаусһофер кем соң? Алар—икәү. Аталы-уллы.Өлкәне—Карл Һаусһофер 1869 елда Мюнхенда туган. Илче буларак Көньяк-Көнбатыш Азия илләрендә яшертен эшләр алып барган. Бригада генералы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Мюнхен университетында профессор булып эшләгән. Рейх тарихына ул геополитика (дөньякүләм сәясәт) институтын оештыручы буларак кереп калган. Имештер дә, арий расасы чәчәк атсын өчен "Яшәеш галәме" ("Жизненное пространство") кирәк дигән, ягъни яна җирләр басып алуны нигезләүче теория-тәгълимат тудырган.

Фашистик Германиянең "Барбаросса" планы, ягъни Советлар иленә сугыш ачу турындагы фәлсәфәсе, нәкъ менә шушы тәгълиматка нигезләнә дә инде. Ә шушы кабахәт фашистның улы Альбрехт Һаусһофер бөтенләй башка караштагы кеше булып чыга. Ул Мюнхенда 1903 елда туа. Әүвәле үзенең туган шәһәрләрендәге, аннары Берлиндагы университетларда география фәненнән укыта. Иҗат белән шөгыльләнә: шигырь, драма әсәрләре, эсселар яза. Ин мөһиме—нацизмны сөйми. Лекцияләрдә ирек-азатлык хакында фашизмны фаш итеп ялкынланып сөйләгәне өчен аны эшеннән куалар һәм 1941 елда кулга алалар. Хәер, беренче кулга алынуы озакка сузылмый. Күрәсең, әтисенең югары даирәдәге бәйләнеш-элемтәләре ярдәм иткәндер. Чыннан да, атасының тугры шәкертләреннән берсе Рудольф Гесс бик зур көчкә ия була.Ул аны төрмәдән коткарырга булышкан булса кирәк.

Әмма Альбрехт Һаусһофер төрмәдә "тиешле сабак" алмый, нацистларны фашлаудан туктамый. Шуна күрә аны 1944 елда янә кулга алып, Моабит төрмәсенә утырталар. Бу төрмә безнең халыкка яхшы мәгълүм—Җәлилнең атаклы шигырьләре шушы зиндан исеме белән билгеле. Совет гаскәрләре Берлинга керергә берничә көн калганда, төгәле—1945 елның 23 апрелендә - Альбрехтны төрмәдән алып китеп, кайдадыр атып үтерәләр. Риваятьләргә караганда, аның кулларында Моабитта язылган шигырьләр дәфтәре була.

Соңыннан әлеге шигырьләр "Моабит сонетлары" исеме белән басылып чыга. Алар антифашист шагыйрьләрнең җыентыкларында дөнья күрә, антологияләргә керә. 2001 елда Берлинда Альбрехт Һаусһоферга бюст куела.

Әтисе улыннан соң әллә ни озак яшәми, 1946 елда үзенә кул сала. Бәлкем, элекке инануларының дөрес түгеллеген, улының хаклы икәнен аңлагандыр? Электрон мәгълүматлар базасында аталы-уллы шушы ике кешенең фаҗигасе шактый тулы һәм тирән яктыртылган.

Без А. Һаусһоферның бер китабын үзебез белән алып кайттык. Профессор Әхтәмҗанның хәләл җефете Хәдичә ханым берничә шигырен русчага тәрҗемә итеп бирде. Шушы шигырьләр аша без бу шагыйрьнең Җәлил белән аваздаш икәнлеген тойдык. Югыйсә, алар бер үк төрмәдә утырсалар да бер-берләрен белмәгәннәр. Әмма немец шагыйре дә Муса Җәлил кичергәнне кичергән.

*Мөмкинме соң йоклау таш төрмәдә?*
*Тәнне-җанны телә салкынлык.*
*Язмышыңны яклап чыгар өчен*
*Сүз әйтергә хәтта хакың юк.*

Әйе, нәкъ Җәлил кебек, Альбрехт Һаусһофер да азат Алман иле, бөек иҗат әһелләре Гете һәм Бетховеннар ватаны хакында уйланган, намус газабы кичергән. Юк, фашистлар гаеп иткәнчә түгел. Ул үз авазын вакытында меннәрчә-меннәрчә кешеләргә ишеттерә алмаганы өчен әрнегән. Ләкин бу изге көрәштә берүзе түгеллеген тою аның күнелен бераз юаткан.

*Миннән битәр бик күпләргә язган*
*Бу коллыкта газап кичәргә.*
*Берләшкәндә генә төн карасын,*
*Явызлыкны мөмкин җиңәргә...*

Шушы юлларда да (татарчага Г. Садә тәрҗемә итте) Җәлилгә хас ялкынлы хисләр чагыла. Алман илендәге дусларыбыз да әлеге ике шагыйрьнең бер тамырдан булуын әйттеләр. Иң мөһиме шунда: алар фашизмга каршы чыкканнар һәм шушы рәхимсез көрәштә үлемсезлек дигән биеклеккә ирешкәннәр.

## Плетцензее төрмәсенең мәкерле серләре

Берлиндагы Плетцензее районы биниһая зур сәнәгать төбәге булып санала. Монда завод-фабрикаларның тәбәнәк кенә ыслы-корымлы корпуслары тезелеп киткән. Һәртөрле соры-соргылт складлар, пакгаузлар... Тимер юллары, шулар тирәсендә тау-тау өелгән төзелеш материаллары...

Биек кирпеч койма белән әйләндереп алынган Плетцензее төрмәсе шәһәрнең шушы төбәгенә һич ямь өстәми. Төрмә хәзер дә эшли. Анда балигъ булмаган җинаятьче үсмерләр тотыла. Ләкин төрмә территориясенең бер өлеше һәм андагы җәзалау барагы мемориаль зона итеп калдырылган. Әлеге зонага керү юлында таш дивар корып куйганнар. Аңа немец телендә: "Гитлер диктатурасы корбаннарына. 1933—1945 еллар" дигән сүзләр язылган. Әлеге стена сугыш чорыннан бирле берниндн үзгәреш кичермәгән җәзалау барагына килеп тоташа. Биредә дар агачында яки гильотинада төрле милләттәге өч мең чамасы кеше җәзалап үтерелгән.

Бу җәһәттән Плетцензее төрмәсеннән тыш Берлинда күпләп җәзалап үтерү алымы кулланылган тагын өч төрмә булуын әйтергә кирәк. 1945 елның язына үлем җәзасына хөкем ителүчеләр саны 16560 кешегә җиткән. Ләкин бу гитлерчылар тарафыннан корбан ителгәннәрнең бик аз өлеше генә. Миллионнарча кешеләр берниндн хөкем карары чыгармыйча үтерелә. Йөзләрчә мең тоткыннар концлагерьларда, хәрби әсирләр өчен корылган лагерьларда ачлыктан һәм тиф авыруыннан һәлак була, газ камераларында яндырып үтерелә.

Безне озатып йөрүче гид, Мемориаль комплекс хезмәткәре, әлеге төрмәнең җанны өшеткеч, мәкерле серләре турында сөйләде.

Тоткыннарны гадәттә көннең беренче яртысында җәзалап үтергәннәр. (Исегезгә төшерәм: җәлилчеләрне 1944 елның 25 августында 12 сәгать 06 минуттан 12 сәгать 36 минутка кадәр вакыт эчендә юк иткәннәр). Немец юстициясе кагыйдәләре нигезендә җәзалау алдыннан прокурор тоткынга хөкем карарын укыган. Бу җәһәттән җәлилчеләр үзләренә нәрсә янаганын 25 августта иртәнге 8 сәгатьтә Тегельдән Плетцензее төрмәсенә алып килгәч кенә беләләр. Аларны Үлем йорты дип аталган аерым баракка урнаштыралар. Аннары кулларын артка бәйләп, хөкем карарын укыйлар. Шунардан соң мулла белән очраштыралар.

Тоткыннарны билгеләнгән сәгатьтә Үлем йортыннан җәзалап үтерү барагына алып киләләр. Гильотина үзе күренмәслек итеп калын кара пәрдә белән каплап куелган була. Сакчылар тоткыннарны берәмләп эләктереп алып гильотинага ыргыталар. Бик үткенләп кайралган 75 килограммлы балта шунда ук башны чабып өзә. Шул мизгелдә корбанның үле гәүдәсен читкә алып ташлыйлар, гильотинага чираттагы тоткынны китереп кертәләр.

Гидның сөйләвенә караганда, монда өч палач эшләгән. Җәлладларга елына 3 әр мең марка акча түләгәннәр. Өстәвенә киселгән һәр баш өчен өстәмә түләү бирелгән. Җәлладның булышчылары да өлешсез калмаган. Ә сугыш ахырында, хезмәтләренең

"авырлыгын" искә алып, өстәмә паек: җәзалап үтерелгән һәр кеше өчен 8 сигарет биргәннәр.

Бигрәк тә Реттгер дигән палач явызлыгы белән аерылып торган. Чордашлары сөйләвенә караганда, ул имансыз, канэчкеч җинаятьче—патологик яктан авыру адәм актыгы булган. Кешеләр гомерен ул җәзалап үтергәне өчен алган акча бәясе белән генә санаган, монардан искиткеч тәм тапкан. Йөзендә һәрчак мыскыллы, ыржаюлы елмаю булган, авызыннан беркайчан да сигарет төшермәгән. Атлап йөреше дә башкаларныкына охшамаган: караклардай кача-посып, киез чүәкләре белән цемент идәннән тавыш-тынсыз атлап йөргән. Тоткын өстенә селәүсендәй сикереп, аны гильотинага ыргыткан һәм шунда ук кнопкага баскан.

Әмма җәлилчеләрне фашистик Германиянең баш палачы Эрнест Раендель үзе җәзалап үтергәндер, мөгаен. Кыяфәте белән ул могтәбәр булып тоелган, үзе һәрчак ыспай кара сюртук киеп йөргән, ике кулының да бармакларына алтын йөзекләр кигән. Э. Раендель гадәттә җәзалау көне алдыннан үлемгә хөкем ителгәннәрнең камерасына кереп, аларның авызын ачтырып караган: алтын тешләре бармы-юкмы икәнлеген тикшергән. Соңыннан, алар дөнья белән хушлашкач, шул тешләрне каерып алган.

Әгәр тоткын авызын ачмаса, хәтта аның йөзенә төкерсә, Раендель ерткыч җанвардай ырлаган:

—Аз гына көт... Башыңны чабып өзгәч, мин әле синең күзеңә карармын...

Чыннан да, ул үзенең шушы кабахәт антын үтәгән. Тоткын башы идәнгә тәгәрәп төшүгә, палач аны кулына алып йөзенә караган. Җәлладлар фикеренчә, адәм башы өзелүгә дә карамастан, каны агып бетмәгәнлектән, күпмедер мизгел үз аңында кала икән. Палач шушы әкренләп тоныклана бара торган күзләргә карап, үзенә ниндидер гайре табигый тәм тапкан. Моны аңлау да, аңлату да мөмкин түгел: бу фәкать ерткыч җанварларга гына хас.

Плетцензее төрмәсендәге мемориаль комплекска ел саен 50-60 меңләп турист килә. Җәлилчеләргә багышланган стендны ачу тантанасы вакытында гына да берничә автобус килеп туктады. Килүчеләрнең күпчелеге мәктәп укучылары иде. Бу балалар үз илләренең үткәне белән кызыксыналар, ә иң мөһиме—алар мондый фаҗига беркайчан да кабатланмасын дип хыялланалар.

## Алар мәңге хәтердә

2002 ел, 25 октябрь.

Без, Татарстан делегациясе вәкилләре, җәлилчеләр җәзалап үтерелгән урынга чәчәкләр куйдык. Безнең белән бергә Берлин сенаты һәм "Россия халыкларының Берлиндагы дуслары" җәмгыяте җаваплы хезмәткәрләре шундый ук изге гамәлне кылдылар.

Бу көн безгә тагын шунысы белән истәлекле булды: әлеге йортта җәлилчеләргә багышланган стенд ачылды. Шушы мемориалда куелган 14 нче стенд ул. Монда Җәлил белән Алиш рәсемнәрен, "Моабит дәфтәрләре"нең кайбер күчермәләрен күрергә була. Шунда ук алман халкы Җәлил шигырьләрен үз телләрендә укый ала.

Әлеге тантанада Татарстан делегациясе житәкчесе, ТР хөкүмәтенең вице-премьеры Зилә Вәлиева болай диде: "Минем шуны әйтәсем килә, фашизм төрмәсендә җәзалап үтерелгән шагыйрь немец халкына рәнҗү һәм нәфрәт белдермәгән. Киресенчә, ул бөек Һейне, Гете каршында баш игән, илаһи Бетховенның искитмәле музыкасын яраткан. Үлеменә берничә көн калганда ул менә мондый шигырь язган:

*Синме соң бу—бөек Маркс иле*
*Һәм давыллы Шиллер ватаны?*
*Тоткын итеп сиңа китерде дә*
*"Кол" дип мине немец атады.*
*Әйт син миңа: утлы , "Рот фронт"лы*
*Көннәреңне кая югалттың?*
*Нигә мине—Клара әбисенең*
*Сөйгән улын—кыйнап елаттың?*

Муса Җәлил шигырьләре аның соңгы сулышына хәтле үз иленә, демократия һәм гуманизм идеалларына тугры калуы турында сөйли. Тоталитаризмга һәм җаһиллеккә каршы көрәштә ул немец халкының иң яхшы көчләренә таянган, Җәлил-Кормаш төркемендә немец патриотларыннан да берәү булган. Ни кызганыч, хәзергәчә без аның исемен ачыклый алмадык.

Без шулай ук Берлиндагы Фашизмга каршылык күрсәтү музеендагы дусларыбызга тирәнтен рәхмәтлебез. Алар шулай ук фашизмның кара афәтенә каршы көрәштә һәлак булган безнең ил гражданнарын хәтерләрендә саклыйлар. Без әлеге дусларыбыз аркасында Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең батырлыгын тасвирлаган бик мөһим бер документны эзләп табуга ирешкәнебез өчен зур рәхмәтебезне юллыйбыз. Алда әйтелгәнчә, бу документ—совет патриотларының "немец армиясен таркатуда" һәм "зыян китерүдә" гаепләү турындагы акттан бер өзек. Кыскасы, якташларыбыз үз Ватаннарына тугры булып калганнар.

Минемчә, безнең әлеге эшлекле бәйләнешләребез киләчәктә дә ныгыр һәм үсәр."

## Бөркет сыман

Меңьеллык Казанның Ак кирмәне каршында бакырдан коелган Җәлил һәйкәле тора. Шагыйрь, югарыга очар өчен канатларын җәйләп куйган бөркет сыман, киң адым ясап, алга омтылган. Аның богаулы куллары артка бәйләнгән, һәм шагыйрь, коллык чылбырларын өзә-өзә, кыя башында басып тора. Татар халкының намусына һәм батырлык символына әверелгән Муса үзенең мәңгелек пьедесталына күтәрелгән...

Һәйкәл янына шигырь һәм ирек сөючеләр, туристлар меңнәрләп килә, яшь егетләр һәм кызлар, никахлашу алдыннан һәйкәл янына чәчәкләр куя. Сугышта катнашкан карт пенсионерлар, хезмәт ветераннары һәйкәл алдында баш иеп, озак кына уйланып тора. Аларның күзләрендә батыр шагыйрьне олылап искә алу да, аның изге рухына якынаю хисен дә чамаларга була.

Җәлилнең тормыш һәм иҗат батырлыгы матур легенда булып бөтен дөньяга таралды. Аның шигырьләрендә чор-заман сулышы, илнең, халыкның йөрәк тибеше сизелә. Шагыйрь фашизм тоткынлыгындагы патриотик эшчәнлеге белән генә түгел, ә бөтен тормыш юлы һәм ялкынлы иҗаты белән көрәшче-әдип, патриот-шагыйрь дигән исемнәрне тулысынча аклады. Бу—аның әдәбиятыбызда һәм халык күңелендәге урынын билгеләүче төп сыйфат. Хәзерге әдәбият белемендә "Җәлил традицияләре" дигән төшенчә барлыкка килде. Шагыйрьнең сугышчан, олы гражданлык традицияләрен хәзерге заманда яңа буын шагыйрьләр—әйтик Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Ренат Харис, Разил Вәлиев һәм башкалар уңышлы рәвештә дәвам итәләр. Шуны истә тотып, алар Җәлил исемендәге премия белән дә бүләкләнделәр.

*2005*

## Илдар Юзеев

# УНӨЧЕНЧЕ

*Баллада*

*Егетләр унике булганнар,*
*Аяусыз үлемгә барганда.*
*"Юк, унөч, унөч!" дип кабатлый*
*Күңелем һаман да.*

*Унөченче...*
*Ул булган егетләр янында*
*Иң соңгы йөзенче адымда,*
*Башларын югары күтәрткән*
*Һәлакәт алдында.*

*Дөньяның килерен хәл итеп*
*Булмыйдыр тәвәккәл ир-атсыз,*
*Һәрберсе белән дә үлемгә*
*Кергән ул чиратсыз.*
*Бер булып киткәннәр егетләр,*
*Сайларга бер генә юл калган.*
*Унөченче...*
*Ул калган*
*Һәм китеп... хәбәрсез югалган.*

*Унөченче...*
*Ничә ай, ничә ел эзлим мин,*
*Табалмыйм, җанда — бер үкенеч,*
*Әйтәләр: "Алар бит унике!"*
*"Юк, унөч!"*
*"Юк, унөч!"*

*Унөченче...*
*Җалладның балтасы астыннан*
*Бердәнбер сау калган каһарман...*
*Мин беләм, ул — исән, табармын,*
*Ә, бәлки, табалмам...*

*Унөченче...*
*Иң көчле дошманны җиңдем дип,*
*Җай саен кычкырмый торгандыр,*
*Ул тыйнак, дуслары сымандыр, —*
*Табылмый шуңадыр.*
*Баһадир икәнен белмичә,*
*Тын гына, шау-шулар эчендә*
*Янадыр, көядер, сөядер*
*Дуслары өчен дә.*

*Унөченче...*
*Ул калган*
*Һәм китеп... хәбәрсез югалган.*

*Иң соңгы йөзенче адымда*
*Мусалар җырлаган моңлы җыр...*
*Моңлы җыр — билгесез каһарман.*
*Мин беләм: син исән, табармын.*
*Ә, бәлки табалмам...*

Шәүкәт
Галиев

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ КЫЗЫ ЧУЛПАНГА КИЛЕП ҖИТМӘГӘН ХАТЫ

*"...җиңгәч, мин өйгә кайтырмын.*
*Синең туган көнеңне бәйрәм итәрбез.*
*Мин сиңа бик яхшы бүләк бирергә*
*җыенган идем, кайткач бирермен".*

Җәлилнең фронтка барганда
кызы Чулпанга язган хатыннан.
*28 февраль, 1942 ел*

*Кичер, балам, кичер әткәңне,*
*Мин сүземдә тора алмадым,*
*Туган көндә була алмадым...*
*Тик бурычлы булып калмадым —*
*Җиңү булды сиңа бүләгем,*
*Мин тыныч көн сиңа теләдем —*
*Кадерен бел, балам, кадерен!..*

*Көткәнсеңдер нәни чагында,*
*Үскәч инде үзең аңладың,*
*Вакытында кайта алмадым,*
*Тик барыбер читтә калмадым —*
*Азат илем сиңа бүләгем,*
*Мин бит сиңа бәхет теләдем —*
*Кадерен бел, балам, кадерен!..*

*Сагнуларым калды мәңгегә —*
*Җырга барсын сала алмадым...*
*Белеп киттем, якты дөньяда*
*Мәхәббәтем исән калганын —*
*Газиз әнкәң сиңа бүләгем,*
*Мин бит сиңа шатлык теләдем —*
*Кадерен бел, балам, кадерен!..*

## Әхсән Баян

### МУСА ҖӘЛИЛГӘ

*Синең гомер легендага тартым,*
*Тик бәхәсле булды кай ара.*
*Безне әйткән кая, дөнья хәтта*
*Каһарманнар белән шаяра.*

*Шаярдылар үчле һәм үчсезләр,*
*Күселәр һәм күсе төслеләр.*
*Һәйкәл ташын кимерделәр кайчак*
*Тешләләрдән күрмәк тешсезләр.*

*Таш катысы торды мантыйк белән:*
*"Шулкадәр үк дошман исәрме —*
*Үзенә дус, ялчы, кол булганның*
*Башларын ул әллә кисәрме?"*

*Балта сыман баш өстендә торган*
*Катылыкны без дә татыдык.*
*Әмма күптән гильотина белән*
*Хәл ителгән иде батырлык.*

*Шуннан китте җырлы сокланулар,*
*Сырышулар данлы форсатка:*
*"Булыр идек без дә аның кебек,*
*Андый хәлдә калган очракта!"*

*Күкрәк сукмыйк — бәлки, булыр идек...*
*Ак кар яугач... кызыл кар яугач...*
*Актык мәрмәр сүзне әйтербез, тик*
*Башыбызны кисеп карагач.*

## Роберт Миңнуллин

### ТАТАР БАШЫ БАШКА КИСЕЛМӘСЕН!

*Ә бит нинди шәп егетләр булган!*
*Куркытмаган хәтта үлем дә.*
*Батыр булып, татар булып калган*
*Ул егетләр дошман өнендә!*

*Алар әле һаман исән кебек,*
*Алар әле безнең йөрәктә...*
*Безгә бүген Муса Җәлил кирәк,*
*Җәлилчеләр кирәк бигрәк тә!*

*Без дә бүген җәлилчеләр кебек,*
*Без дә бүген Җәлил хәлендә.*
*Һәр татарның җаны тулы яра,*
*Булмаса да яра тәнендә.*

*Татарга да кояш чыгып ала,*
*Тарих бит ул аклы-каралы.*
*Ничә тапкыр чыгаралар инде*
*Халкыбызга үлем карары.*

*Шундый ук хәл хөкем сөрә бүген —*
*Барасы юк ерак-еракка.*
*Стенага китереп терәделәр,*
*Тик басасы калды курокка...*

*Гильотина юкмы безнең өстә? —*
*Баш очына ешрак карагыз!..*
*Ерагаймый, якыная гына*
*Җәлилчеләр белән арабыз.*

*Җәлилчеләр булыйк, әй егетләр!*
*Җәлил булыйк, шагыйрь иптәшләр!*
*Куркып тормыйк башны кисәрләр дип,*
*Барыбызныкын да кисмәсләр...*

*Баш имәгән татар! Нишлисең бит,*
*Баш имәгән башны кисәләр.*
*Нишләр идек бүген, дошманнарга*
*Башын игән татар, дисәләр?!.*

*Ачы да соң татар язмышлары!*
*Бер уйласаң, исең китәрлек...*
*Татар башы башка киселмәсен!*
*Киселгәннәре дә җитәрлек...*

Фәрит
Габдерәхим

## НИНДИ ҖАН БУ?

*Тарих сөйли... Миһербанлы халкым,*
*Йәсин чыгып туар таңына,*
*Киң дөньяга сыя алмаганнар*
*Сөңге батырганнар җанына.*

*Нинди җан бу синдә — бик түбәнме,*
*Әллә инде бик-бик югары?*
*Җаның ярып кергән шул сөңгене*
*Кайнар каның белән сугарып,*

*Үстергәнсең Җәлилләреңне син:*
*Гыйбрәт булсын бөтен галәмгә.*
*Бу — бердәнбер могҗизадыр, бәлки:*
*Алмагачка сөңге әйләнгән!*

Юмарт халкым! Күзләр җиту белән,
Инсаннарның кече-олысын
Җыясың да шушы алмагачның
Җимешләре белән сыйлыйсың.

Киң дөньяга сыймаганнарның да
Оныклары синең табында.
Нигә өясеңдер алмаларның
Иң сутлысын алар алдына.

Син чыгасың көрәш мәйданына,
Сөңге түгел, тотып сөлгеңне.
Нинди җан бу: әйләндергәнсең бит
Алмагачка җәллад-сөңгене!

*Уфа*

Ирек
Сабиров

## ҖӘЛИЛ СУРӘТЕ

Сабый чакның кайбер мизгелләре
Еллар буе китми башымнан.
Сүз чыкканда, безгә кырын карап,
Пышылдады зурлар: "Сатылган..."

Әллә нинди хаста туган иде
Яшь җанымда шушы сүзләрдән:
"Исән икән... "Теге як"та яши...
Яшерендә... Исемен үзгәрткән..."

Әмма тиздән тарих гаделлеге
Бик гыйбрәтле сабак өйрәтте, —
Хәтеремдә: указ. Журнал бите.
Алтын йолдыз. Җәлил сурәте.

Еллар узды. Тәкъдиркәем мине
Анда бәреп, монда ыргытты.
Бу дөньяның явыз утларыннан,
Ачыш ясап, таптым чынлыкны.

Без бит иң-иң батыр егетләрне
Сау башлары белән түгел лә,
Гүр ташлары белән саныйбыз.
Туксан тугыз канлы газап аша
Үтсәң генә сине таныйбыз.

Күпме булса дәртең, шулкадәрле
Хәтәр оча дошман уклары.
Пакь йөрәкле адәм баласының
Авыр була тормыш сукмагы.

Без үзебез аңламаган эшне
"Ап-ак җирдә шакшы тап" дибез,
Әүвәл бәреп егып таптыйбыз да
Соңра күккә чөеп мактыйбыз.

Кардәшләрем! Ә без бүген менә
Аңлыйбызмы тарих гыйбрәтен?
Кичер, Җәлил! Чыкмый хәтеремнән
Иске журнал битләрендә күргән
"Җырларым" һәм якты сурәтең.

*Чиләбе өлкәсе,*
*Яман Елга шәһәре.*

## Нурия Измайлова

### ҖӘЛИЛЧЕЛӘРГӘ

*Андый җырлар калмас елап үлгәннәрдән,*
*Ышанам мин — сез елмаешып үлгәнсез —*
*Елау заты юк Җәлилнең җырларында.*
*Күз яшьләрен көн нурына яшергәнсез!..*

*Елмайгансыз... Тик яшергән яшьләрегез*
*Көн нурыннан*
*минем күзгә күчкән мәллә! —*
*Уйлыйм — елыйм, сөйлим — елыйм...*
*Мин бары тик*
*Сезне сагынып елар өчен үскән мәллә?*
*Кичерегез мин елакны.*
*Ах, бу кояш*
*Бигрәк моңлы ядкарь сездән —*
*исәннәргә...*

***АКШ, Принстон шәһәре.***

## Мөхәммәт Мирза

### БАТЫРЛАРЫН БАРЛАП ТОРА ХАЛКЫМ

*Батырларын барлап тора халкым,*
*Дәверләргә бүлеп, чорларга.*
*Дастаннарга кереп калган алар,*
*Әкиятләргә, бәет, җырларга.*

*Хәтерләргә мәңге кереп калган,*
*Йола алмас һичбер ак тап та;*
*Иблис язган ялган тарих битен*
*Хаклык җиле барыбер актарта.*

*Идегәйләр кайтты, мең елга бер*
*Урап кайткан комета сымак;*
*Исхакыйлар, җәлилчеләр кайтты,*
*Оныклардан фатиха сорап...*

# ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ

1968 елда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты әдәбият-сәнгать өлкәсендә яшь көчләрне үстерү, иҗатларын стиммуллаштыру һәм пропагандалау нияте белән Муса Җәлил исемендәге премия булдырган иде. Ул республика комсомолы премиясе саналды һәм аңа 1968-1990 елларда язучылардан 13 кеше лаек булды. 1991-2002 елларда премия бирү туктал͏ып торды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1997 елның 27 февралендә чыккан карары нигезендә М. Җәлил исемендәге бу премия яңадан гамәлгә керде, премия бирү тәртибенең яңа нигезләмәсе булдырылды. Ул хәзер Республика премиясе дип атала. Нигезләмәдә болай дип язылган: "М. Җәлил исемендәге Республика премиясе Татарстан Республикасы яшьләренең сәнгатьне, фәнне, мәгарифне, тәрбия бирүне үстерүгә шәхси өлеш керткән, яшьләр кәсәбәчелеге, яшьләр программаларын тормышка ашыру өлкәсендә югары казанышларга ирешкән сәләтле вәкилләренә бирелә." Премия ике елга бер мәртәбә бирелә, лаек булган лауреатлар исемлеге М. Җәлил туган көнне игълан ителә.

## Муса Җәлил исемендәге Республика премиясенә ия булган язучылар



**1968. Юзеев Илдар Гафур улы**—шагыйрь, "Миләүшә" дигән шигырьләр һәм балладалар китабы өчен.



**1970. Фәйзуллин Равил Габдрахман улы**—шагыйрь, "Мәрмәр" исемле шигырьләр китабы өчен.



**1972. Харисов Ренат Мәгъсүм улы** (Ренат Харис)—шагыйрь, "Кеше" ораториясенең тексты өчен.



**1974. Миңнуллин Туфан Габдулла улы**—драматург, "Нигез ташлары" һәм "Үзебез сайлаган язмыш" дигән пьесалары өчен.



**1976. Кашшафетдинов Миргази Солтан улы** (Гази Кашшаф)—язучы-галим (үлгәннән соң), каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең мирасын барлаудагы, аның тормышын һәм иҗатын өйрәнүдәге зур хезмәтләре өчен.



**1976. Мостафин Рафаэль Әхмәт улы**—язучы-галим, каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүдәге зур хезмәтләре өчен.



**1978. Яруллин Фәнис Гатаулла улы**—язучы, "Аерылмас дустым", "Сагыш" дигән җыентыклары өчен.



**1982. Вәлиев Разил Исмәгыйль улы**—әдип, шагыйрь, "Яшисе килә" дигән повесте һәм яшьләргә багышланган җырлар циклы өчен.



**1982. Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы**—шагыйрь, балалар өчен язылган "Акбай цирк карый", "Җиде абый тай җигә", "Айга очтык" дигән шигъри китаплары һәм телевидение аша әдәбиятны актив пропагандалаганы өчен.



**1984. Хәмидуллин Ризван Мирхәбибулла улы** (Ризван Хәмид)—драматург, "Китәм инде", "Синең урыныңа кайттым" дигән пьесалары өчен.



**1988. Маликов Дөлфәт Госман улы** (Зөлфәт)—шагыйрь, "Күзгә учаклар" дигән китабы һәм соңгы елларда "Казан утлары", "Ялкын" журналларында басылып чыккан шигырь бәйләмнәре өчен.



**1989. Түбән Камадагы "Җидегән чишмә" әдәби-музыкаль берләшмәсе (җитәкчесе—язучы Хисмәтуллин Рәхмәтулла Хисмәтулла улы—Рахмай Хисмәтуллин).**



**1990. Зәйдуллин Ркаил Рафаэль улы**—шагыйрь, "Күрәзә" исемле шигырьләр китабы өчен.



**2003. Вәлиев Мөдәррис Харис улы** (Салих Маннапов)—Татарстан Республикасының "Мәгариф" Милли нәшрияте директоры, шагыйрь, әдәби тәнкыйтьче, талантлы яшь авторларга эзлекле ярдәм күрсәткәне өчен.



**2003. Республика яшьләренең "Сәләт" иҗтимагый фонды (җитәкчесе—шагыйрь, техник фәннәр докторы Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы).**

## Татар әдәбияты турында
## Луи Арагон

*Парижда Франциянең прогрессив язучысы, бөтен дөньяга билгеле атаклы шагыйрь, тынычлык өчен актив көрәшче Луи Арагонның "Совет әдәбияты" ("Litteratules sovietidues") исемле яңа китабы басылып чыкты. Автор бу әсәрдә Советлар Союзының күп милләтле әдәбияты турында бик кызыклы фикерләр әйтә, татар әдәбиятына да (башлыча, Муса Җәлил турында) бер бүлек багышлый. Түбәндә без Луи Арагон китабыннан әнә шул бүлекне китерәбез.*

*Луи Арагон хезмәтендә татар әдәбияты турында кайбер фикерләр булуына аспирант Нил Юзиев игътибар итә һәм Мәскәүнең В. И. Ленин исемендәге китапханәсеннән китапның ул битләрен фотокәгазьгә төшереп алып кайта. Текстны французчадан редакция өчен Х. Курбатов тәрҗемә итте.*

**Редакция**

# МЕНӘ НӘРСӘ БУЛДЫ БЕРЛИН ШӘҺӘРЕНДӘ

1944 елның 10 январенда Берлиндагы Моабит төрмәсендә палач балтасы бер шагыйрьнең башын чабып өзде. Шунысы гаҗәп, безгә, атып үтерелгән Гарсия



Лорканың исемен ишетеп җаны тетрәгән, атылган Жак Декурның соңгы сүзләрен яки нацистлар тарафыннан асылган Юлиус Фучикның төрмәдә язган китабын тын да алмый укып чыккан французларга, ул совет шагыйренең хәтта исеме дә билгеле булмады. Бу — безнең өчен оят иде. Бу кеше үзенең һәрбер туганы — Казандагы һәм Новосибирскидагы, Одессадагы һәм Самаркандтагы, Владивостоктагы һәм Ленинградтагы, Тбилисидагы һәм Ригадагы туганнары өчен үлде. Ул шулай ук безнең өчен — французлар яки чехлар өчен дә үлде. Ул д,Этиен д'Орве яки Пери кебек үк үлде, ләкин без аның хәтта исемен дә, аның шагыйрь булуын да, аның башы Моабит төрмәсе ишек алдына җәелгән ташларга тәгәрәгәнен дә, аның каны палач бүкәнендә кипкәнен дә белми калдык. Ә палач шул вакыт үзенең балтасына карады, аны җентекләп сөртте, аннары үзенең балалары белән уйнарга китте. Яки ул үзенең кесәсеннән аларның фотосын сөйрәп чыгарды, — хәтерләгез... 1953 елда, Казанда, беләсезме, Казан: Россиянең Европа өлешендәге шәһәре... яки барыннан да бигрәк РСФСРдагы Татарстан Автономияле республикасының башкаласы, Казанка елгасы буена урнашкан, Казанканың Иделгә кушылган урыныннан ун километр, Мәскәүдән көнчыгышта тугыз йөз километр, Ленинградтан көньяк көнчыгышта бер мең алты йөз илле алты километр ераклыкта булган, 55°47' төньяк киңлеккә һәм 46°45' көнчыгыш озынлыкка урнашкан шәһәр... Унөченче гасырда Кыпчак империясенен, Алтын Урданың, башкаласы булган шәһәр. Ундүртенче гасыр азакларында Мәскәүнең бөек князе Василий Дмитриевич Самарадан Вяткага кадәр сузылган Казан ханлыгына һөҗүм итә, барын да җимерә. Ләкин татарлар үз шәһәрләрен аякка бастыралар. Шуннан соң руслар аңа каршы йөз ел буена гаскәр җибәреп торалар һәм, унбишенче гасырның ахырыннан башлап, Казаннан налог җыялар. Аннары руслар патша Иван Грозный белән тагын киләләр һәм уналтынчы йөзнең

уртасында шәһәрне камап алалар... Хәтерегездәме, "Борис Годунов"та Варлаам, кулына шешә тотып, ничек җырлый:

*Казан дигән ай шәһәрдә*
*Усал патша ашап-эчте, типтерде.*
*Рәсәй буйлап йөрмәсеннәр өчен,*
*Татарларны, һай, шәфкатьсез*
*Кырып салды, йорт-җирләрен көйдерде.*

*Ташланды да патша зур яу булып Казанга,*
*Казып керде астын Казанканың — елганың,*
*Ә шәһәрдә кайнашалар татарлар,*
*Күзәтәләр Иван патшаны —*
*Күзәтәләр ачуланган татарлар.*

*Кайгы басты усал патшаны,*
*Салындырды башын уң якка.*
*Тупчыларын ул тотынды чакырырга,*
*Ут салучы тупчыларын — барысын.*

*Әй төтенли балавыз шәм —*
*Мичкәгә ут сала яшь тупчы.*
*Дары тулы мичкә тәгәри,*
*Әй, тәгәри чокыр буйлап... һәм шартлый.*

*Кычкырдылар ачу белән татарлар,*
*Каргадылар усал патшаны.*
*Иксез-чиксез татар каны түгелде,*
*Кырык өч мең татар егылды.*

*Казан дигән ай шәһәрдә, менә ни булды...*
*(Григорийга.)*
*Ник син җырламыйсың,*
*Нигә кушылмыйсың бу җырга?*

Һәм Ялган Дмитрий Варлаамга ничек җавап бирә: "Мин теләмим". Бу җырны, бу усал җырны без дә җырламаячакбыз. Чөнки заманалар хәзер гаҗәеп үзгәрде, инде мин сезгә Казанда, 1953 елда, татар телендә, шагыйрьнең үз телендә басылып чыккан шигырьләр — Муса Җәлил тарафыннан Моабит төрмәсендә, аның гомерен палач балтасы өзгәнгә кадәр язылган шигырьләр турында сөйлим. Бер татар кешесе, өстенә палач балтасы төшкәнгә кадәр, Россиядә яшәүчеләрнең барысы өчен дә, безнең өчен дә әнә шул шигырьләрне язып калдырган, һәм мин сезгә әйтеп үткән съездның башында ук, докладчы Алексей Александрович Сурков үзенең чыгышының өченче өлешендә ул шигырьләрдән менә бу дүрт юлны китерде:

*Мин тез чүкмәм, катил, синең алда,*
*Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә;*
*Кирәк икән, үләм аягүрә,*
*Балта белән башым киссәң дә.*

Дүрт юл шигырь... Һәм шунда ук ул "туплар сөйләгәндә музалар тын тора" диюче "сәнгать — сәнгать өчен" тарафдарлары турында ирония белән сөйләп китте... Татар Муса Җәлил шигыреннән дүрт юл... Поэзия турында доклад ясаучы әзәрбайҗан шагыйре Сәмәд Вургун трибунага менгәч, Муса Җәлил тавышы аның тавышы белән тагын яңгырады.

Муса Җәлил тавышы безгә таба Моабит төрмәсеннән күтәрелде. Сәмәд Вургун Ватан сугышы көннәре турында сөйли башлый. Менә... Нәкъ менә шул чакта без шагыйрь сүзенең "кеше көче полководецы" булуын аеруча нык аңладык:

*Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,*
*"Ул егылган арып", — дисәләр,*
*Син ышанма, бәгърем!*
*Мондый сүзне*
*Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр.*

*Байрагыма каным белән язган*
*Антым чакра алга барырга,*
*Хакым бармы минем абынырга,*
*Хакым бармы арып калырга?*

*...Илдән киттем ил һәм синең өчен,*
*Автоматым асып аркама.*
*Илемне һәм сине алмаштыргач,*
*Җирдә миңа тагын ни кала?*

*Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,*
*"Муса инде үлгән",—дисәләр,*
*Син ышанма, бәгърем!*
*Мондый сүзне*
*Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.*

*Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас*
*Ялкынлы җыр тулы күңелне,*
*"Үлем" диеп әйтеп буламы соң*
*Җиңеп үлгән мондый үлемне?*

Муса Җәлил... Сез, Франция диварларында эленеп торган зур кызыл афишаларны оныткан кешеләр, кабатлагыз бу исемне, хәтерләгез сезнең палачлар кылә торган рельсларны шартлаткан Манушиянны — әрмәнне. Манушиян да төрмәдә шигырьләр язган... Искә төшерегез Муса Җәлилнең исемен: сөеклесеннән ул үзенең үлүенә ышанмауны үтенгән, чөнки җырның гомере — кешенекеннән озын. Һәм аңлагыз, ничек, ни өчен Григорий Отрепьев, Чудов монастыреннан качкан монах, соңра меңләгән тәшвиш һәм законсызлыклар белән изге туганнарның рухына тынычсызлык салган Григорий..., Варлаамның "Казан дигән ай шәһәрдә..."не җырлауга ник кушылмыйсың, диюенә каршы, ничек җавап бирә... Аңлагыз, ни өчен мин Григорий Отрепьев кебек әйтәм: "Мин теләмим". Муса Җәлилнең ялкынлы җыры түгел, бәлки салкын тәне туфрак белән күмелде, Иван Грозный солдатлары өчен түгел, Казанны яндыручылар, Казанны әллә ничә мәртәбә яндыручылар өчен түгел, үч алырга чакыручы байрак астында ант иткән руслар — бердәм туганнар өчен күмелде. Ул ант аларны алга илтте, башка бер шәһәргә — Моабит төрмәсе булган, Моабит төрмәсе урнашкан Берлинга алып китте, бөтерелеп әйләнгән җыр ялкыны анда барып җитәр алдыннан алып китте. Бу кешеләр, үзләре казыган окоплардан чыгып, поход адымы белән Рейхстагка барып җиттеләр. Аларның берсе Рейхстаг түбәсенә—бик югарыга ут-ялкын байрагын — кан төсендәге ант байрагын мәңгезеп кадады, һәм шундук салкын җирдә мәетләр калмады, — Муса Җәлил, анда бары тик җиңүчеләр генә иде инде!

Икенче съездда Татарстан вәкиле Кави Нәҗминең — моннан егерме ел элек Горькийның дикъкатьле күз карашы астында шул ук трибунадай сөйләгән язучының чыгышы. Ул көнне Кави Нәҗми Горькийдан өземтә китерде — анда болай диелә: "Мин татар поэзиясенең һәм прозасының күкрәп чәчәк атуын телим, ләкин бу — әдәбият мәсьәләсенә җитди караганда гына булырга мөмкин"... Андый әдәбиятның үткәндәге бай мираска нигезләнмәгән булуы мөмкин түгел: моннан егерме ел элек мин Кави Нәҗминең шушы гасыр башы классик шагыйре — царизм золымы астында иҗат иткән Габдулла Тукай турында сөйләгәнен тыңладым. Ул шагыйрь үзенең бер шигырендә әйтә:

*Килде тоткынлык, түбәнләнде уемның куллары;*
*Хөр заман ак кул белән күкләрдә йолдыз чүпләдем.*
*...Ул—түгел күңлем эшеннән, тик ялан кулның эше;*
*Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылып чүпләрем.*

Әнә шундый кырыс башлангыч, Тукай һәм Мәҗит Гафури поэзиясе, Галимҗан Ибраһимовның типографиядә конфисковать ителгән[1] романнары Татарстан

---

[1] Сүз Г. Ибраһимовның 1914 елда патша цензурасы тарафыннан конфисковать ителгән "Безнең көннәр" романы турында бара (Ред.).

республикасы совет язучыларына юл хәзерләде. Күренә ки, Горький аларга ташламалар ясамаган, һәм бу очракта өлкән туган кинәшләре — күпне күргән һәм иҗат өчен авыр шартларны—Тукай һәм Ибраһимов кичергән шартларны үзе татыган һәм үзе ул шартларга каршы көрәшкән рус язучысының кинәшләре милли әдәбият үсешенә никадәр зур этәргеч була.

Егерме елдан соң Кави Нәҗми, каләмдәшләре каршысына үзенең туган ил әдәбияты исеменнән килеп, эшчәнлеге ике съезд арасында дәвам иткән Шәриф Камалны ихтирам белән искә алып үтә, аннары Муса Җәлил турында, Фатих Кәрим турында сөйли: "...Совет ватанына соңгы шигъри юлларынача тугры хезмәт иткән шагыйрь һәм солдат. Аның Казан музеенда изге реликвия буларак саклана торган шинеле генә түгел, кулъязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән". Кави Нәҗми гомере хәрби госпитальдә өзелгән Гадел Кутуй турында сөйли. Ул — Маяковский поэмасының бормалы-сырмалы юлларында кайчандыр бервакыт мин очраткан иске таныш булып чыкты:

*Килеп керә татар:*
*"Мин*
*татарча*
*"Сул марш"ны*
*укыйм*
*сезгә",* — ди.

Кави Нәҗми бу сүзләрнең әле генә искә алып үтелгән шагыйрь турында булуын безгә әйтте. Татар әдәбиятында монарчы күрелмәгән жанрның тууы турында сөйләде: Фәйзинең Тукай турындагы романыннан башлап тарихи роман; Газиның "Онытылмас еллар"ы; шулай ук Гыйззәтнең, Мөхәммәт Галинең, Уразиковның, Исәнбәтнең тарихи драмалары. Ул үз иле әдәбиятындагы Сталин премиясе белән—Гомәр Бәшировның "Намус" романына бирелгән премия белән горурланды... Аннары шагыйрьләрнең исемнәрен атады: Хәким, Маннур, Баттал, Садри, Арсланов, Давыдов... Бу исемнәрдән, безне Моабит җырларына илтеп җиткергән әдәбияттан, боларның барысыннан чыгып без нинди нәтиҗәгә килә алабыз? Язучыларын без белеп бетермәгән уннарча халыкларның берсе шушы түгелмени? Ничек алар белән ныграк танышырга?

СССРда ленинчыл милли политика әдәбияттагы милли мәсьәләләрне тулысынча яктырта ала икән. Ләкин шуның белән бергә төрле якка чәчелгән көчләрне бергә туплау, хаксызлыкны төзәтү, искелек калдыкларын җимерү бик җиңел булгандыр дип уйламагыз. 1917 елның Октябреннан соң утыз сигез еллап вакыт үткәч җыелган Икенче съезд нәкъ менә шул политиканың җиңүе нәтиҗәсендә зур әһәмияткә ия булды да инде. Бу җиңү, әлбәттә, Советлар Союзының төрле телләрендә зур һәм әһәмиятле әсәрләрнең тууына, Горький тәкъдим иткәнчә, фольклорны һәм шул телләрдәге борынгы классик әдәбиятны тирәнтен өйрәнүгә, шулай ук өлкән рус язучыларының, гомумән башка милләт язучыларының шул республикада чыккан әсәрләрне тәрҗемә итеп популярлаштыруга актив катнашуларына бәйле. Шуның белән бергә бу җиңү Советлар Союзындагы зур милләтләрнең язучылары әсәрләрендә — романнарында һәм поэмаларында башка милләт темаларының, үткән тормышка, милли мираска, табигать күренешләренә һәм үзенчәлекле гореф-гадәтләргә кагылышлы темаларның, шулай ук милли кадрларның туктаусыз үсеш-үзгәреше белән бергә барган социалистик төзелеш темасының барлыкка килүенә дә бәйле.

Мин Татарстан әдәбиятына бер очракка бәйләнешле рәвештә генә тукталдым. Аны тирәннән һәм төрле яклап тикшерергә кирәк.

*1956, № 10*

* * *

*...Әнә бер читтә һәрвакыт ялгызы гына утырырга яратучы, "халык дошманы" Хәсән Туфанның хатыны Луиза Салиәсгарова. Ул кешеләрдән курка, кача, аз сөйләшә. Аның күңеле китек, йөзе тулы сагыш.*

*Ә. Гобәйдуллина-Камалетдинова*

*Идел, 2004, № 11.*



Хәсән
Туфан

## КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ

*Дөнья мине*
*Үзгәртте:*
*Еламаска өйрәтте.*
*Күлмәк җиңен ертасымы? —*
*Бәйлисе бар*
*Йөрәкне.*

*Сугышлардан замана*
*Туктап торган арада,*
*Яраларны ямаштырып*
*Ята идем*
*Далада:*

*—Кайт!.. — дип хатлар килделәр...*
*Юллар... озын иделәр...*
*Кайттым,*
*—Бусы алкалары,*
*—Бусы — кабере... — диделәр.*

*Әгәр тагын килсәләр,*
*Сау дип хәбәр бирсәләр,*
*Вулканга да керер идем,*
*Шундадыр ул, дисәләр...*

*Бирде дөнья кирәкне;*
*Еламаска өйрәтте...*
*Кайсыгызның кулы җылы? —*
*Бәйлисе бар йөрәкне...*

*1956.*

*1963, № 1*

*Журналыбыз турында*

## Хәсән Туфан:

**—Утызынчы еллар уртасында журналның редколлегиясендә Галимҗан Нигъмәтиләр, Гомәр Галиләр белән, Кәрим Тинчурин һәм Шәриф Камал абыйлар белән, Гомәр Толымбайскийлар белән бергә эшләгән идем, бергә яшәгән идем...**

**"Казан утлары" Татарстан шагыйрьләре һәм язучылары өчен үзенә бер мәктәп булып тора. Бу журнал менә инде ничә дистә ел татар әдәбияты үсүенә әйтеп бетергесез зур өлеш кертеп килә.**

**Дәвам итә безнең нурлы юл,**
**Анда шигъри шоңкарлар калка.**
**Зур һәм көчле дәртле халыкның**
**Әдип халык, шагыйрь халыкның**
**Чын баласы, үз баласы булганнар калка,**
**Дәвам итә безнең нурлы юл,**
**дәвам итә.**

*1972*

*Елмаеп та, көлеп тә...*

Камил
Мостафин

## ЯРАМЫЙ ШУЛ...

ПАРОДИЯ

*Ә мин көнлим сине — ят күзләрдән,*
*Иңнәреңә яткан чал туннан,*
*Алларыңа алтын чәчен сибеп,*
*Сер бүлешкән төнге лампаңнан.*
Сажидә Сөләйманова.

*Көнлим сине, көнлим — ят күзләрдән,*
*Бармагыңны кочкан балдактан,*
*Ыспай чәчләреңне аралаган*
*Үзең сатып алган тарактан.*

*Иңнәреңә яткан туннан көнлим,*
*Син юына торган сабыннан...*
*Галстук та, чая кызлар кебек,*
*Муеныңа әнә сарылган.*

*Яшерермен сине ят күзләрдән*
*(Мин хәзергә әле сабырлы),*
*Тик нишләтим икән шул лампаңны,*
*Тарагыңны, тунны, балдагыңны*
*һәм галстук белән сабынны?!*

*Атар идем утка, барсын җыеп*
*һәм үч итеп сиңа, юләргә!..*
*...Әйе, шулай итәр идем дә бит,*
*Ярамый шул — акча түләнгән!*

*1978, № 10*



Язучы, тәнкыйтьче, рәссам бергә киңәшләшә. Уңнан сулга — Шәриф Камал, Гази Кашшаф, Байназар Әлминов. 1941 ел.



Совет чоры әдәбиятының күренекле вәкилләре — латыш Вилис Лацис, Кави Нәҗми, кыргыз Аалы Токомбаев, рус Александр Фадеев. Үткән гасырның 50 нче еллары.



Ватан сугышында катнашкан бер төркем язучылар. Беренче рәттә (сулдан уңга): Сибгат Хәким, Габдрахман Минский, Риза Ишморат, Афзал Шамов, Госман Бакир, Гомәр Бәширов, Гариф Галиев; икенче рәттә—Атилла Расих, Мөхәммәт Садри, Геннадий Паушкин, Сафа Сабиров, Юрий Белостоцкий, Тихон Журавлев, Шәйхи Маннур; өченче рәттә—Мәхмүт Хөсәен, Сәет Шәкуров, Мәгъсүм Насыйбуллин, Габдулла Шәрәфи, Нәби Дәүли, Мәҗит Рафиков, Габдулла Шамуков, Кави Латыйп, Әхмәт Исхак. 1980 ел.



*"Казан утлары" авторлары Матбугат йорты балконында. Сулдан уңга — Нәби Дәүли, Сәрвәр Әдһәмова, Баян Гыйззәт, Хәсән Хәйри, Хәсән Туфан, Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов, Әнвәр Давыдов. 1965 ел.*



*Үткән гасырның 60 нчы елларында Шигырь бәйрәме Тукай һәйкәле янында (элеккеге Куйбышев, хәзер Тукай мәйданы) үтә иде.*



*"Совет әдәбияты" журналы редакциясендә. Сулдан уңга — Малик Хәмитов, Нил Юзиев, Фатыйх Хөсни, Яхья Халитов, Вил Ганиев, Абдулла Гомәр (баш редактор), Габдрахман Әпсәләмов. 1962 ел.*



Миргазиян
Юныс

# БЕЗНЕҢ ЙОРТ ӨЯНКЕ АСТЫНДА ИДЕ...

Миргазиян Юныс 1927 елда Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында туган. 1944 елда армиягә чакырыла. Совет авиациясендә хезмәт итә. 1955 елда Кара диңгездәге сәүдә флотына эшкә урнаша. Шул ук вакытта ул Мәскәү Дәүләт университетының филология факультетына читтән торып укырга керә һәм 1961 елда шул факультетның СССР халыклары әдәбияты бүлеген тәмамлый.

"Безнең йорт өянке астында иде..." исемле бу хикәясе—авторның беренче әсәре.

Кайбер кыска гына очрашулар да бик озакка хәтергә кереп кала икән. Нибары ике генә тапкыр күргән бер карчыкны мин гомергә оныта алмам шикелле.

...Пароходыбыз Генуя портында причалда торганда, без Италиянең халык герое—Рязань тимерчесе Федор Полетаевның каберенә чәчәкләр куярга барган идек. Генуяның атаклы Стольено зиратына керсәң, тәэсирләнми чыга алмыйсың. Зираттагы мәрмәр һәйкәлләр дә кеше кайгысына кушылып елыйлар кебек.

—Нигә кирәк инде мондый кыйммәтле матурлык? Үлгән кешегә нинди кабер дә барыбер түгелмени?—ди кочегар Трак.

Штурман Маркин аның фикере белән килешми:

—Җүләр син, Трак. Каберне бизәү—кеше үлгәч тә кадерен югалтмый дигән сүз ул.

"Поэтан" батырның каберендә яна чәчәкләр бер дә бетеп тормый. Генуя портына якорь ташлаган һәрбер судно экипажы бу кабергә чәчәкләр сала. Россиядән килеп Италия азатлыгы өчен гомерен биргән бу партизанга Генуя халкы зур ихтирам күрсәтә. Хәтта ваемсыз турист халкыннан да чәчәкләр бар.

Кабергә чәчәкләр куйгач, бераз сүзсез калып, тын гына басып тордык. Кая гына ташламый кешене язмыш дигән нәрсә... Мондый вакыйгалар алдында сүз көчен җуя. Шуңа күрәдер, чыгу юлына таба киткәч, без бик озак сүзсез атлыйбыз.

—Галереяны урап чыкмыйбызмы?—ди Маркин.

Өчәүләп галерея буйлап һәйкәлләр арасыннан барабыз. Менә чалгы күтәргән скелет—Үлем—яшь кызны алырга килгән. Кызның күзләрендә—курку, ә күнелендә—яшәү өмете, тереклекнең мәңгелегенә ышану. Горький "Кыз һәм үлем" поэмасын шушы һәйкәл тәэсирендә язган, диләр.

Кочегар Трак һәйкәлләргә бик исе китми генә бара иде, җилкәнле көймәгә баскан яшь малай скульптурасы янына җиткәч, туктап калды:

—Гаяз Бакирович, укыгыз әле, нәрсә язылган монда?

Һәйкәлнең постаментына Торквато Тассоның атаклы поэмасыннан ике юл шигырь язылган.

—"Кеше гомере давыллы диңгездәге көймәдәй тормыш аша үтә",—дип тәрҗемә итәм мин бу язуны.

Бер һәйкәл үзенең чын реализмы белән башка һәйкәлләрдән аерылып тора. Аның тарихы болай икән: карчык гомер буена зират янында крендель сатып үзенә һәйкәл салдыру өчен акча җыйган.

Шул карчык һәйкәленә карап торганда, безнең янга өлкән яшьләрдәге бер хатын килеп туктады да, кулын селти-селти, ниндидер телдә бездән нәрсәдер сорый башлады. Аның артыннан шулай ук бик дулкынланган яшь кенә бер хатын килеп кушылды.

—Итальянча сөйләшә беләсезме?—дип сорыйм алардан итальян телендә.

—Әйе...—Яшь хатын елап та җибәрде.

—Ни булды сезгә?

—Улыбызны югалттык...

Мин иптәшләремә тәрҗемә итәм.

—Әйдәгез эзлибез!—ди Маркин.

Югалган малайның исемен сорагач, шушы һәйкәл янында очрашырга сүз куешабыз да, өчебез өч якка таралабыз.

—Пьетро-о-о!!—дип кычкыра яшь хатын. Сүзнең соңгы иҗеге үксеп әйтелгән кебек яңгырый. Тыныч зиратта бу тавыш бигрәк тә каты ишетелә. Тик бу чакыруга беркем дә җавап бирми. Каберләр тын.

Ресорҗиментоның[1] юлбашчысы Мацини мавзолеена менә торган юлга чыккач, нарат чикләвекләре җыеп йөрүче бер малайны очраттым.

—Пьетро!—дим малайга. Малай миңа аптырап карап тора.

— Синең исемең ничек?—дип сорыйм анардан итальянча.

— Пьетро,—ди малай.

—Әйдә әниең янына. Ул сине эзли.

Малай карыша. Кулыннан тотып алып бара башлагач, еларга кереште. Кулны тешләргә тели. Мин аны күтәрәм дә галереяга теге крендель сатучы карчык һәйкәле янына таба атлыйм.

Галерея янында безне картрак хатын куып җитте.

—Пьетро!—диде карчык кочагын җәеп. Карчыкны күргәч, малай көлеп җибәрде, җиргә сикереп төште дә карчыкның итәгенә ябышты.

— Нәни разбойник,—дим карчыкка малай турында.

Карчык дәшми.

—Итальянча сөйләшә беләсезме?—дип аптырап кабат сорыйм карчыктан. Карчык өчен малай җавап бирә:

—Сөйләшә белми. Ул грекча гына сөйләшә белә.—Карчык малайдан нидер сорый.

— Ә сез кем соң?—ди Пьетро итальянчага тәрҗемә итеп.

—Мин диңгезче, Советлар Союзыннан.

—Русски?—дип сорый карчык кинәт кенә.—Я русски понимайт мала-мала.

—Откуда вы знаете по-русски?

—Я из Рәчәй, давна Рәчәй.

Таныш акцент яшен тизлеге белән татар авылы картларының русча сөйләшүләрен хәтерләтте.

—Әби, сез татар түгелме?

—Татар... И ходаем, әллә саташам инде...

Карчык бөтенләй югалып калды. Ни әйтергә, нәрсә эшләргә белми хәлсез куллары белән күлмәк итәген сыпыра.

---

[1] Ресорҗименто — Италиядә 1848–1861 елларда Мацини һәм Гарибальди җитәкчелегендәге берләшү хәрәкәте.

— И ходаем... и ходаем...

— Сез нинди язмыш белән монда килеп элләктегез соң?

— Язмыш, улым, язмыш... Әйтмә инде... И ходаем...

Карчыкның күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәп чыкты да җыерчык буйлап битенә таралды. Пьетро аптырап китте. Үзенә аңлашылмый торган телдә сөйләшү ошамады ахры аңа—карчыкны читкә сөйри башлады.

—Әйтмә инде, улым, әйтмә... Мин Караярныкы, Самар губернасыннан.— Карчык учы белән тамак төбен уа. Күзләреннән һаман мөлдерәп яшь ага.

—Хәзерге Татарстандагы Караяр булса, мин аны беләм. Безнең Чыршылыдан егерме чакрым гына. Мин, әби, Бөгелмә районыннан.

— Без дә Бөгелмә өязендә тора идек. И ходаем... и ходаем...

Шулай сөйләшеп торганда, Маркин белән Трак әйләнеп кайттылар.

—Таптыгызмыни?—ди Трак.

—Әйе,—мин әйтәм,—таптык. Малайның әбисе минем якташ булып чыкты. Әби, сау булыгыз. Безгә вахтага басарга кирәк, соңга калабыз. Безнең пароход Лантерна маягы янында гына тора.

—Үзегез кунакка килегез, улым. Кызымның торуы Сестри дигән җирдә, Грамши урамы, ундүртенче йорт.

Без йөз метр чамасы киткән идек, карчык кулын болгый-болгый безнен арттан килә.

—Улым, корабыгызда туган җир туфрагы юкмы? Иснәп кенә тотар идем...

Пароходта туфрак булмый инде ул. Кайдан аласың аны? Юк, тукта әле, минем искә пожар сүндерү өчен тота торган ком килеп төште.

—Табарбыз, әби. Күпме кирәк кадәр алырсыз.

Икенче көнне иртән айлык отчетны язарга гына утырган идем, өстәлдә телефон шалтырады.

—Вахтенный штурман тыңлый.

—Гаяз Бакирович, ниндидер карчык пароходка керергә тели. Бераз русча да сөйләшә белә кебек үзе. Ләкин нәрсә сораганын аңлап булмый.

—Минем каютага озатыгыз.

Буфетчы хатынга шалтыратып чәй китерүен сорап кына өлгергән идем, ишектән кичә очраткан татар карчыгы килеп керде.

—Түрдән узыгыз, әби.

—Рәхмәт, улым, шушында гына утырыйм әле. Бүлмәң бик яхшы икән. Кыйммәтле җиһазлар. Син башлыкмыни, улым?

—Шулайрак шул.

Карчык яшь чагында бик чибәр булган ахры. Әле дә хәрәкәте салмак, гәүдәсе җинел һәм пөхтә. Коңгырт кара күзләрендә элекке шаян очкыннар урынында аналарча сөйкемлелек.

—Пароходта туган ил туфрагы юк икән, әби. Икенче килүдә алып килермен. Без монда еш киләбез.

—Хәерле булсын инде. Саклап кына тотармын дигән идем. Бүген төн буе Караяр белән саташтым.

—Авылыгызны һаман онытмагансыз икән.

—Оныта ди. Картайган саен ныграк сагындыра. Безнен йорт өянке астында иде. Тәрәзәдән карасаң, Ык тугаенда ап-ак булып шомырт чәчәк ата иде... Анда керне һаман да бәләкләп чайкыйлармы әле?

—Белмим. Ял вакытларында бер дә күргәнем булмады.

—Бәләк тавышлары су буеннан бик матур ишетелә иде. Язын сабан туена, көзен каз өмәсенә җыела идек... И ходаем, ничек үлмәдем икән бу кадәр сагынуымнан!

Буфетчы хатын каютага чәй кертте.

—Ашап кына эчегез, әби. Бу икмәк, бәлки, Ык буенда үскәндер. Карчык ашавыннан шып тукталы. Учы белән тамак астын уа. Иреннәре дерелди. Нидер әйтергә тели—ләкин авызыннан сүзе чыкмый.

—Әби, ник ашамыйсыз?

—Рәхмәт, улым... Бу сыныкны төйним әле, саклап кына тотармын.

—Ничек бу илгә килеп чыктыгыз соң, әби?

—Әйтмә инде, улым... Бәхетсезлеккә каршы, ходай шулай язгандыр инде... Ирем сатучы иде. Караярда кибет тота идек. Рвәлүция чыккач, Кырымга киттек. Анда да бәлшәвикләр килә дип ишеткәч, Истанбулга күчеп килдек. Анда сәүдәләр унмады, Грециягә килдек. Грециядә ачлы-туклы гына яши идек, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, сугыштан соң ирем үлде. Ике кызым, бер улым бар иде. Олы кызым Әмерек кешесенә кияүгә чыкты. Өч ел хәбәре юк инде... Ә кечесе монда, Генуяда. Ире дингездә йөзә. Елына бер-ике мәртәбә кайтып күренгәли: әллә бар, әллә юк... Караярны сагынам...

Карчыкның күзләреннән чыккан яшь бөртекләре җыерчык буйлап битенә ага. Иреннәре дерелди. Үзе бармаклары белән яулык очын бөтерә.

—Караярны сагынып еласам, кызларым ачуланалар. Алар белмиләр бит туган илне: берсе Төркиядә, берсе Грециядә туды. Малаем татарча белә иде, елдан артык хәбәре юк: грек эшчеләрен каршылыкка котырта дип төрмәгә яптылар... Авылда минем әткәй калган иде, исәнме икән? Безнең йорт өянке астында иде. Ык яры буенда...

—- Елама, әби. Безнең консулга язарга кирәк, бәлки, кайтырга рөхсәт итәр.

—Ирем, мәрхүм, исән чагында язып караган иде, эш чыкмады.

—Отпускага кайткач, мин Караярда сораштырырмын әле. Әтиегез ни исемле иде?

—Шәмсулла исемле. Сатучы Шәмси дип йөриләр иде. Ике энем, кияүдәге бер сеңелем бар иде. Алар исәннәрме икән?

—Алар турында да белермен. Без Генуяга еш йөрибез. Италия белән сату-алу эше яхшы бара бит.

Карчык бик ышанып та бетми кебек. Әллә озак еллар буе өметсез яшәгәнгә, бу хәлгә күнегә алмый ахры. Ул дәвам итә:

—Мин бит монда кунакта гына. Сагынуыма чыдый алмыйча Грециядән килдем. Үзем улым белән бергә Левадия шәһәрендә тора идем, аны төрмәгә япканчы...

Карчык тагын бераз утырды да кайтырга җыена башлады. Ишек тоткасын кулына алгач, кинәт кенә маңгае белән ишек янагына терәлеп үксеп елый башлады.

—И ходаем... Алып кайт син мине, улым... Кая булса да яшер... нинди җәзага да риза... Алып кайт! Караярны күрәсем килә. Ык буен, өянкеләрне... Карга тавышларын ишетәсем килә... Алып кайт, яме?!

Карчыкны тынычландырырга тырышам. Консульствога язарга вәгъдә бирәм. Ул тыңламый.

—Өебез булмаса да, өянкеләребез исәндер әле. Алып кайт, яме? Кайтсам, ичмасам, туган илемдә үләр идем. Сөякләрем туган ил туфрагында ятар иде...

Траптан төшкәч, карчык озак итеп пароходка карап торды. Бераздан аның гәүдәсе әкрен генә кыя артына китеп күмелде.

Кич белән бик озак йокыга китә алмый яттым. Төшемдә әни карчыкны күрдем. Уянгач, әни ялгыз булса да, туган илендә яши әле дип, шатланып куйдым.

Иртәннән бирле башым авырта иде, шуна күрә бераз йөреп кайтыйм әле дип, шәһәргә чыккан идем, Колумб йортына, Паганини музеена кергәнлектән, төштән соң гына кайттым.

—Теге карчык тагын пароходка килгән иде, порттагы полисмен куып җибәрде, кертмәде,—дип каршы алды мине вахтенный матрос.

—Кайчан килгән иде?

—Иртүк. Сезне көтеп көн буе утырды. Әле яна гына куып җибәрделәр үзен.

Кич белән безнең пароходны төяп бетерделәр. Сәгать кичке унда якорьны күтәрдек тә илебезгә кайту ягына юнәлдек. Тәүлек ярым дигәндә, без Мессина бугазында идек инде. Лигурия һәм Тиррен дингезләре безне тыныч кына үткәреп җибәрде. Ионий дингезе вак, житез дулкыннар белән каршы алды.

Ә кичкә таба жил, көчәйгәннән-көчәеп, давылга әйләнде. Дулкыннар гөрселдәп пароходка килеп бәреләләр. Җил ыжгыра, һавада су кисәкләре оча. Җир белән күкне аерып булмый. Пароход калтырый, менә-менә таралыр шикелле тоела.

Мин, вахтаны тапшырып, ял итәргә яттым. Караватта ятып булмый, тәгәрәтә. Диванга күчәм. Өстәлдәге әйберләр идәнгә коела. Дулкын килеп бәрелгән саен нәрсәдер шартлап ярыла.

"Дүртенче трюм капкачының резинкасы бик тузган иде, трюмга су кермәсә ярар иде",—дип уйлап ятам. Барып тикшерер идең, палубага чыгып булмый—күз ачып йомганчы дулкын юып алып китүе мөмкин. Вахтенный механикка телефоннан шалтыратам:

—Льяль[1] насослары төзекме?

—Төзек, Гаяз Бакирович.

—Вакыты-вакыты белән насосларны җибәреп, суны суыртып торыгыз. Льяльләрне үлчәп булмый, горловиналары су астында.

—Тыныч булыгыз, Гаяз Бакирович, насослар яхшы эшли.

Матапан борынын үткәч, шторм бераз басыла төште. Эгей дингезендә вак дулкыннар салмак кына уйныйлар иде. Ә Мәрмәр дингезе безне штиль белән каршы алды.

Мин кесә фонарен алдым да трюмнарны тикшерергә киттем. Беренче трюм коп-коры. Икенче трюмга да су үтмәгән. Өченче трюм дымлырак, ачып жилләтергә кирәк: безнең йөк юешлекне яратмый. Дүртенче трюмга төшү белән аягым юешкә батты. Күнелем сизгән икән. Хәзер менеп капитан белән киңәшергә кирәк. Морской протест[2] язмыйча булмас. Күпме юешләнде икән, буйдан-буйга әйләнеп чыгыйм әле дип киттем.

Трюмның койрык ягы почмагына житеп, борылып кына килә идем, аяк бер йомшак нәрсәгә басты. Аны фонарь белән яктырттым. Нәрсә бу? Кеше түгелме сон? Иелеп капшап карыйм да урынымда катып калам. Тәнгә чымырдап ток йөгергән сыман була. Арканы салкын тир баса. Үлек! Тәне кап-каты, салкын.

Рубкага ничек менгәнемне дә сизми калдым. Жыелып төштек тә трюмга люстра астык. Мәетне күтәргәч, тагын бер мәртәбә ток суккан кебек сиздем үземне: Генуяда очраткан теге татар карчыгы. Әллә тыны бетеп, әллә шторм вакытында чайкалуга йөрәге чыдамыйча үлгән, мескен.

Күрәсен, безнен пароход Генуяда сонгы кичне торганда, карчык, ничек булса да туган илгә кайтырга үзенчә карар кылып, сиздермичә генә палубага үткән дә трюмга яткан.

...Без аны Феодосия портында сонгы юлга озаттык. Мәрхүмә карчык үз теләгенә ирешә: аның сөякләре туган иле туфрагында ята.

*1964, № 8*

[1] Льяль—трюм идәне һәм пароходның төбе арасындагы бушлык. Су үтсә, льяльләргә ага да, аннан насос белән суыртыла.

[2] Морской протест—команда бөтен көчен куюына карамастан, стихиядән йөкне саклый алмавы турында документ.

## АНЫКЛАГЫЧ МӘГЪЛҮМАТ

«Безнең өй...»гә кадәр язылган «Железный слон» исемле хикәям Паустовскийның 70 яшьлек юбилеена багышланган конкурста беренче урынны алган иде.

Ул чорда, Такташ сүзләре белән әйткәндә, туган тел «калган, югалган» иде. Өстемдә Сингапурда алган хаки, кесәдән кызыл тышлы загранпаспорт күренеп тора. Рестораннарда официанткалар гына түгел, метрдотельләр, хәтта шеф-поварлар минем корефаннар. Белмим, шушы дәрәҗәгә җитеп кылтайган бәндәне Генуя зиратында очраган татар карчыгы ничек уятып, чынбарлыкка кайтара алган икән? Карчыкның әниемә охшаганлыгымы? Тетрәнү чиктән тыш көчле булган, күрәсең. Бусы аңлашыла, шул тетрәнүдән котылыр өчен, бушаныр өчен, ниһаять, карчыкның чыраендагы газапны онытыр өчен язганмын мин ул хикәяне.

Карчык белән без башта зиратта сөйләштек, аннан соң ул безнең корабка килде. Карчык нәрсә әйткән булса, хикәягә мин тамчы да үзгәртмичә шул сүзләрне яздым.

Үземнән мин бары тик бер эпизод өстәдем: карчыкның трюм эченә кереп үлүен. Хәзер инде аңлыйм, ялгыз карчыкның причалда калуын үзгәртмичә әдәбият таләбендә биргән булсам, хәтта отышлырак та чыгар иде.

Нокта куйганнан соң хикәямне конвертка тыктым да портка килеп туктау белән энем Вахитка җибәрдем.

Хикәяне җибәрдем һәм... оныттым... Шулкадәр сәер тоелды миңа «Безнең йорт өянке астында иде...»не «Совет әдәбияты» журналында күрү.

Туган телемдә язылган беренче хикәям мине Казанга алып килде.

Ул чакта әдәби журналыбыз «Совет әдәбияты» атала иде. Мине журналның баш мөхәррире Газиз Мөхәммәтшин каршы алды. Кош теле зурлыгындагы сыңар хикәя авторына шундый хөрмәт күрсәтү? Мин моны аңлый алмыйм. Ул чакта газета-журнал редакцияләре Бауман урамы, 19да иделәр. Газиз мине редакторларның күбесе белән таныштырды. Минем бәхетемә каршы, «Совет әдәбияты»на Фатих ага Хөсни белән Габдрахман Әпсәләмов та килгәннәр иде. Баш редактор алар белән дә таныштырды. Мине хәйран калдырган нәрсә— алар да минем хикәямне укыган булып чыктылар. Җылы сүзләр әйттеләр, киңәшләрен бирделәр.

Хикәянең авторы буларак, моны белгертү миңа шактый уңайсыз. Финляндиядә фин татарлары минем беренче хикәямне елый-елый укулары турында сөйләделәр. «Ул чакта Советлар Союзында яшәүче кан-кардәшләребез белән элемтә юк иде. Аралашуга, безнең бар икәнебезне татар халкына белгертүгә без бик тә мохтаҗ идек. Шул чакта безгә сезнең хикәягез килде. Безнең бар икәнлегебезне беләләр икән, дип күз яшьләренә тыгылып шатландык»,—дип аңлаттылар миңа фин татарлары.

«Безнең өй (хикәя исемендәге «йорт» соңыннан шулай «өй» дип үзгәртелде) өянке астында иде...»гә булган җылы караш мине урыс телле язучы булып китүдән коткарып калды. Урысча язу миңа күпкә җиңелрәк иде. Өлкән абзыйлар телендә иҗат иткән булсам, мин бик күп китап чыгара алыр идем. Китапларым күп булыр иде, әмма бәгъремне тырнап әрнеткән сүзләремне урыс телендә әйтеп бушана алыр идемме? Юктыр. Туган тел бит ул...

АВТОР.

*2006*

# ФӘНИС ЯРУЛЛИН ШИГЫРЬЛӘРЕ

Фәнис Яруллин 1938 елда туган. Элекке монтер һәм Совет Армиясе солдаты Фәнис, дүрт ел инде, каты авырый. Ләкин яшь шагыйрь рухын төшерми, урын өстендә хәрәкәтсез яткан хәлдә дә, матур-матур шигырьләр яза. Соңгы вакытларда аның шигырьләре өлкә матбугатында еш басылалар. Хәзер Фәнис Яруллин Ютазы районы, Кызылъяр авылында яши.

## *ТЕЛӘК*

*Нәрсә эшлим сөйгән халкым өчен?*
*Нишләргә дә килми хәлемнән;*
*Һәр көн саен кими бара көчем,*
*Китә бара тормыш тәнемнән.*

*Авыр миңа йомшак түшәкләрдә*
*Көннәр буе эшсез аунавы;*
*Иң авыры — илгә, кешеләргә*
*Файдасызлыгымны аңлавы.*

*Карап ятам: юлдан машиналар*
*Нидер төяп ашыгып узалар;*
*Бик биектә җитез самолетлар*
*Зәңгәр күккә ак юл сузалар.*

*Халкыбызның данлы эшен күреп*
*Тоямын мин тормыш ләззәтен.*
*Их, минем дә шулай ак юл булып*
*Сузылсачы иде хезмәтем!*

*1962, №6*



*Фәнис энисе Гафифә апа белән. «Бәкер» санаторие. 1964 ел.*

# «КАЗАН УТЛАРЫ»

1965 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА




**ЖИТӘКЧЕЛӘРЕ:**
С. Хәким (1965, № 6—җаваплы редактор); Р. Мостафин (1965, 8-1968, 4—җаваплы редактор); З. Нури (1968, 9—җаваплы редактор, 1968, 10-1971, 10, 1974, 1-1982, 12—баш редактор); Г. Ахунов (1971, 11-1974, 10—баш редактор); Р. Харис (1983, 1-1989, 12—баш редактор); Р. Фәйзуллин (1990, 1-1990, 6—баш редактор, 1990ның 7 нче саныннан алып—баш мөхәррир).

*Журналыбыз турында*

## Гариф Ахунов:

***—"Казан утлары" журналы редакциясендә ун ел буе эшләдем. Әдәби хезмәткәр, проза бүлеге мөдире, җаваплы секретарь, баш редактор. Шулай булгачыннан, "Казан утлары"ның минем тормышыма йогынтысын сүз белән әйтмәсәң дә аңлашыла торгандыр.***

***"Казан утлары"нда Кави Нәҗми, Афзал Шамов, Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким кебек өлкән буын язучылар белән таныша алу бәхетенә ирештем. Шушы журналда эшләгәндә Гомәр Бәшировның "Намус" романын аркылыга-буйга өйрәнеп, Галимҗан Ибраһимов иҗатына барып тоташтым.***

***Журналның редакторы Гази Кашшаф мине колагымнан тартып диярлек әдәбиятка алып керде, көне-төне, арып хәлдән тайганчы эшләтте, авыр кара эштән курыкмаска өйрәтте. Проза жанрында эшләүне дә ул миңа көчләп диярлек такты, юкса минем я тәнкыйтьче, я шагыйрь булып китәргә ниятем бик зур иде. Гази абый — минем әтием урынындагы кеше, олы остазым — безнең буынга, әдәбиятка сугыштан соң килгән яшьләргә якты күз белән карап, ярдәм кулын сузып торды, безне гел кайгыртып яшәде. Муса Җәлилне — шагыйрьне һәм геройны яратырга, олыларга, күп милләтле совет әдәбиятының горурлыгы, йөз аклыгы итеп танырга иң башлап ул өйрәтте.***

***Журналда эшләгәндә, татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен, тугандаш әдәбиятлар гаиләсендә тоткан зур урынын күрдем, барлык жанрларны укып, күзәтеп барырга гадәтләндем, шул гадәтем бүген дә саклана.***

***Ниһаять, "Совет әдәбияты" — "Казан утлары" журналында эшләгән дәвердә татар әдәбиятына кем чынлап, күңелен биреп, намус белән хезмәт итә, кем әдәбиятны кәсеп итеп кенә карый, кем анардан үзенең шәхси мәнфәгатьләренә азык кына эзли,— шуларны аерырга, шуларның икесенә ике төрле мөнәсәбәттә булырга өйрәндем...***

***Гомумән дә минем язучылар арасына килеп эләгүем, язучы булып китүем әдәби журналыбыз белән бәйле. "Казан утлары"на гомерем буе рәхмәтлемен.***

*1982*



Редакция журнала "Казан утлары"
("Огни Казани")

# УКАЗ
## ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР

О награждении журнала "Казан утлары"
("Огни Казани") орденом "Знак Почета"

За заслуги в области советской литературы и активное участие в коммунистическом воспитании трудящихся наградить ЖУРНАЛ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСКОЙ АССР "КАЗАН УТЛАРЫ" ("ОГНИ КАЗАНИ") орденом "ЗНАК ПОЧЕТА".

Председатель Президиума
Верховного Совета СССР Н.ПОДГОРНЫЙ.

Секретарь Президиума
Верховного Совета СССР М.ГЕОРГАДЗЕ.

Москва, Кремль.
17 января 1977 г.
№ 5091-IX.

# СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УҚАЗЫ

**«Қазан утлары» журналын «Почет билгесе» ордены белән бүләкләү турында**

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре һәм хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә актив катнашуы өчен **Татарстан АССР Язучылар союзының «Қазан утлары» журналын «Почет билгесе» ордены** белән бүләкләргә.

**СССР Верховный Советы Президиумы Председателе**
**Н. ПОДГОРНЫЙ.**

**СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре**
**М. ГЕОРГАДЗЕ.**

Мәскәү, Кремль.
1977 ел. 17 январь.

Ибраһим
Гази



# ТУРГАЙ КАРТАЯМЫ ИКӘН?

ХИКӘЯ

Шәйхәттәр бабай җәй көннәрендә, урамга чыгып, үзләренең капка баганасына сөялеп торырга ярата. Үткән-сүткән кешеләр, аңа сәлам биреп: "Нихәл, бабасы!" дип китәләр, ә телгә үткенрәкләр: "Аумасын дип әйтәсеңмени, Шәйхәттәр бабай, капка баганасын терәп торасыңмыни? Колхоз трутдин түлиме соң аудармый тотып торган өчен?"—дип, карт кешенең кәефе китәсен-китмәсен дә исәпләмичә, шаяртып узгалыйлар.

Әллә капка баганасы елдан-ел үсә, калыная инде, әллә бабагыз кечерәя, юкара, соңгы берничә елда ул багана янында солы көлтәсе хәтле генә булып калды. Авылда анардан да картрак кеше юк, дип сөйлиләр. Имеш, ул, әби патша заманасында ук солдатка алынып, бер чиләк аракыны ялгыз башы чөмереп бетергән дә әллә кемнәрнең кара мунчаларын нигезе-ние белән авылның икенче башына күтәреп илтеп куйган... Анысы, әби патша заманасында дигәннәре бик карт дип әйтүләре генә инде, билгеле. Ә мунчаны күтәреп илтеп куйган диюләренә ышанырга да була, яшь чагында ул яман да көчле булган дип сөйлиләр. Аның каравы хәзер... Әллә чынлап та капка баганасы үскәннән-үсә, калынайганнан-калыная инде!..

Авылда тагын бер карт кеше бар. Анысы Гөлҗиһан әби. Шәйхәттәр бабай белән бер чама дип сөйлиләр.

Яшь чагында бик матур булган, имеш.

—Гөлҗиһан әби, син авылда матурларның матуры булган дип әйтәләр,—дигәч, әбиегез:

—Ией, кызым, мин узганда җәяүле җиргә ятып карар иде, атлы атыннан төшеп карар иде, - дип әйткән ди.—Хәзер генә ул мине күргән кеше куркып китә, теге вакытларда... иех!.. Саргаючылар күп булды минем өчен, берсе әле дә исән,—дип әйткән, имеш.

Саргаючыларның берсен әлеге шул капка баганасын терәп торучы Шәйхәттәр бабайга юрыйлар. Имеш, бусы житкән егет, теге житкән кыз чакта араларында нидер булган... Хәер, авыл телендә йөргәннең барысына да ышана китсәң... Шулай да Шәйхәттәр бабагызның үзеннән сорап бакканнар. Картыгыз башта бик озак кына аңламаганга салышып торган, кабат-кабат сорагач кына, көлеп җибәргән сыман иреннәрен кыймыл-кыймыл китергән дә:—Кххм...—дип куйган, ди. Бу "кххм"ны бераүләр: "Булган иде, бик булган иде,—дип әйтте дип баралар. Чишмәгә су алырга килгән җирендә кочаклап үпкәч, көянтәсе белән җилкәгә кундырган иде: янәсе, кеше алдында икенче ябышмассын, ә кич белән мунча артында күрешкәндә үзе куенга кереп утыра иде, соңгы әтәчләр кычкырганга тикле

кочактан чыкмый иде", дип әйтте дип баралар. Икенчеләр исә бу "кххм" карт кешенең тамак язып җибәрүе генә булды, безнең сорауны ул бөтенләй аңламады да, димәкче булалар. Белмәссең...

Аңламадымы икән, ай-һай!.. Шәйхәттәр бабагыз үткәннәрне бик яхшы хәтерли, гүя аның хәтере моннан күп еллар элек борып туктатылган да шуннан бирле бер тапкыр да янадан җибәрелмәгән... Авыл моннан әллә ничә еллар элек нинди булган булса, Шәйхәттәр бабагыз шул авылны гына белә. Ничектер Казан артистлары концерт куярга килгәч, баганага сөялгән бабагызны күргәннәр дә:—Клубыгыз кайсы урамда?—дип сораганнар. Бабагыз:—Мәчет каршында,—дип өйрәтеп җибәргән. Авылда мәчетнең юклыгына инде утыз ел! Шәйхәттәр бабайның бөтен сөйләшүе шушы "мәчет каршында"га бик ошап тора. Фәләннәр коесы, фәләннәр тыкрыгы—аның гел әйтә торган сүзләре, ә ул кое инде күптән юк, колхоз авылга артезиан коесы казытканга әллә ни гомер, суны электр чыгара, ә фәләннәр тыкрыгы урынында хәзер колхозның алма бакчасы... Ә Шәйхәттәр бабагыз өчен боларның гүя берсе дә юк. Хәер, монда да кайберәүләр, ул мутлыгы белән генә шулай итә, аның белмәгәне юк, көн буе урамда сөялеп тора-тора бөтен авылның нишләгәнен энәсеннән җебенә тикле белеп тора, аның саңгырау булып кылануы да мутлыктан гына, үзенә кирәкне бик ишетә ул, әнә теге вакытны...—дип, моннан берничә еллар элек булган бер вакыйганы сөйләп бирәләр.

Бер тапкыр шулай, Шәйхәттәр бабагызны саңгырауга исәпләп, аның янында колхоз председателе Мөхип белән кырчылык бригадиры Салихҗан икәү авыл халкын сүгеп торалар икән: янәсе, ялкаулыкның чигенә чыктылар, үз тамакларын гына кайгырталар, колхоз эшенә йөрмиләр. Шәйхәттәр бабай баганага сөялгән килеш барысын да ишетеп тора икән. Менә бервакыт Мөхипне "Кил әле, улым, бирегә" дип, кул изәп, үз янына чакырып китергән дә тотынган тегене ипләп кенә... Син авыл кешесенең тамагын туйдыр әүвәле башта, аннары ялкау дип әрлә. Ничә ел инде трутдингә чыпчык туенырлык та иген бирмисез, әле дә рәхмәт әйтерлек безнең авыл кешеләренә, шул килеш тә көннәр буе эшләп йөри...

Мөхип бик зур кеше бит инде авылда... Аңардан зуррак шул тау башында җил тегермәннәре генә бар. Авылга сыя алмыйча йөри, борын югары, район башлыклары белән дә әшнәлек зур. Аларга балны тәпәне-тәпәне белән биреп җибәрә. Алма бакчасында алма өлгергәч, "Волга" белән килеп, алманың яхшысын гына төяп китәләр. Итне, майны әйтәсе дә юк инде... Шушыларның барысын да әйбәтләп кенә тезеп чыккан Шәйхәттәр бабагыз председатель Мөхипкә. Мөхип каршы сүз әйтә алмыйча тыңлап тора ди шул. Шәйхәттәр бабай, мин багана төбендә генә басып торсам да бияләй эчендә бармак кыймылдатканыгызга тикле сизеп торам, миннән яшерә алмассыз...—дип әйткән ди. Шунда Мөхип әйтә, имеш: мае да, балы да әрәмгә китми, Шәйхәттәр бабай, курыкма, шунсыз комбайннарга, тракторларга запчасть алып булмый, май белән майлагач кына запчасть шалт итеп кайтып керә, эшләр чиратсыз йөри башлый, дип акланырга тырышкан, ди. Менә әйт син бабагызны саңгырау дип... Шушы вакыйгадан соң Шәйхәттәргә сәлам биреп узучылар кинәт күбәйде, югыйсә, ул барыбер ишетми дип, аның ягына карамый гына узып китәләр иде.

Анысы мутлыгы да бардыр, ләкин картлыгы да бар. Бу авыл аның күз алдында авыл булды. Ул малай чакта инеш башында барлыгы биш-алты гына йорт иде. Әнә теге юан өянкеләр... башларында бүрек-бүрек карга оясы... Юк иде бит, аларны Шәйхәттәр бабагыз үзе утыртты. Тал чыбыгын кисеп алып кайтты да су буена төртте, хәзер әнә карагыз аларга... Бишәү килеп кочакласаң да кочагын, житмәс. Гомер дигәнең... Үтә дә китә икән.

Бүген бала-чага атасы булып картаеп баручыларның бишектә аяк бармакларын имеп яткан чакларын белә бит әле ул. Төпсез ыштан киеп урам чапкан чакларын... Имән бармакларны маңгаена мөгез итеп куеп, Мөхипкә бер акаеп карасаң, чырый-чырый елап өйләренә кереп кача торган иде, ә бүген район башлыкларын майлап йөри, авыл халкы өстеннән зур башлык... Бармакларны мөгез итеп, маңгай астыннан бер акаеп карап, бик яхшы гына куркытасы бар әле үзен... Юкса ансат эшкә җыен үз кардәшләрен утыртып бетергән: тегермәндә аныкылар, умарталыкта аныкылар, китапханәдә тагын үз нәселе... Авыр эшкә якын да килмиләр...

Бүген нишләптер күнеле гел егет чагына кайтып төшә әле. Кояш та бүтән иде дип әйтерләр ди картлар. Юк, кояш шул ук иде, тургайлар да шушы ук. Гөлҗиһан белән булды, ай, булды... Әнә теге йөгереп узып баручы кызчык та картаер микән? Аны да сөячәкләр бит инде, аны да кочакка кысачаклар. Кояш күрмәс, ай күреп торыр. Ай дигәннән Гөлҗиһан белән Шәйхәттәрне дә гел күреп торды. Ай белән тургай картаймый, алар гел булачак, ә менә Шәйхәттәр юк инде. Гөлҗиһан да юк, бик күптән инде. Теге, йортлары авыл уртасындагы Гөлҗиһан карчык дисезме? Сүз ул бетәшкән карчык турында түгел. Юк. Бөтенләй башка Гөлҗиһан. Буйлары Идел камышы, күзләре ут иде ул Гөлҗиһанның... Кочакка кыскач сөлек булып бөтерелә иде. Мулла тәкбир әйтә-әйтә ут эченә озатмаган булса, Шәйхәттәр фронтларда озак югалып йөрмәгән булса, кем белсен... Колчак килә дигәч, авылдан чыгып качты. Күрше урыс авылының Чтапан карт базарга печән алып бара икән, рәхмәт төшсен, чанадагы печән астына кереп посарга рөхсәт итте. Шул килеш кызыллар ягына фиуть... Гөлҗиһан да ул әйләнеп кайтканчы фиуть. Ашыкты шул, ашыкты... Тургай күпме яши икән?.. Колхоз башлангач, ике ат җитәкләп колхозга барып керде. Мөхип ул вакытта юл тузанында ыштансыз уйнап йөри иде әле. Хәзер бостон кия, йортның менә дигәнен торгызды...

Кешеләр капка баганасына сөялгән Шәйхәттәргә сәлам биреп узалар. "Вәгаләйкем" дип кала бабагыз авыз эченнән генә... Кая ашыгып баралар соң бу күрәк күтәргән кешеләр? Булды, ай, булды... Мулла тәкбир әйтеп сугышка озатмаган булса... Ашыкты шул, ашыкты... Вәгаләйкем,—дип кала бабагыз,—Вәгаләйкем! Кая кузгалдылар көрәкләр күтәреп?

Мөхип тарантаска утырып, авылдан чыгып бара. Дәшми генә узармы, дәшәрме?

—Шәйхәттәр бабай, замандашың Гөлҗиһан әби дөнья куйды бит, кабер казышырга бармыйсыңмы?

Тарантас чабып узды... Әллә капка баганасы кинәт бик каты үсеп китте!? Шәйхәттәр бабагыз идән себеркесе хәтле генә булып күренә... Мөхипкә ул бер җавап та кайтармады... Тарантастан соң урамда тузан болыты эленеп калган иде. Кара болыт бик озак таралмый торды. Бабагызның күзләре урамнан узучыларны таный алмый...

Менә ул кыймылдады да багана янынннан кузгалды.—Вәгаләйкем,—диде ул сәлам бирүчеләргә каршы... Аяклары әйбәт кенә атлый әле. Көрәк күтәреп баручыларга ул да иярде...

—Ашыкты... Тагын ашыкты...—дип пышылдый иде аның иреннәре...

*1966, № 11*

*Журналыбыз турында*

## Әдип Маликов:

***1945 ел, сентябрь башы. Бөек Тын океан киңлекләрендә тагын бер сугыш учагының яңа гына сүндерелгән чагы. Безнең Сахалин дивизиясе Тоэхарэ (хәзерге Южно-Сахалинск) шәһәренә килеп керде. Урман, тау араларында әле атыш тынмаган. Анда-санда качып йөргән самурай группаларын коралсызландырып, соңгы разведкадан кайтып кергән бер көндә, кулыма гранат сыман озынча төргәк тапшырдылар. Мин аны сүтәргә ашыкмадым, башта печатенә, кире адресына күз төшердем: "Казан". Күңелемнән бер уй йөгереп узды: әллә басылды микән?***

***Чик буе землянкасында, окопта язылган күләмле беренче шигъри әсәрем — "Атаудагы хисләр" поэмасын шул елның маенда мин Казанга җибәргән идем. Бер бит чамасы сәлам хаты да яздым. Ә поэманың башында — түбәндәге юллар:***

*Бир урныңны*
*ерак атаудагы*
*Солдат хисләренә, Казаным!*

***Кат-кат төрелгән ул "гранат"ны мин, дөресен әйтим, дулкынланудан калтырана-калтырана гына ачтым. Эченнән "Совет әдәбияты" журналы килеп чыкты. Редакторы — Газиз Иделле, диелгән. Журнал "2 нче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хат" белән ачылган. Хат астына генераллар, бик күп офицерлар, татар сугышчылары, шул исәптән, фронтовик-шагыйрь Шәрәф Мөдәррис, фронтовик-язучы Гамир Насрый кул куйганнар. Повестьтан өзек, фронтовик язучыларның хикәяләре, шигырьләре арасында минем беренче поэмам да бар иде. Хәтта тыгып җибәргән хатымны да басып чыгарганнар. Менә бит, шушы кадерле төргәк, төргәк эчендәге бердәнбер калын журналыбыз Сихотэ-Алин таулары һәм диңгезләр аша, сугыш юллары буйлап, ун мең чакрым ераклыктагы атауга үзенең яшь авторын эзләп килгән! Мин үз гомеремдә, шул елларны истә тотканда, ике зур шатлык кичергәнмен икән: берсе — сугыштан исән чыгу, икенчесе—"Совет әдәбияты" журналының 1945 ел, 7 санын кулыма алу шатлыгы!***

*1972*

*Елмаеп-көлеп кенә...*

## Фәнияр[1]

## ЭПИГРАММАЛАР

*Гөлшат Зәйнашевага*

*Сандугачлар сайраса да*
*Җырларын язып алам.*
*Бәрәңге бакчасыннан да*
*Мин җырлар казып алам.*

*Мөдәррис Әгъләмовка*

*Эшлә диләр, эшлә диләр,*
*Мине эшкә димлиләр.*
*Эшләп чалбар туздырамы*
*Минем кебек гениләр.*

*1975, № 11*

## Зыя Мансур

* * *

*Ни күтәрелми,*
*Ни төшми томан.*
*Юк, томан түгел,*
*Мостафа Ногман.*

*1955, №11*

[1] Фәнияр—Фәнис Яруллин тәхәллүсе (псевдонимы).

**Nadir Dəwlət**

# «KAZAN UTLARI»NIŊ TATAR MƏDƏNİYƏTENƏ KERTKƏN ƟLEŞE[1]

*«Kazan Utları»nıŋ* (monnan soŋ KU) menençe sanı çığa dip Razil Əfənde Vəliev xəbər itkəç həm bu turıda ber-ike yul yazuımnı sorağaç, ütkən belən bügen arasındağı vaqiğələr fil'm tasmasında yazılğan sıman minem xıyal ekranımda kürsətelə başladılar. Çɵnki KU belən bəyle tɵrle xatirələr, kiçə bulğan kebek, küz aldıma kilep tɵştelər. Dɵnyalar "timer pərdə" belən ikegə bülengən 1960–1970 yıllarda bezneŋ kebek SSSR belən bəylənеşe bulmağan yıraq diasporada—çit illərdə yəşəwçe tatarlarğa ildən, il yaqlarınnan ni də kilsə bik tansıq ide. Ul çorda yəş bulğan bezlər ɵçen ɵylərdə ɵyrənelgən tatarçadan, yattan ɵyrənelgən "Tuğan tel" belən berniçə xalıq cırınan başqa ədəbi çığanaq yuq ide disəm yalğış bulmas. Ğomümən, 1900 belən 1950-nçe yıllar arasında Yıraq Kɵnçığışta yəşəgən tatar-başqortlar üz kɵçlərе belən məktəp-məsçetlər saldılar, kitap, jurnal həm gazetalar basıp çığardılar. Şulay itep telne, dinne həm ğoref-ğadətlərne saqlap qaldılar. Əmma ikençe dɵnya suğışınnan soŋ AQŞ, Tɵrkiə, Kanada, Avstraliə kebek illərgə küçərgə məcbur bulğannar, yəki Japoniə belən Germaniə kebek illərdə qalğannar ɵçen bigrək tə başta ni oyışmalar tɵzi alırlıq maddi kɵç, ni də şartlar yuk ide.

1950-nçe yıl urtalarında şuşı Jıraq Kɵnçığışnıŋ Mançjuriə, Qıtay, Korea həm Japoniə kebek illərennən ikençe mɵhacirlekkə çığıp Tɵrkiəgə küçep kilgənnər İstanbul, Ankara həm İzmir kebek zur şəhərlərgə taraldılar. Tɵreklər belən ber ük İslam dinenən həm sɵnni məzhəbennən bulu səbəple, dini ixtiaclarnı qaplaw kirəkmi ide inde. Məsçet oyıştıru eşenə kereşməgəç, milli-mədəni eşlərne oyıştıru da bik kirək isəplənmədе. Şulay da, 1960-nçı yıllar başı belən urtalarında Yıraq Kɵnçığıştan küçkən, ata-anaları cəmğiət tormışı traditsiəsenə künekkənnər dini bulmasa da, mədəni ɵlkədə uqmaşırğa, oyışırğa buldılar. Ə 1890-nçı yıllarda Russiədən küçep kilgənnər awıl keşelərе bulğanlıqtan, Tɵrkiədə də awıllarğa urnaştırılalar. Şul səbəple də, alarda mədəni ber xərəkət bik kürelmədе.

Yıraq Kɵnçığıştan küçkənnər 1963-nçe yılda İstanbulda "Tuqay Yəşlər Tügərəge" isemle ber oyışma tɵzilər, şuşı oyışmanıŋ 1965 (mart) belən 1968 (noyəber) tarixları arasında 24 (37?) san *Tuqay Bülteni* dip atalğan waq küləmdə taş basma nəşriatları dɵnya kürə. 1969-nçı yılda "Tuqay Yəşlər Tügərəge" hər yəştəge Tatarlarnı da əğzalıqqa qabul itü maqsatınnan çığıp, isemen "Kazan Tɵreklərе Mədəniət həm Yərdəmləşü Oyışması"na almaştıra. 1970-nçe yılda isə Tatar bayı Əxmət Vəli Məngər (*Əxmət Vəli Məngər-Xatirələr həm istələklər, Kazan: Ğasırlar Awazı Nəşriatı, 1977)* oyışmağa maddi yərdəm kürsətə başlıy.

Menə min 1960-nçı yıllarnıŋ azaqlarında şuşı oyışma eşlərе arqılı Vəli abzi belən bəğlanışqa kerə başlağaç, anıŋ ɵyendə berençe mərtəbə *«Kazan Utları»* jurnalın kürdem. Tabiği, bez, yıraq diasporada yəşəgən tatarlar ɵçen kiril xərefləre belən yazılğan ber jurnalnı uqu mɵmkin tügel ide. Bigrək tə yəş buın rusça da uqımağanlıqtan bu xərefləme tanıy almıy ide. Yari, min universitetta tarix kafedrasında uqığanda rusça tel kursına yəri başlağanlıqtan kirilitsanı da ɵyrəngən idem. Əmma başta kiril xəreflərе belən yazılğan tatarçağa künegü bik ciŋel bulmadı. Urısça belgənnərneŋ də tatarça uqırğa künekməgənnərеn, uquda intekkənnərеn, yəki bɵtenləy baş tartqannarın kürep şaqqatqan idem. Tatar bulıp tuwunıŋ qıyınlıqların yəşəgən sayen, ə üz mədəniətе, tarixı belən qızıqsınunıŋ isə, keşegə ɵstəmə cəza buluwın tikşerenülərgə kereşkən sayın yaxşıraq aŋlıysıŋ ikən. Tatar ul iŋ kimendə dürt əlifbanı belergə tiyeş (Ğərəp, Yanəlif, Kirilitsa həm bugenge Latin). Monda Tɵrkiə, Finləndiə yəki AQŞtağı tatarlarnıŋ üzlərеnə kürə qullanğan latin xəreflərеnə tuqtap ta tormıym. Yari, minem tüzemlelegem kɵçle bulğan ki, menə şulay itep Vəli abzinıŋ Almaniə aşa aldırtqan KU jurnalların aqtara, üzemə kürə qızıqlı tapqan məqələlərеn uqıy başladım.

---

[1] Мәкалә, автор язганча, латин алфавитында бирелә.

Bügen üz şəxsi kitapxanəmə qarasam, mindəge KU-nın iñ iske nəsxəsenen 1968-nçe yıldağı 8-nçe (august) sanı buluwın kürəm. Dimək, bez KU belən qırıq yılğa yaqın tanış ikən. Ə 1986dan bugenge kengə xətle, yəğni soñğı 20 yılnıñ barlıq sannarı da mində cıyılğan. Monı üzenə kürə şuşı jurnalğa, dəresrəge tatar telenə, ədəbiatına məxəbbət bilgese, yəki ber çir-xastalıq dip tə bəyələrgə məmkin. Çənki cıyılğan jurnal, kitaplarnı əydə totıp bulmıy, yarar, miña universitetta maxsus ber bülmə birdelər. Ləkin monnan ayrılıp çıqqaç şuşı kitaplar belən ni eşlərgə belməsəm də, əle haman kitap, jurnal ciyunı dəwam itəm. Bu inde aqıl eşe tügel, tereklər əytmeşli, "iyələşkən qotırğannan da yamanraq" ikən. Ləkin bu çir bulmasa, tatarlar turında küp nərsəne də yazalmağan bulır idem.

KU bik az sanda çit illərgə çıqsa da, üzenə kürə ilham birü rolen də ütəde. Bigrək tə min üzemnen KUnan küp nərsələr əyrənüwemne əytə alam. Misal əçen, Alfred Xalikov-Ravil Fəxretdinovlarnıñ "Tatar xalqı turında zur fənni xezmət" (august 1968, b. 147-154) isemle məqələsennən Məskəwdə "Nauka" nəşriatı tarafınnan *Tatarı Srednego Povolj'ya i Priural'ya* isemle ber əsərnen dənya kürgənen əyrənep şuşı kitapnı aldırtqan həm üz tarixıbız turında baytaq nərsələr əyrəngən idek. KU *Tuqay Bultene* belən 1970-nçe yılnıñ azağında çığa başlağan *Kazan* jurnalınıñ tışlığına da ilham birgən ide. Hər ike jurnalnıñ tışlığına bez də KU kebek Səyembikə manarasınıñ surəten quyğan idek. Tatar xalqınıñ tarixi simvollarınıñ bik az sanda buluwın iskə kitersək, Səyembikə manarası nindi genə rejimnarda yəşəməsennər, tatarlarnı berləştergən ber simvolğa əwerelgən. Dəres, bu simvol Səyembikənen açı yazmışın çağıldıra həm hərdaim keşedə ruxi təşenkelek tərbiyəli. Ə bit hər xalıqqa tarixı belən gorırlanırlıq, maqtanırlıq, yəş buwınnarda dərt uyatırlıq, quət birerlek simvollər kirək (minemçə, Aq Bars, Qol Şərif məsçete kebek yañaları bar).

KU-nıñ 1970, 1980-nçe yıllardağı sannarına qarağanda, sostrealizm cimeşləre, sotsializm,kommunizm qaharmannarına mədhiyələr, maqtaw süzləre belən suğarılğan yəki alarnıñ əstenlek həm batırlıqların üz teması itkən baytaq şiğer, povest', əkiyət həm başqa ədəbi ürnəklərne bik yış oçrata idek. Minem əçen bolar xiç tə qızıq tügel ide. Bolarnıñ məcburiət şartlarında yazılğanın şuşı yazmalarnıñ isemnərennən ük añlarğa bula ide. İnde yazuçı, şağir həm ədiplər niçek bulsa da yəşəp qalırğa, tormışların alıp barırğa tiyeşlər bit. Totalitar rejimnarda moñarğa şaqqatırğa kirəkmi. Bugen Kuba xalqı fəqirlektən inteksə də ləm-mim ber süz də əytəlmim, ə meñləgən-unmeñləgən kubalı ülemne də küz aldına alıp dingez yulı aşa AQŞ-qa sıyınırğa tırışa. Ə tege yaqtan liderlarınıñ məydannarda yasağan çığışlarına meñləgən keşe cıyıla. Üzenə kürə ber paradoks, ləkin nişliseñ. Bəlkem KU-da çıqqan mədhiyələrneñ qayberlərenen ədəbi dərəcəse də yuğarıdır. Monı min bəyəli almıym. İnde anı tənqitçelər bəyələr. Mine isə bigrək tə xatirələr, tarix turında, borınğı ədəbiatıbıznıñ, revolutsiədən elekke çorlar turında məğlümət birgən məqələlər qızıqsındıra ide. Qızğanıç bolar bik az bula ide. Şularğa qarap asılda ildəge səyəsi hawanı da isnərgə məmkin ide. Misalğa 1969-nçı yılnıñ unınçı sanında "Dərdmənd" (San 10, 1969, b. 177) turında anonim ber məqələnen çığuına inde burjuaz şağirebez alqana başladı, yəki şul uq sanda Yəxya Abdullinnıñ "Tatar məğrifətçelegenen üzençəlege" isemle məqələse (san 10, 1969, b.158-168) belən, Əbrar Kərimullinnıñ "Tormışqa aşmağan proekt (Tatarça gazeta-jurnallar çığaru əçen kərəş səxifələrennən)" isemle məqələsenən (san 7, 1970, b. 147-159) isə revolutsiədən elekke zialılarıbıznıñ cəditçelek xərəkəten əyrənergə irek birelə başlandı, digən bəyə birgən idem. Şiksez, bu az sanlı məqələlərne yəki terle əkiyətlər, xatirələr arasınnan yul aralarına sibelgən çınbarlıqlarnı küzətep, tatarnıñ ütkəne turında məğlümət cıyu xiç tə cinel bulmadı. Ləkin niçek kenə bulmasın, ildən kilgən nəşriatnıñ üzenə kürə ber sixere, qızığı, üzenə kürə xuşise bar ide. KU aşa əyrəngən kitaplarğa ireşü də ber maçara sıman tırışçanlıq taləp itə ide. Hərwaqıtta da alarğa ireşep bulmıy ide. Münxendəge rusça kitaplar kitertə torğan kitap səwdəse belən şəğelləngən "Kubon und Sagner" isemle maxsus kibetnen kiştələren berəm-berəm aqtarıp eşkə yaraqlı tatarça yaki rusça kitap taba almasmın mı dip niçə mərtəbələr ozaq səğətlər waqıt uzdırğanım istə. Azçılıq tellərdəge kitaplar, bigrək tə aftonom respublikalarda basılğan kitaplarnıñ katalogları bik az yəki hiç təzelməgənlektən, şulay kiştələrenə küz salırğa turı kilə ide. Çənki məğlümətkə susağan minem kebeklərnen susızlığın beterünen başqa yullarlı yuq dərəcədə ide.

KU minem kebeklərgə məğlümət, informatsiə birü belən berrəttən, tatar telenen soñğı 40-50 yılda nindi üzgərgən, nindi bayığan buluwın da əyrətte. Minem kebek tatar məktəbendə uqımağan, əydə əyrəngən xətle telgə, qayber inqilaptan elekke Gayaz İsxaqi, Tuqay kebek ədip-şağirlərnen ədəbi əsərləren genə uqıp telne şomartırğa tırışqannarğa KU ayıruça məğəmllim wazıfası da kürde. Şulay da yaña üzləşterelgən qayber süzlər yəki

terminologiələr belən tulısınça kileşep betə almawımnı da əytergə tiyeşmen. Rusçadan tərcemə itelgən məqələlərdəge cөmlələr yəki turıdan-turı rusçadan süzgə-süz tərcemə itelgən "Bəyrəm belən, Qış Babay h.b." mine hərdaim şaqqatırdı. Şulay da, KUda basılıp çıqqan əsərlərgə qarap, tatar telenen ni xətle tərəqqi itüenə soqlanam, üzemnen bu dərəcəgə hiçber waqıtta ireşə almayaçağımnı anlap künelsezlənə idem. Əmma yıllar ütep yullar açılıp tatarlar belən küreşə, alar belən ğəpləşə başlağaç, şuşı künelsezlek xalətennən qotıldım. Nigə disəgez, KU-ndağı telne qullana alğannarnın sanının az buluwın, tatarlarnın küpçelegenen tuğan telne belməwen yəki az belüen, xətta ike-өç süzdə ber rusça qatnaştırıp söyləwen, tatarça söyləgəndə sizmi qalıp ta rusçağa küçüwen, xətta tatar tele belən cawaplı urınnarnı da biləgənnərnen "mina tatarça nı, rusça nı, barıber" dip əytüləren işetep, ğөmumən şəhərlərdə yəşəwçe tabib, injener kebek yuğarı belemlelərnen isə tatarça belən bөtenləy qızıqsınmawların kürep, өstəwenə "bik yaxşı tatarça söylisez" digən maqtaw süzləren işetep üzemnen yartı-yortı tatarçam belən xətta ğorurlana da başladım. Ləkin beləm ki, KU-nda qullanılğan ədəbi tel belən yazudan min bik yıraq toram. Şunın өçen KU bugenge kөndə də minem ostazım bulıp qala birə.

KU-nın tatar millətenen ütkənendə həm bugenendə uynağan role bəlkem də şuşı funksiəse kimi barğan şuşı telne saqlap qaluğa, şuşı tel belən icat itkənnərgə ber tayanıç buluğa өleş kertüe buldı. Şulay da, şiksez, ütkəndə tөrle çikləwlər, senzuralar arqılı eşen cinel genə alıp baralmadı. Bolarğa ürnək itep 1982-nçe yılda KU-nın tirajının kinəttən təşüwen kürsətergə bula. 1981-nçe yılnın 12-nçe sanı 102000 tirajda çıqsa, ber aydan son, yəğni 1982-nçenen 1-nçe sanının tirajı 65000-gə təşte. Başqa süzlər belən əytkəndə, 40 protsent tirajın yuğalttı. Ber ük waqıtta bəyəse də 50 tiennən 90-ga kütərelde. Dөres, bu xəl tik KU-nın ğına başına kilməde. *Azat Xatın, Sovet Məktəbe, Çayan, Yalqın, Tatarstan Kommunistı*—həmməsennen tirajları təşerelde. Ləkin xiçbere şul xətle yuğarı protsentta bulmadı. Tatar basması ber kürsətmə belən 135 men tiraj yuğalttı. Əmma bu turıda ni ber məqələ yazıla aldı, ni ber protest buldı (Nadir Devlet, A. Specimen of Russification: The Kazan Turks (Tatars), *Central Asian Survey*, II, no. 3 [1983], b. 79-88).

KU ul çorda, yəğni 1970-nçe yıllarda, 6-6,5 million tatarğa birelgən, çikləngən mədəni xoquqlar səbəple, basıla almağan əsərlərne də basu eşen üz өstenə alğan ide. Tatar Yazuçılar Berlegenen 8 belən 9-nçı Qorıltayları arasında (1974 belən 1979) KU üz bitlərendə 11 roman, 46 povest' həm 11 poema basıp çığarırğa məcbür buldı. Bu isə 700 tirəsendəge yəş yazuçı belən şağirne qənəğətlənderüdən bik yıraq ide (şunda uq). Ləkin tege yaqtan dəwlət tarafınnan birelgən supsidiələr bulmasa tatar ədəbiatının bu dərəcədə də üsərlek mөmkinlegenen bula almayaçağı da ber fakt. Xətta bugenge kөndə də Tatarstan xөküməte tiyeşle maddı yərdəmne kürsətməsə, bolay da kimi barğan tirajlar belən KU-nın üz-üzen finanslawı mөmkin bulmas ide.

KU belən bəyle xatirələremə tübəndəge yullarnı da өstəməsəm künelem tınıçlanmas. 1990-nçı yılnın mayında berençe mərtəbə Tatarstanğa kildem. Mina bik zur qunaqçıllıq kürsətelde. Qazan, Çallı, Alabuğa, Tübən Kamalarnı kürdem, tөrle oçraşularda qatnaştım. Tormışımnın bu borılış noqtasında alğan təsiratım turında da yazğannarımnı KU-nın basıp çığaruwı mində zur xatirə bulıp qaldı ( "Gərçə anda tumasam da..., san 1, 1991, b. 151-158). Şunın belən min berençe mərtəbə tatar matbuğatında da urın alğan buldım, şiksez, bu çınnan da zur ber şatlıq, onıtılmaslıq xatirə.

KU 80 yıldan artıq yəşı həm 1000-nçe sanı belən tatar ədəbiat tarixi өçen ber ensiklopediə dərəcəsenə də ireşte. Bigrək tə niçə yıllardan birle tatar ensiklopediəse çığarıla almawın istə totsaq, KU sannarı yaqın tarixıbıznın ədəbiatı өçen berdənber çığanaq dərəcəsendə. KU-nan tatar ədəbiatı macarasın, yazuçı, şağirlərgə ni bulğanın, telnen niçek üzgərgənen hb.nı kürergə mөmkin. Mona cannarı-tənnəre belən өleş kertkənnərne də şuşı unaydan qotlarğa kirək. Baş mөxərrir Ravil Fəyzullinğa, redkollegiə əğzalarına KU-ın bugenge şartlarda, yəğni ədəbiatqa, dөresrəge, uquğa qızıqsınunın bik kimegən şartlarında, anı yəşətep qalu өçen alıp barğan kərəşləre, kürsətkən fidəkərleklərə, tüzemleleklərə өçen rəxmət əytəse genə qala. Yuğisə, alar da dөnyanın imanına əwerelgən aqça artınnan ğına yөgersələr, mondıy izge eşlər başqarıla almas. Menə mondıy şəxeslər arqılı tel də, ədəbiat ta, xalıq ta yəşəp qala.

**İstanbul, Ginwar 2006**

*Журналыбыз турында*

## Нажар Нәжми:

***—"Казан утлары" журналы "Идел" чыкканга кадәр татарча язылган матур әдәбиятны чагылдырган, аның яңалыкларын күрсәткән, бик тапталган сүз белән әйткәндә, аның бердәнбер көзгесе иде. Бездән, Башкортостаннан торып карагаңда аны татар әдәбиятының илчесе, дип тә атарга мөмкин. "Казан утлары"н Башкортостанда укучылар саны (заманында рәсми тыюлар аркасында журналны алдыручылар саны бик нык кимегән булса да) хәзер ел саен арта бара. Бу очракта саннарга мөрәҗәгать итми мөмкин түгелдер. Мәсәлән, журнал бездә, Башкортостанда, 1991 елда 7884 данә таралган булса (бу мәгълүмат журналда чыккан иде инде), 1992 елда аның саны 8901 гә җитте, ә киләсе елларда аның арта барачагы көн кебек ачык. Ни өчен шулай? Нинди сәбәп? Беренчедән, әлбәттә, журналда басылган әсәрләрнең сыйфаты сәбәпле булса, икенче сәбәп— халык күңеленең, милли тойгының нык уяна башлануы, милли зәвыкның үсә баруы. Бу үсештә турыдан-туры журналга кагылмаса да, Башкортостандагы Татар иҗтимагый үзәгенең һәм "Кызыл таң" газетасының эшчәнлекләре эзсез түгел, дип әйтер идем.***

***Шушы уңай белән, кызык өчен генә булса да, татар әдәбиятына байтак язучылар биргән районнарыбызда журналның ничек таралуын әйтеп китмәкчемен. Мәсәлән, Дүртөйле районында 1992 елда 440 данә (1991 елда 385), Илеш районында 500 данә (1991 елда 458), Кушнаренко районында 263 данә (1991 елда 232), Яңавыл районында 188 данә (1991 елда 239). Яңавыл татар әдәбиятына Нил һәм Илдар Юзеевларны биргән район, әмма быел аларның якташлары "саранланганнар" шикелле. Ә менә Бүздәк районы барсыннан да уздырып җибәргән — анда журнал 529 данә таралган. Шунысы кызык, узган елда бер данә дә алдырмаган Архангель районы быел килеп ун данә журнал алдыра.***

***Миңа килгәндә, "Казан утлары" журналын, "Агыйдел" журналы шикелле үк, туган журналым итеп тоям. "Казан утлары"нда кайчан басыла башлаганымны хәтерләмим, әмма мәрхүм, зур шагыйрь Нури Арсланның (ул вакытта журналның шигърият бүлеген алып бара иде) "Татар теле" шигырен соратып алганлыгы истән чыкмый. Уфага телефон аша шалтыратып, минем Мәскәү янындагы иҗат йортында икәнлегемне белеп, шунда язуы онытырлык түгел. Шуннан соң ул вакыты-вакыты белән шигырьләр җибәрүне сорап, хатлар язды. Мондый сыйфат һәр кешедә дә булмый һәм мондый мөнәсәбәт һәрбер авторга тәтеми.***

***Нури Арслан журналдан киткәч, шигырьләр җибәрүне сорап хат язучылар булмаса да (бәлки соңыннан үз авторлары итеп тә исәпләгәннәрдер), шигырьләремне журналга тәкъдим итә бардым, шуларның берсе дә кире кагылмады.***

***"Казан утлары" журналы "Казан" дип кенә, утсыз гына аталган хәлдә дә аның уты, җылысы, яктылыгы ерак-еракларга барып җитәр иде. "Казан утлары" чынчыннан милли ут, милли аһәң, милли горурлык!***

*Уфа.*
*1992, № 5*



## Нажар Нәҗми

# *ТАТАР ТЕЛЕ*

*Туган җирең Идел буе,*
*Һәр телнең бар туган иле.*
*Туган җирең кебек назлы,*
*Җырдай моңлы татар теле.*

*Ак алъяпкыч бәйләсәләр,*
*Өзелеп тора кызлар биле.*
*Кызлар кебек шат чырайлы,*
*Ачык йөзле татар теле.*

*Халкың кебек уңган да син,*
*Хезмәттә син көне-төне.*
*Ир-егетләреңдәй дәртле,*
*Гайрәтле син, татар теле.*

*Фәннән сине аерса да,*
*Гасырларның афәт җиле.*
*Аксакалларыңдай олпат,*
*Акыллы син, татар теле.*

*Ассалар да, киссәләр дә,*
*Үлмәдең син, калдың тере.*
*Чукындырган чагында да*
*Чукынмадың, татар теле.*

*Яндың да син, туңдың да син*
*Нишләтмәде язмыш сине.*
*Дөньяда күп нәрсә күрдең,*
*Әй мөкатдәс Тукай теле.*

*Төрмәләргә дә яптылар*
*Җәлил белән бергә сине.*
*Төрмәләрдә дә килмешәк*
*Булмадың син, татар теле.*

*Зинданнарны ярып чыктың,*
*Ялкынланып чыктың кире,*
*Хәтта фашист тегермәне*
*Тарта алмады анда сине,*
*Әй син, батыр татар теле.*

*Кабатланмас үткәннәрең —*
*Гасырларның яман чире.*
*Кабатлар сине гасырлар,*
*Татар теле, дуслык теле.*

*1966*

*1968, № 4*

**Шушы бер шигыре өчен Нажар Нәҗмигә 1994 елда ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе бирелде.**

* * *

“Мөхәммәт Мәһдиев—әдәбиятыбыз мәйданында һич тә көтмәгәндә күренгән әдипләрдән. Беренче китабы басылып чыкканда аңа 39 яшь иде.

—Мөхәммәт Сөнгатович! Үзегезнең язучы икәнегезне кайчан белдегез? Әдәбиятка беренче адым ничек ясалды?

—Рафаэль Мостафин белән Гаграда бергә ял итәргә туры килде. Көймәдә йөргәндә, пляжда мин, гадәтемчә, төрле кызык әйберләр сөйли идем. Ул “Нигә боларны язмыйсың?” дигәч, кыска хикәяләр язып карадым. Язам да, Рафаэльгә укыйм. Ул “бусы бара”, “бусы бармый” дип мөһер салып тора... Бу кыска хикәяләр “Казан утлары”нда, соңрак “Атадан бала яшь кала” дигән исем белән аерым китап булып басылды”.

*Рәфикъ Юныс*
*«Татарстан яшьләре», 1975 ел, 1 ноябрь.*



# Мөхәммәт Мәһдиев

ЭТЮДЛАР

## Кеше күңеле

Мәгъфүрә апа бик яшьли тол калды. Балалары да юк иде, гомере ялгызлыкта үтте. Ул мәктәптә каравылчы булып эшли иде. Йорт-җире, мал-туары да булмаганлыктан, үзенең бөтен рухи һәм матди дөньясын мәктәпкә бәйләде. Мәктәп янындагы кечкенә өйдә үзенә бер почмак ясады, чаршау корды, стенасына конфет кәгазьләре ябыштырды. Стена сәгатенең герен такта чәй укасына төреп асты. Аны вакытында су җылытмагансың дип тә, мәктәп бакчасына тавыклар кергән дип тә ачуландылар. Ә директор һәр алла бирмеш көнне иртән бер, кичен бер мәртәбә орышып килде. Һәр орышуының ахырында ул: “Эшлисең килсә эшлә, эшлисең килми икән, дүрт ягың кыйбла, как хоти”, дип тәмамлый иде.

Ләкин Мәгъфүрә апа үз гомерендә бер тапкыр да күз яшен күрсәтмәде. Аны ачуланучы күп иде, әмма дәшмичә генә мәктәп хуҗалыгын алып баручы ул үзе генә булды. Аның турында: “Мәгъфүрә җылый белми ул, аның ялгызлыктан күз яшьләре кипкән”, дигән сүз дә йөри иде.

Гомерләр узды, көз айларының берендә мәктәп коллективы тантаналы рәвештә Мәгъфүрә апаны пенсиягә озатырга җыена башлады. Бер кичне мәктәпнең коридоры өлкән класс укучылары, укытучылары, мәктәп хезмәткәрләре белән шыгрым тулды. Местком председателе кечкенә өйгә кереп Мәгъфүрә апаны халык җыелган коридорга култыклап алып чыкты. Җыелган халык Мәгъфүрә апаны басып каршы алды. Баянда марш уйнап җибәрделәр. Барабан кагып, быргы кычкыртып тордылар. Мәгъфүрә апаны кызыл җәйгән өстәл артына утырттылар.

Мәктәп директоры сүз алды. Ул көр тавыш белән укып җибәрде:

“Мәктәп буенча приказ. 135 нче номерлы. Параграф беренче. Мәктәптә утыз ел буенча каравылчы хезмәтен намус белән башкарганы өчен Мәгъфүрә Зиятдиновага рәхмәт белдерәм.

Параграф икенче. Ялгызлыгына карамастан утыз ел буе тырыш хезмәт итүен искә алып, каравылчы Зиятдинованы бер күлмәклек штапель белән бүләклим”.

Директор сүзне местком председателе Сибгатуллинга бирде.

—Иптәшләр,—диде Сибгатуллин, түшәмгә карап,—безнең кичәге утырышның карарын укыйм. “Протокол номер ундүрт, 19 сентябрь. Тыңланды: пенсионерка

Зиятдинованы яна квартирага күчерү турында. Карар кылынды: Зиятдинованың утыз ел буе намуслы хезмәтен искә алып, аны, 21 сентябрьдән дә соңга калдырмыйча, укытучылар өчен салынган квартираның Нәҗмиевләр белән тоташ ягына күчерергә. Карар бертавыштан кабул ителде".

Приказлар укыганда һәм бүләкләр тапшырганда берөзлексез баян уйнап, быргы кычкыртып, кул чабып тордылар.

Ниһаять, Мәгъфүрә апаның үзенә сүз бирделәр. Ул басты, ипләп кенә тамагын кырды, халыкка озак итеп карап торды да... кычкырып елап җибәрде.

Бу—тәбрикләүләргә каршы аның җавап сүзе иде.

## Галиябану

Бу көнне халык ай ярым көтте. Кемнең кайсы рольне, нәрсә киеп уйнаячагы, кайсы пәрдәдә нәрсә булачагы барысы да мәгълүм иде. Чөнки авыл халкы кечкенә клубта репетиция барганда ай ярым буе актив катнашты, киңәшләр бирештеләр, колхоз хисапчысы Фәсхине инде Исмәгыйль, укытучы Алсуны Галиябану дип кенә йөртәләр иде. Утыз йортлык авылда өй эченнән спектакльгә кешесе катнашмаганнар самовар, читек, камзул, себерке күтәреп килеп сәхнәне әзерләштеләр, клуб янындагы өйдә Галиябануны бөтен авыл хатыннары җыелып бизәндерде.

Спектакльгә ферма каравылчысы Гарифулла белән сукыр Минсафа карчыктан башка бөтен кеше килде. Мич артында, сәхнә буенда, тәрәзә төпләрендә балалар сырышкан, инә төртерлек тә урын юк иде.

Спектакль шома барды, суфлер тавышын уйнаучылардан берәрсе ишетми торса, залда утыручылар әйткәләп җибәрә тордылар. Тик соңгы пәрдәдә, Фәсхинең бер атна буе эш ташлап РТС мастерскоенда ясап яткан алтатары гына спектакльне бозды. Ягъни, Фәсхи шырпыны сызуга, алтатарның көпшәсенә төйгечләгән кәгазе чыгып китте. Моннан соң инде "шарт" итеп ату турында уйларга да ярамый иде, һәм көпшәдәге дары чыжылдап янып та бетте. Фәсхи бөтенләй өметсезлеккә бирелеп суфлерга пышылдады:

—Чукынып кына китсен, шартлатып булмады, нишлибез?

Халык, моны ишеткәч, тетрәнеп, тынсыз калды. Ләкин берничә секундтан арттагы рәттә тавыш куптардылар:

—Гыйлемханга йөгерергә кирәк!

—Гыйлемхан кайда, чык әле тиз бул!

—Аның өе ерак бит, Нурида да бар ул!

—Чыксын, чыксын, Гыйлемханны чакырыгыз!

Иң алгы рәттә, куян мамыклы шәл бөркәнгән хатынына сыенып, тальян гармунын тоткан аучы Гыйлемхан утыра иде. Эшнең төбен аңлап алгач, гармунын хатынына бирде дә артка таба кузгалды. Сәхнәдә Хәлил егыла алмый калган иде, шул хәлдә пәрдәне яптылар.

Сәхнәгә ирләр җыелды. Алтатарны әйләндерә-әйләндерә карадылар, Фәсхигә киңәшләр бирделәр. Берәүләр, Гыйлемхан озак торса, дары урынына шырпы күкерте генә салырга кирәк, диделәр. Аста утырган хатын-кызлар кечкенә балаларын җитәкләп клуб артына барып килделәр.

Бер янчык дары күтәреп Гыйлемхан килеп җиткәндә, клубта булган бөтен кешенең шырпыларын кырып алтатарны корып куйганнар иде инде. Пәрдә ачылганчы дип, ашыга-ашыга, дәррәү түбәнгә төшеп киттеләр. Ыгы-зыгы арасында кемдер Фәсхинең кабызырга тиешле шырпысын алган икән, пәрдә ачылуга:

—Фәсхеттин, мә шырпыңны,—дип сәхнәгә ыргытты. Фәсхи шырпыны сызды. Шартлау тавышына кечкенә балалар сискәнеп киттеләр, Хәлил дә сузылып барып төште. Кайсыдыр, халыкны тынычландырды:

—Үлмәде ул, үлмәде, ядрәсе юк аның!..

Спектакль беткәндә халык:

"Рәхмәт төшсен сезгә, артистлардан да яхшы уйнадыгыз",—дип таралды.

*1967, № 5*



Ләбибә Ихсанова

# ИҢ БӘХЕТЛЕ ЧАГЫМ КЕБЕК...

Моннан ун-унбиш еллар элек редакциягә барганда, еш кына, ательеда закройщик булып эшләгән танышымны очрата идем. Буш вакытларында урамда йөрергә ярата иде ул. Ашыкмыйча, җай гына атлап килә, ә күзе кешеләрнең өс-башында. Менә ул үзе теккән пальтоны танып ала: йөзенә матур һәм рәхәт бер елмаю чыга, кайчандыр үзенең клиенты булган кешегә хөрмәт белән баш иеп, исәнләшеп китә... Мин аның хәлен аңлыйм. Ул үз эшен бик ярата, кешеләрнең матур киенеп йөрүләрен күреп шатлана, үз һөнәре белән горурлана. Эш остасында гына була торган профессиональ горурлык анда. Шагыйрь әйткәндәй, "бер горурлык яна битләрдә!.."

Кайда да булса берәр җирдә кулына "Казан утлары" тоткан кешене очратсам, таныш өемнең өстәлендә шул журналны күрсәм, йә булмаса, аның турында сөйләшеп торуларын ишетсәм, мин дә шул танышым кебек шатлана идем. Без чыгарган журнал бит ул дип әйтәсем, йә аларның сүзләренә кушылып журналның хәлләре турында сөйлисем килә иде. Әле булса шул хиснең миндә беткәне юк.

Гомернең ун елдан артыгы шушы редакциядә эшләп узган, журналның йөзләгән санын чыгаруга кул тигән, көч кергән...

Журналның төгәл һәм тыныч эшләнүе өчен редакция бүлмәләрендә бик күп тынгысыз көннәр кичерергә туры килә иде безгә. Күз карасын талдырып, калын-калын кулъязмалар укудан башлана ул эш. Аннан соң редколлегия утырышларында кызып-кызып бәхәсләшүләр. Хәтердә әле, талантлы гына бер прозаикның яңа повестен "сүтәргә" туры килде. Әлбәттә, ул безгә рәхмәт әйтеп утырмады, утырышның ахырында үпкәләп үк чыгып китте. Аның каравы, тынычлангач, бераз суына төшкәч, әсәрен өр-яңадан эшләп килде. Кайчагында журналга кирәк материалның нинди санга керүе турында да кызып-кызып бәхәсләшә торган идек. Менә шуннан соң гына башлана инде ул типографиягә төшәсе санны эшләү.

Андый көннәрне үзем утырган кечкенә бүлмә штабка әйләнеп кала. Тимер-бетон стеналар һаваны начар үткәргәнгә, бүлмә ишеге төбенә кадәр ачык. Хәер, ул болай да ябылып тормас иде. Бүлекләрдә эшләүчеләр, корректорлар, машинисткалар минут саен кереп-чыгып торалар: бер материалны кыскартасы бар, икенчесенең исемен алыштырырга кирәк, бу сүзне язучы үзенчә язган, ә сүзлектә ул башкача алынган — хәл итәсе бар. Шул арада командировкага җыенучы берәр автор килеп керә. Аның белән сүзең бетми, телефон шалтырый — автор корректураларын укыган, төзәтүләр белән риза түгел... Ярата идем мин шундый тыгыз, тын алырга да вакыт булмаган көннәрне. Хәтта журнал басылырга төшеп киткәч, бушап калган тыныч көннәрдә бераз күңелсезрәк тә була башлый.

Безнең эштә тагын бер күңелле вакыт — журнал басылып бетәр алдыннан сигнальный экземпляр киләсе көннәр була. Менә техник редактор бер кочак журнал күтәреп килә. Аңар ияреп үк бүлмәгә башка иптәшләр кереп тула, кулдан тартып алгандай журналны алып бетерәләр, кайсы утырып, кайсы баскан көйгә, тиз-тиз актара башлыйлар. Ул сандагы һәр материал таныш югыйсә, бәхәсләшә-тартыша төзәтелгән, кат-кат укылган. Шулай да күрәсе килә, журнал булып төпләнгәч ничегрәк чыкты икән: материал кеше күзенә күренерлек итеп урнаштырылганмы, матур хәрефләр белән җыелганмы, буявы тигез төшкәнме... Бу минутларда безнең барыбызны да айлар буе тырышып эшләгән эшебезнең нәтиҗәсен яхшы итеп күрәсе килү тойгысы биләгән була — үз эшебез белән горурланасы килү, профессиональ горурлык тойгысы...

*1982*

# ЯШЕРЕН ВАСЫЯТЬ

"Урыс кышы", "урыс каены", "урыс чәе"... Кубада, Әфганстанда, Анголада урыс мәнфәгатьләре, шул мәнфәгатьләрне саклаучы совет танклары һәм ракеталары. Кайдан килә бу? Боларның чишмә башлары кемгә тоташкан?

Тарих китапларында һәрвакыт урыс халкының бөеклеге, күршеләренә аның дуслык һәм мәдәният кенә алып килүе хакында укыйсың. Казан ханлыгын да Иван патша үз дәүләтенә куша һәм "гаделлек" урнаштыра, янәсе. Петр патша Азов диңгезенә походлар ясап, Төркиянен "артык" биләмәләрен эләктерергә омтыла, анда эш барып чыкмагач, 21 ел буе Швеция белән сугышып, Балтыйк диңгезенә "тәрәзә ача". Аннары тагын көньякка юнәлә —Каспий диңгезе буена килеп, Иран белән "дуслыгын ныгыта", аның да бер "кыргый" өлешен үз "мәдәни" дәүләтенә кертеп, бәхетле итә. Диңгезләргә гашыйк "тәрәзә ачу" остасы ничек инде мәмләкәте чигендә ике уем ясау белән канәгатьләнсен? Яна диңгезләргә тәрәзә яки форточка ачар өчен аның оныклары ун мең чакрымдагы Камчаткага, хәтта аннан да ерактагы Аляскага да барып житәләр, юл уңаенда тагын дисгәләгән халыкларга ясак түләү бәхетен бүләк итәләр. Шуңа күрә мондый патшаларын урыс халкы "күренекле дәүләт эшлеклесе", "атаклы хәрби юлбашчы", "тиңдәшсез үзгәртеп коручы", "мәшһүр галим" дип мактап килә. Мәдәният алып килүе өчен бездән рәхмәт укуны көтә.

Әмма без генә түгел, барлык кыйтгаларның алдан бер өлешенә ия булган, тәрәзәне инде ундүрт диңгезгә "ачарга" өлгергән урыс халкы үзе дә бәхетсез бүген. Чөнки бәхетле булыр өчен җир киңлегеннән, диңгезләр күплегеннән бигрәк, матди муллык, рухи хөррият кирәгрәк. Соңгы казанышларга ирешү өчен исә диңгезләр һәм җирләр иркенлегенә ия булу һич тә мәҗбүри түгеллеген байтак алдынгы илләр, халыклар үсеше раслап килә. Моның өчен милләтләрнең әхлакый сәламәтлеге, сәләтен һәм көчен табигатьне саклауга, хезмәт житештерүчәнлеген күтәрүгә җигүе, мәдәни һәм фәнни кыйммәтләр иҗат итүгә юналтүе кирәк икән.

Русия-СССРның җире дә, суы да хисапсыз күп. Әмма бүген аның халкы ашарга ризык, кияргә кием, торырга торак, суларга саф һава житмәүдән интегә. Урманнары мәгънәсез әрәм-шәрәм ителә, кырлары-далалары уңдырышсыз тозлакка һәм чүлгә әверелдерелә, чишмә-инешләре генә түгел, диңгезләре дә йә киптерелә, йә терекләге үлгән шакшы сулыкка әйләндерелә. Халыкның тарихи үсеше исә аның юлбашчылары әхлагына, алар куйган максатларга һәм шул максатларга ирешү тырышлыкларына турыдан-туры бәйле. Юньле юлбашчылар халкының сыйфат ягыннан яхшыруына, аның югары казанышларга, житеш һәм бәхетле тормышка ирешүенә сәбәпче булса, икенчеләрнең милләтен ялгыш юлга кертеп җибәрүе бик мөмкин. Әйтик, игенче белән илбасар икесе ике башлангычка нигез сала: игенче тырышлыгы яңадан-яңа байлыкны барлыкка китерә, илбасар исә инде барлыкка китерелгән хәзинәне аның иясеннән генә тартып ала. Беренчесенең тырышлыгы кешелекнең алга атлавына гел куәт кенә өстәсә, икенчесенең кәсебе кинәю сәламәт үсешне буа, паразитик фәлсәфә һәм гамәлләрне арттыра, шуның белән талаучыларның харап булуына яки аларның баш күтәрүенә китерә. Моннан инде гомум кешелек кризисына да ерак калмый.

Халыклар җәллады Явыз Иван (1530—1584). Европа жандармы Беренче Александр (1777—1825), алар арасында күпер булган "тиңдәшсез үзгәртеп коручы" Беренче Петр (1672—1725). Болай тезеп караганда, Беренче Петр әлгәрегесе һәм соңгысы арасында — иң гөнаһсыз хаким, иң мәдәни һәм кешелекле зат. Әмма аның "Васыяте" белән танышканда, бигрәк тә шундагы "кәсеп итеп, сез... бөтен дөньяга ия булырсыз", дигән соңгы юлларны укыганда, СССР дигән илнең бүгенге фаҗигасен, әле кичә генә житәкчелектән киткән, ләкин тагын хакимлекне кулына эләктерергә ажгырып торган сәясәтчеләрнең сыек кына томан пәрдәсе белән капланган фикер сөрешендә, максатларында һәм гамәлләрендә тарихи нәфеснең, илбасарлык шаукымының, Беренче Петрның империячел ашкынулары дәвамын тоясың. Бу — СССРның азчылык милләтләренә генә түгел, урыс халкына да хәвефле, чөнки Беренче Петрның "кәсеп итү" төшенчәсе, "Васыять"тән күренгәнчә, миллионнарның күз яшен, кан дәрьясын агызуга кайтып кала, һичбер тартынусыз, үз ихтыяҗларын бүтәннәрне талау хисабына канәгатьләндерергә дәртләндерә. Ул инде менә ничә гасыр зур бер халыкның сәләтен, куәтен, тормыш эшчәнлеген, энергиясен башкаларның яшәү тирәлеген жимерүгә, матди байлыкларын талауга, яулап алуга юналдерде. Шушы басым һәм һөҗүмнәрдән саклану өчен, күршеләрен чамасыз күп чыгымнар ясарга, бихисап корбаннар бирергә этәрде, Евразиянең балансланган тыныч-тату яшәешен инде ничә гасыр тетрәтеп, фаҗигаләр упкынына этәрде. "Урыс кышы" бәйрәмнәрен Әфганстан уйсулыкларына, тропик Ангола

чулләренә китереп җиткерү — бүген Беренче Петр васыятен үтәү түгелдер, дип кем ышандыра ала?!

Беренче Петрның "Васыяте", ничек кенә яшерен сакланмасын, көндәш илләрнең тәхет ияләренә 1738 елда ук мәгълүм була, шул заманда ук Русия кысрыклавына каршы чаралар күрелә башлый. Дәверләр үзгәрде, хәзер инде кылыч түгел, атом бомбалары, ракеталар белән дә бүре законнарын гамәлгә кертү мөмкинлеге бик нык чикләнде. Әмма моңа карап, тарихи документларның әһәмияте кимеми. Русия империясе һәм СССР җитәкчеләренең (И. Сталинның 1945 елдан соң Төркиядән Босфор һәм Дарданел бугазларын бирүне таләп итүен генә искә төшерик!) халыкара сәясәтен, үткәндәге вакыйгаларны һәм бүгенге кайбер омтылышларны аңлауда бу "Васыять"нең роле әле дә зур. Шуңа күрә "TURK KULTURU" (Анкара) журналының 323 саныннан (1990 ел) алып тәрҗемә кылынган бу тарихи документ белән танышу укучыларыбызга шактый ук гыйбрәтле булыр, дип уйлыйм.

Чит илләрдә игътибар казанган (Akdes Nimet Kurat. Turkiye ve Rusya. Ankara, 1990. B. H. Peter the Great and the ottoman Empete. Oxtord, 1949) Беренче Петр "Васыяте" хакында әлегә тарихчы галимнәребезнең һичбер фикер әйткәннәре юк. Бәлки, шушы документның дөнья күрүе аларның да телен ачар, халкыбыз язмышына нинди дер кагылышы булган бу яки бүтән чыганаклар, хезмәтләр турында сүз алып барырга этәргеч бирер? Хакыйкать тирәнрәк һәм киңрәк ачылса, без үз-үзебезне һәм тирәлегебезне яхшырак танып белербез. Иртәгә дә яши алыр өчен безгә нәкъ менә шундый хәбәрдарлык кирәк.

**Тәүфикъ ӘЙДИ**

## Беренче Петрның 1725 елда язган "Васыятнамәсе"

Бөтен нәсел -нәсәбебез, бер-берсенә ялганып, киләчәктә Европа илләрендә хаким булачактыр, чөнки Европаның барлык дәүләт төзелеше искергән һәм тузган. Фәкать Урыс патшалыгы гына үсештә, без бу үсешкә акылыбыз белән ирештек. Киләчәк нәселемә бер "тәгълимат" шикелле юл күрсәтсен дип, мин "Васыятнамәм"не түбәндәге теләк рәвешендә яздым:

1. Урыс дәүләте аңлы рәвештә сугыш кубу шартларын даими әзерли һәм бу әзерләгән Русиянең алга китешенә сәбәп булсын өчен алып бара.

2. Сугыш вакытларында Европадан мөмкин кадәр хәрби юлбашчыларны, тыныч заманда исә гыйлем ияләрен Русиягә җәлеп итә.

3. Европа илләре арасында ызгыш-талаш чыгару, араларына ут салу һәм, бәрелеш башлангач, алардан берсе белән дуслыкта булу кирәк. Бигрәк тә немес халкы арасындагы болганыш һәм фетнәләрдә актив бер сәясәт тотарга. Чөнки алар безнең белән чиктәш—мәмләкәтебезгә орынып тора.

4. Польшада ыгы-зыгы чыгарырга, аннан хозурына килгәннәренә саранлык күрсәтүдән тыелып, ришвәт биреп, көчләрен таркатырга, дәүләт эшләренә зыян салырга, Мәскәүдән гаскәр китереп, анда урнаштырырга. Әгәр бүтән дәүләтләр безнең бу чарага каршы төшсәләр, "тавышлары тынсын" өчен, Польшаның бер өлешен аерып алып, аларга да бирергә. Эш тәмамланганнан соң, ул өлешне дә кире алырга, урыс патшалыгын көчәйтергә.

5. Швеция һәм Норвегия илләрен мөмкин кадәр бер таяныч төбәгенә әйләндерергә. Чөнки аларның идарәчеләре кулыбызда булса, Швеция һәм Норвегиянең Даниягә дошманлык орлыгы чәчүен тәэмин итү тагын да җиңеләячәк.

6. Русия аксөякләре Герман аксөякләреннән, хакимнәреннән, йогынтылы шәхесләреннән даими кыз алуны онытмасыннар. Чөнки аларның мондый кардәшлеге безгә һәрвакыт файда китерер.

7. Англия хөкүмәте белән берлектә булып, бәйләнешләрне ныгытыгыз. Чөнки сәүдәдә һәм дәүләт идарәсендә бу безгә зур файда бирер. Бөтен төзелеш өчен кирәкле барлык материалларны алардан алырга мөмкин. Бу бәйләнеш һәм корал, һәм корабчылык өчен гаять файдалы.

8. Русия дәүләтенең чиге — Европаның төньягында Балтыйк дингезенә, көньякта исә Кара дингезгә кадәр. Бу биләмәне саклау һәм Русия чиген киңәйтү — нәселемнең бурычыдыр.

9. Русия дәүләтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен, аның башкаласын Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган Истанбулга күчерү шарт. Кичекми һәм ялгышмый эш итеп, Истанбулның көнбатыш җирләренә ия булу кирәк. Шөбһәсез ки, Истанбулга

ия булган патша дөньяда илаһи патша булачак. Бу максатына ирешү өчен Төркия белән Иран арасына дошманлык орлыкларын даими чәчеп торырга, ызгыш һәм сугыш чыгарырга кирәк. Бу эш өчен сөнни һәм шигый мәзһәпләре арасындагы каршылыклар— ин хәлиткеч корал һәм җинелмәс гаскәрдер. Русиянен үтеп керүен Азиягә җәю өчен сөнни-шигый каршылыклары ин яхшы чара. Төркия белән Иран дәүләтләре арасындагы тотрыклы татулыкны шундый итеп бозу кирәк ки, алар бер-берсе белән һичберзаман анлаша алмасыннар, һәм Иран, һәм дә Төркиянен Европа халыклары белән бәйләныш ясавына мөмкинлек бирмәскә кирәк. Әгәр бу илләрнен мөселманнары күзләрен ачып, хокук-бурычларын анлап алса, ул безгә ин яман бәла булачактыр. Һәм Төркиянен, һәм дә Иранның дин эшлекләләрен кулда тоту, алар аша сөнни-шигый каршылыкларын көчәйтү кирәк. Ислам динен Азиядән ераклаштыру, христиан динен һәм мәдәниятен анда җисми бер рәвештә тарату һәм җәю зарурдыр.

## Яшерен тотылсын

Безнен галимнәребезнен бүгенгә кадәр дәүләт эшләренә катнашуы Русия мәмләкәтенен алга китешенә киртә булды. Мин үз сәләтемне һәм бәйсезлегемне файдаланып, аларны дәүләт эшләреннән ераклаштырдым. Руханиларнын дәүләт эшләренә тыкшынуларын туктаттым, хәзер алар сафка тезелгән гаскәриләр кебек, куллары һәм аяклары бәйле калды. Мин моны гаять бөек бер тәвәккәллек белән гамәлгә ашырдым. Руханиларны дәүләт вә милләт эшләреннән читләштереп, вәкаләтләрен бары чиркәүләрдә дини вазифа үтәү белән чикләдем.

Боларга өстәп бүтән төрле чаралар да куллану кирәк ки, Иран иле узган һәр көн саен тагын да акчасызрак һәм сәүдәсезрәк калсын. Кыскасы, Русия дәүләте Иранны даими артка калдырсын, бәйле хәлдә тотсын, аны теләгән вакытта кыенлыксыз гына үтерүгә кодрәтле булсын. Әмма Төркия дәүләтен юк итүдән элек Иранның җанын алуны кинәш итмим.

Грузия иле Кавказ сызыгынын, ягъни Иранның үзәк тамырыдыр. Әгәр Русиянен кодрәтле кулы ул тамырны барып киссә, мескен Иран йөрәгенен тереклек каны агып чыгачак һәм аны шундый хәлсезләндерәчәк ки, мен нәселе терелеп килсә дә, аны кире аякка бастыра алмаячак. Ул чакта Иран мәмләкәте Русия патшаларына дөя кеби тынлаучан булачактыр һәм Төркиядән сон яшәү ялкыны да сүнәчәктер.

Матди ихтыяҗлар даирәсе булган Төркия эшен бетергәннән сон, Иранны читенлексез юк итү, аның башын кисү мөмкиндер. Моның өчен сез, вакытны югалтмастан, Грузия һәм Кавказияне буйсындырып, Иранның хаким шәхесләрен үзегезгә бәйле вә тынлаучан итәчәксез. Аннан сон — Һиндстанга күз атарга. Ул мәмләкәт гаять бөек һәм кин бер сәүдә мәйданыдыр. Анда кул сузган тәкъдирдә, Һиндстаннан Англия кәсеп итен тапкан акча һәм керемнән дә күбрәк товарлар алыначактыр. Һиндстанның ачкычы—Төркиянен башкаласыдыр. Гизә алган кадәр кыргыз, Хива һәм Бохара сахралары тарафыннан юл сабу сезне максатка якынайтсын. Вакытны бушка әрәм итмәгез, әмма артык ашыгу һәм кабаланудан да сакланыгыз.

Австрия дәүләте белән тыштан дус булырга кирәк. Фәкать шундый бер чара күрү тиешле ки: Германия һәм Австрия әкренләп көчләрен җуйсыннар.

Төркияне Европадан аеру һәм бу гамәлдән Австриягә файда тәэмин итү хәерле. Бу эштә ике юл бар: берсе — Австрияне бүтән бер җирдә мәшгуль итү, икенчесе — Австриягә Төркия биләмәләреннән соныннан аны кире кайтарып алу ансат булырлык бер өлеш кисеп бирү.

10. Грекларга тыныч һәм дусларча мөгамәләдә булыгыз. Сугыш вакытында алар сезгә ярдәм итәр, чөнки греклар Төркиядән даими зыян күрделер.

11. Швеция, Норвегия, Төркия, Иран һәм Польшаны басып алганнан сон, Италия һәм Франция белән бердәмлек элемтәсе урнаштырыгыз. Әгәр алардан һичберсе дуслыгыбызны кабул итмәсә, ул чакта, форсаты чыккач, җирләрен басып алыгыз, дәүләтләрен юк итегез. Бу җирләрне кулга төшергәч, дөнья хакиме булырсыз.

12. Әгәр югарыда саналган илләрнен берәрсе сугышны кабул итмәсә, бу ике хөкүмәт (Италия һәм Франция) арасында ызгыш-талаш чыгару кирәк булыр. Бу суратта алардан берсе берзаман уртадан калкып чыгып харап булачак. Җинелгән илләрне талап, кәсеп итеп, сез исә бөтен Европада хакимлек корырсыз. Тора-бара бүтән дәүләтләрнен һәммәсен үз мәмләкәтегезгә кушып, бөтен дөньяга ия булырсыз.

*1992, № 1*

*Журналыбыз турында*

## Гамил Афзал:

***—Сугыш башланганда калын-калын дүрт кулъязма китабым бар иде инде. Сугыш елларында көненә 12 шәр сәгать эшләгәндә дә, конторадан чыгарып түккән кәгазьләрне, иске чертежларны җыеп, шулардан дәфтәр тегеп, шигырь яздым.***

***Сугыштан соңгы елларда миңа Г. Иделле, Ә. Камал язып җибәргән рецензияләр һәм "Совет әдәбияты"ннан килгән "каләмегез өметле генә күренә, ләкин..." дигән хатлар миндәр калынлыгы җыелды. Шунысы сөенечле, уңыш теләп, кайнар сәлам җибәрәләр иде.***

***Йөз шигырь язып берсе дә басылмаган чагында, рәнҗеп һәм усалланып, йөз дә беренче шигырьне язарга тотынырлык өмет һәм ныклык булмаса, шигырь язам дип йөрмә дә икән. Бер дәфтәр начар шигырь язу белән, әдәбиятның түренә кереп, аяк бөкләп утырырга тырышу кирәкми икән.***

***Унтугыз ел тырышканнан соң гына мин әдәбиятка килдем.***

***Башкортстанның Шәрип авылында каты авырып, "миннән булмас, ахрысы, инде үлсәң дә ярый" диебрәк шикләнә башлаганда, 1955 елның ноябрь аенда "Совет әдәбияты" берьюлы тугыз шигыремне бастырып чыгарды. Шуннан мин терелдем, аякка бастым, урамга чыктым. Журнал миңа киң юл бирде, нык канатлар бирде, биек трибуна бирде, тырышкан ташны яра икән дигән ышаныч бирде.***

*1972*



Гамил
Афзал

## ТӘНКЫЙТЬ СҮЗЕ

*Правлениедә җыелыш бара.*
*Парторг Харис сүз ала:*
*"Җәмәгатьләр, социалистик*
*Ярыш ачыйк, ди, үзара".*

*Трибунага кәгазь тоткан,*
*Чыга әби Бибиҗиһан:*
*"Иптәшләр, ди, кая монда*
*Минем картым Әхмәдулла?*

*Мин ярышам картым белән,*
*Эш методын, шартын беләм,*
*Ул да эшкә җитди карар..."*
*Һәм башкалар... һәм башкалар...*

*Бибиҗиһан эшчән кеше,*
*Сөеп эшли колхоз эшен,*
*Сүз җаеннан әйтсәк ярый:*
*Фермада ул бозау карый.*

*Аның карты Әхмәдулла —*
*Чытык йөзле озын колга —*
*Конюшнядә иртә-кичен*
*Зур начальник атлар өчен.*

*Әхмәдулла (әйтү кирәк)*
*Эчеп кайта сирәк-мирәк;*
*Шулай да бик тату алар*
*Һәм башкалар... һәм башкалар...*

*Правлениегә халык тулган.*
*Сөйли әби Бибиҗиһан:*
*"Безнең тормыш алга бара,*
*Минем картым артта кала.*

*И, ходаем, үзең кичер,*
*Минем картта иске фикер,*
*Хатыннарны "чүбек баш" ди,*
*"Кыска акыл, озын чәч" ди.*

*Зәмзәм суын ялмаштыра,*
*Шешә төбен караштыра.*
*Тәнкыйть сүзе үтми аңар".*
*Һәм башкалар... һәм башкалар...*

*Карты белән Бибиҗиһан*
*Кайтып бара җыелыштан.*
*Ачу катыш әйтә шунда*
*Карчыгына Әхмәдулла:*

*"Акча җыйдым — калын төргәк,*
*Алырга дип сиңа күлмәк;*
*Ачу китердең, карчыгым,*
*Хәзер инде тот капчыгың!"*

*Төзәлер ул Әхмәдулла,*
*Онытыр ул ачуын да.*
*Сабак өчен рәхмәт әйтеп,*
*Күлмәк алыр карчыгына.*

*Имин булсын бу дөньялар,*
*Тату гына яшәр алар,*
*Күп сөйләдем инде ярар.*
*Һәм башкалар... һәм башкалар...*

*1956, № 3*



Әмирхан
Еники

# ГӨЛӘНДӘМ ТУТАШ ХАТИРӘСЕ

КЕЧКЕНӘ РОМАН[1]

— Яшь һәвәскәр җырчы Гөләндәм туташ Солтанова! Рояльдә — Салих Сәйдәшев! Рәхим итегез.

"Әйдә, атлагыз!"—диде Салих миңа. Мин... атладым. Якты сәхнә, караңгы зал. Мин шуларның нәкъ чигеннән үтәм кебек... озак үтәм. Ниһаять, рояль янына җитеп туктадым. Шунда ук Салих та килеп утырды (ә мин аның артымнан килгәнен һич тә сизмәдем). Янымда — Камал абый, иелә биреп миннән сорый: "Беренче җырыгыз?" Мин иреннәремне кыймылдатам. Аннары ул залга кычкырып әйтә:

— "Мәдинәкәй".

Ә зал тып-тын... Хәер, бөтенләй үк тып-тын да түгелдер инде, тик минем бөтен-бөтен дикъкатем Салихта — ничегрәк итеп башлар ул?.. Мин бары шуны көтәм, залда хәзергә һич эшем юк.

...Рәхмәт төшсен аның кулларына! Рояль телләренә түгел, гүя йөрәк кылларыма йомшак кына кагылды аның нәфис куллары! Гүя авазлар ярдәме белән дәште ул миңа: чын, саф "Мәдинәкәй" менә шушы була!—диде. Һәм мин аңа буйсынып, аңа ияреп җырладым. Халык ихлас кына кул чапты. Кинәт миңа җиңел булып китте. (Сәхнә дигәнең ул хәтле үк куркыныч урын түгел икән...) Аннары мин "Сакмар"ны җырладым. Үземә калса, моны инде иркенрәк тә, рухланыбрак та җырладым шикелле. Бу юлы халык та ныграк кул чапты. Ләкин мин икене җырлаганнан соң, түбәнчелек белән баш иеп, сәхнәдән чыгарга тиеш идем. Һәм шулай эшләдем дә... Ә халык тынмый, халык "бис" ка чакыра. Тик мин белеп бетермим әле — кыстатыбрак торыргамы, әллә тәвәккәлләп чыгаргамы? Салих күзләре белән генә миңа "ягез!" дигәндәй ишарә ясады һәм без янадан чыктык. Алдан әзерләгән тагын бер көебез бар иде — мин шуны ("Исле гөл"не) җырладым.

...Кул чабулар, "бис"ка чакырулар бу юлы да кабатланды. Әмма ләкин минем үземә бик җитте, ахрысы... Халыкка баш иеп, сәхнәдән ашыга-ашыга чыккач, тукталып та тормыйча, караңгырак бер почмакка барып постым. Миңа бик эссе иде, тынымны өзеп-өзеп алам, ә тез буыннарым туктаусыз калтырый...

Артымнан Салих та килеп җитте.

— Бәгырь, ник болай куян шикелле качтыгыз? — диде ул, сөенечле көлемсерәп. — Ишетәсезме, халык чакыра ич!..

---

[1] Журналыбызда басылган әсәрдән өзек. *Хәз.*

Мина хәзер тел әйләндереп бер сүз әйтүе дә авыр иде. Тик бераздан гына көчкә-хәлгә әйтә алдым:

— Мин янам!..

— Сез бүген, Гөлсем апа әйткәнчә, дәрья кичтегез... Һәйбәт кичтегез! Бүген сезнең бәйрәм, Гөләндәм!.. Йә, шушындый көнне авырырга ярыймы соң?!.

Салихның гадәтен беләм инде, ул шулай шаяртыбрак сөйләргә ярата. Әмма шуның белән бергә ул ике арада ничектер менә табигый үзләшү — якынаю да тудыра белә. Аңа һәр вакытта ышанасы килә. Әлбәттә, ул дөрес әйтә — бүгенге кичәне мин үзем өчен, һичшиксез, бәйрәм дип саный алам. Ләкин нигә ул минем өчен генә?

— Безнең уртак бәйрәм бу, Салих абый, — дидем мин аңа, сөенечемне яшермичә. — Барысына да сез сәбәпче!

— Килешәм, шулай да булсын... Беләсезме, музыкант белән җырчы бербереннән тапсалар, аларның эшләре һәр вакытта уңышлы чыга.

— Сез гел киная белән сөйлисез!

— Ә мин әйтеп бетермәдем әле, — диде ул, минем күзләремә карап. — Тагын бер сәбәбен әйтәсем килә, бәгырь!

— Нәрсәнең?

— Авырырга ярамый диюемнең... Иң төп сәбәбен!.. — Һәм ул башын иеп, бик азга гына тукталып калды. Аннары икеләнүен җиңгәндәй кисәк кенә күтәрелеп, янадан миңа төбәлде.

...Бик тын иде. Без икәүдән-икәү генә. Бүлмә эче ярым караңгы, түшәмдәге ут сүндерелгән, тик почмаклардагы шәмдәлләр генә яна. Нигә ул миңа бу хәтле төбәлеп карый? Минем йөрәгемә үтеп керергә телиме яки миннән берәр нәрсә көтәме? Ә мин... мин аның тагы да караңгыланатирәнәя төшкән күзләренең гипнозына эләккәндәй тәмам югалып, тын алырга кыймыйча утырам.

...Менә ул миңа үрелә төште, сузылып кулыма әкрен генә орынды һәм ашыгып, кайнар пышылдап әйтте, ниһаять:

— Юк, сез белергә тиешсез, Гөләндәм!.. Вакыт, әйе, вакыт! Мин бит сезне яратам, иң саф, иң мөкатдәс бер ярату белән яратам! Ишетәсезме?

Мин ике куллап йөземне капладым. Йа хода, менә кайчан килеп ишеттем мин бу сүзне, хәтәр-көйдергеч сүзне! Ә бит көтә идем, көтә идем, күптән инде йөрәгем аның мәхәббәт сүзенә зарыгып, ачылып тора иде... Әмма ләкин менә хәзер ни әйтә алам мин, нишли алам?!. Шундый хәлсез мин, бөтен тәнем утта яна, буыннарым таралып китәргә тора, тик елыйсым гына килә, үксеп елыйсым гына...

Мин чынлап торып авырдым...

Иң авыр хәлдә яткан минутларымда да мин... Салихны онытмадым. Алай гына түгел, үз-үземне оныткалаган чакларда да ул ничектер минем аңымда яшәде. Соңыннан уйлыйм: әнә шул онытылып киткән чакларымда мин аның исемен дә телгә алмадым микән? Моның булуы бик мөмкин ич! Тик белә генә алмыйм, әйтүче дә юк миңа...

Әгәр шул кичне ул "яратам" дигән сүзен әйтмәгән булса, миңа хәзер күп мәртәбә җиңелрәк булыр иде. Ә ул әйтте, "яратам, мөкатдәс бер ярату белән яратам!" диде. Йа рабби! Мин бит бу сүзне аңымны югалткан минутларда да исемнән чыгармадым, гүя чигәмдәге кан тамыры шикелле ул өзлексез тибеп торды. Әйе, бу сүз, чын була калса, мине терелтәчәк, иң каты авырудан да терелтәчәк! Инде ялган әйткән булса — тәңрем, кичерә күр! — терелү миңа нигә кирәк, нигә?!.

*1975, № 10*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ПАССИОНАРЛЫК*** – Латинча passio – "дәрт" сүзеннән. Лев Гумилев тәкъдим иткән термин (авторның сүзләренә караганда, "пассионарность" сүзе 1939 елда аның "баш миенә яшен яшьнәгәндәй үтеп кергән"). Пассионарлык теге яки бу (еш кына хыялый) максатны тормышка ашыруга юнәлтелгән тыелгысыз эчке омтылышны аңлата. Аерым кешенең пассионарлыгы теләсә нинди: югары, уртача, түбән сәләтләр белән бергә үрелергә мөмкин. Ул бу кешенең психик конституциясенең бер сыйфаты. Ул батырлыкларны һәм җинаятьләрне, иҗади һәм җимерү эшләрен, яхшыны һәм яманны бердәй җиңеллек белән тудыра. Мондый кешеләрне Л.Гумилев *пассионарийлар* дип атый һәм этносның үсешендә аларның гадәттән тыш зур роль уйнауларын күрсәтә. Галимнең фикеренчә, пассионарлык – йогышлы сыйфат. Пассионарийлар үзләренә гавәмне ияртергә сәләтле. Л.Гумилев пассионарлыкның "кире векторы" да бар дип саный. Пассионарийлар үзләрен генә түгел, үзләренең киләчәк нәселләрен дә корбан итәләр: аларның йә балалары булмый, йә пассионарийлар аларны тәрбия итүгә бармак аша карыйлар. Димәк, пассионарлыкны антиинстинкт дип, яки кире (минус) тамгалы инстинкт дип санарга мөмкин.

Мәс., урта гасырларда һөҗүмнәре белән Европа халкын дер калтыраткан норманнар (викинглар) пассионарий булганнар.

Лев Гумилев пассионарлыкның көчле этәреше 1000 еллар тирәсендә булган дип саный. Бу этәреш, мәсәлән, монголларның күтәрелешен китереп чыгара. Галим XIII гасыр башларында пассионарлык кузгалышы Россияне, Литваны, Төркияне һәм Эфиопияне биргән дип билгеләп үтә. Лев Гумилев борынгы башкортларга хас кайбер сыйфатлар (мәс., аларда игенчелек тә, дин дә, хәтта табына торган потлар да булмавы, сугышчанлыклары) бу халыкта пассионарлыкның югары дәрәҗәдә булганлыгын күрсәтә дип яза.

Хәзергә пассионарлыкның генетик нигезләре ачык түгел. Пассионарлык сыйфатының нәселдән ничек бирелүе, аның доминант яки рецессив сыйфат булу-булмавы да билгесез. Лев Гумилев үзе пассионарлык сыйфаты рецессив, ягъни генетик планда башка сыйфатлар тарафыннан бастырыла һәм сүнә бара дигән фикергә авышкан, ләкин моны авторның пассионарлык – йогышлы дигән фикере белән килештерү кыен.

***ПӘНҖӘ*** *ф.* – **1**.Кул чугы, биш бармак. // *Пәнҗә-и Гали*-Гали хәзрәтнең кулы калдырган эз (Багдадтагы төрбәдә?). *Пәнҗә-и Хәсән*-Гали һәм Фатыйма хәзрәтләренең улы Хәсәннең (624/26-669) кулы калдырган эз. Әүлия Чәләби имам Хәсәннең кул эзе махсус тимер савытта төрбә эчендә саклана, бирегә Дагыстан дәрвишләре җыела дип яза. // *Арыслан белән пәнҗә тотмак дәгый кылычка йодрык ормак-гакыйллар эше дәгел.* Сәйф Сараи. **2**.Ерткыч хайванның алгы аяклары, тырнаклары.

***ПӘРӘМӘЧ*** – "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә: "Эченә тартылган ит салып, авызын бераз ачык калдырып майда кыздырып пешерә торган камыр ашы". Татарның яраткан сые. (Кайбер якларда-*шәңгә, дурычмак.*) Бу сүз ымлык мәгънәсендә, көтелмәгән эш-хәлгә гаҗәпләнеп тә әйтелә. Шунысы кызык, затлы ашамлыклардан "бәлеш" сүзе дә шундыйрак ымлык функциясен үти. Руслардагы "вот такие пироги" дигән әйтемне дә янәшә куеп карарга мөмкин, дөрес, аның мәгънәсе башкачарак.

Сүзнең этимологиясенә килгәндә, Р.Әхмәтьянов аны гомумтөрки *бүгрә*//*бугра* "йомарлак" сүзеннән чыгара. "Пәрәмәч"кә охшаш сүз чуаш, удмурт, мари телләрендә

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

дә бар. Ләкин себер татарларында аның "бәйрәмаш" ("бәйрәм ашы") дип аталуы уйланырга мәҗбүр итә.

***ПӘРӘНҖӘ*** *ф.* — Чит ир-атка йөзен һәм буй-сынын күрсәтмәс өчен мөселман хатын-кызлары кия торган өреткеч, *чадра, никаб, хиҗаб, сәтрә.* Башлыгында йөзне каплап тору өчен ат кылыннан ясалган куе челтәре булган, ялган җиңле, озын киң халаттан гыйбарәт. Башта хиҗабны Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хатыннары гына кияргә тиеш була, соңыннан ул барлык ирекле мөслимәләр өчен мәҗбүригә әйләнә. // *Пәрәнҗәсен кыйшык ябынып, кәмпер килеп керде.* Айбек.

Хатын-кызларның хиҗабтан беренче тапкыр демонстратив рәвештә баш тартуы XIX гасырның 70-елларында Мисырда булган.

Пәрәнҗә ташлауны мөселман дөньясы, әлбәттә, уңай каршыламаган. Пәрәнҗәләрен салган хатыннарны *пәрәнҗәсез* дип атаганнар. Татар телендәге *пәрдәсез* сүзе дә шул ук мәгънәдә.

***ПУЛ*** *тар.* — Болгар йортында әйләнештә йөргән бакыр акча. 16 пул 1 *даниккә* тигез булган. Пулның бәясе 0,0475 грамм авырлыктагы көмеш *хаббага* (гарәпчә *орлык*) яки татарча *арпага* бәрабәр исәпләнгән. Пул сүзенең тамыры латинча *фоллис,* Византиядәге *фоллери,* гарәп һәм фарсы телләрендәге *фельс* сүзенә барып тоташа (Ә.Мөхәммәдиев). Борынгы грек телендәге *обол* сүзе дә шул тамырдан (Р.Әхмәтьянов).

XIII-XIV гасырларда Алтын Урдада сугылган. XV гасырда-XVI гасыр башларында Җүчи пуллар үрнәгендә Мәскәүдә, Тверьдә һәм кайбер башка рус шәһәрләрендә дә *"пуло"* дип язылган бакыр акчалар чыгарылган.

***ПЫЯЛА*** — Үтә күренмәле төзү материалы, фарсыча *пийала* сүзеннән. Гарәпчә-*зөҗаҗ.* Урта Азиядә "касә" мәгънәсендәге *пыяла* сүзе электә мондый савытның фарфордан түгел, бәлки гади пыяладан коелган булуына ишарәле кебек. Казан арты керәшеннәре дә *шешәне* пыяла дип йөрткәннәр. Ә менә Пермь ягы, Красноуфим, Эчкер сөйләшләрендә, киресенчә, пыяланы шешә дип атаганнар. Мәс., Себер татарларында *тәрәс шешә*-тәрәзә пыяласы. Тау ягы керәшеннәрендә пыяла (тәрәзә пыяласы) һәм шешә (пыяла савыт) *гелэнҗә* дип аталган. Бу аерманың килеп чыгышын тикшерү керәшен тарихын ачыклау өчен кызыклы булыр иде.

Кайбер сөйләшләрдә "пыяла"-*тәрәзә* дигән сүз (*пыяла төбе*-тәрәзә төбе, *пыяла капкачы*-тәрәзә капкачы). Мордва-каратайларда өйнең *пыялалы ягы* — гүрничә, олы як, ә *мич ягы* — "чылан", ул, димәк, тәрәзәсез булган (соңыннан анда да бәләкәй тәрәзә-*казан тәрәзәсе* уя башлаганнар). Шәрык чыганаклары мөселман табибы Әбү Бәкер Мөхәммәд әр-Разиның (865 ел тирәсе-925) беренче тапкыр пыялалы тәрәзә ясавы турында хәбәр итәләр, шуңа күрә татар телендә "тәрәзә" һәм "пыяла" сүзләренең мәгънәдәш булуы безне гаҗәпләндерми.

Борынгылар тәрәзәләргә кечкенә пыяла "коймаклар" куйган булсалар кирәк, чөнки пыяланы җәеп зур-зур табаклар ясарга соңрак өйрәнгәннәр. Шундый вак кисәкләрдән торган зур тәрәзәләр исә витраж кебек архитектур бизәккә башлангыч биргән дип уйларга мөмкин. Хәер, Самарада алып барылган археологик казу эшләре күрсәткәнчә, кайчак мондый төсле пыяла "коймаклар" шактый зур-диаметрлары 20 см дан алып 50 см га кадәр — булган. Пыяла Болгар йортында да җитештерелгән. Тәрәзә пыяласыннан тыш, бу материалдан беләзекләр, төймәләр, муенсалар ясаганнар.

Россиядә пыяланы заводларда җитештерү Михаил Федорович патшалык иткән заманда җайга салынып, Петр патша чорында аеруча үсеш ала. Пыяла киң таралыш алганчы йорт тәрәзәләренә халык гадәттә карындык тарттырып яки слюда (үтә күренмәле пыялаташ) кисәкләре куя торган булган. Әле тәрәзәгә пыяла куя башлагач та, пыяла куючылар (пыялачылар) *карындыкчылар* дип аталган, алар авыл буенча: "Карындык куям, карындык куям!"-дип кычкырып йөргәннәр. Димәк, электә тәрәзәгә карындык тарттырып куючы осталар булган дип уйларга кирәк. XIX гасыр ахырларына кадәр авторлар тәрәзәләргә карындык куелу фактын билгелиләр әле.

Татар йортларында тәрәзә рамында гадәттә 5-6 өлге булган, ләкин кайбер төбәкләрдә, мәс., элекке Мамадыш өязендә тәрәзәнең өске өлешендәге зур өлге 3 кә бүленгән һәм

моны рамда тәре формасы кабатламасын өчен эшләгәннәр дип уйлыйлар. Әле хәзер дә мәчет тәрәзәләрен пыялалаганда рамның тәре формасында булуын өнәмиләр.

// *Хәләбдән пыяла алыб Йәмәнгә, Йәмәндән борди йәмәни (Йәмән тукымасы) алыб, үз вилайәтемә килеб, тик тиҗарәт кылыб, бер дәкянга кичеб утырмак теләрмен.* Сәйф Сараи.

***РАББЕ** г.* — Аллаһы Тәгаләнең эпитеты. "Тәрбия кылучы вә хуҗабыз" мәгънәсендә. *Раввин* сүзе белән бер тамырлы, ягъни *остаз, рухи җитәкче* мәгънәсенә дә ия. Күплек саны шәкеле-*әрбаб* сүзе дә шуны күрсәтә.

***РӘҖЕМ** г.* — Борынгы гарәпләрдә зина кылган өчен бирелгән үлем җәзасының бер төре. Хөкем ителгән кешене бәйләнгән килеш билдән яки тездән җиргә күмеп ташлар атып үтерүдән гыйбарәт. Әгәр зинаны шаһитлар күргән булса, беренче ташларны шулар ыргытырга тиеш булган. Зина кылучы гаебен үзе таныган очракта беренче ташларны имам яки казый ыргыткан. Хатын-кызны җәзалаганда аның ябынча белән капланган булуы таләп ителгән. Акылдан шашканнарга карата бу җәза кулланылмаган. Әгәр хөкем ителгән хатын көмәнле булса, бер мәзһәбләрдә җәза бирү ул бала тапканчы кичектерелгән, башка мәзһәбләрдә йә бала имезү чоры тәмамланганчы кичектереп торганнар, йә җәзаны бөтенләй бирмәгәннәр. Мондый җәза бик сирәк кулланылган.

***РӘМЕЛ** гар.* — **1**.Ком. **2**.Ком, вак ташлар, ногытлар һ.б. ярдәмендә күрәзәлек итү, ногыт салу (*комалак салу*-Себер татарларында) // *Мирзаван Камәреззаманга алтыннан эшләнгән астраляби һәм рәмел такталарын биреп, әйтте...* "Мең дә бер кичә" әкиятләреннән. *Рәмел ташлары. Гыйльме рәмел.* Гомумән, рәмел тактасы һәм рәмел ташлары "Кодекс куманикус"тан билгеле булган *санар тактаны* хәтерләтә. **3.** Шигырь үлчәве-*бәхре рәмел.* "Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге"ндә "һәр юлы дүрт "фагыйләтен"нән тора" дип аңлатылган.

Тагын кара: *РӘММАЛЬ.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Журналыбыз турында*

## Ренат Харис:

***—СССРда иң беренче булып калын журналлардан «Казан утлары» чыга башлый. Аннан соң «Сибирские огни», аннан соң «Пламя», аннан соң «Новый мир», аннан соң башка һәм башка басмалар, 30 нчы елда «Агыйдел». Менә 22 нче елга кадәр безнең «Казан утлары»ннан элегрәк чыккан калын журнал элеккеге дәүләтебез территориясендә юк. Димәк, бу журналның дулкыны хәзер СНГ дәүләтләренең барлык әдәбиятларына барып җитәчәк һәм бер-бер артлы Әзәрбәйҗан, Төрекмәнстан, Кыргызстан һ.б., һ.б. дәүләтләр үзләренең калын журналларының юбилейларын бәйрәм итәчәкләр. Ни өчен калын, чөнки анда җанлы романнар да сыйган, анда бер юл белән генә әйтеп була торган Әфләтүн хәзрәт сүзләренә тиң татар халкының мәкальләре дә сыйган, анда җылап укый торган шигырьләр дә сыйган, анда киләчәккә фараз да сыйган, анда үткәнгә карап елау да сыйган, киләчәккә карап өметләнү дә сыйган...***

*1992*



Марсель
Галиев

# ХИКМӘТИ СҮРӘ

Кешелеккә Күктән индерелгән изге китап — Коръән сәхифәләренең шигъри асылы бөек гарәп телендә яңгыраш алган. Аны бүтән телләргә үз матурлыгы, үз моңы белән тәрҗемә кылуның гаять тә авырлыгы хакында күпләр әйтеп калдырган. Мин дә моны үз тәҗрибәмдә төшендем. Аңлау рәвешендә генә үз телебезгә күчерергә дип "Ихлас" сүрәсенә күземне төшергән идем, хәйран калдым. Нибары җиде-сигез сүздән торган сүрә югыйсә... Төрлечә тәрҗемә итеп карыйм, юк, һич кенә дә канәгатьләндерми; тагын үзгәртәм, тагын күз унынннан ераккарак куеп, суындырып торам. Коръәннең башка телгә тәрҗемә ителгән нөсхәләрен карап чыгам да гаҗиз калам. Сүз бирешми, карыша, изалый мине. Әллә инде изге Китапка кагылуымны өнәп бетерми.

Күп телләргә әлеге сүрәнең икенче юлы "Аллаһ мәңгелек!" дип тәрҗемәләнгән. Бу йөз дә уникенче сүрәгә кадәр Коръәндә, югыйсә, Аллаһның мәңгелек икәне күп тапкырлар кабатлана. Гарәп теле белгече белән дә сөйләшкәч, мин бу сүзнең икенчерәк төсмердә бирелгәнен аңладым. Сүз — Аллаһның мәңгелегендә түгел, ә Аның тумавы, мәңге тудырмавы хакында бара икән бит!

Сүз карышып, юл бирмәсә, син аны мәҗбүриләмә. Сүзгә үпкәләмә, үзенә үпкәлә икән. Тәкатьле-сабыр булсаң, ләззәтле көттерү газабыннан соң, Сүз үзе килеп ишегеңне кагар.

Юан бер агач төбен каезлый-каезлый, кулымны канатып юна-юна йомычкалый торгач, үзегеннән нәзек кенә карандаш ясап куанган шикелле, мин сүзләр кабыгын әрчи-әрчи, ниһаять, "Ихлас" сүрәсенең мәгънәсен күпмедер дәрәҗәдә аңлау кимәленә ирешерлек итеп тәрҗемә кылдым шикелле:

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.*

*1*

*—Аллаһ — бердәнбер!*

*2*

*Ул мәңге*

*3*

*Тумый һәм үзе дә тудырмый.*

*4*

*Аңа тиңдәш булалмый, — дигән.*

Шушы сүрәнең мәгънәви тирәнлегеннән йөрәк калтырый башлый. Күкләр сулышын сизгән җан күкрәк читлегендә ялкынсына.

Акыл ачкычы — Сүздә.

Күк капкаларын ачар Сим-Симгә нинди Сүз тылсымын табыйм соң? Җирдәге яңашәләрем: гамьле ташлар, агымсулар, нәзберек гөлләр, сез каян?

Олы җан ияләре, Кече җан ияләре, сезнең Җиргә төшкән юлыгыз кайсы йолдыз чатларыннан?

Кем ул — Аллаһ, нинди зат икән ул — Ходай Тәгалә?

Бу — һәрчак алдагыга күчерелә торган, һәм гомер сонында да җавабы табылмаган фәһемле сорау каршында, бәлки, Сүз дәрманы көчсездер?..

Без кайдан... Кайчан... Кая барабыз?..

Шушы сорау-икеләнүләр арасында бәргәләнә инсафлыгын җуймаган инсан җаны.

Без бәләкәй чактан ук Аллаһны ак сакаллы, ягымлы бер карт итеп күзаллыйбыз. Шул изге сурәт, саркып кына шәйләнгән сыман булып, безне олыгайганчы озата бара. Сабый хыялы — шытымдагы акылга бәрабәр. Ходайны кеше сурәтендә итеп күзаллау балигъ була алмаган акылның гөнаһсыз сабыйлык галәмәтеннәндер.

Ходай Тәгалә Адәмне (үзенә охшатып түгел!) үзенә ошаганча яралткан. Без каядыр

Күк гаршендә алтын тәхеттә Аллаһ утыра дип уйлаганда, ингә кунган фәрештәләр, аптырап, бер-берсенә карашып куядыр. Галәми кояш астында җәсәде җитлегеп бетмәгән килеш, акыл алмасын вакытыннан алда авыз иткән өчен, Аллаһ тарафыннан оҗмахтан Җиргә куылган Адәмнең варислары буларак, күп сорауларга җавап таба алмавыбыз белән килешергә кирәктер, бәлки...

Без төсле һәм аһәнле дөньялар чолганышында яшибез, һәммә җисем әйләнештә, үз кояшы тирәсендә түгәрәк булырга омтыла. Галәми чиксезлек — миллиард йолдызлар, күк җисемнәре, галактикалар — җәмгысы бер кафиягә көйләнеп хәрәкәт итә икән — монда илаһият, зиһен җитмәслек хикмәт бар!

Аллаһ хакында без читтән торып уйлый да, акыл җитмәслек зурлыкның сурәтен дә күзаллый алмыйбыз. Чөнки без — Илаһның үзендә, бәгырендә, мәңгелегендә. Рухыбыз Аның рухи хасиятеннән аерыла алмый.

Без — бербөтен Олылыкның уйлы күзәнәге.

Без — Аллаһның кальбендә бар ителгән тере бизәк.

Бу илаһи кодрәтнең йөрәк тибеше, бер сулышлык ара — үзәккә кысылу һәм үзәктән киңәю мизгеле миллиардларча елларга сузылган тибрәнеш хасил итә икән, утлы дәһшәт, коточкыч шартлаулар, давыллы гарасат, яктылык һәм караңгылык арасында галактикалар убыла, кояшлы дөньялар чәчрәп кабына, җәннәт-җәһәннәм кыйтгалары барлыкка килә икән... бу — Раббының табигый яшәү халәте. Искиткеч Олылык Иясенең хәяте-рухында, тән-җәсәдендә чиксез дөньялар бар ителгән. Аңа кадәр, Аннан соң, дигән төшенчә була алмыйдыр. Чөнки бу — әвәле-ахыры, башланышы һәм тукталышы булу ихтималыннан өстен яссылыктагы яшәеш бөҗрасы, мәңгелек хәрәкәт, тотрыклы канунга буйсынып әйләнүче утлы даирә.

Туу һәм үлү... Сүнү һәм кабыну... Шушы бөек тетрәнүләр күчешенең мәңгелек дәвамын тәшкил иткән яшәеш чылбыры әлмисахтан бирле бар һәм булачак илаһи дастан.

Вакыт-вакыт Җир-Ана (ин) белән Күк-Ата (ян) гайрәтле кушылуыннан тектоник тетрәнүләр хасил була. Җирнең бәгырь тирәнлекләреннән утлы магма (шәхүәт) ургылып чыга; убыла, актарыла дөньясы... Яңа таулар калка, дәрьялар кайный, яңа утраулар ярала. Аннары... изрәүле тынычлык иңә... Адәми зат акылы боларны фаҗига, һәлакәт итеп кабул итә. Чынбарлыкта исә бу: бардан — юк, юктан бар булалмаган Җиһанның табигый яшәү ритмы, бер ипкә-игә көйләнеп, туу-үлем, үлем-туу вәзененә салынган яшәү тантанасы.

Бөтенесе Аллаһның һиммәтле ихтыярында. Әмма ул да үзе булдырган бөтендөнья канунына буйсынадыр, аны бозу яисә үзгәртү гөнаһына бара алмыйдыр...

Коръәннең әлеге сүрәсендәге "Аллаһ тудырмый..." дигән мәгънәнең асылы менә хәзер ачыла башлый...

Раббыбыз эзлекле галәми үсеш баскычларының билгеле бер югарылыгында Җир йөзендә тереклекне, хайваннар галәмен һәм инсаниятне бар иткән, Гаршенең түбән катларында шул тереклеккә рухи тәэсир итүче, нурдан яралган Рәсүлләр бардыр. Әмма Раббының Җирдә тереклек ритмына үзгәреш-төзәтмә кертүе, аерым тамга белән үзенә дәвамчы, ярдәмче тудыруы мөмкин хәл түгелдер. Моңа инану, шулай булырга мөмкин дип уйлау Аллаһның кодрәтенә күләгә төшерү, Аның көч-куәтенә шикләнеп карауга тиң булыр иде. Чөнки бибәһа зурлык — Җиһаннар Җиһанының нинди дә булса нәни җан бөртеген аерым игътибар биреп, өстен итеп тудырырга мохтаҗлыгы булалмас!

Чагыштыру җәһәтеннән бер мисал: Җирдәге акыл мөмкинлегеннән чыгып карaганда, кырмысканың: "Мин филдән тудым!" дип бәян итүенә ышанып булыр идеме?! Аллаһтан туган, дигән ялган тәгълиматка ышанып, билгеле бер затны бөеклеккә чөеп табыну, Җирдә болганышлар, кырылыш-сугышлар китереп чыгару гөнаһын өстенә алган кавемнәрне Ходай үзе ярлыкасын!

Ислам дине — иң хак дин, бер кавемне Җирдә иң өстен санап, тигезсезлек тудырып, Аллаһны гаделсезлектә тануга китергән андый уйдырма әкияткә каршы "Аллаһ мәңге тудырмый", дип кискен гыйбарәсен белдергән.

Бөек кодрәт Иясе — Каһһар тарафыннан Җир йөзендәге һәммә тереклек чыганагы, нәфис-төгәл нәкышьләр белән, сәнгатьле итеп, искиткеч төрлелектә, илһамланып, соклану-хозурлык тәмен тоеп, сәламәт сайланыш, яшәү өчен көрәш, үрчү кайнарлыгы биреп иҗат ителгән; аһәнле төс, төсле аһәң индерелеп шигъри шәкелгә салынган. Гаҗәеп мөкәммәл яратылган тереклек ияләре катгый яшәү канунының күндәмнәре итеп җанландырылган.

Бу — Яшәешнең хушнамә поэмасы!

Җиһанның бөекләрдән-бөек газамәтле шагыйре — Җәнабе Хак үзе! Шушы Җир

йөзендә күпме могҗизаи җан ияләре рәхмәтле сулыш ала. Ходай тарафыннан фатиха алган һәр үсемлек, һәр бөҗәк, һәммә җәнлек өммәте Кояш астыннан урын даулый, гадел көрәшкә чыга. Кайчакларда мина үзе иҗат иткән тереклек хәятен Җәнабе Хак Үзе биектән сокланып күзәтеп, истирәхәт кыладыр шикелле тоела. Елларын уйнаклатып дөлдөл атлар чапканын гына кара син: нинди ыспайлык, нинди гайрәт, йөрәктән ут чыгарган тояклар тупырдавы! Хәтта җәнлекләр патшасы юлбарысның корбанына ташланган явыз мизгеле дә — дәһшәтле матур!

Тереклек суы йөгертеп сынландырылган шушы иксез-чиксез манзараларга шигъри әфсен өреп, яшәү нуры таратканга мәдхия җырлар өчен Раббыбыз кешегә Сүз тылсымы биргән, җан-кальбенә шагыйрьлек җенен индергән. Ирләр кавемен тере гөл — хатын-кыз — пәри затларга табындырып, шаукымлы шагыйранә хискә мәңге сүнми торган иләслек уты өстәгән.

Шулай да... Нинди гөнаһы өчендер, Аллаһ кешене бераз рәнҗеткән дә... Хәтерендә, рухында очу дәртен калдырган да, канатсыз кошка әвереллдереп, җиргә төшергән. Очарга тиеш булган ул югыйсә... Кешенен атлап йөрү рәвешен биектән күзәтеп кара син: гәүдә авырлыгын әле бер аякка, әле икенче аякка салып, "аксак"лап баруы мәзәк тә, кызганыч та. Ә күнеленда күкләр кинлеге, канатлы алгысыну. Нәкъ менә шул канатсыз чынбарлык белән канатлы хыял арасында торган нәүмиз ачыну — шигърият дигән тетрәнүгә китерәдер аны. Балет сәнгате юктан тумагандыр. Биюче-оста сәхнә уртасында аяк очына басып, җирдән аерыла, йөзә, бөтерелә, оча, нәзакатьле киерелеп, кош халәтендә рәхәт чигә. Ул кайчандыр аяк табаны белән җиргә тупас басып йөрергә мәгъкуль ителгән җәяүле кош икәнен оныта һәм сине дә оныттыру бәхетенә ирешә.

Балет — кеше тудырган сәнгатьләрнен иң камил бөеклеге.

Җанын сулкылдатып торган очу-йөзү дәрте адәми затның акыл-зиһен эшчәнлеген котыртып, илһамландырып, җилкәнле кораблар, очкычлар ясауга китергән. Һәммәсе дә үзенә бер иҗтиһатлык, шагыйранә төгәллек белән, кул һәм акыл эшчәнлегенә мәдхия мисалында югары сәнгать үрнәгендә күңел биреп эшләнгәннәр.

Очар канатларын кискәнгә, Ходай тәгалә кайчакларда үзе дә үкенү хисе кичерә, күрәсен. Адәми затны төшләрендә булса да очыш дәрте биреп кинәндерә, канатлар куеп, кимсенгән күнеленә дәва орлыклары сала бугай.

Үкенәдер... дип Аллаһ хакында болай гына әйтүем. Әгәр ул кеше кавемен канатлы итеп яралткан булса, Җирдәге шагыйрьлек тәхетенә кемне утыртыр иде... Канәгатьлектән, бәхеттән шигырь тумый ла...

Егәрле Сүз егәрләгән Шагыйрь үзен Җирнен кыл уртасында итеп тоя. Күккә таяныш ул галәми яшәү балдагының тап уртасын эзли.

Җирдәге янәшәләрем: гамьле ташлар, якты агымсулар, нәзберек гөлләр — сез каян?

Тоткан морадыбыз, төшкән юлыбыз кайсы йолдыз чатларыннан?

Әллә соң без... Галәмнәр Иясенен күз карасындамы?

Әллә соң без... Раббының йөрәк тибешендәме?

Әллә соң без... Раббының төш-хыялындагы әлегә тумаган афәтле бәхет җимешеме?

Әллә соң без... Кайчандыр бер яшәп тә, инде сүнгән дөньяның галәмгә тамган үкенечле күз яшеме?

Ни генә булсак та, без, барыбер, Аллаһының кальбендә. Кояш, планеталар, күк сүрүен каймалаган йолдызлар мириадасы белән Лира йолдызлыгына очып баручы Галактика буларак, Раббының тән-җәсәдендәге күзгә күренмәслек нәни күзәнәгендә зәррә (атом) булып сулкылдыйбыздыр.

Без — Аллаһының кальбендә. Әзәли җиһанның Рух коесына бәрәкәтле тамчы булып тама алабызмы, якты төшерә алабызмы Аның йөз суына?..

Әллә соң Газазиллы гөнаһтан авырайган Җиребез үзәктән куылу көче белән яшәеш бөҗрасыннан галәм упкынына ыргытылачакмы?!

Мең-мең сораулар.

Шигъри Сүз алга сорау, сиземләү, икеләнү, кисәтү генә куя ала, җавап бирергә алына икән, шигырь үлә...

Белмәгәненне белергә теләп нинди генә догалар укысаң да Күк капкалары ачылмас. Ачкычлары бирәүгә дә насыйп ителмәгән.

Нинди гадел чишелеш...

*Журналыбыз турында*

## Миркасыйм Госманов:

***—Шәхсән минем үз тормышымда, үземнең рухи дөньямда да "Казан утлары"ның үзенә генә хас "мөнбәре" бар. Беренче мәртәбә мин ул журналны, әле "Совет әдәбияты" дип аталган чорында, 1947 елда ук кулыма алган, 1948 елдан исә анда басылган әсәрләрне йотылып укый башлаган идем.***

***Бу елларны атавым очраклы түгел. 1937-38 еллардагы кансыз репрессияләр, бигрәк тә Икенче дөнья сугышы чорында Казаннан әдәбият, китаплар килү өзелеп торганнан соң, шул кырыгынчы еллар ахырында гына, "Күк капусы" ачылган төсле, Кытайда без яшәгән Голҗа шәһәренә дә Казанда чыккан журналлар, китаплар яңадан килә башлаган иде. Андагы татарларның (СССРдагы хәлләрдән, сугыш гарасатларыннан хәбәрдар кешеләрнең) беренче реакцияләре үсмер чактагы хәтеремә сеңеп калган: "Казан әле исән, рухы да тере икән!" (Мондый җөмләне нык хәтерләвем очраклы түгел. 1946 елда иде бугай, базарда күтәреп газит-журнал сатучы зәңгәр күзле бер татар агаеннан этиебез: "Казаннан берәр нәрсә юкмы?" — дип соравына каршы әлеге агай: "Казан молчит, братым..." дип җавап биргән, икесе дә мәгънәле рәвештә башларын иеп куйган иде. Мин исә этидән "молчит" белән "брат" сүзләренең мәгънәләрен соравымны онытмыйм...)***

***1948 елда ук журналда басылган "Намус", "Язгы җилләр" романнарын, төрле мәкаләләрне, шигырьләрне уку әлеге "исән, тере икән" ише шатлык һәм сөенечләрне көчәйтте генә.***

***Журналның санаулы нөсхәләрен нәүбәтләшеп, без яшьләр үзара чиратка языльш, түземсезлек белән көтеп алып укый идек.***

***Мондый хәл, минемчә, бер бездә генә булмагандыр. Соңрак ачыкланганча, Алманиягә эләккән, Төркиядә яшәгән милләттәшләребез дә шул журнал аша туган ил хәбәрләрен белеп торганнар икән. СССРның төрле төбәкләренә сибелгән татарлар хакында әйтеп тә торасы юк. Аларга журнал, чит илләрдәге кардәшләренә караганда, тәртиплерәк килеп торган. Журнал тиражының елдан-елга арта баруы очраклы түгел иде...***

***Әгәр XX гасыр башындагы рухи хәлләребез, теләк һәм омтылышларыбыз, шул юнәлештәге конкрет гамәлләребез хакында "Шура" һәм "Аң" битләреннән белә алсак, соңгы 70-80 еллык иҗтимагый, рухи тормышыбызны, фикерләү үзенчәлекләребезне, казаныш һәм уңышсызлыкларны белер, аңлар өчен безгә "Казан утлары"н актарырга кирәк булыр иде.***

***Әлбәттә, журнал узган юл әлләни шома, гел үргә менү генә булмаган. Әдәбилеге бәхәссез, сыйфатлары югары әсәрләр белән мәҗбүри тагылган примитив агиткалар да, башларга (язмышларга) суга торган күсәк-мәкаләләр дә билгеле елларда басылгалады анда. Ничек кенә булмасын, алар да тарихыбызның (язмышларыбызның!) аерылгысыз өлешләре булып кала.***

***Шул ук вакытта бу журналның соңгы 30-40 еллык, бигрәк тә якын 15-20 елындагы аның тоткан юлыннан, әдәп-әхлагы чагылышы булган затлылыгыннан канәгать булырга кирәктер. Шөкер! "Үзгәртеп кору", "реформалар үткәрү" дип бер адым алга атлап, икене чигенгән, "кыргый капитализмга" күчү ише тотрыксызлык, башбаштаклык, әдәпсезлек, ертлачлык һәм кансызлыклар хөкем сөргән елларда да ул сабыр вә саллылык, чын әдәбиятка хас әдәплелек хисләрен югалтмады. Затлы әдәби басмаларга хас сыйфатларын җуймады. Афәрин!***

***Объектив сәбәпләр аркасында тиражы шактый кимегән, таралыш даирәсе тарайган хәлдә дә популярлык эзләп мәгънәсез кыланмады, вакланмады ул! Әдәп-әхлак нормаларын саклау, саклый алу нигездә редакция хезмәткәрләренең, мөхәррирләрнең җаваплылыгына бәйле. Сыйфатны саклый алу аларның казанышы. Рәхмәт аларга!***

***Әдәбиятыбыз, хәзерге әдәби фикеребез көзгесе булган "Казан утлары" журналының МЕҢЕНЧЕ саны чыгу белән мин иң элек татар халкын, күпсанлы журнал укучыларын котлыйм! Журнал бит үзе өчен, редакция хезмәткәрләре өчен түгел, ә халык өчен, конкрет кешеләр — реаль укучылар өчен яши һәм чыгып килә.***

*2006*

Рәфикъ
Юныс

# МЕҢЬЕЛЛЫК КАЗАН НИ КАЙНАТЫР?

ТАРИХИ ГОМУМБӘЙРӘМ ТУРЫНДА ШӘХСИ УЙЛАР

**Башкалабызга мең яшь тулу сөенечен күккә чөйгән салют утлары күптән сүнде. Бәйрәмнең җирдәге эзләре җыештырылып, Самосырово чүплегенә озатылды.Ниләр калды соң?**

## Өч нольле сан җиңел язылмады

Әйе, иң олы казанышыбыз булып "1000" саны торып калды. Казанның "туу таныклыгы"на җуелмаслык итеп язылды ул.

Ошбу санның никадәр олы вә саллы икәнен, мөгаен, Альфред Халиковтан да ныграк тойган кеше булмас иде. Бу археологыбыз үзенең күпме вакытын, тырышлыгын, күңел вә йөрәк көчен күп бәләкәйрәк санны раслатуга сарыф итте. Әмма шул максат белән язылып, инде басылып та җиткән китабы юк ителгән, эше хак дип табылмаган галим җинелүче булып дөнья куйды.

Юкса Казанның 1977 елга тәгаенләнгән 800 еллык бәйрәме чып-чын булып төсмерләнә иде инде. (Хәтта юбилей значокларына кадәр өлгертелә.)

Аяк чалырга ажгырып торучылар күп була. Моңа хәтта минем үземнең дә өлеш керде кебек.

"Ленин бакчасы" тукталышындагы бинаның ян диварына КПССның чираттагы съездын лаеклы каршыларга өндәгән зур плакат беркеткәннәр. Трамвайда үтеп барышлый мин анда бер хәреф хатасы күрдем. Шактый гомере гәзит полосасыннан хата чүпләп үткән кеше буларак, түзеп кала алмадым: шәһәр партия комитетының идеология секретарена шылтыраттым. Ничә көн үткәндер, инде хәтерләмим, әмма "хатаны төзәттеләр": элеккесе урынына шундый ук зур бүтән бер плакат беркетеп куйдылар—Казанның 800 еллыгы турындагысын.

Мәскәүдә, башта Археология институтында, аннары СССР Фәннәр академиясенең Тарих бүлегендә әлеге мәсьәләне тикшергән чакта, А. Халиковның дәлилләре галимнәрне ышандырып җиткерми. Әмма хәлиткеч сүзне, гадәттәгечә, КПСС Үзәк комитетында әйтәләр. Бетәргә тиешле татарның башкаласы яшь ягыннан Мәскәүгә тиңләшә язуга (аерма 30 гына ел каласы иде бит) һич тә юл куясылары килми монда. Шуңа күрә фәнни дәлилләр житеп бетмәүдән бик оста файдаланалар. Казаннан килгән бер шикаять исә соңгы сәяси тамчы кебек була. Алар партия съезды турындагы плакатны алып атып, үзләренең юбилейлары турындагы плакатны куйдылар, дип язган икән бер партия ветераны.

Үзәк комитет секретаре М. Сусловка да, В. Егоровка да (юбилейга теш-тырнагы белән каршы чыккан галим), теге пенсионер агайга да рәхмәтләр яусын инде. Юкса киләсе елны Казанның 830 еллыгын билгеләп үтәсе идек бит.

Хәер, "кәттәрәк" вариантлар да булган әле.

88 нчеме, 89 нчымы елны (мин Татарстан китап нәшриятында баш редактор урынбасары булып эшләгән чак), расларга дип җибәргән еллык темпланыбыз Россия дәүләт нәшриятлар комитетыннан бер җитди дәгъва ияртеп кайтты: планга Казанның... 600 еллыгы уңаеннан бер генә китап та кертмәгәнбез икән бит!

Баксаң, бу теге вакытта шул ук Вадим Егоров башлап җибәргән эшнең шаукымы икән. Безнең 800 еллыкны кире кагу белән генә канәгатьләнмәстән, баш шәһәребезгә тиздән 600 яшь тулачагын дәлилләп, "Советская археология" журналында мәкалә

чыгарган булган икән ул (1975, N 4). Рус елъязмаларында Казанның "беренче иң чын искә алынуы"на ("самое достоверное упоминание") таянып, ошбу "бәйрәмне" ул бездән 1992—1995 еллар арасында уткәртмәкче икән...

Менә шушы фонда карасаң, меңьеллык хөрмәтенә чөелгән салютлар фантастик бер эш булып күренер. Ничек мөмкин булган соң ул? Мин Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Рафаэль Хәкимов белән (1999, 2001 елларда) һәм "Казан кремле" археологик экспедициясе башлыгы Фаяз Хуҗин белән (2001 елда) тәфсилле әңгәмәләр уткәргән идем. Шулардан чыгып моны менә болай күз алдына китерәм. Кремльдә нығытып, күп урында казый башлыйлар,—мең ел дигән фикергә этәрерлек материал бер-бер артлы җир астыннан чыга тора. Муенса төймәләре, йомшак таштан ясалган орчык башы, ук очлары, чүлмәк ватыклары, тәңкәләр.Шул җөмләдән, дөньяда табылганнар арасында әлегә бердәнбер Ващлав тәңкәсе. Моны катламга махсус ташлаганнар дип әйтә алмыйлар инде—шушы тәңкәгә нигезләнеп чехлар үзләренең дәүләтчелек тарихын ике йөз елга борынгылаталар. Теге җинелүдән гыйбрәт алып, Казанның яшен билгеләү эшенә С.-Петербург, Мәскәү һәм чит ил галимнәре җәлеп ителә. Казанда дистәләрчә ил галимнәре катнашында халыкара конференцияләр уткәрелә. Казан табылдыклары Германия, Австрия, Франция, С.-Петербург, Мәскәү лабораторияләрендә тикшертелә. Шуннан соң гына мәсьәлә Россия Фәннәр академиясе каравына чыгарыла. Аның Тарих бүлеге утырышында егермеләп академик катнашып, шуларның берсе генә битараф тавыш бирә. Калган бөтенесе дә хуплый. Казанның яшен билгеләгәндә кулланылган методиканы исә академиклар фәнни ачыш дип бәялиләр.

Нигә Казан нәкъ менә 30 августта "туган"? Һәм нигә—2005 елны? Р. Хәкимов болай диде: "Күпмедер дәрәҗәдә шартлы нәрсә инде бу. Тарих өчен 4-5 ел берни түгел ул. Без әле Казанның салынганын үзебез күреп торсак та, юбилей елын төгәл генә билгели алмас идек. Йә, әйтегез менә, Казан метросының тарихын кайчаннан исәпли башларга? Метро төзеләчәге хакында хәбәр басылуданмы? Тукай мәйданында "М" хәрефен утыртып куюданмы? Казый башлауданмы? Беренче станция төзелеп бетүдәнме? Әллә беренче поезд кузгалып китүдәнме?"

## Күзең күрмәүгә Корбюзье гаепле түгел

Йөзгә кызыллык килмәслек итеп исбатланган, указлар белән нығытылган, көненә кадәр тәгаенләнгән меңьеллыкны көтүләре күңелле иде.

Ләкин 100 процент ышанып бетеп тә булмый. Татарстан Конституциясен Россиянеке белән тын да алдырмый тәңгәлләштерү, суверенитетыбызны тавык кетәгенә куып кертү башланды. "Идел"дә тикмәгә генә мондый мәзәк басылмагандыр (Риф Бәдри шуклыгы): "Меңьеллык та тәтемәс, ахры. Татарстан прокуроры Кафил Әмиров Дәүләт Советына чираттагы таләбен кертқән: Казанның туган елын Мәскәүнеке белән тәңгәлләштерергә!"

Бер караганда, бу юбилей мондый чакта юаныч, жуйганның беразын кире кайтару кебек тә инде, әмма барыбер бәйрәм көтүнен беркадәр тәме китте. Җитмәсә, милиция дә алдан ук колачлы әзерлек җәелдереп җибәрде. Әледән-әле туктатып документ тикшерәләр. Радио-телевидениедән, өлкән яшьтәгеләргә кичләрен бәйрәмгә (ягъни төп бәйрәм чараларына) чыкмау хәерлерәк, кебек кинәшләр ишетәсең. Әйтерсең лә, Казан тарихы яшь-җилкенчәккә генә газиз... Шәһәр ни уйлаганны беләсең килсә, мунчага бар. Мунчада исә "безнең бәйрәм түгел лә ул, түрәләр бәйрәме" кебек сүзләр дә яңгырый башлады.

Юбилей атнасы инде тәмам килеп җитте дигәндә булды бу хәл. Мунчадан чыгып, автобус көтә идем. "Восстание" урамы ягыннан үзәккә таба машиналар үтеп китте, аларда хәрби фуражкалы халык, ялгышмасам, Эчке эшләр гаскәре солдатлары иде. Колоннаның урта өлешендә барган берничә машинадагы "мал"ны исә бутау һич мөмкин түгел иде: тоныК кына елкылдап торган зур аксыл

чорнамнар—чәнечкеле тимер чыбык иде бу. Эчкә шом йөгерде. Башкортстанның Благовещинск шәһәрендәге кыйнаулар да бик-бик истә. Россия Эчке эшләр министрлыгының моңа юл ачкан приказы да юкка чыгарылмаган әле.

Шөкер, күсәкләр кулда уйнамыйча, усал чыбык сузылмыйча калды...

Казан кунаклары, шәһәрегез танымаслык булып матурланган, диделәр. Бәйрәмнән калган, шәһәр халкын иң нык сөендергән нәрсә шушы булды. Тиз арада искиткеч зур күләмдә эш башкарылды бит. Димәк ки, бик күпләр тарафыннан булдыклылык, егетлек күрсәтелде. Ләкин, гадәттәгечә, көнәнә өлгертик дип, биналарга иннек сөртеп, кершән ягып кына чыгулар да булды. Ашыгуның хәтәррәк нәтиҗәләреннән Ходай саклый күрсен инде. Моның бер мисалын үзем дә китерә алам.

Онычым Камилә белән, гигант "М" хәрефенә йөз төбәп, яна күпер янына бардык. Икәүләшеп сөендек. Берзаман бу "ярдан ярга күчү корылмасы" ачылып, куәтле насос кебек, Вишневский урамыннан бер яклап машина суыра, икенче яклап машина куа башлады. Шмидт урамы турыннан бу урамны кичүче җәяүлеләр ажгырып килгән машиналарга әллә бар, әллә юк. Чөнки светофор да, ак полосалар да, тизлекне чикләүче билге дә юк. Нигә юкмы? Чөнки проектта урам аша җир асты юлы бар (дүрт айлап вакыт үтеп, Яңа ел алдыннан гына ачылды ул)... Бер тапкыр шушыннан урамны кичкәндә бер апа чытырдатып беләгемә килеп ябышты. "Бергә чыгыйкчы, куркам, өч кеше тапталды инде монда",—диде...

Меңьеллык объектларыннан мине иң нык сөендергәне метро иде. Пассажир буларак кына да түгел. Үзәк станция, Тукай станциясе, шундый итеп бизәлгән ки—әйтерсең лә ул шагыйрьнең тагын бер, җир асты китабы! Язма һәм әйтелмә игъланнарның ике телдә булуы да күңелгә хуш килде... "Кремль" станциясе дә тарихи бизәлеше белән гүяки шунда ук, җир астында йокымсыраучы ерак үткәнебезгә тоташкан. Өске яктагы, күпләрне оригиналь матурлыгы белән сокландырган "Әмәт" исә халык яшәгән җирләрдән аерылып, ике мәгънәдә дә һавада асылынып калган... Кыска булу сәбәпле, җир асты юлы әлегә экзотика—аш төрләндерү кебек кенә...

Биш ярым гектарлы "Казанның меңьеллыгы" паркы, андагы Колгали һәйкәле, бик тә зарыктырып калыккан Сәйдәш һәйкәле (нигәдер "Сайдашев" дигән имза белән тамгаланган) сөендерде.

Тиз арада янарган Казаннан милли зыялыларыбыз да асылда бик канәгать калды. Тарихи һәм милли йөзе югала бару да пошамангa салмады. Татар авылларының үзенчәлеге ни? Чисталык, төзеклек. Бәс, шулай икән, чиста, төзек Казан да—татар шәһәре —шундыйрак фикер әйтүчеләр дә булды. Алайса, чын татар шәһәрләре Европададыр инде.

Казанның 1973 елгы баш архитекторы Мөнир Агишев белән гәп корганым булды. "Казан—тарихи шәһәр, бу һәрвакыт зур плюс булып калачак. Безнең эштә хәзер төп юнәлеш—шәһәрне үзенә генә хас сызыкларын һәм милли колоритын саклаган хәлдә үстерү. Казанның соклангыч ландшафты моның өчен зур мөмкинлекләр ача",—33 ел элек кабинеттан әнә шулай дип сөендереп чыгарганнар иде мине. Әмма бу сүз генә булып калды. Мөнир әфәндедән үз иҗаты—Консерваториянең аквариумны хәтерләткән концерт залы (хәзер С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы) бинасын да нык кына "редакцияләргә" туры килде әнә.

Берлиннан килгән туристларга аптырап мондый сорау биргәнем бар: "Шәһәрегез Казаннан күп өлеш матуррак ләбаса, монда ни карап йөрисез соң сез?" "Казанда Кремль бар, бездә юк",—диде берсе. "Сезнең иске йортлар, тарихи биналар безнекенә охшамаган",—диде икенчесе.

Меңьеллыкның гигант сукыр кәтүге әнә шул үзенчәлекне рәхәтләнеп издетаптады. Бер очтан дәүләт саклавындагы дисталәгән мәдәният ядкаре дә сытты. Татар тарихы, татар мәдәнияте югалтуларының исемлеген җентекләп төзисе бар әле...

"Квартир—яшәү өчен машина ул"—Ле Корбюзьеның әнә шул канатлы сүзе

девиз итеп алынып, алтмышынчы елларда дөньяда архитектураның инженерлык ягы алга сөрелә. Ләкин бина авторларының күнел күзе күрмәгәнгә Корбюзье гаепле түгел икән бит. Мәшһүр архитектор әлеге билгеләмәгә бөтенләй бүтән төрле мәгънә салган икән. "Кеше өчен йөрәк машина булган кебек",—дип очлаган ул аны.

Яшәр өчен Көнбатышта "иномарка квартирлар" ясасалар, безнең конвейерлардан "Москвич", "Запорожец", "Ока" кебек квартирлар төште. Тегендә, хаталарын аңлап, күптән инде йөрәк җылысы сеңгән, табигый яме булган йортлар салалар. Бездә исә, горурланып-хозурланып, татар башкаласын алтмышынчы елларның иң хөрти "иномаркалары" белән тутырып яталар.

Юкса "меньеллык" үзе дә ерак үткәнгә, борынгылыкка ялганганлык дигән сүз бит инде. Шундый тарихы булган Казанны Чаллының Яңа шәһәре кебек хәтерсез-тамырсыз калага әйләндерү фаҗигасен кичегеп йөрүче татар акылы төштән соң да аңлап житкермәде кебек әле...

*2006*

*Дәвамы киләсе санда*

*Журналыбыз турында*

## Туфан Миңнуллин:

***—Мин татарча чыккан бөтен журналларга диярлек язылып, аларны укып-караштырып барырга тырышам. Кайберләрен җыеп та барам. "Казан утлары"н аеруча төгәллек белән җыйдым. Минем китап шүрлегендә аның үз кадерле урыны бар. Ара-тирә мин журналның моннан утыз-кырык еллар элек чыккан санын алып карыйм-актарам, хөрмәт иткән исән һәм мәрхүм каләмдәшләремнең шул чакта язган әсәрләренә күз салам, аннан, журнал битенең бөкләнгән читләрен төзәткәләп, урынына куям.***

***1963 нче елдан башлап җыелган байлык. 502 сан. Мең санлык хәзинәнең яртысы. Кайчак шулар тезелеп куелган шүрлек каршына басам да уйланам. Болар бит татар әдәбияты узган катлаулы һәм мактаулы юлның бер өлеше. Әлбәттә, анда кыйммәтләре төрле-төрле булган әсәрләр: энҗе бөртекләренә тиңнәре янында заман сынавын үтә алмаганнары да юк түгел. Бу—табигый. Әдәби процесс гел классик әсәрләр басудан гына тормый. Бигрәк тә вакытлы матбугатта. Журналда басылганнарның барысы да миңа кадерле. Чөнки алар безнеке-үзебезнеке. Аларга бәя биргәндә бик сак булырга кирәк. Үзеңнең үткәнеңә төкерү—җинаятькә тиң гөнаһ.***

***Китаплар күп, шүрлектә урын җитми дип журналларны берәр китапханәгә бүләк итмәкче идем, кулым бармады, күңелем тартмады. Хәзинәмнән аерылсам, бушап калырмын сыман тоелды. Гомеремнең ахырына хәтле язылып, бик кирәкле дип санаган язмаларны укып (бөтенесен дә укып барып булмас—күзләремнең көче кимегәннән кими), һәр яңа санны "абыйлары" янына куеп барырга насыйп булсын. Бу дөньядан киткәндә аларны оныкларыма мирас итеп калдырырга җыенам. Алар да мирасыбызга хөрмәт белән карарлар һәм журналны өйләренә алдырырлар дип өметләнәм. Мин бер генә журналыбызга да кимсетеп карарга җыенмыйм, әмма "Казан утлары"—безнең милләтнең төп әдәби журналы, татарга аның авыр язмышында таяныч булган журнал һәм, Алла боерса, шулай булып калыр да.***

*2006*

# Б

**БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ.** Татар телендә махсус балалар өчен язылган беренче әсәрләр 18-19 йөзләрдә барлыкка килә. Татар Б.ә. гомуми әдәби процесс кысаларында үсә. Дини эчтәлекле китаплар ("Иман шарты", "Һәфтияк", "Бәдәвам", "Кисекбаш китабы" һ.б.) б-н беррәттән дөньяви (мәс., Габди шигырьләре) һәм дидактик эчтәлекле (Колмөхәммәднең "Мөһиммәтес-сыйбъян" – "Сабыйларның бурычлары", 1810; "Тәгърифел-вилдан" – "Балаларга аңлатма", 1815) әсәрләр дә күренә башлый. С.Хәлфинның беренче басма "Татар теле әлифбасы" (1778), Аллаһияр Суфиның балалар арасында популяр булган "Сөбател-гаҗизин" ("Гаҗизләрнең ныклыгы", 1802) китабы, М.Ивановның "Татар хрестоматиясе" (1842), Таҗетдин Ялчыголның "Рисаләи Газизә" "Рисаләи Газизә" ("Газизәгә хат", 1795), С.Кукләшевнең "Диване хикаяте татар" (1859) китабы, Казан типографияләрендә дөнья күргән башка басмалар дөньяви татар Б.ә.нең формалашуында һәм үсүендә гаять зур роль уйныйлар. Татар Б.ә.на нигез салучы – галим һәм мәгърифәтче К.Насыйри. 1860 елда ул табигать күренешләре турындагы кыска, мавыктыргыч хикәяләрдән торган "Буш вакыт" исемле җыентык чыгара (соңыннан күп тапкырлар кабатлап басыла). "Кырык вәзир кыйссасы" (1868), "Әбугалисина кыйссасы" (1872), "Кырык бакча" (1880) китапларында, шулай ук тәрбия һәм әхлак мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрендә К.Насыйри балаларны белемле, кызыксынучан, эшчән кешеләр итеп тәрбияләү ихтыяҗы турында яза. Балалар өчен В.В.Радловның "Белек" ("Знание", 1872), Т.Яхинның "Сабый вә сабыялар өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗәеб булган гыйбрәтләр" (1897) хрестоматияләре, шулай ук Ф.Халиди, Г.Фәезханов әсәрләрен, Г.Рахманколый шигырьләрен рус һәм шәрекъ телләренә тәрҗемә итү һәм аларны 19 йөз ахырында – 20 йөз башында бастыру нәтиҗәсендә Б.ә.нең тематикасы һәм жанр даирәләренең кысалары киңәя. 1905-07 рев-ция аның үсүенә көчле этәргеч була. Балалар өчен вакытлы матбугат чыга башлый: Мәскәүдә 1907 нең гыйнварыннан мартына кадәр беренче татар балалар ж-лы "Тәрбияи-әтфаль", Казанда 1907 дә ата-аналар өчен "Тәрбия" ж-лы, 1913-16 елларда "Ак юл" ж-лы чыга. Балаларга багышлап Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Н.Думави, М.Гафури, З.Ярмәки, М.Укмасый, Ш.Әхмәдиев һ.б. әсәрләр язалар, "Балалар календаре" (1908) басыла башлый.

Татар Б.ә.нең эчтәлеге һәм жанрлары баюында, халыкчалашуында Г.Тукай иҗатының роле зур. Г.Тукайның аңа кадәр яшәгән балалар язучыларының һәм замандашларының реалистик традицияләре нигезендә язылган кызыклы шигырьләре, әкиятләре, мәсәлләре, кыска хикәяләре Б.ә.нең тематик һәм эстетик яктан яңа биеклеккә күтәрә. Әсәрләрендә ул балаларны белемгә, хезмәткә өнди, сәнгать чаралары б-н аларда миһербанлылык, ата-анага, туган телгә, табигатькә карата мәхәббәт тәрбияли. Г.Тукай балалар өчен дәреслекләр һәм хрестоматияләр төзи ("Яңа кыйраәт" – "Яңа уку китабы", "Балалар күңеле. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре"). Аның иҗаты Б.ә.нең сыйфат ягыннан үзгәрүенә юл ача: Г.Тукай балаларга карата кешелекле һәм гуманистик мөнәсәбәте б-н аерылып торган, үзенә күрә бер "мәктәп" тудырды. Соңыннан аны М.Гафури, Ф.Әмирхан, Н.Думави, З.Ярмәки, М.Укмасый, Ш.Әхмәдиев дәвам иттерделәр.

1917 ел вакыйгаларыннан соң балалар язучылары яңа вәзгыятьне һәм тематиканы үзләштерә башлыйлар. Беренче пионер оешмалары төзелә (1923), вакытлы совет матбугаты оеша: "Кечкенә иптәшләр" ж-лы (1924 тән), "Яшь ленинчы" г-тасы (1924 тән) чыга башлый. 1920 елларда Б.ә. нең үзәген рев-ция һәм Гражданнар сугышы (М.Гафуриның "Кызыл байрак", Сириннең "Октябрь нурлары", "Кызыл гаскәргә", Һ.Такташның "Караборынның дусты", К.Нәҗминең "Яр буенда учаклар" әсәрләре); балалар ятимлеге (Х.Туфанның "Зәңгәр бүре", Г.Толымбайның "Үксезләр" әсәрләре); мәктәп тормышы (Һ.Такташның "Ләйлә", "Пионерлар маршы", К.Әмириның "Фабрик баласы", М.Крыймов әсәрләре һ.б.) темалары били. Балалар өчен беренче пьесалар языла (С.Әдһәмованың "Авыл тормышыннан бер күренеш", "Хәзер бул!", К.Әмиринең "Уңган кыз", "Урманда йөрү",

М.Фәйзинең "Коммунага", К.Хисаметдиневнең "Кызыл чәчәкләр" әсәрләре), беренче спектакльләр куела, әдәби-музыкаль радиотапшырулар эфирга чыга.

1934 тә оешкан ТАССР Язучылар берлегендә Ф.Кәрим җитәкчелегендә Б.ә. секциясе эшли башлый. Б.ә. өлкәсендә әдәби тәнкыйть барлыкка килә. 1930 елларда язылган әсәрләрдә шул чор вакыйгалары тасвирлана: Гражданнар сугышы һәм авыл хуҗалыгын күмәкләштерү елларында олыларга ярдәм итүче балалар образлары туа (Г.Гобәйнең "Маякчы кызы", "Ялгыз йортта", "Каланча", Ә.Айдарның "Ташбай", М.Әмирнең "Батыр исемле малай турында хикәяләр" әсәрләре). А.Алиш әкиятләре ("Сертотмас үрдәк", "Нечкәбил", "Ана әкиятләре" циклы) һәм хикәяләре ("Әбиләргә кунакка", "Мин дәү — син кечкенә", "Утлы йомырка", "Уңышсыз рәсем") балаларны намуслы, эш сөючән, батыр, җаваплылык тоючы, бер-берсенә яхшы иптәш, ватанны һәм табигатьне яратучы шәхесләр итеп тәрбияләүгә юнәлтелә. М.Җәлил балалар өчен язган әсәрләрендә күптөрле фикерләр һәм темалар күтәрә: белемгә омтылу ("Сәгать", "Беренче дәрес"), ватанга мәхәббәт ("Җилләр", "Туган ил", "Яңгыр"), ватанпәрвәрлек ("Шмидт бабай", "Безнең җыр"), хезмәтне сөю ("Уңыш бәйрәме", "Арыш кырында"). Ул иң сабыйлар өчен дә яза ("Бишек җыры", "Маэмай", "Карак песи" әсәрләре). Бөек Ватан сугышы елларында балалар язучыларының күбесе фронтка китә, ләкин Ф.Кәрим ("Пионерка Гөлчәчәккә хат", "Тирән күл", "Ант", "Үлем уены"), А.Әхмәт ("Солдат балалары", "Зәңгәр конверт", "Карт солдат" әсәрләре), Г.Кутуй ("Рөстәм маҗаралары" повесте), М.Җәлил ("Суык бабай", "Чыршы җыры") балалар өчен актив язуларын дәвам итәләр.

Сугыштан соңгы Б.ә.на темалар һәм жанрлар төрлелеге хас. Ә.Фәйзи ("Бал корты", "Кечкенә Апуш"), Ш.Маннур ("Миләүшә китабы", "Минем кошкаем", "Ямьле җәй", "Елмаюлы кояш турында"), Н.Исәнбәт ("Куянкай", "Мыраужан агай хәйләсе"), Җ.Тәрҗеманов ("Кояшлы иртә", "Ямьле көн", "Шуктуган", "Шаян белән Наян", "Көмешкойрык маҗаралары"), Ә.Бикчәнтәева ("Бүләк", "Дәү әнием", "Бакча гөлләре", "Ана йөрәге", "Мин аңлыйм сине", "Хуҗа Насретдин балалар янында"), Ә.Кари ("Балаларга бүләк", "Гөлбакча", "Дуслык"), Н.Гайсин ("Зәңгәр күктә", "Түтәлләр", "Безнең мәктәп", "Таза Мортаза"), Г.Латыйп ("Дусларым минем", "Язлар җитәр"), З.Нури ("Син мәктәпкә йөрисең", "Бу безнең китап"), Б.Рәхмәт ("Кем көчле", "Нәниләр китабы", "Укыйсым килә", "Ялкау, Иренчәк һәм Кире", "Курчак батыр") иҗатлары аерым урын алып торалар.

1950 елларда Д.Аппакова ("Йолдызкай", "Шыгырдавыклы башмаклар", "Сөяк саплы пәке", "Саранның башыннан үткәннәре", "Гөлчәчәк белән сандугач", "Сөмбел", "Кечкенә Бану тарихы"), И.Туктар ("Нәни хикәяләр", "Җир җиләге"), А.Шамов ("Каюмның балачагы" повесте) иҗатларында әхлак проблемалары күтәрелә. Совет кешеләренең сугыш кырында һәм тылдагы батырлыклары темалары Г.Бакир ("Партизан малай"), Г.Гобәй ("Замана балалары", "Маратның язмышы") повестьләрендә чагылыш таба. Г.Гобәйнең "Без үскәндә" повесте тарихи-революцион тематикага багышланган. Яшүсмернең эчке дөньясы үзенчәлекләрен И.Газиның "Онытылмас еллар" романы гәүдәләндерә, кызыклы сюжетка корылган әсәрләр — Г.Кутуйның "Рөстәм маҗаралары" повесте, А.Расихның "Бәхет орлыклары" фәнни-фантастик повесте, Г.Галиевнең "Җил кошларны җыя", "Аю агачлар белән сөйләшә" әкиятләре балаларны мавыктыргыч планда язылган. Балалар өчен драматик әсәрләр иҗат ителә: А.Аппакованың "Тапкыр егет", "Илдус", Х.Вахитның "Ышаныч", А.Әхмәтнең "Үги кыз", Т.Гыйззәтнең "Бердәнбер бала", Г.Бакирның "Ватык звонок", Г.Нәбиуллинның "Алтын нарат", Г.Насрыйның "Ана күңеле" пьесалары дөнья күрә. Б.ә. өлкәсендә әдәби тәнкыйть тә җанлана төшә ("Балалар әдәбияты турында", 1957).

1960-80 елларда Б.ә.нда балалар психологиясендә тәҗрибәле белгеч — Ш.Галиев исеме б-н бәйле юмористик юнәлеш үсеп китә. Аның изгелек һәм юмор б-н сугарылган шигырьләренә тормышны сөю хисе хас. Шәвәли б-н Камырша образлары аеруча популярлык казана. Соңыннан бу юнәлештә Р.Миңнуллин, Х.Халиков, М.Фәйзуллина һ.б. иҗат итәләр. Балалар поэзиясе өлкәсендә Ә.Исхак, З.Мансур, М.Садри, Ә.Бикчәнтәева, З.Туфайлова, Э.Мөэминева, Г.Нәбиуллин, И.Юзеев, Ф.Яруллин, Н.Мадьяров, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалим, Х.Халиков, Ә.Габиди, Разил Вәлиев һ.б., прозада — Г.Мөхәммәтшин ("Бал чүлмәге", "Ун бәбкә", "Без әле җирдә яшибез" хикәяләре), И.Туктар ("Абыем бүреге", "Алма", "Батырлыкта — матурлык" хикәяләре), Л.Ихсанова ("Җир астында җиде көн", "Саралан малайлары", "Космонавтлар урамы", "Очкын", "Наил һәм Фаил" повестьләре), Ф.Шәфигуллин ("Тагын икеле", "Командир", "Мин дә

үсәрмен әле" хикәяләре, "Өй салуның ние бар", "Ак маңгайлы бүреләр" повестьләре), Р.Хафизова, Б.Камалов, Р.Бәшәр, Л.Лерон һ.б. зур уңышларга ирешәләр.

1980-2000 еллар Б.ә. тематиканың һәм жанрларның төрләнеге б-н аерылып тора. Балалар өчен Х.Халиков, Җ.Дәрзаманов, М.Фәйзуллина, Р.Мингалим, Ф.Яруллин, Л.Лерон, З.Гомәрева, Р.Корбанов, Р.Газизов, Ә.Нигъмәтуллин уңышлы язалар. Г.Тукай, Ә.Фәйзи, Б.Рәхмәт, Ш.Галиев традицияләрен үстереп, онытылмас балалар образларын Р.Миңнуллин иҗат итә. Аның шигырьләрен үзенчәлекле юмор, кешелеклелек, бала психологиясе нечкәлекләрен аңлау, сәнгати камиллек аерып тора. ("Олы булсам", "Алма бабай", "Кояш алмасы", "Сөенсеннәр әле сабыйлар"). Әкият (Р.Хафизова, Ф.Яруллин, Р.Батулла, Р.Мингалим), хикәя (Гәрәй Рәхим, Н.Фәттах, З.Хөснияр, Л.Сабирова, Ш.Маннапов), повесть (Л.Ихсанова, Б. Камалов, Р.Бәшәр, Җ.Дәрзаманов) жанрлары уңышлы яшәп килә. Сугыш-патриотик тематика С.Шакир, Ш.Рәкыйпов, Разил Вәлиев, Ш.Мостафин иҗатларында, фәнни фантастика — А.Тимергалин әсәрләрендә, сәяхәтнамә жанры — М.Юныс китапларында чагылыш таба; туган табигатькә мәхәббәт б-н Ә.Баян, Г.Хәсәнов, Ә.Хәсәнов әсәрләре сугарылган. Драматургия өлкәсендә Т.Миңнуллин, Р.Батулла, Р.Мингалим, Р.Корбанов, Н.Фәттах, Гәрәй Рәхим, М.Гыйлаҗев, А.Гыймадиев, Р.Гыйззәтуллин һ.б. иҗат итәләр. 1980 елда басылган "Татар балалар поэзиясе антологиясе" (төз. Н.Исәнбәт, Гәрәй Рәхим, Р.Рахмани), 1984 елда дөнья күргән "Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен" (төз. Н.Исәнбәт) җыентыгы татар. Б.ә. тарихында күркәм күренеш була. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә Ф.Ибраһимова, Р.Рахмани һ.б. эшлиләр.

Әд.: Кукушкин Р. Канатлы дөнья. К., 1984; Ибраһимова. Ф. Сабыйларны үз итеп. К., 1998.

Ә.М.Шәрипов.

**БАЛАСАГУНИ** Йосыф Хас-Хаҗиб (1016 б-н 1021 еллар арасында туган, Баласагун ш. - 1070 тән соңрак), төрки шагыйрь, Караханилар дәүләте сараенда Баш вәзир (Олугъ хас-хаҗиб). Карлук-уйгыр шивәсендә язылган һәм төрки халыкларның уртак әдәби ядкәре булган «Котадгу белег» («Бәрәкәтле белем», 1069/70) исемле үгет-нәсыйхәт характерындагы поэма авторы. Әсәр Идел буе һәм Урал алды татарлары арасында киң тарала. Шул заманның фәлсәфи мәсьәләләрен тирәннән яктырткан, фәнни һәм әдәби кыйммәткә ия поэмасы өчен автор хас-хаҗиб - сарай вәзире итеп билгеләнә. Төрки телле шигърияттә беренче булып гаруз шигъри үлчәм системасын куллана. «Котадгу белег» поэмасы сигез бу-ынлы кыскартылган мөтәкариб (∪−−∪−−∪−−∪−) вәзене б-н язылган 6722 бәйттән, шигъри һәм чәчмә кереш сүзләрдән, 85 бабтан һәм өч бүлекле соңгы сүздән тора. Әсәрнең тоташ сюжеты юк. Башындагы 4 бабта, Шәрекъ шигърияте традицияләренә хас булганча, Аллаһыны мактаудан, Мөхәммәд пәйгамбәр, беренче дүрт хәлиф һәм караханилар идарәчесе Табгач Богъра ханга мәдхия укудан гыйбарәт. 5 нче бабта Бруж йолдызлыгы тасвирлана, 6-11 бабларда шагыйрь Игелеклелек, Акыл, Белем һәм Сүз бөеклеге, мәңгелеге турында фикер йөртә. Поэма әлеге сыйфатларны чагылдыручы персонажларның үзара бәхәсе рәвешендә корылган: Көнтугды, Айтулды, Угдулмыш (Зирәк) - Шәрекъ дөньясының мәңгелек рухи кыйммәтләреннән булган Гаделлек, Акыл һәм Бәхетне гәүдәләндерүчеләр. Дүртенче символик образ — Үзгәрмеш — суфичылык тарафдарлары алга сөргән кеше гомеренең кыскалыгы, үлемнең котылгысызлыгы турындагы фикерләрне чагылдыра.

Поэмада Караханилар дәүләтенең иҗтимагый тормышы сурәтләнә, сарай әһелләренең һәм феодаль-клерикаль аксөякләрнең әхлакый йөзе тасвирлана, җәмгыятьнең социаль төзелеше мәсьәләләре күтәрелә. «Котадгу белег» — урта гасырлар төрки әдәбиятында кешенең бөеклегенә дан җырлаучы, дәүләт б-н гадел һәм акыллы идарә итү идеалын чагылдыручы, закон хакимиятен өстен куючы беренче классик әсәр. Поэмада төрки халык иҗаты үрнәкләре (мәкаль һәм әйтемнәр) зур урын алып тора. Анда борынгы төрки, һинд-кытай, гарәп-фарсы әдәбиятларындагы иң камил әхлакый-этик традицияләр бергә кушылган, төрки әдәбиятта дидактик юнәлешкә нигез салынган. Поэма 20 нче йөзгәчә төрки халыклар әдәбияты үсешенә көчле йогынты ясый. Татар әдәбиятында «Котадгу белег» әсәренең йогынтысы Кол Гали, Мәхмүд Болгари, Котб, Мөхәммәдъяр, Мәүла Колый, Утыз Имәни, Акмулла, Дәрдемәнд, Г.Тукай, М.Гафури, Г.Исхакый һ.б. әдипләрнең иҗатларында чагылыш таба.

Әсәр.: Наука быть счастливым. М., 1971; Благодатное знание. М., 1983.

Әд.: Валитова А.А. К вопросу о фольклорных мотивах «Кутадгу билиг» // Советское востоковедение. 1958.N 5; Абилов Ш. «Кутадгу билиг» в булгаро-татар-

ской литературе // Советская тюркология. 1970. N 6; Ганиева Р.К. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. К., 1988.

Р.К.Ганиева.

**БАЛЛАДА** (франц. ballade - биим), поэзиянең лироэпик жанры. Традицион Б. нигезендә гадәти булмаган героик, тарихи, фантастик яки көнкүрештәге вакыйгалар ята. Аерым үзенчәлекләре б-н (хикәяләү һәм сюжетка ия булуы) Б. поэмага тартым. Хикәяләүченең кичерешләре Б.га тирән тойгылык һәм лирикалылык өсти. Татар әдәбиятында Б.га нигез салучы булып Г.Тукай тора («Шүрәле», «Су анасы»). 1930 елларда күп кенә Б.лар иҗат ителә, мәс., Ә.Фәйзинең «Дала һәм кеше», «Кара таш ник дәшми?». Соңрак Б. жанрына М.Җәлил («Сандугач һәм чишмә», «Кызыл ромашка»), Ф.Кәрим («Тимер һәм тимерче», «Үлем уены») мөрәҗәгать итәләр. Сугыштан соңгы елларда Б. жанры үсешенә Х.Туфан («Уп-кыннар өстендә»), С.Хәким («Күргәннәр аны», «Сары капкалы йорт»), Ә.Давыдов («Солдат турында баллада») үз өлешләрен кертәләр. Хәзерге татар әдәбиятында Б. жанры Ә.Баян («Төнге бәхәс»), Роберт Әхмәтҗанов («Соңгы танк», «Таш елады», «Фидаи»), М.Әгъләмов («Шагыйрь турында баллада»), Р.Зәйдулла («Каләм турында баллада») һ.б. иҗатларында уңышлы дәвам иттерелә.

Әд.: Гильманов Г. Татарская баллада. К., 1989; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

Т.Н.Галиуллин.

**БАСЫЙРОВ** Кәшфи (Кашшаф) Хәбир улы (17.4.1906, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Бәләбәй р-ны Мәтәүбаш а. - 16.1.1943), язучы, тәрҗемәче. Бәләбәй пед. техникумын тәмамлый (1927). Кукмарада һәм Казанда мөгаллимлек итә. 1934-42 елларда Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир, әдәби тәрҗемәче була. Беренче хикәяләре 1925 тән «Белем», «Безнең юл», «Совет әдәбияты», «Азат хатын» ж-лларында басыла. «Танышлар» исемле сайланма хикәяләр җыентыгы 1958 дә Казанда нәшер ителә. Татар теленә М.Ю.Лермонтовның «Герой нашего времени» романын («Безнең заман герое», 1937), К.Г.Паустовскийның «Колхида» (1938) повестен, А.П.Чехов хикәяләрен (1940), Н.В.Гогольнең «Мёртвые души» («Үле җаннар», 1947) романын, ш.у. В.П.Катаев, А.Серафимович, В.Г.Короленконың кайбер әсәрләрен тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986; Алар сафта. (Төз. С.Шакир). К., 1961.

**БАТТАЛ** (Батталов) Салих (Салихҗан) Вазыйх улы (5.8.1905, Казан губ., Спас өязе Зур Тигәнәле а. - 12.3.1995, Казан), язучы. Чистай мәдрәсәсендә укый. 1921 елда акча эшләү теләге б-н Мәскәүгә китә. Оренбург очучылар учщесын тәмамлый (1929). 1929-35 тә хәрби очучы буларак Брянск һәм Казан авиаотрядларында хезмәт итә, Мәскәүдә Хәрби Һава Көчләренең махсус конструкторлык бюросы каршындагы сынау отрядында эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач Тын Океан флотының авиация частьларында хезмәт итә. Әсәрләре 1924 елдан басыла. «Еллар җыры» исемле беренче шигырь җыентыгы 1929 да дөнья күрә. Ул «Очучылар» (1935) романы, «Сигезенче кем?» (1965; русчага тәрҗемәсе «Кто же восьмой?, М., 1974) маҗаралы повесте, шигырь һәм поэмалары тупланган «Илеманам» (1944), «Тылсымлы балдак» (1980), «Төрле еллар мозаикасы» (1983) җыентыклары, «Олы юл буйлап» (икенче исеме «Газзә», 1953; русчага тәрҗемәсе «По столбовой дороге», М., 1956) поэмасы, Гражданнар сугышы елларында татар авылларында социаль үзгәрешләрне, татар крәстиәннәренең рухи көчен һәм әхлакый йөзен чагылдырган «Чирмешән якларында» шигъри романы (1967), «Баштан үткәннәр» (1974) автобиографик повесте, «Сынау» (1938), «Киртә» (1959), «Яңа өйгә күчкәч» (1959), «Үтеп барышлый» (1960) исемле пьесалар авторы. Б.ның поэзиясе яңача фикерләүгә, ритмик аһәңнәргә, төрле рифмаларга, үз төбәге сөйләшеннән алынган сөйләм берәмлекләренә бай. Прозасы характерларның һәм конфликтның катлаулылыгы б-н билгеләнә, мораль-этик проблемаларның кискен куелышы б-н аерылып тора. Б. А.С. Пушкин, Н.Н.Никитин, В.В.Маяковский һ.б.ның кайбер әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1972-74.

Әд.: Мәҗитов З. Һәр шагыйрьнең үз тавышы // Сугышчан поэзия. К., 1975; Фәйзуллин Р. Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т.4; Батулла Р. Халыкның үсеше // Татарстан. 1995. N7,8.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Гәүһәр Хәсәнова (Мәһдиева)



Гәүһәр Мөхәммәт кызы Мәһдиева 1959 елда Татарстанның Арча районы Казанбаш авылында укытучылар гаиләсендә туган. Әтисе—булачак галим һәм халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев, әнисе—Лилия Бәширова (халык язучысы Гомәр Бәшировның кызы).

1960 елда Мәһдиевләр гаиләсе Казанга күчеп килә. 1976 елда Гәүһәр Мәһдиева Казанның 126 урта мәктәбен, 1982 нче елда— Казан дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый. 1982 елдан Казан педагогика институтының рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасында ассистент булып эшли. 1984-1987 елларда Казан дәүләт университетында аспирантура үтә, 1988 елда Урал дәүләт университетында (хәзерге Екатеринбург шәһәре) рус әдәбияты тарихы буенча кандидатлык диссертациясе яклый. 1990 елда Г. Хәсәнова Татарстан китап нәшриятына матур әдәбият редакциясе редакторы булып эшкә килә һәм бүгенгәчә анда хезмәт итә.

Татарчадан русчага тәрҗемә итә башлавы 90 нчы елларга туры килә. Беренче тәрҗемәләре "Идел" журналында басыла. Бу өлкәдә үзенең остазлары һәм ярдәмчеләре итеп ул Сергей Малышев, Роза Кожевникова, Рөстәм Сабировны саный.

Г. Хәсәнова тәрҗемә иткән авторлар арасында—Аяз Гыйләҗев, Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Әхәт Гаффар, Зиннур Хөсният, Факил Сафин, Әнәс Хәсәнов, Фәнис Яруллин һәм башкалар. Әдәби әсәрләрдән тыш, Гәүһәр Хәсәнова күп кенә публицистик һәм мемуар язмалар тәрҗемә итте.

Г. Хәсәнова тәрҗемәләре "Идел", "Татарстан", "Наш современник" журналларында дөнья күрде. Фәнис Яруллинның "Йөртә безне язмышлар" исемле повесте 2000 елда өч телдә аерым китап булып чыкты, русчага тәрҗемәсен ("Былинка на ветру") Г. Хәсәнова эшләде. 2005 елда Татарстан китап нәшрияты "Мөхәммәт Мәһдиев: Язучы турында замандашлары" исемле китап-альбом бастырды. Китапның концепциясе, төзелеше, фото һәм әдәби әсәрләр, интервью, көндәлек дәфтәрләрдән өзекләр сайлап алу язучының кызы—Г. Хәсәнова тарафыннан эшләнде. Быел Татарстан китап нәшрияты Г. Хәсәнова тәрҗемәсендә татар язучыларының хикәяләре җыентыгын рус телендә бастырып чыгарачак.

Татар әдәбиятының матур үрнәкләрен русча укучыларга җиткерү—әдәбиятыбызның мөһим бурычларыннан берсе. Бүгенге көндә Гәүһәр Хәсәнова Мөхәммәт Мәһдиев һәм бүгенге талантлы татар язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итү белән мәшгуль.



*"Казан утлары"ның редколлегия әгъзалары. Беренче рәттә, сулдан уңга — Шәйхи Маннур, Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Әмирхан Еники; басып торалар — Рәфыйк Нәфигов, Атилла Расих, Шәукәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Гали Халит. 70 нче еллар.*



*Күренекле шагыйрь Нәҗәр Нәҗми журналыбызның актив авторы һәм редколлегия әгъзасы иде. 1987 ел.*



*«Казан утлары» журналы нәшер ителәүче «Идел-Пресс» бинасы.*



*"Казан утлары"ның 80 еллык юбилее тантанасыннан күренеш. Сәхнә түрендә редакция хезмәткәрләре. 2002 ел.*



*Татар ПЭН-үзәк әгъзаларыннан бер төркем. "Казан утлары" редакциясендә. 2003 ел.*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2006 елны Татарстан Республикасында Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итү турында

Әдәбият һәм сәнгатьнең Татарстан Республикасы халыкларының бай мәдәни потенциалын ачудагы бәяләп бетергесез ролен, төрле мәдәниятләр һәм цивилизацияләр очрашуы нәтиҗәсендә туып күпмилләтле Татарстан халкының бердәмлегенә хезмәт итүче кабатланмас иҗади мирас тупланууын игътибарга алып, 2006 елда Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Натан Рахлин, Александр Ключаревның, башка күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең юбилейлары бәйрәм ителүне һәм шулай ук Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының 100 еллыгын күздә тотып, карар бирәм:

1. 2006 елны Татарстан Республикасында Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бер ай эчендә:

Татарстан Республикасында Әдәбият һәм сәнгать елына әзерләнү һәм уздыру буенча комиссия төзергә, аның составын расларга;

Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарын, җирле үзидарә органнарын, иҗат берлекләрен җәлеп итеп, шул исәптән Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуны, Татарстан Республикасының башка күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре юбилейларын бәйрәм итүгә бәйле чаралар уздыруны күздә тотып, финанслауның күләмен һәм чыганакларын күрсәтеп, Әдәбият һәм сәнгать елына әзерләнү һәм уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Президенты каравына бирергә, тиешле чараларны уздыруда финанслар белән булышуны һәм хәйрия ярдәме күрсәтүне сорап предприятиеләргә һәм оешмаларга мөрәҗәгать итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә, иҗат берлекләренә, предприятиеләргә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Әдәбият һәм сәнгать елына әзерләнүдә һәм аны уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы "Татмедиа" массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Республика район һәм шәһәр массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Әдәбият һәм сәнгать елын уздыруны киң яктыртуны оештырырга.

5. Указ кул куйган көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

Казан, Кремль
2005 ел, 30 декабрь.

## МУСА ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАНА

Мәскәүдә Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган чараларга әзерлекне тикшерү унаеннан оештыру комитетының утырышы үтте. Анда ТР Премьер-министры урынбасары — мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

Шагыйрь Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил — илебезнең иң күренекле улларыннан берсе. Инде 50 елдан артык ул халкыбызның Ватан сугышында күрсәткән батырлык һәм каһарманлыгы символы булып тора, аның шигырьләре күпмиллионлы тиражлар белән басыла, алар дөньяның 56 теленә тәрҗемә ителгән, ә "Моабит дәфтәре" дөнья поэзиясенең казанышы булып санала. Шунлыктан шагыйрьнең 2006 елның февралендә билгеләп үтеләчәк 100 еллыгы татар халкының гына түгел, бәлки күпмилләтле Бөтенроссия халкының тормышында да мөһим вакыйгаларның берсе булып тора.

Татарстанда М. Җәлил юбилеена әзерлек инде 2002 елда ук башланган иде. Бу җәһәттән, Президент М. Шәймиевнең "Муса Җәлилнең йөзьеллыгын бәйрәм итү турында" карары дөнья күрде. 2005 елның 14 октябрендә РФ Мәдәният һәм гаммәви коммуникацияләр министрлыгының "М. Җәлилнең 100 еллыгы белән бәйле иҗтимагый, мәдәни-агарту чараларын үткәрүгә булышлык күрсәтүче оештыру комитеты төзү турында" боерыгы басылып чыкты. Оештыру комитеты составына РФ мәдәният һәм гаммәви коммуникацияләр министры Александр Соколов, Мәдәният һәм кинематография буенча Федераль агентлык җитәкчесе Михаил Швыдкой, Федераль архив агентлыгы җитәкчесе Владимир Козлов, ТР Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, ТР Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин керә. Шагыйрьнең 100 еллыгына багышланган тантаналы кичәләр Казанда (М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында), Мәскәүдә (Үзәк әдипләр йортында), Оренбургта һәм Екатеринбургта үткәреләчәк.

Муса Җәлилнең тормышы, иҗаты һәм батырлыгына багышланган тапшырулар, "Шагыйрьнең әйләнеп кайтуы", "Плетцензее — үлем театры" телефильмнары "Беренче канал", "Россия", "Культура", "Маяк" теле һәм радиоканаллары аша иштертереләчәк һәм күрсәтеләчәк. Үзәк матбугатта Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын яктырткан материаллар бастыру турында килешенгән.

Юбилей чараларын Берлинда, Фашизмга каршылык күрсәтү музеенда да үткәрү планлаштырыла. Юбилей елында Россиянең эре шәһәрләрендә (Мәскәү, Екатеринбург, Түбән Новгород һ. б.) күчмә күргәзмә эшләячәк, анда "Моабит дәфтәре"нең төп нөсхәсе күрсәтеләчәк.

Оештыру комитеты шулай ук Мәскәүнең Столешников тыкрыгындагы 11 нче йортта (анда М. Җәлил 1935-41 елларда яшәгән) истәлек тактасы кую турындагы карарны раслады. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы М. Җәлилнең "Моабит дәфтәре" циклын мәктәп программасына мәҗбүри кертүне хуплады. Муса Җәлил — дөньякүләм танылган шагыйрь, шуңа күрә бәйрәм чаралары Түбән Новгород, Саратау, Ульян, Иркутски, Әстерхан, Мурмански өлкәләрендә, Алтай краенда, Удмуртия, Коми республикаларында, Кыргызстан, Әзәрбайҗан һәм Украинада да үтәчәк. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты булышлыгы белән әлеге төбәкләрдә әдәби-музыкаль кичәләр, фәнни-гамәли конференцияләр һәм иҗади очрашулар уздырылачак.

## КАЗАНДА ИРАН КОНСУЛЛЫГЫ АЧЫЛАЧАК

Казанда Иран Ислам Республикасы Мәҗлесе рәисе Голәмәли Халлад Адел җитәкчелегендә зур делегация булып китте.

Делегацияне Кремльдә ТР Президенты Минтимер Шәймиев кабул итте. Иранлылар безнең парламент эше белән дә таныштылар.

Очрашулардан соң М. Шәймиев һәм Голәмәли Адел, Россия хөкүмәте карарына нигезләп, Казанда Иран Ислам Республикасының Генераль консуллыгын ачу хакында сөйләштеләр.

Казан шәһәре башлыгы Илсур Метшинга якын арада әлеге консуллык бинасы өчен җир участогы бүлеп бирү бурычы йөкләнде.

## ЯРУЛЛИННАР ИСЕМЕНДӘГЕ

Композиторлар—Заһидулла Ярулла улы Яруллин һәм Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәрит Заһидулла улы Яруллин, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Мирсәет Заһидулла улы Яруллинның исемнәрен мәңгеләштерү максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Мамадыш шәһәре балалар сәнгать мәктәбенә композитор Яруллиннар исемен бирү һәм аны алга таба "Композитор Яруллиннар исемендәге балалар сәнгать мәктәбе" дип атап йөртү турында карар чыгарды.

# *Бу санда*

ЗӨЛФӘТ. Яшәр безнең журналыбыз! *Шигырь.* ... 3

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Мең сан – миллион уй. ... 4

Минтимер ШӘЙМИЕВ, Зилә ВӘЛИЕВА, Назиф МИРИХАНОВ, Илсур МЕТШИН, Ринат ЗАКИРОВ. Татарстан язучылары котлаулары.

**"БЕЗНЕҢ ЮЛ"**

"Безнең юл" идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә (сөючеләргә) мөрәҗәгать. ... 13
Латыйф ГОМӘР. Төп җитәкче Г. Ибраһимов иде. ... 14
Гасыйм МАНСУРОВ. "Безнең юл" турында. ... 15
Һади ТАКТАШ. Мәңгелек әкият. *Шигырь.* ... 16
Р. САБИРОВ. Татарстан җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык. ... 18
Шамил УСМАНОВ. Краском мәхәббәте. *Хикәя.* ... 21
Муса ҖӘЛИЛ. Әсирлектә. *Шигырь.* ... 25
Риза ИШМОРАТ. Татар скульпторы Мирзаҗан Байкиев. ... 28
Шәриф БАЙЧУРА. Патша хөкүмәте вакытында Төркестанда татар мөгаллимнәре. ... 31

**"ЯҢАЛИФ"**

КӨЛӘКӘЙ. Иске-москы. *Көлке.* ... 35
"Булат Батыр". ... 36
М. ЯУШЕВ. Боз кузгалды. ... 37
Контрреволюцион яшерен "Җидегәнчеләр" турында Татар совет язучылары оешмасы. ... 39

**"АТАКА"**

"Безнең юл" журналы укучыларына. ... 41
Кем нәрсә яза? ... 41
Пролетариат Язучылары Ассоциацияләре янындагы бөтен татар секцияләренә һәм бөтен татар пролетариат язучыларына. ... 42
Литфондның Татарстан бүлеге төзелде. ... 43
ТАПП оешмасында. ... 43
Ж. ИРТУГАНОВ. Донбасста татар матур әдәбияты. ... 44
Галим СӘГЫЙДИ. Кавказ артында татар әдәбияты. ... 45
Язучылар өчен ял йорты булырга тиеш! ... 46

**"СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ"**

Совет язучыларның Беренче Бөтен Татарстан съезды. ... 47
Гомәр БӘШИРОВ. Уйланулар. ... 48
Сибгат ХӘКИМ. "Гомер яңа башлана" дигән шигырьдән өзек. ... 56
Халык дошманнарының һәм аларның калдыкларының йөзен ахырынача ачарга!. 57
Ибраһим САЛАХОВ. Тайгак кичү. *Роман-хроникадан өзек.* ... 60
Зәет МӘҖИТОВ. Шагыйрьнең яралы җаны. ... 63
Фатих КӘРИМ. Кыр казы. *Шигырь.* ... 64
Кави НӘҖМИ. Мәҗит Гафури һәм патша цензорлары. ... 66
Мәҗит ГАФУРИ. Татар егетенә. *Шигырь.* ... 68
Ш. МАННУР. Татар халкы. *Шигырь.* ... 70
А. КЛЮЧАРЕВ. Татар халкының музыка иҗаты. ... 72
Гази КАШШАФ. Нигез ташларын салганда. ... 75
А. ШАКИР. Гадел Кутуй белән бергә. ... 77
Гадел КУТУЙ. Сагыну. *Нәсер.* ... 79
Афзал ШАМОВ. Журналның бер нөсхәсе. ... 80
Хатип ГОСМАН. Мәче баласы. *Хикәя.* ... 82
Илья ЭРЕНБУРГ. Татарлар. ... 85

Татар язмышына кизәнгән карар. 87
Нәкый ИСӘНБӘТ. Татар теленең фразеологик әйтемнәрендә тарихилык
һәм үткән белән хәзергенең чагылышы. 88
Татарстан Совет язучыларының гомуми шәһәр җыелышы резолюциясе. 90
Мидхәт ФӘЙЗУЛЛИН. Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләреннән. 92
Шәраф МӨДӘРРИС. *Пародияләр.* 93
Хәсән ТУФАН. Кайсыгызның кулы җылы. *Шигырь.* 138
Камил МОСТАФИН. Ярамый шул... *Пародия.* 139
Миргазиян ЮНЫС. Безнең йорт өянке астында иде. *Хикәя.* 142
Фәнис ЯРУЛЛИН. Теләк. *Шигырь.* 148

**МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Муса ҖӘЛИЛ. Кичер, илем! *Шигырь.* 96
Константин СИМОНОВ. Бер камерада. 98
Җәлил турында совет язучылары. 107, 112
Шагыйрь турында шагыйрьләр. Самед ВУРГУН, Семен ДАНИЛОВ,
Михаил ДУДИН, Ильдар ЮЗЕЕВ, Шәүкәт ГАЛИЕВ, Әхсән БАЯН,
Роберт МИҢНУЛЛИН, Фәрит ГАБДЕРӘХИМ, Ирек САБИРОВ,
Нурия ИЗМАЙЛОВА, Мөхәммәт МИРЗА *шигырьләре.*
Рафаэль МОСТАФИН. Халык шагыйре, халык каһарманы. 114
Луи АРАГОН. Менә нәрсә булды Берлин шәһәрендә. 134
Шагыйрь исемендәге премия. 132

**"КАЗАН УТЛАРЫ"**

"Казан утлары" журналын "Почет билгесе" ордены белән бүләкләү турында
СССР Верховный Советы Президиумы Указы. 150
Ибраһим ГАЗИ. Тургай картаямы икән? *Хикәя.* 151
Nadir DӘWLӘT. "Kazan utları"nın tatar mədəniyətenə kertkən өleşe. 155
Нажар НӘҖМИ. Татар теле. *Шигырь.* 159
Мөхәммәт МӘҺДИЕВ. *Этюдлар.* 160
Ләбибә ИХСАНОВА. Иң бәхетле чагым кебек... 162
Тәүфикъ ӘЙДИ. Яшерен васыять. 163
Гамил АФЗАЛ. Тәнкыйть сүзе. *Шигырь.* 166
Әмирхан ЕНИКИ. Гөләндәм туташ хатирәсе. *Кечкенә романнан өзек.* 168

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. 170
Марсель ГАЛИЕВ. Хикмәти сүрә. 173
Рәфикъ ЮНЫС. Меңьеллык Казан ни кайнатыр? 177
Журналыбыз турында (Мөхәммәт ГАЛИ, Роберт ӘХМӘТҖАН,
Сибгат ХӘКИМ, Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ, Мостафа ӨНӘР, Зәки НУРИ,
Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ, Фатих ХӨСНИ, Хәсән ТУФАН, Гариф АХУНОВ,
Әдип МАЛИКОВ, Нажар НӘҖМИ, Гамил АФЗАЛ, Ренат ХАРИС,
Миркасыйм ГОСМАНОВ, Туфан МИҢНУЛЛИН).
"Казан утлары" архивыннан. 26, 69, 108, 140, 186
"Татар энциклопедиясе" битләреннән. 181
Берлекнең яңа әгъзалары. 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 188

---

*Алхәбәр*

## Без кабызган утлар... китап булыр

Кадерле укучыларыбыз!

Озакламый "Сүнмәс утлар балкышы ("Казан утлары" журналының меньеллык хәзинәсеннән")" дигән китап дөнья күрәчәк.

Мең сан эченнән иң шәп хикәяләр, шигырьләр, истәлекләр, юмор-сатира әсәрләре, әле дә кызыклыгын җуймаган, бүгенге күп кенә хәлләргә ачкыч булырлык мәкаләләр һәм документлар сайлап кертелгән бу китапны татар тормышының көзгесе дип атарга мөмкин.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

Номер—юбилейный, тысячный. По этому случаю коллектив журнала поздравил Президент РТ М. Ш. ШАЙМИЕВ.
Номер открывается вступительной статьей гл. редактора журнала Р. ФАЙЗУЛЛИНА.
Публикуются также поздравления заместителя Премьер-министра РТ—Министра культуры РТ З. ВАЛИЕВОЙ, Полномочного представителя РТ в Российской Федерации Н. Мириханова, главы администрации г. Казани И. МЕТШИНА, председателя исполкома Всемирного конгресса татар Р. ЗАКИРОВА, писателей республики.
Журнал с 1922 года издавался под названиями "Безнең юл" ("Наш путь"), "Яңалиф" ("Яналиф"), "Атака", "Совет әдәбияты" ("Советская литература"). Все они, а также "Казан утлары" представлены литературными произведениями и материалами, имеющими интерес и для сегодняшнего читателя. В. т. ч.—статья Р. САБИРОВА "Экономическое положение Республики Татарстан и голод", документ о "контрреволюционной организации "Җидегән", воспоминание А. ШАМОВА о "похождениях" одного из экземпляров "Совет әдәбияты" на фронте, статья Т. АЙДИ о тайном завещании Петра I... Юбилейный номер иллюстрируется лучшими образцами творчества классиков татарской литературы— Х. ТАКТАША, Ш. УСМАНОВА, Г. БАШИРОВА, К. НАДЖМИ, Ш. МАННУРА, Х. ТУФАНА, Г. КУТУЯ, Н. ИСАНБЕТА, Ф. КАРИМА, С. ХАКИМА и др.
Публикуются также воспоминания известных писателей и бывших работников журнала.
Большой раздел номера посвящен 100-летию со дня рождения Мусы Джалиля.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

Anniversary issue, The thousandth..
In this case the President of the Republic of Tatarstan M. SHAIMIEV congratulated the collective of the magazine. The number begins with the introductory article of the Chief editor of the magazine R. FAIZULLIN.
Also there published the congratulations of the Deputy of Prime minister of the Republic of Tatarstan, the Minister of culture of the Republic of Tatarstan Z. VALIEVA, the Plenipotentiary of the Republic of Tatarstan in Russian Federation N. MIRIHANOV, the Mayor of Kazan I. METSHIN, the chairman of the executive committee of the World congress of Tatars R. ZAKIROV, writers of the Republic.
Since 1922 the magazine was published under titles "Beznen Yul" ("Our way"), "Yanalif" ("Yanalif"), "Attack", "Sovet Adabiaty" ("Sovet literature").
All of them, and also «Kazan utlary» are presented by literary works и materials, having interest for today's readers.
Including the article by R. SABIROV "Economic situation of the Republic of Tatarstan and famine", the document about "the counterrevolutionary organization "Djidegan", memoirs of A. SHAMOV about "adventures" of one of the copies of "Sovet Adabiaty" at the front, article by T. AYDI about the secret will of Peter I...
Anniversary issue is illustrated by the best samples of creativity of classics of Tatar literature,— H. TAKTASH, Sh. USMANOV, G. BASHIROVA, K. NADJMI, Sh. MANNUR, H. TUFAN, G. KUTUY, N. ISANBET, F. KARIM, S. HAKIM etc.
Memoirs of well-known writers and former workers of the magazine are also published.
A big section of the number is devoted to the 100th anniversary of Musa DJALIL.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахәнәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 27.01.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3–18. Тираж 10 000.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2
© «Казан утлары», 2006 ел.



